# Казан УТЛАРЫ

АВГУСТ № 8
1965

# *ХӨРМӘТЛЕ ИПТӘШЛӘР!*

„СОВЕТ ӘДӘБИЯТЫ“ журналы шушы елның июнь аеннан „КАЗАН УТЛАРЫ“ исеме белән чыга башлады.

Журнал 1966 елгы Бөтенсоюз каталогына да „КАЗАН УТЛАРЫ“ исеме белән кертелде.

„КАЗАН УТЛАРЫ“ журналына Советлар Союзының барлык элемтә бүлекләрендә, Союзпечатьның барлык бүлекләрендә елның теләсә кайсы аенда чикләүсез язылырга мөмкин.

**Редакция журналга язу белән шөгыльләнми.**

„КАЗАН УТЛАРЫ“НА түбәндәге адрес белән дә язылып була:

*Казань, ул. Куйбышева, 17/25, областной отдел Союзпечати.*

Урыннарда нинди дә булса сылтау белән журналга язмасалар, турыдан-туры редакциягә хәбәр итүегезне үтенәбез. Безнең адрес:

*Казань, Баумана, 19, Дом печати, редакция журнала „Казан утлары“*

РЕДАКЦИЯ

# Казан утлары

АЙЛЫҚ ӘДӘБИ ҺӘМ ИҖТИМАГЫЙ-ПОЛИТИҚ ЖУРНАЛ

ТАТАРСТАН ЯЗУЧЫЛАРЫ СОЮЗЫ ОРГАНЫ

*ҚЫРЫҚ ДҮРТЕНЧЕ ЕЛ ЧЫГА*

АВГУСТ **8**

КАЗАН 1965

## Бу санда:

### РОМАННАР, ПЬЕСА, ХИКӘЯ, ШИГЫРЬЛӘР


Г. Хуҗиев. Минем дә бар үз тәрәзәм; Тоеп торам сезнең сулышны; Кочаклардай булып тормышны; Өч сугышның солдаты сез; Күңел җилкәне. Шигырьләр . . . . . . . . . . . . . . 3
Ф. Хөсни. Ике агроном, бер овчарка. Хикәя . . . . . . . . 6
Х. Вахит. Карлыгач канат кага. Комедия. Ахыры . . . . . 12
Ш. Маннур. Муса. Роман. Дәвамы . . . . . . . . . . . 32


### ДУСЛАР ҖЫРЫ


Юстас Палецкис, Риза Халид шигырьләре . . . . . 89


### АФРИКА ХИКӘЯЛӘРЕ


Элфред Хатчинсон. Лиззиның гаебе . . . . . . . . . . . 95
Филис Альтман. Шимбә көн кич белән . . . . . . . . 99


### ОЧЕРКЛАР


Җәмил Мостафин. Казанда үскән батыр . . . . . . . 104


### ПУБЛИЦИСТИКА


М. Мостафин. Барыр юлыбыз . . . . . . . . . . . . 111


### СОВЕТ ВЛАСТЕНЫҢ 50 ЕЛЛЫГЫНА


А. Әхмәдуллин. Көрәш һәм мәхәббәт . . . . . . . . 117


### ЯЗУЧЫНЫҢ ИҖАТ ПОРТРЕТЫ


Р. Мостафин. Алга барышлый . . . . . . . . . . . 126


### ӘДӘБИ ТӘНКЫЙТЬ


И. Нуруллин. Әдипнең ике пьесасы . . . . . . . 139


### ӘДӘБИЯТ ТАРИХЫНА МАТЕРИАЛЛАР


Яңа ярлык . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 146
И. Рәми. Татарлар арасында революцион хәрәкәт көндәлегеннән. 150


### КИТАП КҮЗӘТҮ


Ф. Ибраһимова. Яшь укучы образы . . . . . . . . . 152
Г. Иделле. Йолдызлар астында . . . . . . . . . . . 154

Әдәбият һәм сәнгать яңалыклары . . . . . . . . . . . 156


***Редакциягә килгән кулъязмалар кире кайтарылмый.***


Редакциянең адресы: *Казань, ул. Баумана 19, Дом печати, 2 этаж.*
Телефоннар: җаваплы редактор — 2-68-21, җаваплы секретарь — 2-39-52, бүлекләр — 2-39-52.
Хатлар өчен: *Казань, почтамт, почтовый ящик 52. Редакция «Казан утлары».*

*Гали Хуҗиев*

## Минем дә бар үз тәрәзәм

Дөнья киң ул, дөнья чиксез,
Өстемдә — биек күге.
Һәркемнең үз тәрәзәсе,
Үзенең биеклеге.

Минем дә бар үз тәрәзәм;
Дөньяга аннан карап,
Күрәм күңел күзем белән
Ерактан — ераккарак.

Күрәм бөтен җир тормышын,
Ачыграк күрәм һаман.
Биреп тынмас омтылышын,
Күңелемнән уза заман.

Һәм, булса да төрле чагы,
Мин аңа һаман гашыйк.
Кагылса да циклоннары,
Тәрәзәм һаман ачык.

Аның аша киләчәгем
Яктырып алга баса.
Ачылган ул минем өчен
Миллионнар күңеле аша.

Карый аңа яз кояшы,
Кыйбласы һаман яңа.
Туган илем язмышының
Яктысы төшә аңа.

## Тоеп торам сезнең сулышны

Әйтим әле башлап шул хакта,
Җир ялкында иде ул чакта.

Болай диде миңа бер солдат,
Яраланып чыккач сугыштан:
«Ихлас сүзгә ихлас җавапны
Көтеп була бары чын дустан».
Эндәшкәндәй газиз улына,
Бу сүзләре аның хак иде.
Саклаганы йөрәк турында —
Полкташы язган хат иде.

Нихәлдә сез, башкорт дусларым,
Шигърияттә полкташларым!?

Сөйми күңелем рухи бушлыкны,
Сирәгәйсә әгәр хатыгыз.
Ут эчендә туган дуслыкны
Онытырга бармы хакыбыз?

Каш җыеру җиңел, әлбәттә,
Һәм бар моның кемгә кирәге?
Өстен торса һәрбер гайбәттән,
Чиксез көчле кеше йөрәге.

Үз сукмагы бар һәр көчсезнең,
Юлдаш түгел аңа кыюлар.
Ярыла торган пуля шикелле
Тоелырлар аңа бу юллар.

«Агыйдел»нең шигъри җиленнән
Тоеп торам сезнең сулышны.
Салаватның туган җиреннән
Мул җыясыз һәр ел уңышны.

Халкыгызның күңел кыры киң,
Ул, әйтерсең, үзе бер Галәм.
Уңдырышлы аның туфрагы;
Шуннан шыткан Бабич һәм Сәләм.

Шуннан шыта җыры Кудашның,
Шуннан шыта сезнең җырыгыз.
Нурларыдай язгы кояшның,
Килә безгә күңел җылыгыз.

Истә сүзе теге солдатның,
Кайтмаса да үзе сугыштан:
«Ихлас сүзгә ихлас җавапны
Көтеп була бары чын дустан».

## Кочаклардай булып тормышны

Кайчан гына салкын кыш иде,
Боз каплаган иде Иделне.
Ә ул акты, тыну белмичә,
Әйдәгәндәй минем күңелне.

Ә ул акты, тыну белмичә,
Син бит минем тамчым, дигәндәй.
Әйе, аның мин бер тамчысы,
Һәм ул мине, тынгы бирмичә,
Зур диңгезгә әйдәп кергәндәй.

Болытыдай бозлы яңгырның,
Килде кайгы минем өстемә.
Җитте ләкин түзем-сабырым,
Һәм өзмәдем өмет һич кенә.

Якын дуслар, сездән аерылган
Чакларда да ялгыз булмадым;

Йөрәгемә каннар савылган,
Күтәрмәстәй авыр тоелган
Минутларда сезне уйладым.

Ышанып һәм ихлас дус күреп,
Сез килдегез хәлем белергә.
Кирәк икән, кабат әзер мин
Сезнең белән утка керергә.

Тик берәүне, көтеп-көтеп тә,
Һаман көтеп ала алмадым.
Ярты гасыр гомер итеп тә,
Күп дусларны яңа аңладым,
Күп нәрсәне яңа аңладым.

Болыты уза бозлы яңгырның,
Кабат иркен алам сулышны;
Һәм аякка басам савыгып,
Кочаклардай булып тормышны,
Кочаклардай булып тормышны.

## Өч сугышның солдаты сез

*Госман Бакировка*

Өч сугышның солдаты сез;
Соңгысын бергә үттек.
Дзот итеп газетаны,
Дошманга ялкын сиптек.

Сез әле дә уң флангта,
Мактауга хакыгыз бар.
Тоям: сезнең һәр китапта
Чын күңел яктыгыз бар.

Җитмеш баскыч үрләү өчен
Никадәр түзем кирәк.
Әмма күрәм: чәчегезнең
Чалы да әле сирәк.

Сезне ничә очратсам да,
Сез һаман имән кебек.

— Эш күп әле, картаерга
Вакыт юк, — дигән кебек.

Гомерем юлын мин дә сездәй
Ялыкмый үтәр идем.
Министр булсам, сезне күптән
Генерал итәр идем.

Хәер, сездәй солдат булу
Беркайчан начар түгел.
Тик унсигез тулганмыни,—
Һаман яшь сезнең күңел.

Башкалар да шулай дияр,
Бу хакта уйласалар.
Генераллар нигә кирәк,
Солдатлар булмасалар!?

## Күңел җилкәне

Кеше күңеле — үзе бер дәрья ул,
Кеше күңеле белми чикләрне;
Һәм яктырта өмет-хыяллары
Гомер күген — язгы күкләрне.

Хәтәр җилләр, беләм, сез тормышта
Күп дәрьялар аша искәнсез.
Чын мәхәббәт белән җырдан башка,
Кеше күңеле гүя җилкәнсез.

*Фатих Хөсни*

# ИКЕ АГРОНОМ, БЕР ОВЧАРКА

## Хикәя

Басуларда, ферма каралтылары тирәсендә йөргәндә без инде сөйләшәсе сүзләребезне сөйләшеп бетергән идек. Чәй янында үзеннән-үзе җиңел сүзгә, уен-көлкегә күчеп киттек. Шундук тагын ничектер этләр турында гәп китте. Моның үзенә күрә кечкенә генә сәбәбе дә юк түгел иде. Колхоз председателе Мирзаян Касыймовның баскычы төбендә, бәйдә, бозау хәтле овчаркасы тора икән, чакырып кителгән кадерле кунак түгеллегемне чамалапмы дип әйтим, керешли ул миңа бер ташланып алган иде. Кергән ишектән һәм ул этнең яныннан тагы бер үтеп чыгасым барлыкны искә төшереп һәм, гомумән, саклык йөзеннән, ләкин үземнен эттән курыкканлыгымны һич сиздермичә, мин уен-көлке аралаш сүзне янә шул якка бордым. Башка мактаныр нәрсәм булмагач, шул бер уңайдан үземнең Казанда калган Алтушым белән мактанырга тотындым. Янәсе, ул тегеләй, ул болай, чәйне тәлинкәдән эчә, күршебездәге Дианка дигән эткә гыйшык тотканда, унар-унбишәр көн тамактан калып, аларның ишеге төбендә кипшеп-корышып ята. Сәбәбе дә булгандыр бәлки, кыскасы, мин бик кәефле идем ул минутларда...

Ләкин нәкъ шул чагында Мирзаян миңа тетрәткеч бер вакыйга сөйләп ташлады. Минем авыз шундук йомылды, монда иң яхшысы тыңлап утыру иде.

— Авыл хуҗалыгы институтын бетергәч, муенга камыт кигәнче дигәндәй, шулай бер үзебезнең туган яклардан урап кайтырга булдым,— дип, гадәтенчә, салмак кына башлап китте Мирзаян. Үзе дә эш кешесе, аның сүзләре бизәксез, хәтта беркадәр корырак та чыга, ләкин искиткеч тыгыз һәм логикалы иде. Мин аның кебек тыгыз сөйләп бирә алырмындыр дип уйламыйм — күп сөйләп, күп язып бозылып беткән кеше мин. Әмма Мирзаян авызыннан ишеткән ул вакыйганы, мөмкин хәтле түкмичә-чәчмичә, сезгә җиткерүне үземнең шушы минуттагы бурычым саныйм.

— ...Чаллы ягыннан без. Бертуган абыем Морзахан Касыймов, ул да минем кебек үк агроном, Зәй районында сортлар сынау участогы мөдире булып эшли иде ул чакта. Шулай итеп шул, киттем туган якларга. Абыйны да күрермен, шул уңайдан туган авылга кереп, кардәш-ыруның хәлен белеп, үзебезнең чаптырып ага торган чишмә суыннан кайнаган чәйне дә эчәрмен, мәйтәм. Авылдан чыгып киткәнгә биш-алты ел үткән, ничек кенә димә, сагындырган. Үзара гына әйткәндә, чәйдә түгел хикмәт. Абыйның ничегрәк эшләгәнен күреп, мыекка урардаен мыекка урап кайтырга исәп. Үзегез беләсез, институт дигәненң бирәсен бирде дә үз урынында утырып калды, ә башта яхшы ук буталчыклык хөкем сөрә. Шулай итеп шул, киттем. Авылда күргән-белгәннәрне сөйләп тормыйм, кем күрмәгән дә, кемгә тансык.

Ә менә Морзахан абый янындагыларын... дөресен әйткәндә, аларын да барысын да сөйләп тору хаҗәт түгел. Һәр кешенең үз эше. Берәүгә кызык, икенчегә кызык түгел.

Ә шулай да менә бер вакыйга истә калган, анысы бөтен кешеләр өчен дә кызыклы булыр дип уйлыйм. Һәрхәлдә, табигать күргән, хайваннарга якын торучы, аларны «аңлый» белүче кешеләр мине аңларлар. Үзләрен артык цивилизованный санаучы кешеләр, ишетергә теләмәсәләр, колакларына мамык тыксыннар, башлыйм мин башлыйм дигәнне:

...Этләрдән китте бит әле безнең сүз. Шулай итеп шул, бер дә беркөнне Морзахан абый мине, үзе янына тарантаска утыртып, ерак басуларына алып китте.

— Бәзәге-мәзәге бергә булыр... болыннар буйлап барасы, һич югы берәр бытбылдык атарбыз,— дип, тарантас башына мылтык та тыктык. Киттек без. Кызык булсын дип абыйның Полкан исемле яшь ярымлык овчаркасын да иярттек. Иярттек түгел, үзебезнең янда тарантаска утырып бара. Ике агроном, бер овчарка. Көн яктысында, мин сиңайтим. Колхозларның печәнгә төшкән чагы. Яхшы түгел, бер караганда. Абыйга әйтеп карыйм, ишетергә дә теләми.

— Малайлыгыңа барма, монда безнең эше-ялы бергә,— ди.

Аннары, минем белән түгел, эте белән сөйләшкән кебек, авыз эченнән генә мыгырданырга тотына:

— Биш елга бер кайткан энекәшне алып чыккан икәнмен... Эш белән дип күз буямыйк, күз буяучылар бездән башка да җитәрлек. Кырлар карарбыз. Болыннар ямьле безнең, болын юлларыннан үтәрбез. Кәефкә ошаган берәр җирдә туктап, коньяк салып алырбыз... Кем әйтер сүз? Әйтеп карасыннар. Шулай бит, Полкан? Син минем яклы бит? Аңлатып бир безнең янда утырып баручы менә бу тәти абыеңа.

Полкан, аның сүзен җупләгән кебек, кыска гына бер өреп куйгандай итте. Бу минутта аның зур күксел күзләре тоташы белән абыйда, әйтеп бетергесез ышаныч белән тулган, әйтеп бетергесез мөлдерәп тора иде.

Абыйны элек-электән беләм, каршы сүз әйткәнне яратмый, бер уйлаганда, каршы сүз әйтергә урын да юк. Бер тын бөтенләй сүзсез барды. Һич югы эте белән сөйләшсен икән, эте белән дә сөйләшми, кашын җыера төшеп, тик бара — янында мин әллә бар, әллә юк.

— Аспирантурада калырга да мөмкин иде, тәкъдим иткәннәр иде,— дип куйдым мин, абыйны ничек тә телгә китерергә тырышып.

— Шикәрләп-баллап имезлек тә каптырып карамадыларммы тагы?— Абый миңа карамыйча гына сөйләнде, аның минем сүзгә ачуланганлыгы әллә кайдан сизелеп тора иде. — Шулай иркәләп үстерәләр бит сез тар балакларны. Өстегезгә җил-янгыр тимәсен, импортный ботинкаларыгыз тузан-туфракка буялмасын, ә үзегез агроном дип аталасыз, ташка үлчим.

Ярый, ул арада икенче бер сәбәп килеп чыкты. Шул тирәдә пар сөрүче бер трактор юлны бозып йөри икән, абый, атны туктатып, тракторның якынайганын көтеп торды. Теге килеп җиткәч, тарантастан төшеп, тракторчының янына китте.

— Кем сезне болай юл бозарга өйрәтте?— дип кычкырып җибәрде ул, әле прицепщик малайга, әле тракторчының үзенә карап. Аның кәгазьгә төшерерлек сүзләре шуның белән бетте, калганы кәгазь күтәрми торган сүзләр иде. Мин абыйның сүгенергә шул кадәр остарганлыгын беренче мәртәбә шунда ишеттем һәм, дөресен әйтим, әле яңарак кына институт эскәмиясеннән торып чыккан кешегә — миңа — яхшы ук уңайсыз булып калды.

— Сезнең басумы әллә? — дип сорап куйдым мин, абый яңадан тарантаска килеп утыргач. Сорамаган булсам, яхшырак буласы икән, күзләре белән ашардай булып элек абый үзе, аннары эте миңа карап алдылар.

— Синең бу соравың ошамый миңа, егеткәем,— дип, гөрселдәп өстемә ябырылды абый,— агрономныкы булмаган басу юк. Әллә син, минем басу түгел, дип җир бозучылар яныннан тыныч кына узып китә алыр идеңме? Алыр идең. Сезгә соң җир кадерлеме? Сезгә диплом кадерле.

Мине сүгәргә алып чыккан икән бу, дим эчемнән генә. Ләкин каршы килеп сүз кайтарырга телем бармый, нәрсәдер бик каты өнле иде абый ул минутта. Миңа, бертуган энесенә, адәм рәтле сүз тапмаса да, анда-санда этенә эндәшкәләп куя бу. Иркәләп түгел — иркәләү сүзен кече-кечедән белмәде ул — ничектер шунда бушлыкны тутырыр өчен әйткәндәй, өзек-төтек бер сүз ташлый. Эте, аны аңлаган кебек, әле бер мөлдерәп карап куя, әле башын боргалап сырпаланмакчы була. Ләкин хуҗасының кырыслыгын сизеп, шундук күзләрен аска ала, мыштым гына утыруын белә.

Кояш кыздыра төшкәч, шулай да Полканның тарантаста утырып барудан яхшы ук зарыкканлыгы сизелә башлады. Ул сулышын ешрак ала, башын күтәргәләп иснәнгәләп куя, ә бераздан авызын ачып телен үк салындырып төшерде — аның озынлыкка сузылган теле һавада асылынып калды һәм ул тел, һич арттырмыйча-киметмичә әйтәм, күмер лампочкасы кебек, күз алдыбызда янып тора иде...

— Әкренләп менә бу мәхлукны да боза барабыз,— дип сукранып куйды абый, этенә ымлап,— тарантаска утырып бара, үзе әлсерәп телен чыгарды.

Хуҗасының үзе турында сөйләнгәнен аңлап алгандай, эт янә бер сырпаланмакчы булып карады, әмма абый аны терсәге белән коры гына этәрде. Шул җитте: эт шундук телен эчкә яшерде, күзләрен аска алды, кыскасы, шып булды. Ахрысы, алар бер-берсен ымлашып ук аңлыйлар иде булса кирәк.

Без болын юлыннан бара башлаган идек. Тар гына юл, ике якта да күпереп җиткән үлән, чәчәкләр, бал кортлары, шул хәтле байлык, мин сиңайтим, юл читенә үскән тукранбашлар сузылып тәгәрмәч арасына керәләр һәм, җуләр сатып йөрүче ике агроном, бер овчарканың авырлыгын күтәрә алмыйча, башларын салалар. Кыскасы, миңа — таш кала тузаныннан әле тик арынып кына чыккан кешегә — ярап куйды бу сәйранлык. Бер җирдә атны туктатып, үзебез белән алып чыккан коньякны фляга капкачына гына салып берәр йотым кабып җибәргәч, бигрәк тә түгәрәкләнде.

— Абый,— дип сүз башладым мин, чак кына болагайлана төшеп,— син менә күптән эшли торган кеше, әйт миңа: кайсы башыннан тешләп карарга икән бу дөньяны? То-есть, мин әйтәм, җибәрсәләр, китәргәме, әллә аспирантурада калыргамы?

Бу турыда бер мәртәбә сүз ачып, абый авызыма чәпәгән иде инде, кирәк бит тагы шуны элеп алырга. Әлеге дә баягы, шул бер йотым коньяк бәласедер инде. Кем белә, бәлки яшьлек бәласе дә булгандыр, ул чакта миңа булыр-булмас егерме биш яшь кенә иде. Борынга төреп тыгарлык егет, янәсе.

Абый шунда әйтте миңа. Өченче кабат тагы шул бер балык башын чәйнәмәслек итеп әйтте:

— Мин сине, малай, укып, файдалы кеше булып чыккансыңдыр дип уйлаган идем,— күземә туры карап әйтсә, ул хәтле читен булмас иде, ничектер читкә карап, сүзләрне иңбашы аша ыргыткандай әйтте,— ә син, бактың исә, укып-укып, тешкә йомшак калҗа эзләргә өйрәнеп чыккансың икән.

Башканы ул әйтмәде. Хәер, башканы әйтеп торырга вакыт та, кирәге дә булмады. Мин үземә тиешлесен мыекка урадым. Ә абый... абыйны үз мәшәкате урап алды. Мәсьәлә шунда: якындарак кына атлы косилка туктап калган, ә ул абыйлар хуҗалыгыныкы, имеш. Кирәк бит шулай ерактан күреп алырга. Мактана дип уйламагыз, күзе очлы аның, минем Морзахан абыйның.

— Син утырып тора бир, нани,— диде ул миңа, малайга эндәшкән кебек эндәшеп, — мин тиз генә барып, борасы гайкасын борып килим шул сәләгәйнең.

Ул бик кызган иде бу минутта, нилектән икәнлеген чамалыйсыздыр: миңа да серкәсе купкан, болын уртасында атлары, косилкасы белән туктап калган теге булдыксыз җан да күз алдында күз көеге. Китә башлагач, борылып, кычкырды. Әйтте түгел, кычкырды. Тамак төбе белән кычкырды:

— Син анда кара, малай... Этне минем арттан җибәрмә.

Янәсе, мин, авыл хуҗалыгы институтын бетереп чыккан яшь агроном, хәзергесе минутта этне һәм атны тотып торырга ярасам, шул бик җиткән. Теленә, сүзләренә, ул сүзләрне әйтешенә игътибар итегез, «малай» дип мыскыллап бер кычкыруы ни тора. Менә шундый кеше ул минем Морзахан абый! Дөресен әйткәндә, мин аны нәкъ әнә шундый кеше булганлыгы өчен яратам да. Яшерен-батырын түгел, мин шул минутта, чәчәкләрне һәм бал кортларын үземә шаһит итеп куеп, үземә-үзем кистереп әйттем: «Юк, Мирзаян иптәш, тормышны һәм кешеләрне белмәгән килеш, бер эскәмиядән ансат кына икенче эскәмиягә күчеп, син алай фән калҗасына үрелеп мәташмә. Элек эшләп кәҗә маеңны чыгар, теләгең һәм сәләтең булса, аннары карарсың»,— дидем. Бу шул әлеге Морзахан абый янында булып кайтканнан соң тарта башлаган колхоз арбасы инде, абый кеше. Әйтмәгәнем булсын, абый кеше, кәҗә маен чыгаралар монда. Әмма, зинһар, зарлана бу, дип уйлый күрмәгез, зарланган кеше юк хәзерге көндә.

Мирзаян, чак кына көлемсерәгәндәй итеп, миңа карап торды, аның ак тешләре тезелеп күренә һәм, гомумән, ул зарлана торган кешегә һич кенә дә ошамаган иде. Миңа һәм үзенә куе итеп чәй ясаганнан соң, ул, стакандагы шикәрен болгата-болгата, әкрен генә янә ялгап китте.

— ...Әмма ул чагында мин этне тотып тора алмадым, әлеге теге минем янда тарантаста утырып калган Полканны әйтәм. Юк, абый җаным, тотып кала алмадым мин аны и, шулай итеп, күңелдә гомерлек бер көек торып калды.

Мирзаян сүзен дәвам итте, ләкин ул моннан биш-ун минут элек кенә минем янымда көлемсерәп утырган Мирзаян түгел иде. Күзләре каядыр эчкә качты, кашлары күпереп өскә калкып чыкты, тавышы тонykландыр, ул фаҗигале хәл сөйләргә җыйнала, тирәсендә таптанып йөри, ләкин эченә керергә курыккандай күренә иде.

— ...Эт элек бер мәл, хәлне төшенеп җитмәгәндәй, як-ягына карангалап алды, аннары миңа текәлде. «Ә нишләп синең белән мин монда эшсез калдык әле?» дигән төсле иде аның бу карашы. Мин аны тынычландырырга тырышып сыпыргаладым, минем бу куштанлануга исе дә китмәде хайванның. Исе китәргә ни... Мин кем аңарга? Килгән бер кунак. Бүген бар, иртәгә юк.

Шулай да мин моны, әле алай, әле болай юаткалап, бераз тотып тора алдым. Күрәм, Морзахан абый тегендә, учына бер төкереп алып, кыздыра да башлады. Дөрес, мин монда тарантаста утырган җирдән алар арасында ниләр булганын аерым-ачык кына әйтә алмыйм, әмма, кулларын сузгалавына, косилка тирәсендә бөтерелүенә караганда, чамаларга була: малайны да, машинаны да borгалый булса кирәк. Бер мәл бу чабылмаган озын үлән арасында бөтенләй юк булып торды, чыңлатып тимерне тимергә суккан авазлар яңгырап ишетелде: ахрысы, машинаның астына кереп «өшкерергә» үк тотынды булса кирәк. Әлбәттә, мин ул якны гына күзәтеп тора алмыйм, миңа бит әле этне, Полканны тотып тору кушылган. Әмма, дөресен әйтим, минем кулдан килә торган эш булмады бу. Күрәм: этемнең күзләре яшәргәннән-яшәрә бара, кинәт ул бөтен гәүдәсе белән калтырана башлады. Ә аның котырып үскән гәүдәсе мин генә тотып тора алырлыкмы соң! Тарантасны дер селкетеп, менә ул минем кочактан җиргә атылды. Сикереп төшүе булды и тонды хуҗасы артыннан. Чабылмаган үлән арасыннан сырты гына күренеп калды котырганның. «Олага бир»,— мин әйтәм эчтән генә, сиңа соң тәмле

телемне әрәм итеп торган булам. Инде минем эш җиңеләйде, эсселектән бераз чытлыклана башлаган атны тотып торасы да, тарантас башында печәнгә күмелеп калган теге фляга күңелгә шом сала — димәк, үземне тотып торасы. «Әллә, — мәйтәм,— абый юкта тагы бер мәртәбә иренне чылатып карарргамы?». Эссе чак, ирен көя, үзара гына әйткәндә...

Этне мин бер мәлгә күздән үк югалттым. Биек булып үскән үлән арасында мәхлук бөтенләй күренмәс булды. Ә абыйның җилләнеп-җилләнеп косилка, атлар тирәсендә әйләнгәне күренә. Менә ул малайны бер якка этеп калдырды, «бишек»кә үзе менеп кунаклады, дилбегәне кулына алды... Бераздан инде атлар, башларын чайкый-чайкый, кузгалып киттеләр.

«Их, син, чуар йөрәк! Үзең бер әйләнеп килмичә тынгы табарсыңмы соң?»— дип, үз алдыма сөйләнеп куйдым мин. Абыйны мин беләм—мәсьәлә анда түгел. Бер әйләнмәгәе, биш әйләнсен. Мәгәр үземә уңайсыз. Китәсе җиремә тизрәк китеп, җиң сызганып эшкә тотынасы урында, панимаешь, нишләп соң әле мин монда, кеше кояшында пешеп, ат саклаучы малай булып утырам? Соңыннан, еллар үткәч башка менеп җитте, абый янына кайтып килүнең файдасы, күрәсең, шул булган: ул минем канымны кыздырып, яхшы мәгънәсендә көнчелек уты кабызып җибәрде булса кирәк. Юкса, мин әле «Китәргәме? Аспирантурада калыргамы?» дип байтак килэп сарып йөргән булыр идем.

Чү, сүз белән мавыгып, мин бит әле төп мәсьәләне онытып җибәргәнмен, агаем. Төп мәсьәлә дигәнем — әлеге шул эткә кайтып кала. Булды анда безнең эшләр, сөйләве дә әллә ничек хәзер... Абый шул минем, җенләнеп тотынып, кузгалып кына киткән... Кирәк бит хайванга, үлән арасыннан барып, косилка пычагы астына керергә. Хуҗадан калмый, янәсе.

...Мин барып җиткәндә, өч аягы тиң киселгән эт, косилкадан чак кына читтәрәк, үлән арасында, шау кан эчендә тыпырчынып ята иде. Морзахан абый аны, селкетмәскә тырышып, сыңар кулы белән җиргә баскан, үзе, этнең азаплануын күрмәскә теләп, йөзен читкә борган иде.

— Син нигә кирәк монда? — Ул мине күреп түгел, адымымнан танып шулай кайнап чыкты.— Атны барып алып кил тизрәк!..

Мин атны китереп җиткергәндә, этнең, бичараның, баягы тыпырчынулары узган, ул буйсынучан-моңлы күзләре белән, «Нишләтәсез мине?» дигәндәй, әле беребезгә, аннары икенчебезгә караштыргалый, торып-торып теле белән яраларына ябыша, ләкин яраларыннан сирпелеп торган кан анарга яланырга ирек бирми иде. Җитмәсә тагы, кояшы да башны пешерердәй булып кыздыра башлаган иде.

Без, җәрәхәтле этне ничек кирәк алай тарантаска күтәреп салып, атны җан-фәрманга куарга тотындык. Мин тел әйләндереп сүз катарга белмәдем, абый үзе дә җир төсле караңгы, җир кебек сүзсез иде. Атны кай якка куууыннан шулай да чамаладым, райүзәккә чабабыз бугай. Күрәсең, тизрәк алып барып, врачларга күрсәтергә, берәр чарасын күрергә уйлый иде булса кирәк.

Тарантас башына тезләнгән килеш, абый үзе берөзлексез атны куалый, үзе шул арада борылып-борылып эткә күз салгалап ала иде. Ләкин, нишләмәк кирәк, райүзәк ерак, көн бик эссе, этнең җәрәхәтләре яман булып чыкты. Канны берничек тә туктатып булмады. Тарантастагы печән, безнең өсләребез канга буялып бетте. Болында күпме кан ятып калды. Бер уйлаганда, дүрт аяклы бу мәхлукка шул хәтле кан кайдан килгәндер.

Баштарак теле белән яраларына сузылырга омтылышлар ясап караган этебез соңга таба бу азабыннан туктады, теле яртылаш чыккан килеш агарып, хәлсезләнеп калды. Сулыш алулары тигезсезләнде. Бердәнбер җан әсәре күзләрендә генә калып бара иде. Ой, аның шул минуттагы күзләре, агаем! Җәл, мин анадан художник булып тумаганмын.

Карау гына түгел бу, мөлдерәү, үпкәләү, бер үк вакытта бәхилләшү, «Китәм инде мин сездән!» дип өзгәләнүе иде.

Нигә кирәк монда сүз, абыем-җаным. Аннары тагы ул күзләрне, ул мөлдерәп торган күзләрне сүз белән аңлату мөмкинме! Минем үземә дә, әлбәттә, ансат түгел иде. Ул да түгел, Морзахан абый чабып барган атны дәррәү туктатты да җиргә сикереп төште. Сикереп төште дә, нишләргә җыенганлыгы турында ләм-мим сүз кушмастан, җәрәхәтле этне тарантастан кочып алды. Күтәреп, читкәрәк алып китте, яшел чирәм өстенә илтеп сузып салды. Тарантас янына кире әйләнеп килде, үзе һаман ләм-мим сүз кушмый иде. Тарантас башындагы печәндә актарынырга тотынды, ул бик җенле иде бу минутта. Күпкә сузмады, чехолдан ике көпшәле мылтык тартып чыгарды.

— Бар, малай,— диде ул, миңа мылтыкны сузып,— чик куй мәхлукның азабына. Үзем булдыра алмыйм.

Чынлап әйттеме ул бу сүзләрне, әллә юри, мине сынау өчен шулай эшләдеме? Хәзергә хәтле очына чыга алганым юк. Ләкин буйсынмый чарам калмаган иде. Абый тарантас янында, бөтенләй икенче якка борылган килеш, тораташ булып катып калды. Хәтта мылтык тавышына да сискәнмәде! Булса да булыр икән таш йөрәк.

Минем шулай ук телем әйләнми башлаган иде. Кире әйләнеп килеп, мылтыкны чехолына тыгып торганда, сискәнеп киткәндәй, кинәт борылып карады бу.

— Беттеме эшең? — дип сорады, күтәрелеп карамыйча гына. Шулай да мин күреп алдым: абыйның күзләре кызарган иде. Яшен яшерергә тырышып, күрәсең, ул күзләрен нык кына уган иде булса кирәк.

Тарантас артына беркетелгән тимер кыргычны алып, без юл читендәге чирәмлеккә кабер казыдык. Этне күмдек. Аннары, борылып, кайтып киттек. Абый юл буе ләм-мим сүз эндәшмәде. Мин дә, тел әйләндереп, ни дә булса остарырга базмадым. Шул булды эш, шулай бетте Морзахан абый белән йөреп кайту.

Мирзаян, хикәясен сөйләп бетергәч җиңеләеп калгандай, бераз тынып торды. «Я, син ничек карыйсың моңа?»— дигәндәй, миңа карап алды. Минем, ни дип әйтергә дә белмичә, аптырабрак утыруымны күреп, ул — бу юлы инде җиңел һәм уенчак тавыш белән — ярып салды:

— Сез теләсәгез ни әйтегез, ни әйтсәгез дә ихтыярыгыз, абый җаным. Әмма минем үземә кайдадыр әнә шундый кешем булу, шуны күңелем белән тоеп тору рәхәт. Морзахан абыйны әйтәм, таш күңелле, бер караганда. Әй юк, миннән яшерә алмас, мин аны күрдем, таш янында кечкенә генә йөрәк тә бар и шул кечкенә йөрәк барысын да әйләндереп тора.

Март, 1965 ел

●

*Хәй Вахит*

# КАРЛЫГАЧ КАНАТ КАГА [1]

## ҖИТДИ КОМЕДИЯ, ӨЧ ПӘРДӘДӘ

Марсель *(конторада кеше юклыгына ышангач)*. Хәзер, хәзер. *(Өстәл янына килә, эзләнә, әлеге катыргыны тартып чыгара.)*

Бәнат. Нишлисең анда? Әллә этигә дә яздыңмы?

Марсель. Синең этиең дип торып булмас монда. Берсе дә тынгылык көтмәсен.

Бәнат. Каяле *(тартып алып укый)*. «Мууу... сыер булып мөңгерәп йөргәнче, эшкә тотынса иде буuу...» Ха-ха. Мә, җыеп куй, истәлек булыр. Ха-ха-ха... Мөңгерәп йөрүеңнән ни файда, сөтең булмагач. *(Күздән югала.)*

Марсель. Мин эшсез йөримме?! Мин... Мин стенгазета члены. *(Бүлмәдән Кәүсәрия чыга.)* Бүген үк яңаны чыгарабыз. Исемен дә үзгәртәбез: «Карлыгач канат кага». Кәүсәрия апа, мәкалә яз.

Кәүсәрия. Дөнья мәшәкатьләре муеннан ашкан, ахирәт эшләре белән шөгыльләнергә вакытым юк.

Мәйсәрә белән Диләрә керә.

Мәйсәрә. Ильяс абый юк ахры?

Марсель. Менә Мәйсәрә яза. Йөкләмә ала. Һәр сыердан берәр пот сөт.

Кәүсәрия. Борыныңны сөрт. Бүгенге көнне ни бары биш литр.

Марсель. Мәйсәрә, ичмаса ун литрга да җиткереп булмыймыни, ә?

Мәйсәрә. Бер сыер урынына икене саусаң.

Марсель. Ә тырышсаң? Кәүсәрия апа, булмас микәнни?

Кәүсәрия. Нигә булмасын, була, нәнәм, була.

Марсель. Буламы? Унбиш литрга?

Кәүсәрия. Кирәк икән, унбиш литрга да җиткереп була.

Марсель. Ә егермегә?

Кәүсәрия. Ә менә анысы булмый.

Марсель. Нишләп?

Кәүсәрия. Ул чакта гел суга гына әйләнә ул.

Ильяс керә. Кәүсәрия шыпырт кына чыгып китә.

Ильяс. Мәйсәрә? *(Мәйсәрә җавап бирмичә генә кәгазь суза.)* Бу ни, гариза? Эштән чыгаруны сорыйсың? Сәбәп?

Мәйсәрә. Ялкау мин. Эш яратмыйм.

Ильяс. Чү-чү, тыныч кына.

Мәйсәрә. Тотмагыз мине. Кул куегыз да җибәрегез. Эшсез калмам, табармын.

---

[1] Ахыры. Башы—7 санда.

Ильяс. Берни дә аңламыйм.
Мәйсәрә. Мин сездән китәм. Кала алмыйм.
Ильяс. Ни өчен?
Мәйсәрә. Кияүгә чыгам! Шәһәр егетенә!
Диләра. Мәйсәрә, ялганлыйсың бит. Баштан аяк ялганлыйсың.
Ильяс. Нәрсә булды?
Мәйсәрә. Әйтерсең, белмисез. Низами агай белән киңәшеп мине куарга булгансыз ич. *(Чыгып китә.)*
Ильяс. Мин? Низами белән? *(Буылып.)* Ах, менә ничек?! Димәк, Низами эше? Кайда ул?
Марсель. Күптән түгел генә мунчага кереп киткәнен күреп калган идем.
Ильяс. Алып килегез. Мунчасыннан өстерәп чыгыгыз. Ялангач килеш булса да каршыма килеп баскан булсын!
Марсель. Булдырабыз аны. *(Чыгып йөгерә.)*
Ильяс *(үзен көчкә кулга алып)*. Я, агроном, синең ничек анда — өченче бригадада? Ни өчен орлык нитрогенланып бетерелмәгән?
Диләра. Бригадир исерек, кладовщик баш төзәтә.
Ильяс. Ә син?
Диләра. Мин алардан башка нишли алам.
Ильяс. Ах, менә ничек?! Димәк, тынычланып кайттың? Үз өстеңнән җаваплылыкны төшереп? *(Кызып, ни әйтергә дә белмичә йөренә.)* Гаепне аударырга кеше табылган, җавабын бригадир бирсен икән, кладовщик бирсен, тик Диләра гына түгел, ә?
Диләра. Ә син нәрсә эшләргә кушар идең?
Ильяс. Орлык синең участокмы? Синеке икән, алынгансың икән, башкалар өстенә аударып кына тынычланма инде, ярыл — шартла, теләсәң нишлә, анысында минем эшем юк, әмма эш эшләнгән булсын.
Диләра. Нәрсә? Миңа бәлки бригадир урынына төшәргәдер?
Ильяс. Кирәк икән, кладовщик урынына утыр. Әмма ышандырып алынган эшең җиренә җиткерелергә тиеш.
Диләра. Алай икән, үзең генә түбәнгә төшеп калмадың, бездән дә, миннән дә шуны көтәсең икән. Беләсе иде, бу фикер кайчан килде икән синең башыңа. Күптәнме?
Ильяс. Күптән. Сине якыннан белә башлаганнан бирле.
Диләра. О-о, синең мине якын итүең шушымени? Көтмәгән идем. Син алайса мондый юлны — түбәнгә тәгәрәү юлын дим — яраткан кешеләреңә генә тәкъдим итәсең?
Ильяс. Ышанган кешеләремә генә.
Диләра. Рәхмәт.
Ильяс. Рәхмәтең түгел, эшеңнең нәтиҗәсе кирәк.
Диләра. Тыныч булыгыз, иптәш управляющий. Боерыгыгыз үтәлер. Бригадир булырга... кладовщик булырга... Ашыгыйм, урынымны алып куя күрмәсеннәр. М-м-м, туң йөрәк, туң йөрәк. Булса да булыр икән. Йөрәгең күмергә әйләнгән синең.
Ильяс. Диләра!

Диләраның әйтер сүзләре күп, әмма берсен дә әйтә алмый. Ильясны кочаклап үбеп ала да ишеккә йөгерә.

Ильяс. Диләра!
Диләра. Артымнан йөрмә. *(Чыгып китә.)*
Ильяс *(тәрәзәгә ташлана)*. Диләра!!!
Лемара *(бүлмәдән чыга)*. Шулкадәр тавышланмагыз әле. Кеше йоклый. Тсс...

Икесе дә тынып кала. Ут сүнә. Бераздан ут кабына. Өстәлгә җәеп салган чертежга күрсәтә-күрсәтә, Җәүдәт Гыйләҗне өйрәтә. Гыйләҗнең кулында коловорот — боргычлы борау. Үз урынында Сәрьян карт утыра.

Гыйләж. Әһә-әһә, берьюлы ничә сыер керә?

Җәүдәт. Утыз ике. Менә кара син, карусельгә сыер үзе керә. Кергә ишеге механически ябыла.

Гыйләж *(тәмам иләсләнгән, урамнан кергән Кәүсәрияне дә күрми)*. Әһә-әһә... Иллә лә! Көненә күпме сыер савыла дигән сүз инде?

Җәүдәт. Менә исәплә. Алты минутка утыз ике сыер. Димәк, өчдүрт кеше көненә сигезәр-тугызар йөз сыер сава алачак.

Гыйләж *(шаккатып)*. Менә бит ничек ул, аңладыңмы?

Җәүдәт. Кара, үзем аңлатып торам түгелме соң, миннән аңладыңмы дип сорый.

Гыйләж *(Кәүсәрияне күреп)*. Әнкәсе, сизәсеңме, эшләр кая табан бара?!

Кәүсәрия. Кил әле, кил. Яле, өр әле.

Гыйләж. Ау-ау... вау-вау...

Кәүсәрия. Сулышыңны, сулышыңны өр. *(Исни.)* Эчмәгән. Нидән болай теле ачылган соң әле моның дисәм, кулына техника тоттырганнар икән егетнең. Тел ачкычың аракыда гына түгел икән ләбаса. Бирсен ходай. *(Аркасыннан сөя.)*

Урамнан Ильяс керә.

Ильяс *(кожанын сала-сала)*. Өченче бригаданың күперен сипләтмичә булмас.

Җәүдәт. Ильяс абый, ничек, бу карусельгә чынлап керешәбезме?

Ильяс. Шундый зур эшкә уйнап кына керешәләрмени?!

Җәүдәт. Димәк, карусельне ясыйсыз?

Ильяс. Нигә мин, син ясыйсың!

Җәүдәт. Ул чагында менә нәрсә, двигатель булыр. Двигатель бар.

Ильяс *(җанланып)*. Сәрьян абый, ишетәсеңме, нәрсә дигән идем. Ну-ну?

Җәүдәт. Без ул карусельне күптән ясарга тиеш идек инде. Шуның өчен мине Казанга җибәрделәр. Бардым, өйрәнеп кайттым. Кайткач та төннәр буе чертеж өстендә утырдым. Инде эшкә тотынырга гына дигәндә, шалт — бервакыт ишетәм: карусель ясамаска! Имеш, булдырырлык кеше юк. Җәүдәт механик түгел, өйрәнчек кенә. Двигательне пилорамага алырга булганнар. Пилораманың үз двигателе дә эшләрлек, карыйсы гына бар. Ә карусель... Карусель безгә во (!) кирәк. *(Муеныннан сызып күрсәтә.)* Аннан соң, нәрсәгә мин чертежлар белән баш катырып утырдым соң?! Атналар буенча! Шул, тоттым да бер төнне двигательне яшереп куйдым. Бәрәңге чокырына.

Ильяс. Үзләренә аңлатырга кирәк тапмагансың?!

Җәүдәт. Күпме аңлатырга?!

Ильяс. Ах син, ә! Алтын егет син үзең, әмма башсыз егет. Сәрьян абый, ә?! *(Ике кулының бармаклары белән генә ярты литрлы шешәнең озынлыгын күрсәтә.)* Китте!

Сәрьян. Лемара кызым, әйдә, теге чуар тавыкны тотарга булыш.

Лемара. Әбигә ни дип җавап бирерсең. Сиңа да, миңа да көн күрсәтмәс.

Сәрьян. Берәр хәйләсен табарга туры килә инде. Ат аягы баскан диярмен.

Лемара. Һей, ат баскач үлгән була бит ул. Ильяс абыйга үлгән тавык ашатыр хәлем юк.

Сәрьян *(артыннан кычкыра)*. Кайдан өйрәндең бу усаллыкка.

Лемара. Синнән. *(Урамга чыгып китә.)*

Ильяс *(Җәүдәткә)*. Бәрәңге чокырына дисеңме?! Ха-ха-ха... Әмма

шуны бел, эшне сузасы булма. Менә бүгеннән үзем дә сакал үстерә башлыйм. Карусельне төзеп бетергәнчегә кадәр кырынмаячакмын.

Җ ә ү д ә т. Пардан йөрербез.

И л ь я с. Ах сакалбай, сакалбай. *(Үз бүлмәсенә кереп китә.)*

К ә ү с ә р и я *(ашыкмыйча гына Җәүдәт каршына килеп баса)*. Бу эшең барып чыкмас, энем Җәүдәт! Судан коры чыгарга чамалыйсыңмы? Имеш ул двигательне үзе китереп бирә, үзе килеп әйтә. Янәсе, аны бирәү дә мәҗбүр итмәгән. Суд алдына барып басасы килми егетнең.

Җ ә ү д ә т. Син сөйләсәң, Кәүсәрия апа, аңлатып сөйлә.

К ә ү с ә р и я. Аңлыйсың, бик яхшы аңлыйсың.

С ә р ь я н. Кәүсәрия килен, мин үзем дә төшенә алмыйм бит әле.

К ә ү с ә р и я. Сәрьян абый, двигательнең эзенә беренче булып мин төштем. Җәүдәт моны сизеп алган да тизрәк монда йөгергән. Кәүсәрия барып сөйләгәнче үзем әйтим дигәндер. Акланып калырга чамалаган. *(Җәүдәткә борыла.)* Кәнишне, мин күргәч син килеп әйтерсең, башка чараң юк.

Җ ә ү д ә т. Двигательне мин үзем чыгардым. Әнә, чокыр өстендә.

К ә ү с ә р и я. Мин күргәч чыгардың.

Җ ә ү д ә т. А юк, син аны мин чыгаргач күргән.

К ә ү с ә р и я. Син бутама, яме, мин күргәч чыгардың!

Җ ә ү д ә т. Әй, канца-то концов, син күрсәң дә күрмәсәң дә чыгара идем мин аны. *(Чыгып китә.)*

К ә ү с ә р и я. Әһә, ишеттегезме, ишеттегезме, үзе икърар итте. Мин күргәч чыгарганын үзе әйтеп бирде. Совет властен таларга ирек бирмәбез.

Г ы й л ә ж *(кисәтеп кычкыра)*. Кәүсәрия! Син нәрсә азынасың?

К ә ү с ә р и я. Совет властен обижайт иттермәм.

Г ы й л ә ж. Тишек борын, бу карусель кем өчен төзелә, совет власте өчен түгелме?!

К ә ү с ә р и я. Абау, кара ничек котырына. Элегрәк, яшьрәк чакта «фәрештәм» дип кенә йөргән кеше.

Г ы й л ә ж. Хәзер мин аллага ышанмыйм. Кемгә каршы чыкканыңны беләсеңме син? Кара аны, сүзеңне үлчәп сөйлисе бул, муеныңны борырмын. *(Зырылдатып коловоротны әйләндерә.)*

К ә ү с ә р и я. Борырсың, борырсың. *(Гыйләҗнең битеннән сыйпаштыргалый да кисәк муенын борып куя.)* Борырсың. *(Алып чыгып китә.)*

Тәрәзәдән Сәрьянның карчыгы күренә.

К а р ч ы к. Шушында утырадыр дигән идем аны. *(Конторага керә.)* Өеңә аю мае сөртмәгәннәрдер бит. Хәзер кайтам дип чыгып киткән кеше. Ни дип утырасың?

С ә р ь я н. Синнән шүрләп утырам, энкәсе.

К а р ч ы к. Шүрләтерсең сине.

С ә р ь я н. Хәрап итте бит теге явыз.

К а р ч ы к. Нәрсә булды тагын?

С ә р ь я н. Әнә шул каһәр суккан чуар тавыгыңны әйтәм лә. Чистартыйм дип тегү машинасының бер винтигын алып чыккан идем. Такта өстенә куеп торуым булды, нәгъләт төшкере, ни ара килеп тә җиткән, кабып та йоткан.

К а р ч ы к. Машинам винтигынмы? Чуар тавык йоттымы?

С ә р ь я н. Шул булмый кайсы булсын.

К а р ч ы к. Хәрап иткәнсең икән, шайтан дими, кем диясең инде сине. Ул винтиксыз машина эшләми бит инде. Кире чыкмас микәнни?

С ә р ь я н. Аны каравыллап йөрисеңмени?

К а р ч ы к. Алайса, ул тавыкны тизрәк суярга кирәк, үлеп китә күрмәсен тагын.

С ә р ь я н. Суймый нишлисең. Авызына бармак тыгып алып булмый. Әллә суймыйбызмы, әнкәсе? Чәнчелеп китсен винтигы, аның өчен генә тавык әрәм итеп торырга.

К а р ч ы к. Ни дигән сүз, суябыз, суябыз. Әйдә, суябыз.

С ә р ь я н. Лемара кызым, әйдә алайса, тотарга булыш. *(Чыгалар.)*

Урамда машина тавышы. Лемара йөгереп керә.

Л е м а р а. Ильяс абый, Ильяс абый.

Бүлмәсеннән И л ь я с чыга.

Шамил абый килде, тегене нишләтәбез? Шамил абый күрсә хәрап булабыз бит. Сыя торган булса, тумбочкага гына тыгып бикләп куяр идем. Нишләтәбез соң?

И л ь я с. Син болай ит, бүлмәңә кер дә эчтән бикләп куй.

Лемара бүлмәсенә кереп китә. Урамнан Ш а м и л керә. Ул яхшы киемнәреннән. Башны бик горур тота. Директор бит.

Ш а м и л *(Ильяска ике бармагын гына сузып).* Сәлам бирдек. *(Кепкасын, плащын салып Ильяска тоттыра. Ашыкмый. Нәкъ Ильяс гадәтенә охшатып ишекле-түрле йөри башлый. Урындыкка килә. Кулъяулыгы белән каккалаганнан соң гына утыра. Папирос кабыза.)* Так... *(Түшәм почмагына текәлеп.)* Үрмәкүч оялаган димме? Так... Болай булмый бит, егетләр. Сезнең белән нишләргә соң инде миңа. Сөтне киметтегез.

И л ь я с. Ундүртне савып уникегә бүлмибез.

Ш а м и л. Күпер җимерелә башлаган, күрмисез. Әллә инде начальство килеп борчып йөрмәсен дип үзегез җимерәсезме?.. Ремонт бетмәгән, орлык өлгермәгән. Чәчүне өзәргә җыенасыз, что ли? Ну, егетләр, кәҗә маегызны чыгарам мин сезнең болай булса. Продукт кимеде, социалистик законность бозыла, угрылар почетта йөри башлады. Нишләргә инде сезнең белән, ә? Миндә ике бүлекчә...

И л ь я с. Тегесендә эш гөрләп бара.

Ш а м и л. Әйе, гөрләп бара. Ә биредә...

И л ь я с. Һаман да әле сөйрәләбез.

Ш а м и л. Сөйрәләсез.

И л ь я с *(нәкъ Шамил интонациясендә, Шамил хәрәкәтләренә охшатып).* Ишеткән сүзләр, иптәш директор. Колак тынып бетте. Тиргәгәнгә карап кына эш барса иде. Сүздән чабата да үреп булмый. Тиргәве җиңел ул, ә менә эшләве? Сезгә нәрсә, югарыдан гына күрсәтмә биреп ятулары ансат шул. Үзең эшлисе булмагач! *(Шамил елмаюын яшерә алмый.)* Булган ди берәүнең ике хатыны, берсе — карт, икенчесе — яшь. Яшь хатыны моның ак чәчләрен чүпли икән, карт хатыны карасын. Шуның хәленә калдырасыз инде мине. Пеләш итәсез инде..

Шамил көләргә дә, ачуланырга да белмичә утыра. Шулай да, түзә алмый, кулын Ильяс җилкәсенә салып, шаркылдап көлеп җибәрә.

И л ь я с. Без арбаның арт тәгәрмәчләре!

Ш а м и л *(тынып торгач).* Бу хәлләр өчен югарыда рәхмәт әйтерләр дисеңме?

И л ь я с. Рәхмәт өчен эшләмим.

Ш а м и л. Баштан сыйпамаслар.

И л ь я с. Өркетмә. Югарыда ахмаклар утырмый.

Ш а м и л. Ильяс, урманга илле кеше сорадым. Нигә җибәрмәдең?

И л ь я с. Мөмкинлегем юк. Кырга торф чыгарам, ашлама кертәм.

Ш а м и л. Иртәге көн өчен?

И л ь я с. Иртәге көн өчен.

Ш а м и л. Иртәге көндә терлекне корма белән тәэмин итү өчен нәрсә эшлисең? Карар кабул иттеңме?

Ильяс. Карардан кукуруз да, борчак та үсми.

Шамил. Ну, дус кеше, болай булса, тавык фермасына әтәч санарга җибәрәм мин сине. Җәүдәт һаман да ишектә йөри?

Ильяс. Җәүдәтне бирмим, ул миңа кирәк.

Шамил. Карап карарбыз. *(Тәрәзәдән кычкыра.)* Энекәш, Кәүсәрия апаңа әйт әле, шушы тирәдә йөри иде. Монда керсен әле.

Ильяс. Шамил, синең белән хәл итәсе мәсьәлә бар. Мин Низамины бригадирлыктан бушатам.

Ишектә Низами күренә, әмма сүзнең үзе турында барганын аңлап, ишек төбеннән узмый.

Шамил. Бусы тагын ни?! Мин снимать иткән кешеләрне кире куясың, мин куйганнарны алып ташлыйсың?

Ильяс. Шамил, Низами белән булмый. Алга карап эшли ала торган кеше түгел. Үз файдасын гына кайгыртучы. Комсыз. Кара син аның йорт-җирен, кул көче белән эшләп тапкан дисеңме?!

Шамил. Урынына кемне күздә тотасың?

Ильяс. Җәүдәтне.

Низами сиздермичә генә чыгып китә.

Шамил. Син нәрсә, шаяртуыңмы?! Да, милиционер булдымы монда? Мин килгәнче килеп, двигательне табып, җинаятьчене кулга алып куярга тиеш иде.

Ильяс. Килде. Очрашты, сорашты, сөйләште. Тикшеренде, җикеренде, ахырдан тынычланды. Әмма Җәүдәтне гаепли алмады.

Шамил. Кундымы?

Ильяс. Кунды микән, анысын белмим. Хәер, йоклаганын беләм. Йоклады, йоклады. Йоклагач кунган булып чыга инде.

Кәүсәрия керә.

Кәүсәрия. У-у, ике директор да монда икән. Кайсыгызга кирәк булдым? Фу, тавык урлаган диярсең, йөрәгем дөп-дөп итә.

Шамил. Түрдән уз, Кәүсәрия, мин чакырттым. *(Урындык тәкъдим итә.)* Сине тәбрик итәргә кирәк. Уяулык күрсәткәнсең. Премиягә лаеклы.

Кәүсәрия. Нәрсә өчен?

Шамил. Җәүдәтне каптыргансың ич. Двигательне тапкансың.

Кәүсәрия. Кем тапкан, минме? Юктыр, мин булмаганмындыр ул.

Шамил. Син нәрсә тагын?!

Кәүсәрия. Белмим, белмим, җаным, хәтерләмим. Хәтерем бик начар минем. Кичә сөйләгән сүземне бүген онытам. Белмим, белмим.

Шамил. Ах, син алаймени әле?! Күрмәдеңмени?!

Ильяс. Кәүсәрия, бәлки, син аны Җәүдәт чыгаргач кына күргәнсеңдер?

Кәүсәрия. Шулайдыр, шулайдыр. Ярый, чыгыйм мин. *(Юнәлә.)*

Шамил. Син кая?!

Кәүсәрия. И... Ике директорга бер үзем, ничек җавап биреп бетермәк кирәк. Ильяс абый, чыгып торасыз мәллә? Шаһитсыз гына әйтеп бирим булмаса.

Шамил *(шурләп)*. Ну, ну! Ильяс, кузгалма.

Ильяс башта әкрен генә кузгала, аннан кисәк йөгереп чыгып китә.

Шамил. Ильяс дим! *(Артыннан йөгерә, әмма ишекне ача алмый, күрәсең, тыштан Ильяс тотып тора.)* Ильяс, ач! *(Кәүсәрия шаркылдап көлә. Шамил читләтеп кенә килеп тәрәзә буена баса. Тәрәзәне ачып куя.)* Я, сөйлә.

Кәүсәрия. Якынрак килегез.

Шамил. Юк, шуннан гына.

Кәүсәрия. Сез, Шамил Саттарович, Җәүдәт өстеннән сөйләргә кушасыз миңа. Нишләп сөйлим, башыма тай типкәнме. Гыйләҗем Җәүдәт белән карусель ясый, дәртләнеп, канатланып йөри, җанашым. Шуның канатын каерып ташлыйммы инде мин, язмаганны. Ә ул карусель кем өчен ясала дисең? Сыерлар өчен. Ә бит минем бозауларым да сыер булачак. Аларны карусельдән мәхрүм итимме?! Аллам сакласын. Сыер булып җиткәч ни әйтерләр? Йөземә төкереп китәрләр. Юк, күрмәдем мин ул двигательне. Хәтерләмим, белмим, мин булмагандыр ул.

Шамил. Тфү! Димәк?..

Кәүсәрия. Шулай. Дөрес, күрүен беренче мин күрдем. Ә допроска чакырсалар, күргәнем юк диячәкмен. *(Кычкыра.)* Ильяс абый, керсәгез дә була.

Шамил. Ну, знаешь!..

Кәүсәрия. Хушыгыз. *(Каршына Низами очрый.)* Низами абый, бозау абзарының ишеге юк.

Низами *(ачулы)*. Эт бәйләп куй.

Кәүсәрия чыгып китә.

Низамины эштән чыгарам, приказ бирәм, дисең икән. *(Усал көлә.)* Шуны да аңламаска, ә. Син бит миңа түгел, үзеңә приказ бирәсең, энем.

Шамил. Ягъни?

Низами. Миңа нинди гаеп тагасың? Корма әзерләүне өзде дипме? Ә ул чакта, мин өзеп ятканда, син кайда идең соң? Син өзмәдеңмени?!

Шамил. Ну, ну!

Низами. Бу гаеп, беренче чиратта, синең җилкәгә төшә түгелме? Ә ремонтны өзүдә, карусель ясауны өзүдә син гаепле түгел алайса?

Шамил. Син нәрсә?

Низами. Бу эшләр өчен мине снимать итәргә кирәк икән, сине тем более. Эх, иптәш Хәсәнов, үзеңә үзең хөкем карары язып утырасың.

Шамил. Житте, житте.

Низами. Юк, валлаһи, молодец икән бу Ильяс, чәнчи бармагы тирәсендә ничек әйләндерә сине. Ха, кирәк бит. Үзеңнең ахмаклыгың турында үзеңнән приговор яздыра да үзеңнән үк кул куйдыра. Ха-ха... Печать басарга онытма.

Шамил *(маңгаеннан тирен сөртә)*. Ну-ну-ну!

Низами. Хәйлә бар икән үзендә дә. Капкынны ничек оста корган. Шамилең үз аягы белән, үзе теләп килеп кергәнен сизми дә кала.

Шамил. Кем сизми? Кемне чәнчи бармагына чорныйлар, Шамилнеме? Ашыкма, мине алай җиңел генә көлкегә калдыра алмас. Балерина итәм мин аны, бармак очында йөртәм. Ни әйтсәң дә әлегә мин директор, аның язмышы минем кулда. *(Уч төбен күрсәтә.)* Менә монда аның язмышы.

Низами. Дөрес, Шамил Саттарович, бик дөрес.

Шамил *(аның саен кызып)*. Әгәр дә мин тотынсаммы, управляющийлыктан да, директорлыктан да гомергә колак катачак. Әгәр дә мин кирәк тапсам!

Низами. Кирәк, кирәк, Шамил Саттарович. Аны авылдан гына түгел, районнан ук куарга, бөтенләйгә куарга кирәк. Эзе булмасын.

Шамил *(тынып кала)*. Нәрсә? *(Низамига текәлеп карап торгач.)* Туктале, син кая каерасың? Нигә аны бөтенләй куарга?

Низами. Ул куркыныч кеше, ышаныгыз.

Шамил. Куркыныч? Кемгә куркыныч, ни өчен куркыныч? Провокация белән шөгыльләнәсеңме? Андый эшкә юл куймам!

Низами. Ахмак булма, Ильяс бригадирлыкка гына түгел, управляющий урынына да кеше әзерли. Синең урынга да.

Ш а м и л. Вон моннан!

Н и з а м и. Как хош! Миңа димәгәе, бергә эшләгән кеше дип кенә әйтүем. *(Чыгып китә.)*

Ш а м и л *(уйланып)*. Тукта, чыннан да, нәрсә соң бу? Тырышып-тырышып җинаятьче Җәүдәтне яклый. Кәүсәриясен үз ягына аударган. Минем урынга... Тукта-ле, Низами! Низами дим! Кая киттең, шайтан алгыры!.. *(Ишеккә юнәлә, каршына Сәрьян керә.)*

С ә р ь я н. Нәрсәгә кирәк булдым, мин монда.

Ш а м и л. Сине түгел лә.

С ә р ь я н. Шайтан дип чакырдың түгелме соң?

Ш а м и л. Тфү! *(Ишектән үк кычкыра.)* Низами, туктале. *(Чыгып китә. Сәрьян кеткелдәп кала.)*

С ә р ь я н *(кычкыра)*. Ильяс улым! *(Эчке кесәсендә ярты литр аракы күренә.)* Ильяс!.. *(Урам ягыннан тәрәзәгә Сәрьянның карчыгы килә.)*

К а р ч ы к. Атасы дим, атасы! *(Бармагы белән генә Сәрьянны чакыра.)* Тавыкның түшен дә актардым, эчәгеләрен дә, теге винтикны таба алмадым мин.

С ә р ь я н. Шулайдыр. Такта астына тәгәрәгән булган икән, таптым инде мин аны.

К а р ч ы к. Тфү, каһәр генә суккансың икән.

С ә р ь я н. Ә син ни телисең, «шайтан» кушаматын тикмәгә генә күтәреп йөрергәме?! *(Кайтырга юнәлә.)*

Шул чакта ашыгып Җ ә ү д ә т килеп керә. Ярсыган.

Җ ә ү д ә т. Кайда ул?

Л е м а р а *(бүлмәдән чыга)*. Кем, берәү дә юк монда.

Җ ә ү д ә т. Кәүсәрия апа әйтте, кайда сөяркәң? *(Бүлмә ишегенә атлый. Лемара аны кертми.)* Бикләнеп ятасызмы? Ач ишегеңне!

Л е м а р а *(ярдәм сорап)*. Ильяс абый!

Җ ә ү д ә т. Шушы бүлмәдә, икегез генә төн кунарга уйлаган идегезме? *(Ишекне каерып ачып бүлмәгә кереп китә. Лемара нишләргә дә белмичә кала. Бер Ильяс бүлмәсенә, бер телефонга килә. Җәүдәт Альбертны алып чыга. Альберт йокысыннан айный алмый, киерелә, исни.)*

А л ь б е р т. Ох, әйбәт булды. Изелеп йоклаганмын. Төш тә күрелмәгән. Инде эшкә тотынырга да була. Кичкә кадәр авылның астын-өскә әйләндермәсәм.

Җ ә ү д ә т. Кайда сумкасы? Кепкасы кайда? *(Бүлмәгә кереп китә.)*

А л ь б е р т *(аңлап алып)*. Бу ни хәл? Нишләп монда йоклаган мин?

Җәүдәт бүлмәдән сумка ыргыта.

Җ ә ү д ә т *(бүлмәдән кычкыра)*. Кайда кепкасы?

Л е м а р а. Хәрап булдык. Икебезне дә хәрап итә инде. Бетерә, бетерә. Кирәкмәгән көнче. Берни белән дә исәпләшми. Үзе дә бетәр, безне дә бетерер. Ичмаса ишекне бикләп куйгансыз.

А л ь б е р т. Мин?

Л е м а р а. Син булмый кем булсын? Зинһар тизрәк таегыз. Мотоциклыгыз үзегезнеке, утырыгыз да элдертегез. Хәрап булабыз, хәрап булабыз...

Җ ә ү д ә т *(чыга да Лемараны кулыннан алып бүлмәгә таба өстери)*. Әйдәле, табып бир әле.

Л е м а р а. Әййй!.. *(Җәүдәттән ычкына.)*

А л ь б е р т. Нигә китим, мин шүрләүчеләрдән түгел. Мин... Юк, мин... Кайда икән минем мотоциклым? Ярый, исән булыгыз. *(Чыгып китә.)*

Мотоцикл кабызган тавыш ишетелә. Лемара шкафны ачып кепканы ала да тәрәзәдән суза.

Лемара. Алыгыз. Тизрәк, зинһар тизрәк! *(Мотоцикл кузгалып киткән тавыш.)* Хәерле юл, ха-ха-ха... *(Такмаклап Җәүдәт каршына килеп баса.)*

Ал итә, итә, итә.
Гөл итә, итә, итә...

Шул чакта урам як ишеге төбенә кадәр ачылып китә. Ике егет толыпка төренгән Диләраны күтәреп керә. Мәрьям дә шунда. Диләраның аягында олы киез итекләр. Ашыгып Шамил керә.

Шамил *(куркуга кала).* Ни булды?

Мәрьям. Елга аша өченче бригадага барганда бозлы суга төшкән.

Шамил. Нигә елга аша?

Мәрьям. Турыдан бармакчы булган. Ашыккан. Ильяс аркасында. Ул куыра бит.

Шамил. Хәлең ничек?

Диләра. Коры кием китерегез, я үземне өйгә илтеп куегыз. Тизрәк, миңа бригадага өлгерергә кирәк.

Мәрьям. Тфү, Ильяс җене кагылгандыр моңа. Кемгә ачу итеп шулай эшлисең син, ә? Беләм бит, елгага керүең дә үч итеп.

Диләра. Миннән эш көтәләр.

Мәрьям. Хәрап икән!.. Лемара, булыш зинһар. Киемнәр табасы иде.

Мәрьям Диләраны Лемара белән бүлмәгә кертеп җибәрә.

Шамил *(буылып нәрсәдер сөйләмәкче, тузынмакчы була, аннан кисәк кычкыра).* Кайда Ильяс, кайда управляющиегыз?

Урамнан Ильяс керә. Диләраның хәлен белергә ашыга. Башкалар чыгып китәләр.

Шамил. Кара син бу хәлне, нишли бит. Мин җибәргән участковыйны йоклата, минем сеңелне елгага батыра. Ә минем үз урыныма... икенче кеше эзли. Бу ни?! Син минем белән уйнарга керештем дисең инде. Ләкин мин белергә тиеш: нинди уен, кагыйдәсе ничек? Юкса мин синең бу уеныңа катнашудан баш тартам. *(Ильяс дәшми.)* Низами турында приговор яздырып, Шамилнең үзен фаш итәм, дисеңме?! *(Ильяс дәшми.)* Болай булгач, инде үзеңә үпкәлә. *(Кисәк әйтеп куя.)* Кайда вәгъдә иткән уңышларың?

Ильяс. Чебешләрне көз көне саныйлар. Әйе, бүген бераз тоткарлык булуы ихтимал. Ә якын көннәрдә күтәрелеш башланырга тиеш.

Шамил. Безгә бүген кирәк. Иртәгә нәрсә булыр, белмим. Миңа бүген күренеп торсын. Менә син безне бүген канәгатьләндерә алмыйсың. Шунлыктан без сине иртәгә калдыра алмыйбыз. Әйе, директор булараk... *(Ильяс аягына баса.)* Мин сине эшеңнән алырга мәҗбүрмен. Ә ник, булмас дисеңме?

Мәрьям. Шамил, нигә шулкадәр ярсыйсың. Ул сине бөтенләй үк бәреп екмаган бит әле. Әнә, парткомда үзеңне яклап сөйләгән, нәтиҗә ясаса, эшли ала торган кеше дигән. Шулай булгач?! Ул бит сине күтәрде.

Шамил. Күтәрде. Әйберне ташка бәреп ватар алдыннан тоже баш өстенә күтәрәләр. Ныграк кизәнеп бәрү өчен. Менә карап карыйк: кем башы ярылыр икән.

Мәрьям. Шамил!

Шамил. Тыгылма әле, безнең эшне беләсеңмени син?!

Мәрьям. Аһ, алай икән. Менә, Мәрьям, ишетмәсәң ишет, тыгылма, хакың юк. Аш пешерергә, кер уарга, идән юарга хакың бар синең. Ә совхоз эшләре турында сүзеңне әйтергә юк. Көчең кермәгән, тирең таммаган. *(Күз яшенә тыгыла.)*

Шамил. Әйе, әйе.

Мәрьям кул селтәп, үпкәләп кайтып китә.

Мин сине эшеңнән алырга мәҗбүрмен. Юкса һәлакәткә атлыйсың.

Бүлмәдән Диләра чыга. Лемара пальтосын киеп алган.

Бузатерларга почет өләштең, җинаятьчеләрне канат астыңа алдың. Ялгышлык өстенә ялгышлык. Бу үзе җинаять юлына басу. Үзеңне үзең хәрап итәсең түгелме?! Юк, сине коткарып калырга кирәк. Шуның өчен мин сине эшеңнән алырга тиешмен.

Диләра. Абый, син ни сөйлисең?!

Шамил. Башка чара юк.

Диләра. Бар! Әле эш узмаган. Ялгышлыкны төзәтергә була.

Шамил. Ничек? Кем?

Диләра. Ул үзе! Үзе төзәтә ала! Приказны ертып ташлый. Сине үз урныңа утырта. Үзе элекке эшенә — директорлыкка! Бөтенесен кире кайтарырга була. Элек ничек булса — яңадан шулай!

Шамил. Әгәр дә ул элекке хәленә кире кайтырга риза була икән, ул чакта мин... Пожалуйста.

Диләра. Ильяс абый, синең өстә болытлар куера.

Ильяс. Бик әйбәт, күк күкрәр, яшен яшьнәр! Яратам.

Диләра. Син шаяртасың. Юкка. Әлегә соң түгел, Ильяс абый, кайт син отпусканнан. Иртәгә, бәлки, эшеңнең нәтиҗәсе дә күренә башлар. Ә бүген сине юк итәләр. Син агымга каршы йөзмәкче буласың. Мөмкин түгел ул.

Ильяс. Чигенү юк, Диләра. Күперләрне җимереп, көлен күккә күтәреп уздык.

Диләра. Ялгыш юлны дәвам иттергәнче, чигенү яхшырак.

Ильяс. Ах, шайтан, ялгыш булып чыкты микәнни. Минем бит ул турыда уйлаганым юк әле. Вакыт тими.

Диләра. Менә хәзер вакытың бар. Хәзер уйла.

Ильяс *(һаман да шаяртып)*. Файдасы булыр микән? Әйтик, тәртәне кирегә борып элекке эзгә дә кайтып төштем ди. Шуннан ни? Тагын чыгымлап китмәс бу дип уйлыйсыңмы? Юк, мин үземә үзем ышанмыйм. Элекке хәлгә дә кайтырмын, сез әйткәнчә, бу ялгышны да төзәтермен. Ә аннан соң? Ә аннан соң тотармын да тагын нәкъ шушылай ук эшләрмен дә ташлармын. Характер!

Шамил. Бүлекчә артта иде, бүлекчәгә күчтең. Ә бүлекчәдә аерым бер ферма артта булыр, ферма мөдире булып китәрсеңме?

Ильяс. Эш өчен кирәк икән, китәрмен!

Шамил. Бу юл белән барсаң, сыер савучыга кадәр үсеп җитәргә дә күп кирәкми.

Ильяс. Кешеләр безгә ышаналар, ә аларның ышанычын акламаска безнең хакыбыз юк. Үзең дә күрәсең бит, канатланып йөри башладылар. Кара син Җәүдәткә, Кәүсәриягә! Башкаларына! Мин чигенсәм, алар ни диярләр?! Сезнең диңгездә, шторм вакытында, су коенганыгыз бармы? Ургылып дулкын артыннан дулкын килә. Сине күтәрә, әйләндереп ыргыта, үзе белән эчкә алып кереп китә. Ә сиңа рәхәт. Бу эшләр дә мине үз эченә суырып алды. Аңлыйсыңмы, рәхәт. Тормыш кайный, дулкын артыннан дулкын килә. Ә минем тагын да тирәнгәрәк керәсем килә. Үз артымнан Диләраны да ияртәсе иде дим!

Шамил. Диләраны?

Ильяс. Өченче бригадага бригадир кирәк. Эх, шуңа Диләра алынса! Мин аны, әлбәттә, приказ белән куя алмыйм. Әгәр дә үзе теләп алынса...

Шамил. Үзеңнең төшүең генә җитмәгән, инде Диләрадан да шуны көтәсеңме?

Ильяс. Эш өчен кирәкле урынга алынуны мин күтәрелү дип исәплим. Бүлекчәгә агроном табарбыз. Безнең өчен хәзер иң әһәмиятлесе — өченче бригаданы нығыту. Диләра, ни дисең? Мин сиңа ышанам, җиң сызганып тотынсаң, ә!

Шамил. Беләсеңме нәрсә? Хәер, минем синең белән сөйләшерлек бүтән сүзем юк. Монысы инде, монысы — чамадан тыш. *(Диләрага.)* Безне тыңламыйча Казанга китми йөрсәң, менә — ишетмәгәнеңне ишет. *(Тузынып пальтосын ала да кайтып китә.)*

Диләра. Яраткан кешеләргә генә ясый торган тәкъдимең шушымы?

Ильяс. Үз иткән кешеләргә.

Диләра. Ялган. Үз иткән кешене, яраткан кешене түбәнгә төшерү өчен йөрмиләр, күтәрү өчен, үстерү өчен тырышалар. Аның тагын да күркәмрәк булуын, өстенрәк булуын телиләр. Ә син... Аңламыйм, ни өчен син мине шулкадәр күрә алмыйсыңдыр.

Ильяс. Мин ышанам сиңа, аңларсың дип ышанам. Син уйла әле, ашыкма.

Диләра. Юк, юк, тагын бер мәртәбә юк!

Ильяс. Үзеңә караганда мин сине күбрәк белмим микән. Разый булырсың кебек.

Диләра. Юк.

Ильяс. Ир йөрәкле кеше син. Елга аша чыгарга маташуың да ошады миңа. Тәвәккәллек! Миңа үч итеп, ә?! Молодчина.

Диләра. Юк!

Ильяс *(йөзенә туры карап торгач)*. Ә бит син аңа охшагансың.

Диләра. Кемгә?

Ильяс. Хәербанатка.

Диләра. Элекке хатыныңа? *(Тынып калды.)* Ә... Менә мин сине аңладым. Нәрсә, борыным, колагым охшаганмы? Белми идем, үземнең фотография генә икәнлегемне белми идем. Шушы фотографиягә карап син үзеңнең еракта калган мәхәббәтеңне хәтерлисеңме? Һе, истәлек альбомы. Күләгә. Ә мин кемнеңдер күләгәсе булып яшәргә теләмим.

Тәрәзәдә Бәнат күренә.

Бәнат. Диләра апа, сиңа телеграмма.

Диләра телеграмманы алып укый, Ильяска суза.

Ильяс *(укый)*. Көтәм, көтәм, көтәм. Сәгыйт Баймурзин.

Диләра. Көтә. Белмим нишләргә инде?

Ильяс *(бераздан)*. Чакыргач барырга кирәк.

Диләра. Син шундый киңәш бирәсеңме?

Ильяс. Шулай дөресрәк булыр.

Диләра *(Ильясның күзләренә карап торгач)*. Яхшы. Киңәшең өчен рәхмәт. Мин сиңа ышанам, уйламый сөйләми торгансыңдыр.

Ильяс. Хәерле юл.

Диләра. Станциягә кадәр машина булырмы?

Ильяс. Булыр.

Диләра. Бүген үк?

Ильяс. Бүген дә мөмкин. *(Аның күңелендә Хәербанат яраткан музыка яңгырый башлый.)*

Диләра. Исән булыгыз, Ильяс абый, шулай дәвам итегез. Алынган юлыгыздан чигенмәгез. Кешеләрнең ышанычын казану зур нәрсә ул. Чигенмәгез, бер адым да. *(Ишек буендагы Бәнат янында тукталып тора да чыгып китә.)*

Бәнат. Эти!.. *(Килеп әтисен кочаклый.)* Эти, син аны яратасың түгелме соң? Яратасың икән ич, эти.

Ильяс. Дәшмә, кызым.
Бәнат. Әнигә охшаган өченме? Ул чыннан да әнигә охшаганмы?
Ильяс. Дәшмә дим.

Пәрдә

## ӨЧЕНЧЕ ПӘРДӘ

Ферма буе. Тәмәке тарту өчен махсус урын. Өстәл. Яшь агачлар тезмәсе артында ферма каралтылары, арба күренә. Вакыт кичкырын. Низами белән Җәүдәт тәмәке тартып утыра. Гыйләҗ басып тора, кулында гармонь. Авылны күзәтә. Менә бервакыт гармонен тартып та җибәрә, тыпырчынып та ала, җырлап та куя. Йөгереп Кәүсәрия керә, аның артыннан Мәйсәрә күренә.

Кәүсәрия. Абау, Гыйләҗ җаным, нишләвең бу? Көпә-көндез тау өстендә? Әллә инде, ходаем... Сулышыңны өр әле.

Гыйләҗ. Бөтен авылның күз алдында үзем уйнап, үзем җырлап биергә телим. Уен дип беләсеңме, дөньясын нишләттек бит. Карусельне ясап бетереп киләбез. *(Тагын гармонь тарта.)* Көн дә эшләнә торган эш түгел.

Кәүсәрия. Үзем дә бүген төш күрдем. Карусель зыр-зыр әйләнеп тора, ишегеннән бозауларымны кертеп торам, имеш, бер әйләнеп чыгуда болар тана булып өлгереп торалар, имеш, икенче әйләнүдә сыер. Мичкә-мичкә сөт бирәләр, имеш.

Мәйсәрә. Тавык төшенә тары керә, имеш.

Сәрьян килә.

Гыйләҗ. Исәнлекме, нихәл, Сәрьян абый?

Сәрьян. Бер көе, чыршы кебек. Картаймыйбыз да, яшәрмибез дә. Тик менә буяулар гына уңа башлады.

Кәүсәрия. Әй маладис та инде син, Сәрьян абый. Куандырасың безне. Сиксәнгә үрмәлисең бит.

Сәрьян. Исең киткән икән иске чикмәнгә. Минем әти үлмәгән булса, йөзне тутырган булыр иде инде.

Кәүсәрия *(Сәрьянның билбавына кыстырган кечкенә балтасын күреп)*. Бу балтаң нигә кирәк булды? Безгә булышырга килүең мәллә? Сиңа да Ильяс җене кагылмагандыр ич?!

Сәрьян. Ильяс кына булып чыкмады, хәзер Ильяс булды ул. Өйдә ятканчы дим, кая, шунда яшьрәк кызлар тирәсендә миңа да берәр эш табылмасмы? Кул арасына керергә ярап куярмын.

Гыйләҗ. Ай-яй, Сәрьян абый, кайда җылы урын барын үзең сизәсең тагын.

Мәйсәрә. Кара төндә кояш чыккан дип торам, Җәүдәт сакалын кырган, имеш.

Гыйләҗ. Бригадир булгач, сакалдан йөрү килешәмени!

Кәүсәрия. Аңа түгел. Йоклаганда кемдер кайчы белән кыркып киткән.

Мәйсәрә. Кем икән?

Кәүсәрия. Кем булсын, Лемарадыр инде. Ул сакалга аның җен ачуы чыга иде.

Низами. Сакаллар үстереп кемнедер фаш итәргә йөргән булды. Баксаң-күрсәң, начальник булу өчен генә тырышкан икән. Бригадир булып алгач, фаш итәселәрен онытты.

Җәүдәт. Әле син сизмисең икән безнең нәрсә өчен йөргәнне. Авылда гына түгел, бөтен район күләмендә фаш итәбез бит үзегезне. Карусель ясыйбыз! Менә шунда күрерләр кемнең кем икәнен.

Мәйсәрә. Шулай итеп, Низами агай, хәзер: ни сам, ни зам, просто Низам булып калдымыни инде?

Кәүсәрия. Карале, Җәүдәт, мин сине котламаганмын да икән. Бу бригадирлыкны булдыра алырсың микән инде?

Җәүдәт. Булдырып булыр. Эшен дә эшләтеп бетерермен. Тик менә аракысын гына ничек эчеп бетерермен. *(Көлә.)*

Лемара килә.

Кәүсәрия. Комачауламыйк.

Лемара белән Җәүдәттән башкалар кузгалалар.

Низами. Азындылар. Әйтмәгән саен. Һәрберсенең телендә: Низами алай да, Низами болай. Үзе турында гына кайгыртучы, имеш, үзе өчен генә...

Сәрьян. Шулаймы? Алайса сиңа, Низаметдин, бик төптән уйланырга кирәк. Бөтен кеше бер авыздан әйтеп тора икән... Җиде кеше исерек дисә, аек булсаң да ят та йокла, дигәннәр.

Низами. Көнләшәләр. Байлыгымны күрә алмыйлар. Баеса, эшләп тапкан байлык. Көн-төн димәдем, сәламәтлегемне салдым. Башта колхозда, аннан совхозда. *(Кесәсеннән справкалар чыгара.)* Менә, ике врачта булдым, икесе дә...

Сәрьян. Ни диләр?

Низами. Икесе ике төрле киңәш бирә. Берсе Кавказга курортка барырга куша. Икенчесе җәяү йөрергә тәкъдим итә. Белгән юк әле, нишләрмен.

Сәрьян. Алайса син, Низаметдин, курортка җәяү бар. *(Көләләр.)*

Лемара. Сиңа повестка. Нарсудка — допроска чакыралар.

Җәүдәт. Двигатель турындадыр.

Лемара күзләрен тутырып Җәүдәткә карап тора да кисәк башын аның күкрәгенә сала.

Җәүдәт *(аптырап кала)*. Мара!..

Лемара. Андый-мондый хәл булса, нишләрмен.

Җәүдәт. Берни дә булмас, сабыр ит.

Лемара. Суд бит ул. Аңа факт кына булсын.

Җәүдәт. Сабыр ит. *(Туктаусыз үбә.)*

Лемара *(Җәүдәттән ычкынып киткәч)*. Үзең бер дә сабыр итмисең тагын. Бер сүз әйтимме? Сакалың миндә.

Машина килеп туктаган тавыш. Шамил керә. Икенче яктан Ильяс килә.

Җәүдәт. Мине нарсудка чакыралар.

Шамил. Нарсудка? Һе!..

Җәүдәт. Бригадирлыкны кемгә тапшырырга кушасыз?

Шамил. Табарбыз.

Җәүдәт. Бүген үк башкарыласы эшләр күп. Чәчү башланды, карусель ярты юлда. Үзем китеп барсам...

Шамил. Әнә Ильяска тапшыр.

Җәүдәт. Ильяс абыйга? Сез нәрсә?! Бу бит...

Шамил. Нәрсә — бу?

Җәүдәт. Кешене...

Шамил. Ничего... эшләр. Эшнең кечкенәсе юк аның.

Җәүдәт. Эх!

Шамил. Нәрсә, үкендерәме? *(Уза.)*

Җәүдәт. Үкенәм. Тукмаклыйсын тукмаклап, сындырасын сындырып китәсе калган. Бер хирург та төзәтә алмаслык итеп. *(Чыгып китмәкче.)*

Ильяс. Җәүдәт, ашыкма әле, җавабын үзем бирермен.

Җәүдәт. Юк инде, Ильяс абый, үзем барам.

Ильяс. Мине ике кулсыз итәсең. Бик вакытсыз бит. Каруселыне өлгертәбез дигәндә генә.

Кәүсәрия кире керә.

Кәүсәрия. Бригадир, кирәк идең бит.
Җәүдәт. Хәзер мин бригадир түгел. *(Чыга.)*
Кәүсәрия. Юкны сөйләмә, әйдә, үз күзең белән күреп кит.
Ильяс. Нәрсә бар, Кәүсәрия? Әйдәле.
Кәүсәрия. Тукта, тукта. *(Бер Ильяска, бер Җәүдәткә карап тора.)* Әллә инде...
Ильяс. Әйе, хәзергә мин бригадир.
Кәүсәрия. Китче? Ай-яй, үстерәләр сезне, Ильяс абый.
Ильяс. Үзем дә шаккатам. Җаваплылык артканнан арта бара.
Кәүсәрия. Курка башладым, минем урынга менмәсәгез ярый инде, бозаулар мөдире булып.

Сөйләшә-сөйләшә, көлешә-көлешә ферма ягына китәләр. Бәнат күренә. Кулында газетага төргән төргәк. Артыннан Марсель килә.

Марсель. Кемне эзлисең?
Бәнат. Күрмәденме, Диләра апа кайткан, ди.
Марсель. Әнә ич, амбар янында.
Бәнат. Кайткан. Ярый әле кайткан. Кайтмас инде, бөтенләйгә китте дип борчылган идем.
Марсель. Кайтса да озак тормас. Китәр. Кияве белән кайткан.
Бәнат. Юк. Кияве түгел ул. Корреспондент.
Марсель. Әнә ич, икәү киләләр. Кияве.
Бәнат. Түгел дим, газетадан ул.
Марсель. Кемне тикшерергә килгән?
Бәнат. Белмим.
Марсель. Белмисең шул. Әтиеңне, жалоба язганнар.
Бәнат. Ә?.. Исеме ничек?
Марсель. Баймурзин ди. Сәгыйт Баймурзин.
Бәнат. Сәгыйт? Шул үзе. Кияве.
Марсель. Ильяс абыйны тикшерергә килгән, ә? Хурланып үләрсең.
Бәнат. Мин аңа тагын гимнастерканы кидертеп карамакчы булдым.
Марсель. Диләра апагамы?
Бәнат. Аны әти: «Әнигә охшаган», — ди.
Марсель. Но?
Бәнат. Минем үз әниемне бер мәртәбә дә күргәнем булмады. Ул солдат булган. Санитарка. Бу аның гимнастеркасы. Шушыны Диләра апага киертсәм, әниемне күргән кебек булыр идем.
Марсель. Каяле. *(Гимнастерканы алып карый.)*
Бәнат. Ярый әле киертмәгәнмен. Аңа лаекмени ул? Шуны яратып ятам тагын.
Марсель. Бәнат, борчылма. Төкер син барысына да. Юк, төкермә. Көрәш башларга кирәк. Безгә читтән генә күзәтеп йөрергә житте инде! Көрәшергә! Әле дөньяда безнең өлешкә дә калган икән ул көрәш. Аяусыз булыйк! Җиен шайтан таяклары тик ятмыйлар бит, ни өчен без... Моржаларыннан чәүкә булып кычкырырга кирәк, йөргән сукмакларына карикатуралар кадап куярга! Көрәшкә, көрәшкә, яшьлек!.. *(Артта басып торган Диләраны күреп.)* Диләра апа, сез кайчаннан бирле монда торасыз?
Диләра. Сез мине тирги башлаганнан бирле. Исәнме, Бәнат. Син, кызый, әтиең турында кайгыртмыйсың, ахры. 3—4 көн эчендә сизелерлек ябыккан.

Бәнат. Кеше ашамаган өчен генә ябыкмый. *(Марсельдән гимнастерканы алып китмәкче була.)*

Диләра. Тукта, тукта. Нигә үпкәләдең син миңа? Җибәрмим. *(Кулыннан тота.)* Бу нинди гимнастерка? Кемнеке? *(Бәнат тартыла.)* Җибәрмим.

Шамил керә, аның артыннан Ильяс күренә.

Шамил. Сәгыйт кайда?

Диләра. Әнә. *(Шамил Сәгыйтнең каршына китә.)*

Ильяс. Исәнме. Кайтуың белән! Тәбрик итәргәме соң? Туй кайчан? *(Диләра һаман дәшми.)* Аңарчы карусельне җиңә алсак, туеңның түрендә утырырга исәп юк түгел, кода булып. Чакырсаң, әлбәттә.

Сәгыйт Баймурзин белән Шамил керә. Сәгыйт күзлектән.

Сәгыйт. Исәнмесез.

Диләра. Таныш булыгыз. Сәгыйт Баймурзин! Ильяс Айтуганов!

Сәгыйт. Сезнең белән танышуыма шатмын.

Ильяс. Кызганычка каршы, мин аны әйтә алмыйм. Җалоба тикшерергә килгәнсез дип ишетәм.

Сәгыйт. Сез тартасызмы? *(Ильяс урын күрсәтә, утыралар.)*

Диләра *(Бәнат белән Марсельга)*. Әйдәгез әле, сөйләгез. Миннән башка нәрсә булды монда? *(Диләра Бәнат белән Марсельне алып чыгып китә.)*

Сәгыйт. Мин сезне беләм.

Ильяс. Мин дә.

Сәгыйт. Танышлар икәнбез.

Ильяс. Танышлар.

Шамил *(бер Ильяска, бер Сәгыйткә карап алып, үз алдына)*. Шайтан белсен, нәрсә шунда... *(Ул борчулы, кул селкеп, чыгып китә.)*

Сәгыйт. Совхозның иңен-буен аркылап киләм. Берсе сезнең турыда «ул отпускада» ди. Икенчесе «авырый» ди. «Командировкада» ди өченчесе. Көлмиләр дә. *(Тирә-якка күз ташлый.)* Карусель! Бик зурдан купкансыз түгелме?

Ильяс. Бергә совхоздагы барлык сыерларны тупларга уйлыйбыз. Шул чакта бөтен эшне механикалаштырырга, автоматлаштырырга мөмкин булачак.

Сәгыйт. Дөресен әйтим, кеше буларак, үзем буларак, мин сезне аңлыйм. Сез бу адымны атларга мәҗбүр булгансыз. Сез эш кешесе. Житешсезлекләр янынннан күзәтеп кенә, тәнкыйтьләп, күрсәтмә биреп кенә үтә алмыйбыз. Сез аны үз кулыгыз белән төзәтергә тиешсез.

Ильяс. Күргәнсең икән, үтеп китмә, төзәт.

Сәгыйт. Һәм сез аңа ирешәсез дә. *(Сокланып.)* Әнә, бөтен халыкны күтәргәнсез. Зур хуҗалыкның нигезен саласыз. Аңлыйм мин сезне. Сез, артта калган хуҗалыклар булмаска тиеш, дигән карашны тормышка ашырасыз. Сүздә түгел, эштә! Директор кеше бригадир эшен дә эшли белергә тиеш, дисез. Кешеләр белән житәкчелек итү — алар белән бергә эшләү ул, дисез. Коммунизмда шулай булыр. Мин сезне аңлыйм. Бар бит әле бездә шундыйлар: үзе эшли алмый, ә эшли белә торганнарны өйрәтеп йөри. Сез андыйларга әйтәсез, күп белсәң, эшләп күрсәт, дисез. Тел белән тегермән тартып йөргәнче, дисез. *(Көлә.)* Яклыйм мин сезне, мактыйм. Эш өчен шулай борчылган кешеләрне яратам мин. Йөрәкле кеше икәнсез. Сезне формаль як кызыксындырмый. Сез берни белән дә исәпләшмисез, сезнең өчен иң әһәмиятлесе — хезмәт. Аңлыйм.

Ильяс. Сез нәрсәне аңламыйсыз соң?

Сәгыйт. Әнә шул берни белән дә исәпләшмәүне. *(Тәмәкесен тартып бетерә. Кесәләрен актара башлый. Блокнот чыгара. Шул чакта кесәсендәге икенче күзлеге җиргә төшә. Үрелеп ала.)* Фу, чүттән бас-

мадым. *(Юл күзлеген салып, җирдән күтәргән күзлеген кия.)* Берни белән дә... Ә исәпләшергә кирәк иде. Кирәк иде. Менә хәзер үзегезне мушкага утыртырга туры килә инде. Аңламыйсыз? Сез охотаны яратасызмы? Безнең хезмәт шул инде — охота. Аучы җәнлек ауласа, без...

Ильяс. Минем кебекләрне.

Сәгыйт. Материал. Ауга чыккансың икән, мушкага утырта бел. *(төзәп күрсәтә.)* Мушкага ала алсаң, очып барган чебенне атып төшерергә була. Хикмәт мушкага эләктерүдә. Сез элек совхоз директоры идегезме? Хәзер кем? Бригадир? Да — да — да! Димәк, качтыгыз? Язып куйыйк: «качкын». *(Көлә.)* Мушка? Судтан яклап калу булдымы? Мушка. Участковыйны йоклату? Тагын мушка. Низамины эштән алгансыз. Сәбәп? Элегрәк аның белән әңгәмә, беседа үткәрелгән идеме? Юк. Кисәтү дә ясалмаган, выговор да бирелмәгән?

Ильяс. Җыелышта да тикшерелмәгән.

Сәгыйт. Кешене тәрбиялисе урынга...

Ильяс. Еллар буенча.

Сәгыйт. Өйрәтәсе, кисәтәсе, төзәтәсе урынга, сез нишлисез? Тотасыз да урыныннан аласыз. Ай-яй-яй-яй...

Ильяс. Мушка!

Сәгыйт. Үзегез килеп утырасыз. Шулай булгач миңа нишләргә кала?

Ильяс *(каләменә күрсәтеп)*. Курокка басарга. Ялкын бөркесен.

Сәгыйт. Әйе, ялкынлы фельетон булыр бу.

Ильяс. Әмма ялкынны кәгазьгә төрмиләр.

Сәгыйт. Барлык директорлар сезнең эздән барсалар...

Ильяс. Нигә барысы да минем эздән барырга тиеш?!

Сәгыйт. Барысы да кача башласа. Ах да, сез качмадыгыз, сез отпускада. Һе, барлык директорлар бер үк вакытта отпускага чыга башласалар, һәр министр авырый башласа, бөтен партком секретарьлары командировкага китсә... Сезнең кебек... Нәрсә килеп чыгар иде? Анархия. Ничек сез шундый юлга бастыгыз, ә? Сез, беләсезме, кем? Куркыныч кеше. Тәртипне, гореф-гадәтне, традицияне таркатучы. Үзегез дә белмәстән, җәмгыятькә куркынычлы чир таратуыгыз бар. Аның иң куркынычы да шунда — сезне яклаучылар күп. Ә беләсезме, безнең өчен, газетчиклар өчен, кем сез?

Ильяс. Майлы калҗа. Кабасы да йотасы гына.

Сәгыйт. Калҗа? *(Рәхәтләнеп көлә. Аннан язуын дәвам иттерә.)*

Ильяс. Сез теге күзлегегезне киеп яза алмыйсызмы?

Сәгыйт. Кайсын?

Ильяс. Беренчесен.

Сәгыйт. А юк, булмый. Мин моның белән генә яза алам.

Ильяс. Кызганыч.

Сәгыйт. Гомумән, ике күзлек тоту читен. Юл кешесенә.

Ильяс. Шулай, дөньяда күзлексез яшәүгә ни җитә!

Сәгыйт *(күзлеген тотып)*. Язганда кулай, йөргәндә җайсыз. Кешеләр белән очрашсаң, танып булмый.

Ильяс. Шулайдыр. Кеше урынына күләгә. Баягынак — җиргә төшкәч — юкка сез аны басып сытмадыгыз.

Сәгыйт. Сез нәрсә?! Мин күзлексез эшли алмыйм. Мин — фельетонист.

Ильяс. Юкка фельетонист җибәргәннәр. Безгә шагыйрь җибәрергә иде. Поэма язар иде. Әнә, Җәүдәтләр, Кәүсәрияләр турында.

Сәгыйт *(көлә)*. Ә сез артык борчылмагыз. Дөрес, фельетон чыгар. Көлке булып, усал булып чыгар. Сезне эштән дә алырлар. Ә сез...

Ильяс. Фельетонист булып китәрмен.

Сәгыйт күзлеген сала. Диләра керенә, өстендә плащ, төймәләре төймәләнгән.

Д и л ә р а. Кабинетка керсәгез соң.

С ә г ы й т. Атна-ун көнсез бу эшнең очына чыгып булмас, дип уйлаган идем. Монда бер утырып сөйләшүдән үк ачыкланып тора әле. *(Беренче күзлеген киеп ала. Тирә-якка күз ташлый.)* О, зур эшләр башкарасыз, зур эшләр! Хезмәт колачын киң җәйгән! Поэзия!

Д и л ә р а. Ничек, кармакка эләгерлекме?

С ә г ы й т. Эләкте инде.

Д и л ә р а. Димәк, язып чыгарга уйлыйсыз?

С ә г ы й т. Ә син минем язып чыкмавымны телисеңме? Әйт, теләмим, диген, язмаячакмын. Миңа синең бер сүзең җитә. Бер сүзең! «Кызган Айтугановны» диген, кызганачакмын. «Хәрап итмә» диген, итмәячәкмен.

Д и л ә р а. Менә ничек?!

С ә г ы й т. Айтугановның язмышы минем кулда. Дөресрәге, синең кулда. Коткарсаң, аны син генә коткарып кала аласың. Бер сүзең җитә.

Д и л ә р а. Менә хәзер аңладым мин сезне. Юкса аптыраган идем. Айтуганов өстеннән язылган жалобаны тикшерергә нишләп бу үзе килә, дип гаҗәпләнгән идем. Сезгә галиҗәнаплек күрсәтү кирәк булган икән. Жест! Менә күрегез, янәсе, Сәгыйть нинди олы җанлы кеше, көндәшенең язмышы аның уч төбендә, тели икән, сытып бетерергә кодрәтеннән килә, әмма ул аны эшләми. Кызгана. Үч алмый ул, алдына килеп тезләнсәләр, аңар шул житкән. Сез монда тантана кылырга килгәнсез икән.

С ә г ы й т. Ә шулай да, мин көтәм: бер сүз!

Д и л ә р а. Юк. Әгәр дә Ильяс өстеннән язып чыгарга кирәк икән, шулай тиеш икән, шулай эшли аласыз икән, языгыз. Языгыз, җир белән тигезләгез. Әмма кызганырга уйламагыз. Кемнәрнеңдер кызгануына мохтаж кеше түгел ул!

Сәгыйть икесенә дә баш иеп соңгы сәламен тапшыра да бер сүз дә әйтми китеп бара.

Д и л ә р а *(сөзеп карап)*. Бригадир. Фельетон герое.

И л ь я с. Ә шулай да син Хәербанатка охшагансың. Ул да шундый иде. Туры сүзле.

Дилэра дәшми, җавап итеп, кискен хәрәкәт белән башындагы яулыгын тартып төшерә. Ул чәчен бөтенләй икенче төскә буятып кайткан икән. Ильяс башта аптырап кала, аннан шаркылдап көлеп җибәрә.

И л ь я с. Аңа охшамаска тырышып чәчеңне буяттың?

Д и л ә р а. Элекке хатынына охшатып ярата башламасын, дип курыктым.

И л ь я с. Юкка борчылгансың. Миңа инде кырык яшь.

Д и л ә р а. Шулай шул, картайгансың инде. Кая ул яратырга, йөрәгең кумергә әйләнгән.

И л ь я с. И... Болай син бигрәк тә аңа охшагансың бит. Чәчләре шундый иде, ялкын төсле иде аның. Блондинка.

Д и л ә р а. Ялган! Булуы мөмкин түгел. Мин ка́рточкасын күрдем.

И л ь я с. Бәнаттан алыпмы? Ул карточкасы кышлай төшкән. Бүректән. Чәче күренми. *(Тагын көлә.)*

Д и л ә р а. Аңлыйсыңмы син, мин кемнеңдер күләгәсе булып кына, хатирә булып, кемнедер алмаштыручы, бутафор булып яшәргә теләмим. Үзем булып, үз язмышым белән, үз шатлыгым, үз борчуларым белән яшәргә телим. Кеше яккан учакка ялкын өстәп кенә бара алмыйм. Минем үземнең учак ягасым килә. Үз йөгемне тартырга телим. Яраталар икән, менә шушылай булганым өчен, күзем, борыным кемнекенәдер охшаган өчен генә түгел, Диләра булганым өчен яратсыннар... Ә син фотография белән юанасың. Жәллим мин сине. *(Күзендә яшь. Сузып тавышсыз кычкыра.)* Кыз-га-нам!..

Ильяс. Ай, рәхмәт, кызган, шәфкатьле бәндә, мин синең кызгануыңа мохтаҗ. Ярдәм ит. Өченче бригадага бригадир кирәк, разый бул.

Диләра. Юк! Кетмә!

Ильяс. Дөресен әйткәндә, син Хәербанатка бөтенләй охшамагансың. Ул болай идемени? Шушындый зур эшләр барганда читтә калыр идемени?! Ул аның үзәгендә булыр иде. Бөтен дөньясын онытып, үзе артыннан башкаларны ияртеп! Юк, мин ялгышканмын, синең аңа охшашлыгың юк.

Диләра. Мин охшамаганмы? *(Тиз генә төймәләрен чишеп, плащын ачып җибәрә. Аннан бөтенләй сала. Ул Хәербанат гимнастеркасын кигән булган икән. Хәербанат булып җырлап күрсәтә.)*

Вставай, страна огромная,
Вставай на смертный бой!..

Мин охшамаганмы?

Ильяс *(тынып кала. Бераздан)*. Хәербанат?.. Ни өчен? Кем өчен?

Диләра. Бәнат өчен.

Шамил керә. Башта аптырап кала, аннан аңлап ала.

Шамил. Хәербанат? *(Хәтерләп.)* Очкын кебек, омтылып яши иде. Үзен һич аямас иде. Кайда авыр, ул шунда.

Диләра башлап җибәргән «Изге сугыш» җыры үсканнән-үсә бара. Ул аларның күңелләрендә яңгырый.

Шамил. Кара, чыннан да син аңа ничек охшагансың. Төсең дә, киемең дә.

Диләра. Кием охшау, каш-борын охшау гына нәрсә ул. Мин аңа эчке дөньям белән охшаганмы? Юк бит. Аңа охшарга миңа бик күп кирәк әле. Аның эчке матурлыгына. Әй теләр идем!

Шамил. Әгәр дә хәзер Хәербанат исән булып, безнең арадагы хәлләрне күрсә, ни дияр иде? Икебезне дә тотып яңаклар иде. Әйе... Нәрсә дияр иде минем турыда Хәербанат?

Ильяс. Мин сине танымыйм, Шамил, синме бу, дияр иде. Иптәшең өстеннән жалоба язарга керешкәнсең, яла белән туена башладыңмы? Шундый түбәнлеккә төшәрсең дип уйламаган идем, дияр иде.

Шамил. Нәрсә?! *(Каршына килә.)* Син мине кемгә исәплисең?

Ильяс. Ышанган идем мин сиңа. Кеше дип караган идем. Ә син...

Шамил. Сукыр! Моннан соң мин синең белән сөйләшү түгел, кычкырышмаячакмын да. Әйтер иде сиңа Хәербанат: тинтәк, дияр иде, Низами эшен Шамилгә сылтыйсың, дияр иде.

Ильяс. Низами?

Шамил. Мин кизәнеп кенә калдым, ә ул сугарга да өлгергән.

Еракта — болыт тезмәләре артында кызарып кояш байый. Басу юлы буйлап узып баручы тракторларның фараларыннан сузылган яктылык тасмалары кырларны айкый. Җыр үсканнән-үсә бара.

Диләра. Әгәр дә Хәербанат хәзер исән булса, әйтер иде: Диләра, дияр иде, өченче бригада сине көтә, дияр иде.

Шамил *(моны көтмәгән иде)*. Нәрсә, нәрсә?!

Диләра. Эшкә алынгансың икән инде, ярыл, шартла, теләсәң нишлә, әмма эшең җиренә җиткерелгән булсын, дияр иде.

Шамил. Диләра!

Диләра. Эш өчен кирәкле урынга алыну — төшү түгел, күтәрелү ул, дияр иде!

Шамил *(тагын Ильяска борыла)*. Болай булгач, кычкырышырга туры килә. Ю-ук, кычкырышам мин синең белән. Сугышам!

Ильяс *(авызы ерылган, басуга күрсәтеп)*.

Идет война народная,
Священная война!..

Җыр ерагайганнан ерагая бара. Авыл өстендә йөзә бу җыр. Караңгылык куера. Бераздан урамнарда электр утлары кабына. Күз алдында юллар ачыла. Калкулык. Чишмә буе. Зәңгәр кич. Берәү дә юк. Менә яр өстендәге юлда Лемара күренә. Салмак кына атлый. Аның артыннан, беркадәр ара калдырып, Җәүдәт килә. Кулында гармонь, әмма уйнамый, авыз эченнән генә ярым җыр — ярым речитатив хәлендә шигырь әйтә.

Җәүдәт.

Зәңгәр кичләр буе көтәм сине,
Көтәм сине, ник һаман да килмисең син?
Зәңгәр кичләр буе эзлим сине,
Эзлим сине, кайда соң син, нинди соң син?

Йөрәгемә тулган хисләремне
Җырга салып бер туйганчы сөйләр идем.
Зәңгәр күкнең бөтен йолдызларын
Синең килгән юлларыңа сибәр идем.

Куперне әйләнеп чыгалар. Тукталмыйча, бара-бара сөйләшәләр, ләкин бер-берсенә якынаймыйлар.

Җәүдәт. Бергә тора башлагач, шатлыкны да, кайгыны да уртаклашырбыз.
Лемара. Минем кайгым юк.
Җәүдәт. Бергә тора башлагач булыр әле.
Лемара *(бераз баргач)*. Бүген төш күрдем.
Җәүдәт. Я?
Лемара. Тәрәзәмә килгәнсең. Чиртәсең. Ачтым.
Җәүдәт. Шуннан?
Лемара. Сине кочакларга, үбәргә телим, имеш.
Җәүдәт. Я, я, шуннан-шуннан?
Лемара. Әтәч кычкыруына уянып киттем.
Җәүдәт. Каһәр суккан әтәч!

Күмеләләр. Марсель күренә. Икенче якта Бәнат.

Марсель. Нишләп йөрисең?
Бәнат. Әтине эзлим. Ә син?

Икесе дә бер-берсенә карашып алалар да тынып калалар.

Марсель. Сез китәсез икән инде. Совхоз үзәгенә.
Бәнат. Китәбез.
Марсель. Син дә?
Бәнат. Мин дә.

Җиргә текәлеп тик торалар.

Марсель. Ерак.
Бәнат. Ерак.
Марсель. Хәерле юл.
Бәнат. Рәхмәт.

Тагын торалар.

Марсель. Исән бул.
Бәнат. Сау бул.

Торалар.

Бәнат. Йолдызлар. Сөйләшәләр.
Марсель. Нәрсә диләр?
Бәнат. Кич нинди матур диләр. Бәнат, диләр, Марсель, диләр, әй кешеләр, диләр, без сезне югарыдан күзәтеп торабыз, сез дә матур булырга тырышыгыз, диләр.

Марсель. Акыллы йолдызлар икән... Хуш.
Бәнат. Хуш.

Бәнат китә. Марсель аның артыннан озак карап кала.

Марсель *(авыз эченнән генә)*.

Зәңгәр күкнең бөтен йолдызларын
Синең йөргән юлларыңа сибәр идем...

Кайтып китә. Икенче яктан сөйләшә-сөйләшә Ильяс белән Шамил килә.

Шамил. Ну-ну... Кара әле, синең отпускаң үтте түгелме соң? Әйе, үтте. Шулай булгач? Кая, Лемара, шул тирәдә генә йөри иде. *(Карана.)* Хәер. *(Ильясның үзенә, юмор белән.)* Ал кәгазь, утыр, яз! Совхоз буенча приказ. Параграф беренче. «Иптәш Айтуганов Ильяс Гаязовичның отпускадан кайтуы сәбәпле, директорлык вазифасын бүгеннән аңа тапшырам». *(Күлә. Машина ачкычын бирә.)* Ал «Волгаң» ачкычын. Әмма шуны бел, мин директор булып торганда, әнә күпме эш башкарылды. Язгы чәчү дисеңме, карусель дисеңме! Двигателе дә табылды. Кешеләр олы юлга чыктылар, күңелләренә канат үсте. Мин директор чакта! Кара аны, темпны төшермә.
Ильяс. Ә Диләра?
Шамил. Анысын үзара хәл итегез инде.
Ильяс. Рәхмәт. Хәзергә! *(Китә башлый.)*
Шамил. Ә тр-тр?

Ильяс мотоцикл ачкычын бирә. Үтеп китәләр. Бераздан Диләра күренә. Каен төбендә туктала. Кемнедер көтә.

Диләра. Ул килмәде. Шушы минутта минем биредә икәнемне, аны көтеп торганымны ул белә бит. Нишләп килмәде соң ул?.. Ә шулай да бу минутта ул минем турыда уйлый. Уйлый, уйламый булдыра алмый. Үзе килмәсә дә, аның күңеле килә. Килми кала алмый, килә!.. Ул килмәде. Юк, ул килгән булырга тиеш. Башкача булырга мөмкин түгел. Юк, ул биредә. Йөрәгем шулай сизә. *(Кискен.)* Ильяс, чык. Син биредә, чык! Яныма кил.

Каен артыннан Ильяс килеп чыга. Костюмын Диләра җилкәсенә сала. Диләра сисканми дә, борылып та карамый.

Диләра. Без хәзер сиңа кайтабыз.
Ильяс. Минем белән юл авыр булыр. Уйладыңмы?
Диләра. Җиңел юл эзләмим.

Пәрдә.

*Шәйхи Маннур*

# МУСА

## Роман [1]

### II

Рәфикъ артыннан ишеген биклап керде дә чишенеп койкасына ауды. Аның тәне дә, җаны да арыган иде, тизрәк йоклап китәсе килде. Әмма көенечле фикерләре ирек бирмәде. Менә бит ул ничеккә әйләнде: оешмада тагын бер кеше арта дип торганда, ике кеше юкка чыкты. Исрафилев үзенең ышанмавы белән җилкенчәк күңелле Рәфикъны да аяктан егып ташлады. Андый чайкалучан кешеләргә, әлбәттә, таянырга ярамый. Яхшы әле, икесе дә ачык әйттеләр. Эчке уйларын яшереп калып, тегеләй-болай гына ризалык биргән булсалар, шайтан белсен,ниләр килеп чыгуы мөмкин иде... Кайда соң бу Нәзир, нигә һаман күренми ул? Менә ул булса, болай баш тартмас иде! Юк, тизрәк күрешергә, сөйләшергә кирәк аның белән!..

Төн урталары узганда Алиш белән Гаянов редакция эшеннән кайтып керделәр. Муса, тизрәк йоклап китәсе килгәнлектән, үзенең уяу ятуын сиздермәде. Гаянов барында әллә ни сөйләшер сүз дә юк, бик мөһим яңа хәбәрләре булса, үзләре әйтерләр тагын. Ләкин алар да чыш-пыш килеп кенә чишенгәләделәр дә урыннарына чумдылар.

Фәтхи Гаянов аларга Казаннан ук таныш иде. Ул полиграфия буенча административ урында эшләп йөрде. Анда чакта партбилеты да бар иде шикелле, хәзер дә андый-мондый тайгак сыйфатлары беленми сыман. Әмма шулай да Муса аңа үзенең эчке серләрен ача алмады. Ул Гаяновның калтыранып торган бала йон баскан ябык чыраена, нindидер суык ялтырау белән калайланган яшькелт-соры күзләренә, башына сыланган сыек кара чәчләренә, күләгә шикелле җансыз, сүзсез хәрәкәтләренә, берәүгә дә катнашмый һәм баш күтәрми немецчадан тәрҗемә итеп утыруына ике-өч көн карап йөрде дә ныклап бер фикергә килде: юк, бу кешегә ачылырга ярамый! Ни өчен? Ни өчен икәнен, бәлки, Муса беркайчан да ачык кына әйтеп бирә алмас иде. Нindидер бер эчке сагаю көче кушкандыр, күрәсең. Үз уен Алишка да аңлатты һәм ачылмаска киңәш бирде.

— Үзе бик әйбәт кеше сыман күренә ул,— диде Абдулла.— Тик әллә ничек җансыз шул, тере мәет шикелле. Дөньяң янып көл булса да, һич нигә исе китмәс төсле...

Менә шул сәбәпле аларга өчәү бер бүлмәдә яшәве бик кыен, һәрвакыт сагаерга, яшеренергә туры килә иде. Кем белсен, бәлки күзәтергә куйганнардыр аны? Ә бәлки, бер тиенлек тә гөнаһсы юктыр? Нишлисең бит, кеше карбыз түгел, пычак белән ярып карый алмыйсың...

Иртәгесен иң элек Муса торып, урыннарын рәтләде дә юынырга чыгып китте. Аннары Гаянов белән Алиш та кухняга юнәлделәр. Ләкин

[1] Дәвамы. Башы 5—6—7 саннарда.

Алишның кранда гына юып эләсе кулъяулыгы бар икән. Ул шуны алыр өчен кире кереп китте. Ул ара да булмады, чәчен тарый-тарый Муса килеп керде.

— Дөрес йөрисең,— дип пышылдады Алиш, яулык актарган булып.— Мин юри борылдым, сүз бар: Яуш үзенекен теләнгән. Шәфи аңа 30—40 кеше охран бирергә булган. Вустраудан озакламый шунда китәчәкләр. Чара кирәк...

Сүз шунда бүленеп калды. Ишекне тавышсыз гына ачып, Гаянов килеп керде. Алиш, бусагада аңа каршы бәрелә язган сыман итеп, чыгып китте. Мусаның күзәтүенчә, Гаянов берни дә сизмәде булырга тиеш.

Аларның бүгенге ач паек ипиләре кичә үк ашалып беткән иде. Имән чикләвегеннән көйдерелгән кофе сыман нәрсә кайнатып, берәр стакан эчтеләр дә чыгып киттеләр. Алиш баскычтан җырлый-җырлый төште:

Кайгырма син ипи юклыгына,
Иписез дә бик шәп торырсың.
Ныграк кыс билдә каешыңны,
Зифа буйлы солдат булырсың!

Алиш тарафыннан чыгарылган бу гади тезмәне алар, ашарларына юк чакта хәсрәтле көлемсерәү катыш тавыш белән, «Эшче» операсындагы Нигъмәт ариясе көенә җырлыйлар иде. Бүген дә шулай булды: урамга чыккач кына җырлап бетерделәр дә:

— Нигъмәт ариясе,— дип куйды Гаянов.

— Габәши музыкасы,— дип көлде Муса.

— Сүзләре легион солдаты — ач шагыйрь Фәлән Фәсмәтәнскинеке,— дип тәмамлады Алиш.

Юллары озакламый аерылды. Алиш белән Гаянов Кохштрасседагы «Дойчеферлаг»ка киттеләр, газета редакциясе шунда иде. Муса Берлинның көнбатышынарак юнәлде: «Идел-Урал» комитеты Нюренберг урамындагы 14 нче йортка урнашкан иде. Ул шактый күңелсез чырай белән үз урынына кереп утырды, өстәл астыннан ниндидер кәгазьләр чыгарып куйган булды, алардан нәрсәдер эзләде, нидер сызгалады да, карандашын өстәлгә ташлап, уйга калды. Кулында кодрәт булмауга һәм үз эшләрен тизрәк җәеп җибәрә алмауга борчыла иде ул. Чынлап та, тиз арада оешманың беренче утырышын җыярга һәм көчле пропаганда эшен башлап җибәрергә кирәк, ә кешеләр җитәрлек түгел, күздә торкан ике кеше юкка чыкты, башкалар табылмаган. Артык бәйрәмчә яшәргә өйрәнелде бугай ахры! Җитмәсә, ул кырык кеше белән нишләргә? Кулыңда кодрәтең булса, аларны җибәрмәү бик җиңел булыр иде. Татар егетләренең махсус ялланган полицай булып, полякларны изәргә баруына ничек түзеп тору мөмкин? Әмма чара юк. Шәфигә алтын белән түли Яушев. Шулай булгач, ул акча кортын бу ниятеннән кире бору — мөхаль бер эш. Егетләрне анда җибәрүдән тотып калып булмаячак. Димәк, башка юл кирәк... Уйла, Муса, уйла!

Уйлый торгач, ярыйсы гына сыман бер хәйлә табылгандай булды, һәм ул Шәфи кабинетына кереп китте. Президент буласы кеше, бик ләззәтләнеп, каурый белән теш казып утыра иде. Мусаның сәламенә җавап биреп, урын күрсәтте.

— Хикмәти хода,— диде ул каурыен күкрәк кесәсенә кыстырып.— Ни сәбәптәндер тешләр сирәгәя бара, араларына ит тула. Шуларны чүпләмәсәң эч поша.

— Шулай инде ул, әфәндем: сезнең тешкә керә, безнең төшкә керә...— диде Муса.

— Ничек алай?

— Шулай. Чөнки без ит ашамыйбыз.

— Һәй, тел бистәсе,— дип куйды Шәфи кәефе килеп.

Муса үз йомышына күчте:

— Мин монда килдем дә оя баскан каз булдым, өстәл артыннан чыкмыйм,— диде ул.— Мәдәни агарту эшләрен рәткә салып җибәрергә вакыттыр ич?

— Әлбәттә, әлбәттә,— дип җөпләде Шәфи.— Вакыт, вакыт.

— Алайса, мин башта Вольһайде, Даргибель, Вустрау кебек бәләкәй лагерьлардан йөреп кайтыйм, андагы хәлләрне күрим. Аннары Польшага, легионның төп лагерьларына китәрмен. Иртәгә юлга ниятләнәм. Тиешле командировка кәгазьләре бүген үк ясатылса, юл хәраҗәте дә җайланса, яхшы булыр иде.

— Бик һәйбәт. Ниятегез изге күренә,— дип риза булды Шәфи олы кешеләрчә генә.— Кирәк, кирәк. Мәдәни эшләр безнең мөселман арасында гөрләп барсын. Ярый, сөйләшермен, әйтермен, әзер булыр.

Муса үз бүлмәсенә канатланып чыкты. «Бай йомышын йомышла, үз эшеңне онытма!» Ибраһим абыйсы байлар йомышы белән чапканда энеләре әйтә торган иде бу сүзне. Мусаның да төп нияте шул иде. Ул иртәгесен үк Вустрауда булыр, андагы егетләр белән ничек тә җаен табып сөйләшер, аңлатыр. Бәлки, аларны Позananьга баргач палач роле уйнаудан коткару мөмкин булыр...

Өстәл артында утырган Мусаның кәгазь кыштырдатып бер эш тә эшлисе килмәде, һаман үз планнары белән мәшгуль булды. Ниһаять, төшке тәнәфескә звонок бирделәр. Муса коридорга чыкты. Төрле ишекләрдән күләгә төсле кешеләр күренә башлады. Шәфинең бу шомлы оясында байтак кына көртлекләр утыра иде, аларның кайсы нишләгәнен белеп бетерү дә мөмкин түгел, чөнки эшләр шулай яшертен корылган. Көртлекләр үзләре дә ул хакта күп көркелдәргә яратмыйлар. Шул төркем белән ул да парадный баскычына юнәлде. Каршыдагы караңгырак коридордан килүче ниндидер таныш сыман бер фигура күзенә чалынды. Муса аны, баскыч яктысына таба килгәч, танып алды да:

— Нәзир, исәнме! — дип кычкырды, һәм куанычы йөзенә балкып чыкты. Чөнки бу аның якын дусты һәм бик-бик кирәкле кеше иде.

— Я, шулай итеп, син дә монда килдеңмени?..

— Килгән булдым инде шунда...— дип, әкрен һәм сүлпән тавыш белән генә җавап кайтарды Нәзир.

Муса аның мондый хәләтенә игътибар итмәде, чөнки ул әле һаман үз куанычы тәэсирендә иде.

— Әйдә, тәнәфес ич, берәр җиргә кереп, ашап алыйк, сөйләшеп тә утырырбыз, сине күрмәгәнгә биш былтыр бит инде,— дип көлде Муса һәм, аны җитәкләп, түбәнгә йөгерде. Урамга чыккач, ул аның йөзенә карап алды. Бәләкәй генә йомры башлы, шундый ук бәләкәй битле, нечкә муенлы, болганчыграк яшькелт күзле, Мусадан әз генә калкурак, чандыр гәүдәле бу кеше аның балачак дусты, бер үк шау-шулы чорда үскән иптәше Һадиев иде. Муса аның белән Вустрауда чакта бер генә тапкыр сөйләшеп утырды. Сүзләре күбрәк Оренбургта үткән яшьлек, Хөсәения мәдрәсәсендәге көннәр турында булды. Исләрендә калган кызыклы вакыйгаларны хәтерләп алдылар. Аннары, хәзерге хәлләренә күчеп, кара язмышларыннан зарланыштылар, гаиләләрен сораштылар. Ул чактагы сөйләшүдә Муса үзенең төп ниятен әйтеп өлгермәде. Хәер, ашыгуның кирәге дә юк иде. Бүтәннәр белән фикер алышып бетерсен, оешма әз генә гәүдәләнә төшсен, аннары Нәзирне куандырыр. Ике якын дус, икесе дә партияле, берсе галим, берсе шагыйрь, идеаллары бер. Һәм алар бик тиз арада бергә-бергә җиң сызганып эшли башларлар!..

Шуннан соң алар байтак вакыт очраша алмадылар. Нәзир каядыр югалып торды. Вольһайде лагерендагы утыз-кырык татар әсиренә лекция укырга җибәрелгән, диделәр. Булыр да шул, Казан вузының доценты ич Нәзир, галим кеше. Аннары Мусаның Берлинга күчүе, фатир таба алмый йөрү көннәре башланды, Һадиевны ул һаман күрә алмады.

Менә бүген инде алар барын да аңлашырлар, Муса үзенең төп серен ачкач, Нәзир бик сөенер һәм аның белән бергә көрәш мәйданына ташланыр!

Сөйләшеп бара торгач, Муса аны тар тыкрыктагы гади генә бер кафега алып керде. Ярым подвалга урнашкан чиста гына бу ханәнең бер өстәлендә ике генә немец солдаты сыра чөмереп утыра иде. Мусалар алардан ерактагы почмак өстәлне алдылар.

— Гадәттә бу куыш аулаграк була,— диде Муса.— Безнең ише әләмәтрәк комитетчылар бу тирәдә йөрми. Хәрби алманнар күп очракта куркыныч түгел: алар, таш багана шикелле, зыянсызлар, чөнки безнең телне белмиләр.

Карт кына официант килеп, икесенең дә көндезге аш талонын алып китте. Муса, әллә кайчангы сүзен дәвам иттергән шикелле, турыдантуры үз фикерләрен әйтергә тотынды. Тавышын күтәрмәскә, салкын сөйләргә тырыша иде ул.

— Менә шулай, Нәзир туган, мондый үләмәт хәлендә яшәп булмый,— диде.— Без көрәшкә чыгарга тиешбез. Чыктык диярге дә ярый инде. Оешып бетеп киләбез. Моңарчы күрә алмавым гына бу хакта сиңа алдан ук әйтергә мөмкинлек бирмәде. Хәер, синең бу эшнең үзәгендә булачагыңа һичбер шөбһәм юк. Үземә ышангандай ышанам мин сиңа һәм үземнең иң якын таянычым саныйм...

Нәзир тирән итеп сулыш алды. Моңарчы да төссез күренгән бәләкәй йөзе, тагын да сүрелә төшеп, сорыланып китте. Бик озак эндәшмичә утырды. Аның болай телсез калуына Муса гаҗәпләнеп куйды. Әллә алдан ук әйтмәгәнгә үпкәлиме, әллә Муса үз ниятләрен аңлатып җиткерә алмадымы? Юк, үпкәли торгандыр, нәрсәсе аңлашылмасын аның!.. Шулай да легиондагы меңнәрчә кешеләрнең фаҗигале язмышын, аларны коткару эше фәкать үзләре өстендә генә икәнен сөйләп китте.

— Болар Корыч каланы алулары һәм Каф тауларына барып җитүләре белән мактанганда, без тыныч кала алабызмы? Без шул һәлакәт каршындагы газиз илнең аңлы кешеләре, укымышлысы, патриотлары!— дип өстәде ул.

Ләкин Нәзир Һадиевның җансыз йөзендә әз генә дә якты шәүлә чагылмады. Тагын күп кенә сүзсез торганнан соң, теләр-теләмәс кенә авыз ачты:

— Ә «теге як» белән элемтәгез бармы соң сезнең?..

— Кайсы як белән?

— Кайсы, дип... Үзәк белән... Әгәр анда Үзәк калган булса...

Муса шаккатудан шардай булган күзләре белән аңа карады, аскы ирене дә ныграк ачыла төште. Бу аның чамадан тыш нык гаҗәпләнүен, көтелмәгән хәлдән аптырап калуын аңлата иде. «Нәрсә сөйли бу?..» дип уйлады ул, һич нәрсә аңлый алмыйча. Ләкин кабынмады, әүвәлге түземлеге белән генә җавап бирде.

— Мондый эшкә керешкәндә, иң элек телефон корып куймыйлар ич, Нәзир,— диде.— Безнең хәлдә андый эшнең ничаклы кыен булуын үзең дә беләсең. Әмма без аны булдырачакбыз. Иң элек шушы тирәдәге «җеп очларын» эзләп карыйбыз, аннары...

Һадиев тагын бер мышнап, борын аша пошкырып куйды. Нәрсәдер әйтергә теләде шикелле. Ләкин шул чакта кельнер аш китерде. Борчак һәм әрчемәгән бәрәңге салып пешергән эштинең әчкелтем исле җылы пары борыннарны ярып үтте. Моның ләззәтен сизгән ашказаны, оядагы ач бүре баласы шикелле, төрле якка сикергәләп алган төсле булды. Алар йотлыгып ашый башладылар. Берсенең тәлинкәсеннән килеп чыккан дуңгыз күзе белән икенче тәлинкәдән чыккан тишекле танау очы да аларның иштиһасын[1] һәм кәефләрен бозмады.

[1] Аппетитын.

— О, итле аш икән! — дип куйды Муса.— Я, көтәм. Актык сүзеңне әйт тә кул бир! Керештек!

Нәзир тәлинкәдән башын күтәрмәде. Мусага карамыйча гына сулады да әйтеп салды:

— Үзбелдек белән генә башланган эш — кружковщина инде ул. Аңа ышанучы да, белүче дә булмый...

— Без бит кеше белсен өчен түгел, ничәмә мең әсирне мәҗбүри хыянәттән коткару өчен эшлибез,— дип каршы төште Муса.— Кемнең дә булса моны белеп, кәгазьгә теркәп куюының нинди хаҗәте бар? Мондый эшне фәкать яшерен эшлиләр. «Яхшылык эшлә дә суга сал, балык белмәс, халык белер!» дигән акыллылар.

Һадиев тагын мышнады һәм башын һаман тәлинкә өстендә тоткан килеш:

— Юк, Муса, андый вак-төяк эш миннән булмый...— диде һәм бәләкәй битен тагын да яшерә төште.— Мин — әсир. Сугыштан чыгарылган, кулдан корал алынган. Шулай булгач, мин бер якка да катнаша алмыйм...

— Син шаярып сөйлисеңме моны?..

— Юк, чынлап. Ник шаярыйм? Юкка көчәнү генә бит ул...

Мусаның үз колакларына һаман ышанасы килми иде әле. Юктыр, ялгыш ишетәдер, Нәзир каршы киләме соң! Малай чактагы шикелле үрти генәдер ул аны. Менә хәзер көлеп җибәрер дә кулын сузар. Дөрес әйтәсең, дустым, әйе, бергәләп көрәшик! — дияр.

Әмма Нәзир андый сүзне һаман әйтмәде. Саңгырау һәм җансыз килеш калды. Озак көтте Муса. Тик шуннан соң гына:

— Эх син! Котсыз куян! — дип ычкындырды ул, түземлеген җуеп.— Бәләкәй чактагы шикелле бер ярыр идем мин сине хәзер! Юкка көчәнү, имеш! Катнашмыйм, имеш! Ә комитетка килгәнсең ич! Катнашмау шушы буламы?

Нәзир муенын селкеп куйды.

— Мине бит көчләп китерделәр, көчләп куштылар. Әсирне һәрвакыт көчлиләр. Ул — кол. Җиңүче колы.

Мусаның авызыннан аш тәме югалды. Китергән кофены берәр генә чөмерде дә кискен генә урыныннан кузгалды.

— Көтмәгән идем моны синнән! — диде ул ачу белән һәм киң-киң атлап ишеккә юнәлде.

Нәзир аның артыннан чыкты.

— Юк, Муса туган, син ачуланма, кичер,— дип ялынды ул.— Мин сезгә изге теләктә торырмын. Уңышларыгыз өчен куанырмын, кайгыгыз өчен көенермен. Миннән хәер дога сезгә.

— Намаз укып дога кыл син! — дип үчекләде Муса.— Болай аягүрә генә, юмаган ни... белән генә кабул булмас! — Һәм каршыдагы метро бакчасыннан төшеп юк булды. Нәзир, җилкәсен сикертеп, баскан урынында калды. «Һем... Сәер... Мин гаеплемени инде...» дип гаҗәпләнде ул.

Мусаның күзенә ак-кара күренмәде. Ниндидер вагонга немец хатыннары белән кысылып керде дә, кай тарафка юнәлгәнен дә абайламыйча, китеп барды... Тау текәсеннән тәгәрәгән төсле куркыныч һәм ямьсез уйлары, берсе артыннан берсе ишелеп, башын чатнаттылар. Юк, язмыш аннан кычкырып көлә. Аны һаман яңа уңышсызлыклар белән мыскыл итә, әллә нинди кыен хәлләргә куеп, сындырмакчы була, бу эштән күңелен кайтарып, ваз кичерергә тели. Эх, бу каһәр төшкән дөнья нигә шундый суык, шундый ямьсез икән? Үзеңнең балачактан бирле белгән, ышанган иптәшең дә, суга төшкән тавык шикелле, шулай бетәшкәч, шулай ышанмагач, шулай өметсез булгач, башка кем ышансын? Кем сиңа кул бирсен? Кем сиңа тугры юлдаш булсын?!

## III

«Эчең пошса, чык сәхрәгә, сәхрәдә кош моңлана!..»

Мусаның бу җырны авызыннан төшермәгән чаклары шактый еш була иде. Бигрәк тә яшьлек елларында, нинди дер үзе дә ачык белмәгән сәбәпләрдән кинәт кенә моңаю-юксынулар, эч пошулар башланса, авыз эченнән шушы җырны өзлексез көйләргә тотына һәм, кыш булса — чаңгы киеп, җәй булса — электричкага утырып, каядыр еракларга, урманнар дөньясына чыгып югала иде. Ә табигать аны, елның кайсы фасылында гына булмасын, үзенең рәхәт һәм ягерен тынлык тулы кочагын җәеп каршылый, аның уйларына һәм хисләренә, гомумән бөтен кәефенә могҗиз тәэсир ясый. Муса аны үзенең иң якын сердәше һәм күңел юатучысы итеп тоя иде. Еш кына күзәткәне бар хәтта: бер кайгысы булмаган яшьләр дә, җырдагы әнә шул «сәхрә» кочагына чыксалар, канатлы кошка әйләнгән төсле җиңеләеп, очып китәрдәй булалар; аларның көр тавышы, шат җырларыннан дөнья яңгырый; әле гомердә татып карамаган беренче матур тойгылары, ләззәт һәм бәхет тулы мәхәббәт хисләре уяна... Әмма табигать хәсрәтле кеше күңеленә дә искиткеч шифа була. Андый кешенең авыр кайгылары, табигать киңлегендә йөри торгач, кояш нуры төшкән бозлы тәрәзә шикелле, әкренләп эри башлый; күңелендәге әрнүле төеннәр язылып киткәндәй була. Мусаның үз башындагы авыр һәм чуалчык уйлары да, көзге кургаш болытлардай түбәнтен агылып, сиздермичә генә төрле якка тарала, акыл гөмбәзе аязып китә, әле генә борчулы эч пошу һәм сагыш яткан күңел түрләре, әнә шул «сәхрә» киңлекләре килеп кергән шикелле, рәхәт бушанып кала иде...

Бу юлы да шулай туры килде. Нәзир белән әңгәмәсе шундый ямьсез өзелгәннән соң, башка һичкемне күрәсе, сөйләшәсе килмичә, метро базына чумды ул. Метро аны Берлин уртасындагы бер вокзалга китерде. Бормалы баскычтан өскә күтәрелде дә перронга чыгып поездга утырды һәм, ике сәгать узуга, Вустраудә төшеп калды. Дөньяны чәнечкеле тимер чыбыклар белән урап бетерү мөмкин түгел ич. Вустрауның да әле шундый урыннары калган икән. Станция тирәсендәге йортларны узгач, сулда яткан урман сукмагына төште ул. Әлеге авыр һәм ямьсез уйлары аны куа килгән төсле иде. «Кая барсам, кайгы капкыннары — кул-аякны һаман бушатмый,— дип пышылдады ул.— Бу каргалган этләр дөньясы әйбәт кенә кешеләрнең дә әллә нинди әшәке инстинктларын актарып чыгара. Төрле халык кешеләренең милли кылларында уйнап, хыянәтчеләр хәзерли, куркытып-өркетеп агент, шпион ясый. Һадиев һәм Исрафилев ишеләрне «битараф бәрәннәр» сурәтенә кертә. Нинди әшәке җаннар дөньясы бу! Чалт итеп яңагыңа суга да кулыңа прәнник тоттырган була! Менә бит, хәтта мине дә, коммунист икәнемне белә торып, богаудан чыгарды, тамагыма, өстемә бирде. Бакчи, нинди франт мин хәзер: өстемдә һәйбәт күлмәкләр, менә диган зәңгәр бостон костюм, аякта сары туфли, башта яшел эшләпә, кулымда хәтта плащ та бар. Нинди шәп! Кыз янына барасы кияү егетемени! Болар һәммәсе дә аның «яхшылыгы», һәм ул безне шушы «яхшылык» белән миңгерәтергә тели... Хәйләкәр син, немец, нечкә уйлыйсың: аш белән атканга таш белән кем атсын, янәсе. Тик шунсы бар: каян, кем кулыннан һәм нигә шулай бик юмарт коела бу «яхшылык?» Ә моны инде сукыр булмаган кеше бик тиз күрер!..»

Муса атлаган сукмак, карт имәннең җир өстеннән сузылган тамырлары кебек, төрле тармакларга таралып, тора-бара бөтенләй югалды. Ул хәзер сирәк агачлар арасындагы яшькелт-сары үләннәр өстеннән бара башлады. Куе булып үскән вак кыяклы бу үләннәр, үзләренә әллә кайчан инде карт төс кергән булса да, нинди дер бик калын хәтфә палас җәйгәндәй, аякка йомшак, атлар өчен рәхәт булып тоела. Муса бик озак шулай рәхәт кенә атлап барды. Кая барганын да, ни эзләгәнен дә уйламады ул. Көн кояшсыз иде. Күк йөзен пар катыш сыек төтен төсле тоташ

болыт каплаган, ләкин ул яварга-бүселергә торган кебек авырсытып, җилкәгә басып тормый. Көзге болыт булса да, аксыл-көрән чыбылдыгын югары корган җиңел болыт иде. Табигать тын. Әледән-әле узып торган поезд гөрелтесеннән башка, шылт иткән тавыш юк. Гадәттә, көзге урманның бөреле каеннарына җыелып:

«Тим-тим ләй, тим-тим!
Без соң кемнән ким? —
Былбылга без тиң!..»

дип, чыпчыклар мактанышырга ярата торган иде. Монда алар җыры да ишетелми. Сайрар кошлары ни өчендер ташлап киткән бакчага охшый бу урман. Шулай да Мусага начар тәэсир ясамады ул. Гомумән аның баягы ярсу уйлары, яңгырдан соң аккан гөрләвекләр шикелле, әкрен-әкрен тынып калды. Күңеле бушагандай булды. Ноябрь ахырлары булса да, шактый җылымса саф һава аны җиңеләйтеп җибәрде. Ул, үзе дә сизмәстән, «әчең пошса, чык сәхрәгә...»не көйли-көйли, яфраклар җыя башлады. «Табигать — табиб!» дип көлемсерәде Муса. Өрәңге төпләрендәге яфракларның гәрәбә суына манылган төсле үтә күренмәле матур сарыларын һәм биш бармагы биш якка киереп җәелгән уч хәтле зурларын гына җыйды. Өзелми торган кыяк үлән белән бәйләп тә куйгач, бу яфраклар моңарчы һичкем тапмаган нииндидер гайре табигый чәчәкләр букетына охшап китте. Бу гәрәбә чәчәкләр бәйләмен Чулпанына алып кайтыр иде ул... Чулпанына?.. Аңа авыр булып китте. Йөрәгеи нидер чәнчеп алды. Андый авыр уйлардан качарга теләгән шикелле, җәһәт-җәһәт алга атлады. Байтак барганнан соң, колачларын киң җәеп үскән япа-ялгыз ак чыршы янына килеп чыккач, аның тирәсендәге куе үләннәрнең ничектер бигрәк тә саф сыек яшел һәм йомшак күренүенә исе китеп, туктап калды. Шунда ятып, сабыйларча гамьсез бер ауныйсы килде. Плащын җәеп ташлады да өстенә тәгәрәде. Күзләре күккә юнәлде, тик анда бер кызык та юк иде. Күз камаштыргыч саф зәңгәрлекне дә, алтын сөңгеләр тезелгән сыман кояш нурларын да күрү мөмкин түгел. Бөтен күк гөмбәзен сыек төтен чыбылдыгы каплап алган. Уйлыйсы да килми, моңаясы да килми, йоклыйсы да килми. Шулай да рәхәт. Озак-озак итеп ятасы иде шушында...

Әмма кинәт исенә төште: туктале, ул бит бер нәрсәсез чыгып киткән ләбаса! Шәфи әзерлисе командировка язулары да, юл пропусклары да анда калган. Гомумән, ул монда бүген түгел, иртәгә килергә тиеш иде бит. Муса, хәтта сикереп торып, аягүрә басты. Нишләргә соң? Тиз генә кире кайтып китәргәме?.. Кесәләрен капшанып карады. «Идел-Урал»да эшләве турында Розенберг кәнсәләре биргән таныклык кәгазе бар икән. Алайса, шул житәр...

Муса, тынычланып, салмак кына атлавын дәвам иттерде. Әйдә, чүп тә булмас! Ул үзенең ниндидер гаепле һәм астыртын кеше сыман гел сагаеп яшәргә тиешлеген, әллә кемнәр кулында бәйле булуын уйлап, ачы елмаеп куйды. Чынлап та, аның әле үз гомерендә бер генә житди эшне дә яшерен эшләгәне юк иде. Андый эшләр кинолардан гына билгеле иде аңа... Ни өчендер аның күз алдына «Кигәвен» — Артур килеп басты. Муса «Кигәвен» белән үз арасында аз гына булса да ниндидер уртак бер сыйфат бар кебек тоя иде. Аның нәрсәдә икәнен анык әйтүе дә кыен; бәлки, аллаларның изге сурәте тулган мәһабәт гыйбадәтханәдә йөреп һәм табынган булып та, шуларның берсенә дә ышанмаган азат йөрәкле Артур белән фашист чиркәвенә китереп ябылган һәм шундагы аллаларга табынырга мәҗбүр ителеп тә, табынмаган шагыйрь арасында нинди дә булса охшашлык бардыр? Бәлки, шулайдыр, ләкин Муса моны үзе раслый алмас иде. Тик шул хакыйкать: һәрвакыт ике катлы була белергә кирәк. Эчтән янсаң да, тыштан көл. Эчтән көлсәң — тышка чыгарма! Кулыңда гөлләр булсын, куеныңда хәнҗәр булсын!..

Муса ачык лагерьга кич кенә килеп керде. Бик кысмасалар, үзенең документсыз булуын әйтмәскә уйлап, турыдан-туры Хәнәфин торган баракка юнәлде. Хәнәфин, Шәфи Алмазның яшүсмер кызына күз төшереп, хәтта өйләнергә дә өметләнеп йөргәнлектән, хуҗасына һәрвакыт койрык болгап кына торучы Алабай хезмәтен үти иде. Шуңар күрә Шәфи аны мондагы пропаганда курсларына җитәкче итеп куйды. Туган илдә чакта башлангыч мәктәп укытучысы булган бу кеше әсиргә эләккәч бөтенләй сатылганмы, әллә шул кызга кызыгу аркасында гына Шәфи ялчысы булып йөриме,— хәзергә билгесез иде. Шулай да Муса баракның бер башындагы аның бүлмәсенә барып керде: «Этнең оясында булсаң, бүре тимәс...».

Хәнәфин аны якты чырай белән каршылады:

— Исәнмесез, Гумеров абый! — дип күреште.— Әллә безгә лекция укырга килдегезме?

— Була ул,— диде Муса.— Сәгать тапсагыз, укыйбыз. Сезнең монда мәдәни агарту эшләре белән дә танышырга исәп бар. Мин бит хәзер начальник кеше.

— Бик хуп, бик күңелле! — һәм ул, Мусаны ашханәгә илтеп, кичке аш ашатты. Хәтта талон да сорамыйча, каяндыр үзе юнәтте.

Баракның калган өлешендә булачак пропагандистлар белән Яушев заводына китәсе кайбер әсирләр яши, һәм аларга да лекцияләр тыңлау мәҗбүри икән. Үгетләп җибәрмәкчеләр, күрәсең. Муса алар белән сөйләшеп утырды.

— Ничек соң, үзегезне мәдәни яктан агарталармы?

— Агарталар инде, кершән яккан шикелле! — диде берсе.

Элек ябык лагерьда бергә яткан Мулланур Гәрәев та монда икән хәзер. Ул да сүзгә кушылды.

— Агаруның аръягына чыгып барабыз инде,— диде ул.— Караны да ак дип атый башладык...

— Сез дә пропагандист буласыз алайса? — дип сорады Муса аңардан.

— Юк, Муса абый, без Познаньга озатыласы кешеләр. Кайбер лекцияләрдә генә булабыз,— диде ул гаепле кеше сыманрак.— Без бит полякларга охран торасы. Шулай булгач, аларга мәгърифәт чәчеп булмас... Автомат белән чәчсәк — шул җитәр...

Бу сүздән сүрән генә көлешеп алдылар. Барак эченә яңа кешеләр кайтып тула торды. Шулардан бер калкурак буйлысы үз койкасы янында башын кырын салыбрак карап торды да Муса каршына килеп басты.

— Әһә, агайне, тотылдың бит! — дигән булды ул көлеп, һәм Мусага кулын сузды.— Ә сине танырлык та түгел, маскировканы бик нык үзгәрткәнсең!..

Муса шундук хәтерләп алды: Гани Сәләхов фамилияле бу кеше белән Каунастагы алтынчы форпостта бәрәңге чүпләп яткан иде ул. Шпигель чокырыннан соң туйганчы бәрәңге ашап, сахаринлы крахмал кисәлләре белән сыйланганнар иде алар. Аннары юллары аерылды: төрле якка озаттылар. Хәзер Муса аны яңадан күрүгә сөенеп куйды: начар малай түгел иде ул егет.

— Кара, кара, син түгелме соң бу, Гани дускай! — диде Муса, кул биреп.— Исәнме! Сине дә монда китереп тыктылармыни?

— Шулайрак...— дип сулады Гани.— Безне, Миңгали белән, Вольһайдегә китергәннәр иде, шунда яттык. Ә хәзер мәнә монда сөйрәделәр.

— Миңгали дә биредәме соң?

— Юк, ул Вольһайдедә калды. Немес телен өйрәнә. Аны Симаев дигән егет үзенә алырга йөри,— дип җавап бирде Сәләхов.

Алар сөйләшеп киттеләр. Ганине пропаганда курсына китергәннәр, ә аның бер дә ул эшкә күңеле тартмый икән. Познань төркеменә иярмәк-

че була икән... Сәләхов аны почмактагы үз койкасына алып килде. Урыны булмаса, бергә йокларга тәкъдим итте.

Муса рәхмәт әйтте, аны урын түгел, икенче нәрсә борчый иде. Сәгатенә карады. Төнге унбер. Барак кешеләренең ятар вакыты җиткән. Алар йоклар алдыннан бер-бер артлы тышка йөри башладылар.

— Син Мулланур Гәрәевны беләсеңме, Гани? — дип сорады Муса әкрен тавыш белән.

— Монда килгәч таныштык һәм якташлар булып чыктык, ошый ул миңа, иплe егет күренә.

— Алайса, менә нәрсә, дускай,— диде Муса пышылдап.— Сез аның белән төнге өчтә тышка чыгыгыз әле, сүз бар, киңәш бар... Син аңа алдан әйтеп куй. Чамалабрак йоклар.

— Була ул,— диде Сәләхов әзер кешеләрчә.— Чыгабыз аны. Миндә дә юк түгел иде кайбер сүз...

Муса, аның белән хушлашып, Хәнәфин бүлмәсенә керде дә кушетка сыман бер урынга ятты.

— Бик йомшак булмас инде, Гумеров абый,— диде Хәнәфин гафу үтенгәндәй.

— Ничава! — дип куйды Муса.— «Бер кичкә — кер мичкә»,— дигәннәр ич. Солдат мендәре — мылтык төйтәсе...

Бүлмә ярыйсы гына җылы иде. Муса плащын чыштырдатып бөркәнде дә йокыга китте. Ул инде редакциядә эшләгәндә үк үзен теләсә нинди вакытта йоклап китәргә һәм уянырга өйрәткән иде. Аның бу гадәте хәзер бигрәк тә ярап куйды: ачлы-туклы эшләп йөргәндә, буш ара табып унбиш минут черем итсәң, тәндә күбрәк егәр саклана кебек...

Ниндидер эчке «будильник»ның йомры башлы бәләкәй генә чукмары йөрәгеи тибрәтә башлавын сизеп, Муса уянып китте һәм сак кына кузгалды да, һичбер кыштырдаусыз булырга тырышып, ишеккә юнәлде. Тышка чыкканнан соң сәгатенә карады: өч туларга унбиш минут иде. Әле генә җылы урыннан кубарылган гәүдәсенә шунда ук төнге салкын йөгерде. Җилкәсенә салган костюмын киеп, төймәләп алды да читтәрәк торган бер юан агачка сөялде, кәүсәгә берегеп үскәндәй булып калды. Егерме минутлар чамасы көткәннән соң баскыч төбенә бер күләгә килеп чыкты. Як-ягына карангандай селкенеп тамак кыруыннан Муса аның Гәрәев икәнен танып алды, үзе дә тамак кырды һәм агач кәүсәсеннән аерылды. Озакламый икенче бер күләгә дә күренде. Бу ике күләгә аның янына килә башлагач, Муса тагын да читкәрәк китеп, аларны көтеп алды. Утын лапасы төслерәк бер алачык бар иде, шунда килеп сыендылар...

— Мулланур,— диде Муса пышылдап,— син үзеңнең исемең бик матур икәнен һәм аның сиңа кадәр кемнеке булганын беләсеңме?..

Гәрәев, исе-акылы киткәндәй, шаккатып калды: «Ничек инде бу?.. Төнге сәгать өчтә кешене уятып чыгар да аның исеме матурлыгы һәм элек кемнеке булуы турында сораш?..» Шулай да абайлап алды: сыный... әвәрә кылмакчы була... Бераз сәерсенеп торганнан соң:

— Беләм,— дип җавап бирде Гәрәев шулай ук пышылдап,— Вахитовныкы булган...

— Синең туган елың кайсы әле?

— 1918...

— Менә ничек бит. Димәкки, әти-әниләрең белеп кушкан бу исемне?

— Әйе, минем әти укытучы булган.

— Ә беләсеңме, нәрсә өчен үлгән Вахитов?

— Беләм, Муса абый. Имтиханыгыз бик вакытлы. Мулланур Вахитов татар халкының азатлыгы өчен һәлак булган. Мәҗит Гафуриның шигырен дә укыганым бар.

— Ә Мулланур Гәрәев бу турыда ничегрәк уйлый икән?..

— Җавабы ансат, эшләве кыен,— диде егет шактый тын торганнан соң. — Чөнки туган илем өчен үләргә мин дә әзер, ләкин бу шартларда ничек итеп көрәшү юлын белмим...

— Синең җавапларың бик ошый миңа, афәрин, дустым! — дип куйды Муса һәм егетнең кулын кысты. Аннары Сәләховка эндәште:

— Ә синдә нинди уйлар бар, Гани?..

— Син инде, Муса абый, минем холыкны беләсең — гәрәчиерәк,— диде ул.— Мин пропагандистка риза түгел. Познаньга китәсем килә. Аннан поляк партизаннарына юл якынрак бит...

— Юк, син риза бул,— дип кисәтте Муса.— Һәм шушы төркемнең пропагандисты булып Яушев заводына кит. Муллануր белән бергәләп эш башлагыз. Үзегезгә тагын берничә ышанычлы иптәш табыгыз. Беренче бурыч болай: зинһар өчен поляк эшчеләренең зөбание була күрмәгез! Ә Яушев сезне шундый итәр өчен чакыра. Завод полициясен үз татарларыннан — ышанычлы кешеләрдән — куя, янәсе. Моны бөтен төркемгә бик оста гына аңлатыгыз. Тотылмагыз. Поляк эшчеләре — безнең союзник. Үзләре белгәнчә көрәш алып баралар. Тимәгез, юл куегыз. Сез нинди булсагыз, алар безнең татар халкы турында да шулай уйлаячак. Димәкки, сезнең кечкенә төркемнең полицайлык хезмәте дә халык исеме белән бәйләнгән. Онытмагыз моны!

Икенче бурыч: качу оештырыгыз. Аны болай эшләгез: ышанычлы поляклар белән элемтәгә кереп, качарга теләгән егетләрне өч-дүрт кешелек төркемнәр белән поляк партизаннарына озатыгыз. Ахырда үзегез дә качарсыз. Охрана таралсын, Искәндәр Яушев кишер түтәле өстендә утырып калсын!..

Егетләр тавышсыз гына хихылдашып алдылар.

— Я, ризамы сез шуңа? — дип сорады үзе дә елмайган Муса.— Бирәсезме кулыгызны?..

Иң элек аны Муллануր кочаклап алды. Әллә туңудан, әллә дулкынланудан, бөтен гәүдәсе дерелдәп төсле иде аның.

— Риза, Муса абый! — диде ул кайнар пышылдап.— Көчем җиткәннең барын да эшләрмен. Җан аямам! Антым шушы булсын!..

Аннары Сәләхов кул бирде.

— Мин дә риза! — диде ул шулай ук кайнар дәрт белән.— Качасы да булгач, бу эш мине кызыктыра! Ишетерсең, туганкай, без анда кайбер хитри нәрсәләр дә маташтырырбыз әле! Әйтик, завод үзе төтен булып очмагае!..

— Ләкин башсыз кыланмагыз! — диде Муса.— Үзегезне хәрап итәрсез.— Ул аларның икесен дә кочаклап алды һәм якын бер хис белән аркаларыннан какты.— Ышанам сезгә. Хәерле юл!..

Гәрәев белән Сәләхов кереп урнашканчы, Муса бәдрәф тирәләреннән әйләнеп килде дә, ишек төбендә тукталып, эчкә колак салды. Андагыларның гырлап йоклавыннан башка һич тавыш-тын ишетелми иде. Песи адымнары белән генә эчкә чумды.

Иртәгесен Муса лекция укымыйча китә алмады. Курстагы егетләре үзләре килеп үтенделәр. Болай караганда, алар Гитлер Германиясен һәм аның «киң ирек»ләрен мактаучы булып чыгарга тиешле агитаторлар. Ләкин, кем белә бит, мондагы кешенең эчендә һәрвакыт бөгәрләнгән керпе ята. Ак керпеме ул, кара керпеме? — анысын белүе дә кыен. Әмма ничек кенә булмасын, бу адәмнәрнең күңеленә дә кадерле бер орлык чәчеп калдырырга тиеш ул. Бәлки, иң әшәке дигәненә дә бәләкәй генә бер файда бирер. Аның темасы әзер иде: «Татар композиторлары һәм татар музыкасының үсеше».

Салих Сәйдәшев турында сөйләгәндә, «Наемщик» һәм «Кандыр буе» әсәрләренә тукталды. Муса Батыржан һәм Гөлйөзем арияләренең никадәр тирән моң һәм матурлык белән яңгыравын композиторның талантына гына түгел, үз халкын, үз туган җирен яратуына бәйләп сөй-

ләде. Атаклы маршын мандолинда уйнап күрсәтте. Егетләрнең йөзләре балкып китте. Алар, үзләре дә сизмәстән, Мусага кушылып маршны көйли башладылар. Шул чагында лагерь башлыгы Френцель килеп керде:

— Бу нинди концерт? — дип сорады ул кырыс тавыш белән.

Хәнәфин, җитәкче буларак, бөтен формасын китереп җавап бирде:

— Татар музыкасы турында Гумеров әфәнде лекция укый, майн һерр. Бу безнең атаклы композитордан бер иллюстрация.

— Ә мин сезне Кызыл Армия маршы уйныйсыз дип торам.— Френцель елмайган булды.— Ничектер бик шундый тоела!

— Аллам сакласын, мин андыйга юл куяммы соң? — дип өтәләнде Хәнәфин.

Френцель чыгып киткәч, егетләр бик мәгънәле итеп Мусага һәм Хәнәфингә карашып алдылар.

— Шулай да, Гумеров әфәнде, бик мавыкмагыз,— дип куйды Хәнәфин борчылып.

— Хафаланмагыз, — диде Муса тыныч кына. Чөнки, рәсми яктан караганда, лекциягә ачыктан-ачык бәйләнер урын, әлбәттә, юк иде. Андагы һәрбер сүз үлчәп әйтелгән, хәтта явызлар да борын тыгарлык һәм дәлил китерерлек түгел. Әмма шулай да күп кенә күңелләргә гүзәл орлык чәчә иде ул. Муса сүзләре тыңлаучыларда матур хисләр уятып, туган якларны сагындырып куйды. Аңа барысы да рәхмәт әйтеп, озатып калдылар.

## IV

Вустрау читендә егетләрдән аерылгач, Муса кичәге сукмагы белән поездга юнәлде. Аны мондагы эшләренең уңышлы узуы куандырса да, кичәге әрнү күңеленнән китмәгән иде әле. Шундый якын дус булган һәм ышанган Нәзирнең баш тартуын, бер почмакта посып калырга маташуын ул һич кенә дә аңлый алмады. Уйлаган саен ачуы кабарды. Аның өчен хәтта курка башлады. Әллә хыянәтче булырга җыена микән, каһәр суккан өркәк, котсыз куян!.. Ә менә бу гади егетләр, Мусаны Нәзиргә караганда йөз тапкыр ким белә торган кешеләр, аңа ышаналар. Аның белән эшкә тотынырга атлыгып торалар. Эх, Нәзир, Нәзир, белмәгән икән Муса сине моңарчы ныклабрак! Астыртын җан икәнсең син!..

Шул хакта көенеп бара торгач, кичәге матур чыршы төбенә килеп чыкты ул. Анда кичәге гәрәбә яфраклар бәйләме, ташландык бер чүп шикелле, ауналып ята иде. Муса, тукталып, аңа карап торды. Хәтта иелеп кулына да алды. Ул коры яфраклар һаман әле шиңмәгән, алар әле көзнең нindидер үлеп бара торган матурлыгын һаман саклыйлар иде. Ә Муса аларны кичә онытып, ташлап киткән һәм һич хәтеренә дә килмәде. Күрәсең, ул алтын яфракларны кемгәдер сузып, куандырыр кешесе булмагангадыр инде. Күрәсең, андый яфраклар белән юанырдай гамьсез чаклар, әллә кайларда калып, югалганнар. Күрәсең, бу яфраклар шиңгәнче Чулпанкай белән күрешүләре дә мөмкин түгел. Юллар шундый әйләнеч, җиде диңгез кичәсе, җиде сыртлы Каф тавын узасы гына түгел, җиде башлы аждаһаның муенын кисәсе, җитмеш чакрымлы ут күперен үтәсе бар әле. Ерак, һай ерак ул юл!..

Якын тирәдә нindидер бала-чага тавышы ишетелә башлады. Муса, уйларыннан арынып, шул якка күз йөгертте. Ул аларның немец балалары икәнен күрмичә дә белеп тора һәм эчендә аларны читсенү, үз итә алмау хисе барлыгын да сизә иде. Шул чит балалар белән очрашканчы дип, җәһәт кенә үз юлыннан атлап китте. Әмма балалар аны барыбер күрделәр. Күрделәр дә тукталышып калдылар. Муса белән дә гаҗәп бер хәл булды. Аның бала сөяр күңеле шунда ук эреп китте һәм

киң елмаеп җибәрде. Юк, бу балаларны чит күрү, яратмау тойгысы чын булмаган, ахры. Үзләрен күргәч, Муса андый хисне күңеленнән таба алмады һәм аларга табан атлады.

— Гутен таг, ребята! — дип кычкырды ул дусларча тавыш белән.

Малайлар да теләр-теләмәс кенә: «Гутен таг» дип җавап бирделәр. Сыек сары чәчләренә күзләре төсле үк зәңгәр бант бәйләгән бер матур кызчык аны бигрәк тә үзенә җәлеп итте. Муса аның янына килеп, олы кешеләрчә кул биреп күрешеп дә гәрәбә яфраклар бәйләмен аңа сузды. Икенче бәләкәй кызчыкка кесә төбендә калган конфет кисәген чыгарып бирде, сыңар күзен кысып, телен шартлатып куйды. Башка кесәләрен яңадан актарып карады, ләкин берни дә табылмагач, «бигайбә» дигән шикелле, калган балаларга да шулай ук каш сикертеп, телен шартлатып, кул суза-суза күрешкән булып чыкты: «Здрасти-гутен таг! Здрасти-гутен таг!» — дип кабатлады ул. Балалар үзләшә башладылар. Хәтта берсе «Здравствуйте!» дип җавап та кайтарды. Муса гаҗәпләнеп калды. Кара, кара, каян отып алган бу?..

Ул ара да булмады, калкурак буйлы бер малай артына борылды да, кул болгый-болгый: «Дядя Тулиян, коммен зи һир!» [1] дип кычкырды. Муса тагын аптырашта калды. Туктале, нәрсә соң бу? «Дядя Тулиян?» Кем булыр ул? Тукта, тукта: Шпигель лагере... Чокырдаш күрше... Әйе, монда бергә килделәр бит... Шуннан бирле күргәне юк... Ул һаман биредә микәнни?.. Да-а... Ә нишләп болар белән соң ул?..

Эре яфракларын әле һаман да коеп бетермәгән куе куаклар арасыннан Мусага караганда шактый озын буйлы, кара кыл чәчле, әрмәнчә зур борынлы Тулиян үзе килеп чыкты, аның кулында искерәк кенә бәләкәй чыбык кәрзин, эчендә төрле төстәге гөмбәләр тулган иде. Янында тагын бер-ике бала күренде. Ул чыршы төбенә килеп җитүгә, шаккаткан төстә күзләрен зурайтып, буш кулы белән ботына шап итеп сукты да:

— Муса?! Каян, нинди җилләр белән? — дип куйды.

Кочаклашып күрешкәннән соң, хәл-әхвәл сорашу китте. Геһам Тулиян балаларга атлый торырга кушты.

— Син нәрсә, әллә гувернер булдың? — диде Муса көлеп.

— Түгел, болай гына. Алар белән шаярсам, алар белән йөрсәм, күңел ачыла. Яратам бугай, ахры, үзләрен. Аннары шул ягы файдалы— немесчәгә өйрәнәм.

— Синме? Кара син аны! Әллә берәр фрәйләйнгә гыйшкың төштеме?

— Юк, башка мөһимрәк эшләр бар...

Муса Тулиянның күзләренә сорау белән карады. Ләкин Тулиян башка бер сүз дә әйтмәде. Аның да хәзер өс-башы үзгәргән, ярыйсы гына цивильный киемнәр кигән, төс-битендәге ачлык эзләре дә беткән диярлек иде.

— Вустрауда берәр немкага йортка кермәгәнсеңдер бит, алай тырышып немецча өйрәнгәч?..

— Туктале,— диде Геһам Тулиян,— бик сорыйсың да сорыйсың, ә син үзең кем соң? Өс-башың да шома күренә, битләрең дә түгәрәкләнеп киткән төсле, бөтенләй франт булгансың диярлек! Тик мөгез башлы тросточка гына җитми.

— Анысы да булыр әле, фюрер исән булса,— диде Муса җитди сыман төс белән.— Ул мине бик нык кайгырта.

— Юк, шулай да кайда эшлисең, кем булып? — дип сорады әрмән егете гаҗәпләнгән тавыш белән.— Күптән күрешкән юк бит...

---

[1] Тулиян абый, монда килегез!

— Кем дисеңме? Әйтергә дә була: без хәзер милли деятель. Киләчәктә безгә зур урыннар вәгъдә ителгән!.. Рәхмәт фюрер әфәндегә. Күзләремне ачты. Буду служить верой и правдой, рус әйтмешли.

Тулиян беркавым сүзсез торды да кәрзин төбеннән бер учлам нарат җиләге яфраклары тартып чыгарды.

— Менә,— диде ул,— монда да үсә икән... Хәтерлимсең, Шпигель оҗмахында ятканда, синең аякларны дәвалаган идек...

— Булгандыр инде, күптән бит...— диде Муса, андый вак-төякне хәтерлисе килмәгән шикелле.

— Шпигель «комиссиясе»н дә оныттыңмы? Безне чишендереп, яһүд эзләгәнен?..

— Ничек дип әйтим? Барын да хәтерләп, явыз күңелле буласы да килми. Фюрернең хәзерге яхшылыклары үткәндәгеләрне күмеп китә ич...

Геһамның йөзенә бәргән ярсу кан аны бүртендереп җибәргәндәй итте. Ул, утлы күзләрен уйнатып, як-ягына каранды. Балалар шактый ерак киткән, ә тирәдә генә бер кеше дә юк иде. Артына борылды, анда да тыныч иде. Шуннан соң кинәт кенә кәрзинен җиргә селтәде дә ике кулы белән Мусаның якасыннан буып алды:

— Инде тәмам сатылып беттеңмени, эт баласы! — дип пышылдады ул тешләрен шыкырдатып.

— Менә монысы миңа ошый, ичмаса! — дип гыжылдады муены буылган Муса, көлә-көлә.— Яратам шул көчле кешеләрне! Алар кулында, волейбол тубы шикелле, күккә чөелергә дә мөмкин!..

— Шаяртма, дуңгыз! — Аны тагын да ныграк кысты әрмән егете.— Җаның минем кулда!

Ә Муса, көчкә-көчкә генә тын алса да, һаман көлә иде. Аның йөзендә әз генә дә курку заты күренми; әйтерсең, Тулиян аның белән шаяра гына. Геһам моңа аптырап калды. Юри шулай курыкмас булып кыланамы, бу җүнсез? Әллә...

— Җибәр,— диде Муса шул ук гөнаһсыз сыман көлү белән.— Фюрер биргән яңа костюмымның якасын умырып чыгарсаң, мин нишләрмен?

Ачулы доктор теләр-теләмәс кенә кулларын ычкындырды да учларын җәеп чалбарына ышкып куйды. Гүяки аның куллары ниндидер бер пычрак нәрсәгә буялган иде.

— Монысы да шәп! — диде Муса.— Кая, шул кулларыңны үбим әле!

Егет, тагын да аптырабрак, кулларын артына яшерде, Мусаның моңа да исе китмәде.

— Бирәсең килми, дөрес эшлисең! Тик шунсы бар,— дип куйды Муса,— мин дә сиңа кагылган кулларымны чалбарыма сөртимме? Синең өстә дә башка киемнәр ич хәзер?

— Мин синең кебек сатылган җан түгел! — дип җавап бирде Геһам җирәнүле тавыш белән.

— Алай булса, кил, мин сине кочаклап үбим, Геһамҗан! — дип кычкырды Муса һәм, кулларын җәеп, озын буйлы яшь докторның киң күкрәгенә сарылды. Аптыраган Тулиян әле һаман читсенә, Мусаның болай кыланышын һаман аңламый, үзенә якын җибәрергә теләми иде. Муса, шуларның бөтенесенә чиксез җәберсенгәндәй, кинәт көлүеннән туктап, әрнүле тавыш белән көрсенеп куйды:

— Эх, дускай! Кадерле дускай!.. К чорту маску! Буылам!..

Ниһаять, алар аңлаштылар. Сүз белән дә, дәлил һәм антлар белән дә түгел, бу очракта андый нәрсәләр көчсез һәм ышанычсыз иде. Юк, алар бер-береңнең ничек тын алуыннан, ничек күз каравыннан икесе дә саф икәнлекне аңлап алдылар. Аңлашып алгач инде, үзләренең әле генә уздырган көлке кыланышларын онытып, һични булмагандай тату

гына гәпләшә башладылар. Тик Тулиян гына, җирдә чәчелеп яткан гөмбәләрен саклык белән кәрзиненә сала-сала:

— Гөмбәләремне хәрап иттерә яздың, җүнсез,— дип зарланып куйган булды.— Шунда ук туп-туры әйткән булсаң, ярамаган идеме? Менә ничек ватылганнар...

Җиргә чүгәләп, Муса да аңа гөмбәләрен җыешты. Гөмбәләр кәрзингә тулгач, шунда ук йомшак көзге үлән өстенә утырдылар да, Гегам тәмәке тарта башлады.

— Я, сезнең бөек «Идел-Урал» тирәсендәниләр бар? — диде ул.— Мин синең анда эшләвеңне мондагылардан сорашып белдем инде. Ниләр җимертәсез?

— Кавказ тауларын җимерергә җыенабыз,— дип җавап кайтарды Муса.— Мин дә «Әрмән легионы» төзелеп ятуын беләм... Сездә ниләр бар?

— Бездә эшләр кайный! Озакламый Кавказны кызыллардан коткарабыз да, хөрмәтле фюрер кушуы буенча дөньядагы бөтен әрмәннәрне җыеп, Бөек Урарту дәүләте төзибез. Аларны урнаштыру өчен мәңгелек дошманыбыз грузиннарны кисеп чыгабыз. Бөтен җир һәм мөлкәтләре безгә кала. Фюрер үзе шулай вәгъдә итә. Грузин легионы да төзелә. Алар ден дошманнары әзербәйҗаннарны кырачаклар. Әзербәйҗан легионы исә шундый ук ден дошманы булган әрмәнне кырачак. Менә безнең эшләр ничек гөрли, дускаем! Борынгы Варфоломей төннәре, «әрмән-татар суешы» яңадан дөнья шаулатып узачак!

— Шәп, шәп! — диде Муса башын селкеп.— Искиткеч! Болай булгач, сезгә әрмән легионын бик нygытырга кирәк була инде... Бәлки, шул юнәлештә эшләүчеләр дә бардыр сездә, ә?..

Тулиян, зур кара күзләрен кысып, Мусага текәлде. Беравык сынап караганнан соң:

— Ай-яй, күпне белергә телисең! — дип куйды. Аннары, тирә-ягын күзәтеп, ярым пышылдап кына әйтте: — Булса нишләтерсең?

— Нишләтим? Акыл өйрәнермен,— дип көлде Муса һәм үзләренең дә шундый ук эшләр башларга йөрүләрен әйтте. Тулиянның йөзе бөтенләй яктырып китте хәзер.

— Бездә ул «Өченче комитет» дип атала. Әзербәйҗаннарда «Икенче», ә русларда «Беренче»...

— Менә ничек? — дип гаҗәпләнде Муса.— Сезнең алар белән дә элемтә бармы?

— «Остарбайтер»лар аша бәйләнештек. Алар арасында куып кителгән әрмәннәр дә бар. Ләкин рус комитетының төп үзәге Одердагы Франкфуртта булырга тиеш. Берлинда филиаллары гына...

Мусаның күге кинәт җәелеп китте. Әнә ничек икән эшләр! Һәркем кыймылдый, берәү дә, язмышка буйсынып, тик ятмый икән! Болар һәммәсе дә безгә канат! Тизрәк Франкфурт белән табышырга кирәк...

— Алайса, без «Дүртенче комитет» булабыз, исеңдә тот, Гегам дус,— диде ул.— Киләчәктә без тыгызрак бәйләнешербез, иптәшләреңә әйт, элемтәче билгеләсеннәр.

— Хәзергә минем аша, — диде Гегам. — Мин монда врач. Безнең элекке карантинда хәзер — пропагандистлар курсы. Авырулар да ялга һәм дәваланырга килгәли. Легионга китәсе кешеләргә, фюрер сабаклары белән аралаштырып, оеткы салып җибәрәбез. Әлбәттә, сайлап. Үзең беләсең...

— Ә кешеләрне ничек ачыклыйсыз, ничек базып беренче сүзне кушасыз? — дип сорады Муса.

— «Кояшлы Арарат» дигән җыр түгәрәге бар безнең. Кешеләрнең күңелен җыр ачып бирә...

Ерактан балаларның «Дядя Тулиян!» дип кычкырган тавышлары ишетелде. Күрәсең, алар бөтенләй югалтканнар аны һәм авылга ялгыз

кайтып керүләренә ышанмыйлар иде. Тулиян да, Муса да, урыннарыннан торып, аерылыша башладылар.

— Антмы? — диде берсе. — Мондагы сүз монда калырмы?

— Ант! — диде икенчесе һәм, кочаклашып үбешкәннән соң, каты итеп кул кысыштылар.

Тулиян балалар янына ашыкты. Муса аны күз карашы белән озатты да станциягә атлады.

«Кешеләрнең күңелен җыр ачып бирә безгә...». Кызык сүз бу. Дөрес шикелле тоела. Җырны безгә дә легионда киң яңгырату кирәк булыр. Ул бит әле кешене дәртләндерә дә, өмет һәм омтылышлар да уята...

## V

Берлин уртасындагы Александерплацның аргы читендәрәк кафе-ресторан сыман аулак кына бер урын бар иде. Андагы ашау-эчүнең иң шәбе булган «мундирлы бәрәңге»не Алиш ачып, бөтен иптәшләрен дә шунда ияләндереп өлгергән иде инде. Шуның өстенә, шактый тыныч та тагы үзе. Әз акчалы кешеләр генә күренә һәм, озак утырмыйча, алмашынып торалар. Бүген дә Алиш Муса белән Гарифны һәм Фоат белән Әхмәтне шунда җыеп алып килде. Фоатның бүген әллә чынлап, әллә юри генә туган көне булып чыкты. «Мин сезне симез каз итле, өрелемайлы бәрәңге белән һәм шампански белән сыйлыйм!» — дип көлдерде ул. Өстәлгә, буларын бөркеп, олы тәлинкә тулы «чикмәнле бавырсак» һәм ак күбекләре ташып торган нәзек озын сыра бокаллары килеп утырды. Фоат Булатов һәрвакытта диярлек үзен күтәренке күңелле итеп күрсәтергә һәм җор телле булырга тырыша иде. Бүген дә аның авызыннан мәзәк сүз өзелмәде:

— Ишеттегез микән, бер елны Хуҗа Насретдин Казанга килеп чыккан бит, — дип башлады ул нәүбәттәге мәзәген. — Казан Кремлендә йөргәннән соң Сөембикә манарасына менеп, тирә-як матурлыгын күзәтә икән. Моны күреп калган бер хәйләкәр саилче Хуҗаны кызык итәргә уйлаган. Сөембикә манарасы төбенә килгән дә: «Я, Хуҗа әфәнде, сиңа бер гозер йомышым бар иде, төшеп кенә килсәңче!» — дип кычкырган. Хуҗа төшкән. «Тыңлыйм гозереңне, агайне, сөйлә», — дигән. «Менә, Донбасстан кайтып килә идем, семьям авырып бальниска керде, үземнең кесәмне бастылар, — дип тезеп киткән теге саилче. — Бер тиенсез калдым, сәдәкадән рәхим итсәгез лә!..»

Хуҗа тегенең күзләренә карау белән хәйләсен сизеп алган: бер дә инде Донбасстан түгел, ә Казанның киселеп беткән алдар теләнчесе! «Я, тәкъсир, хәлең бик мөшкел икән! — дигән Хуҗа, кайгырган булып. — Кил, зинһар, рәхим ит», — дигән һәм кесәләрен актара башлаган. Берсеннән дә акча чыкмагач: — «Һай, ашыгу бәласе, алтын янчыгымны манара башында калдырганмын бит, томалангыры, — дигән. — Әйдә минем арттан, гозереңне мул итеп үтәрмен», — дигән һәм манара башына менеп тә киткән. Аның артыннан «ах-ух» килеп әлеге теләнче дә менеп җиткән. Караса, бер дә андый-мондый алтын янчыгы күренми. «Я, Хуҗа, кая, бир инде сәдәкаңне», — дигән бу. Шунда инде Хуҗа күккә бармагы белән төрткән дә әйткән: «Син, энем, ходайдан сора, дигән, ул моннан якынрак та, ә миндә бакыры да юк», — дигән. «Алай булгач, ник алдап алып мендең?» — дип бәйләнгән теләнче. «Ә син мине ник алдап төшердең? Шуннан гына да сорый ала идең бит!» — дигән Хуҗа. Шунда бетте. Көлегез, җәмагать, ату мин елый башлыйм хәзер!

Егетләр бокалларын күтәрделәр.

— Әйдәле, Хуҗа әпәнде, — диде Шабаев үзбәкчәләбрәк, — сез, бәлкем, Ташкәнт мосафиредер. Мең дә беренче яшегез тулган көнне кот-

лап тизрәк күтәрик. Юкса, сыра суына, кәртүпнең күбеге шиңә... Яшә мең ел тагын!.. — Чәкәшеп сыра чөмерделәр һәм бәрәңгегә һөҗүм башланды.

— Тупланган кадәребез шушы биш баш хәзергә, — диде Муса, башын бәрәңге өстеннән күтәрмичә генә. Ул Исрафилев, Һадиев, Гыйльфановларның баш тартуы өчен әле һаман бик әрнесә дә, монда алар турында сөйләп торуны кирәк тапмады, ә киләчәк хәрәкәтне ничек башлап җибәрү хакында кайгырткан төс белән дәвам итте:

— Беренче эш — вәгазьгә каршы вәгазь! Кешеләрнең әүвәлге рухын кайтару. Моның өчен күбрәк һәм ешрак «хат»[1]лар чыгару. Без аны «туган ил хатлары» дип атарбыз. «Җырлар»[2]ны Симай «күктән»[3] тота. Хатны язучы — мин. Симай үзенең ике егете белән «карындык»[4]ка сугтыра. Булат белән Шабай аны «аяк машинасы»[5]нда күбәйтәләр. Хатны саклаучы һәм тиешле кешеләргә тапшыручы — Алиш була. «Сәүдәгәр тастымалы»[6]нда бик әшәке нәрсәләр җибәрмәү, анда «умеренный тон» саклау эше дә Алишка йөкләнә. Һәммәгез дә «тегеләр»[7] белән дипломатик шома буласыз. Этне ырлатудан файда юк, тешләп алуы мөмкин, — Муса үз бокалыннан тагын бер-ике йотым чөмереп куйды. Башкалар тәмәке кабызып җибәрделәр. Алиш бәрәңге сыпырды. «Әмма безнең яктагы «Молтан» бәрәңгесенә җитми инде барыбер», — дип, туган як бәрәңгесен сагынып алды ул. Фоатка мәзәк өчен шул җитә калды:

— Теге крәстьян дә шулай дигән бит...

— Ничек? — дип сорадылар аннан, яңа бер мәзәк көтеп.

— Балык бистәсеннән бер агай Казанга килеп төшкән. Үсиядә баржадан карбыз бушатып яталар икән. Бик кызыгып карап торган да, «беткән баш беткән» дип, бер бөтен карбыз сатып алган. Аннары, Идел ярына аякларын салындырып утырып, кесәсеннән чалгы пәкесен чыгарган да, «бисмиллаһи» дип, карбызны урталай ярган. Бакса: карбыз апак! Бик хәтере калган моның. Мескен, башын кырын салып селкә-селкә: «Һәй-й, сәвит дисәң сәвит шул, карбызы да аппак бит! Кая инде ул Микулай карбызларына җитү!» — ди икән.

Егетләр көлешеп алган булдылар.

— Мин аны «кызлар хаты» дип атар идем, — диде Симай. — Хатның беренчесе әзер. Карындык безнең үзебездә. Тегеләр аңа үз вәгазьләрен сугып, аяк машинасында күбәйттеләр. Алар кайтып киткәч, бикле бүлмәне җай гына ачып керәбез дә «Ундервуд»та шул карындыкка үз хатыбызны төшерәбез. Фәйзелхаков дигән егет бармакларын уйната, мин әйтеп торам, Газизов дигән егет сакка баса. Шуннан соң обмотка эченә яки кунычка чорнап тыгып, Абдулла абыйга китерәбез. Калган ягын ул белә инде...

Фоат Булатов комитетта экскурсияләр буенча эшләү белән бергә, немецларның «Тагеблатт» дигән солдат журналын да кечкенә аяк ротациясендә басарга тиеш иде. Шабаев белән икесе бу машинаны бик яшерен рәвештә листовка басу өчен дә файдалана башладылар. Хәзер алар шул хакта кыска гына сөйләп бирделәр:

— Безнең карт әбинең дә әле Урынбурда чакта ук шундый җеп машинасы бар иде. Аягы белән әйләндереп, гел җон эрләп утыра, аннары шуннан безгә бияләй бәйли иде. Хәзер, күрәсең, аның машинасы миңа мирас булып калган, — дип көлдерде Фоат. — Җон җебе чыкмаса да, «кызлар хаты» әйбәт чыга.

Муса яңадан сүзгә кереште:

— «Кызлар хаты»ның әзер булуы бик яхшы. Мин, озак юанмастан, Польшага кунакка җыенам. Шунда матуррак кызларга биргәләрмен.

---

[1] Листовка. [2] Сводка. [3] Эфирдан радио белән тоту. [4] Синтетик матрица. [5] Бәләкәй ротация. [6] Шәфи Алмаз газеты. [7] Немецлар.

Анда татарчасы күбрәк китәр инде, ә монда, «Ост...»лар арасында русчасы яхшырак булыр...— Мусаның бокалы буш иде инде. Калганнар да ялтыратып куйганнар. Кесә төпләрен кырып, тагын берәр бокал китерттеләр.— Монысы кызлар арасында уңышларыбыз булсын өчен! — диде ул. Алар чаң-чоң китереп чәкештеләр, көлештеләр. Мөмкин хәтле шау-шулы күренергә, кыз һәм эчемлек ярата торган мәгълүм егетләр булып танылырга тырыштылар. Үзләре берәр генә йотым чүмереп куйдылар. — Күршеләр дә тик ятмый икән, — дип дәвам итте Муса, кызык сөйләгән тон белән. — Тулиянны беләсез инде, ул сөйләде. Алар хәтта бездән алданрак тотынган булсалар кирәк. Олы күрше [1] «Беренче» дип аталган. Калганнары: «Икенче», «Өченче» дип исем кушканнар. Без «Дүртенче комитет» дип йөртербез инде...— Муса бу сүзләрен сагая төшебрәк әйтте һәм сиздерми генә тирә-ягына карады. Әле кичке күңел ачу вакыты җитмәгәнлектән, залда халык бик аз һәм почмак өстәлләрдә генә иде. — Франкфуртта да кунак буласым килә. Одер буйларында йөрсәм, бәлки, берәр «матур кыз» [2] табып, элемтәгә керермен, дим. Олы кардәшнең «төп төенчеге» [3] шунда, имеш...

Муса әйткәннәр белән килешеп бетмәүчеләр дә булды.

— «Дүртенче...» дип кенә бик коры булмас микән? — диде Алиш. — Берәр шигъри һәм чакыра торганрак исем кирәк иде кебек...

— Юк, Абдулла, — дип каршы төште Шабай. — Аның кычкырып торуында хикмәт булмас. Без бит ниндидер матур сүзләр белән мавыктырырга җыенмыйбыз, тыйнак һәм конкрет хәрәкәт кирәк безгә. Ул исемгә усал күзләр төшкәндә дә артык игътибар итәрлек булмасын...

— Гел вәгазь-нәсихәт белән маташу да ничек булыр икән? — дип куйды Симаев. — Кызыксыз булмасмы?

— Ашыкма, Әхмәт, — диде Муса. — Беренче чор өчен шулай кирәк. Тупланып җитик, колач җәйик, аннары тормыш безгә үзе әйтер.

— Димәк, хәзергә кызлар һәм аларга хат? — дип нәтиҗә ясагандай сорады Булатов.

— Шулай... Кызлар дигәннән, Аккүл тирәсендә күп кенә хатын-кызлар эшли, имеш. Барыбыз да анда өелешеп йөрү килешмәс; күз тиюе мөмкин, — дип елмайды Муса. — Анда, минемчә, Гарифны билгеләсәк җитәр. Калганнарыгыз шәһәрнең башка өлешләренә йөрерсез. Анда да табылыр матур кызлар...

Шул чагында залга Карип Ишбулдин килеп кергәне күренде. Аның астыртын елтыр күзләре тычкан баласыдай уйнаклый иде.

— Ашка таракан төште, егетләр, ычкына башлагыз,— диде Фоат пышылдап. — Тикмәгә йөрмәс бу...

Ишбулдин, елмайган сыман авыз ерып, алар янына килде.

— О, майне фройнде! Кәеф-сафалар хуш булсын, — диде ул, сирәк тешләрен калкайтып. — Үзебезнең чикмәнле бавырсак белән ләззәтләнәсез икән! Бик хуп... Ә мин сине эзли-эзли җаннарым чыкты, Алиш! Бик интересный җиргә чакырганнар иде, үзең дус дигән буласың, үзен әйтми дә китәсең...

— Менә бит, егетләр алып китте, — дигән булды Алиш урыныннан кузгалып. — Сине караштырган идем, тапмадым, тамак та бик ачыккан иде...

Муса да аягүрә басты, китәргә җыена башладылар.

— Кая болай, мин килгәч кенә? — диде Карип гаҗәпләнеп. — Алайса, мин дә синең белән, Алиш.

— Һәй, што син! — дип каршы төште калган егетләр. — Утырыйк әле, Карип дус. Алар гел китә бирсен. Монда да «зер интересант!» булачак...

---

[1] Руслар комитеты.

[2] Белгән-күргән кеше.

[3] Төп оешмасы.

— Озакламый безнең таныш немкалар киләсе, — дип өстәде Фоат, сер итеп кенә әйткәндәй. — Сиңа да бер матурны табарбыз...

— Син миңа карама, Карип, — диде Алиш. — Минем әле алдагы номерның материалларын укымаган, сәркатип кеше бит, үзең беләсең.

Ишбулдинның тиз генә риза буласы һәм Алишны күздән ычкындырасы килмәде. Чөнки бүген иртә белән генә аны Гаптрахман абыйсы пешкәкләп алган иде.

— Жалунияңнән тыш, үзеңә кесә акчасы да жәлләмим, син аны бик хуп күреп аласың да, кабарэларга йөреп, немкалар ботына кызыга-кызыга, үзең эчеп бетерәсең, — диде ул. — Ә инде Алишны сыйларга, аңа да бер майлы немка табып, егетнең эч серенә керергә кулыңнан килми! Болай булгач, нинди хадим син? Юк, жебегән сыер дучмагы!

Ишбулдин өчен бу эш, чынлап та, ярыйсы ук кыен иде. Алишны ул ун елдан артык белә. Казанда чакта дус булып, бергә яшьлек мәҗлесләренә һәм кызлар белән күрешергә йөргән вакытлары да булды. Седельце лагеренда очрашкач та «җан дусым!» дип игълан итте. Алишның аңа бик күп яхшылыклары да тиде... Әмма ләкин Гаптрахман абзасы да бик кирәкле кеше шул. Аннан башка ничек яшәмәк мөмкин? Ул биргән маркылар тукталып калса, легион унтеры жалуниясе белән генә нинди кызыгы бар дөньяның? Бигрәк тә, Берлин шикелле, күңел ача торган урыннары һәм алтын чәчле, зәп-зәңгәр эмаль күзле, шикәр муенлы матур туташлары күп булган бер Европа шәһәрендә акчасыз яшәү — ни дигән сүз ул? Гомердә ике килми бит мондый рәхәт! Шулай булгач, дус-фәлән дип торып булмый инде... Хәер, әллә нәрсәсе дә юк бит. Гаптрахман абыйсы, үзенең кадрларын яхшырак өйрәнү өчен булса кирәк, Алишның ниләр сөйләвен, ниләр эшләвен генә беләсе килә. Шушындый гөнаһсыз нәрсәләр хакында Карип аңа хәбәр иткәләп тора икән, моның нинди гаебе бар? Шәфи Алмаз гестапо түгел лә ул!..

Ишбулдин, вак-төяк эчке борчылулардан шулай арынып, Гаптрахман абзасын берәр шәбрәк яңалык белән сөендерү өчен монда килсә, әнә нәрсә күренде: кабыклы бәрәңге ашап утыралар, адәм көлкесе! Менә сиңа Надпинкертон! Карипнең Шәфигә дә, үзенә дә ачуы килде. Алиш кайтып китә башлагач, тагын да яманрак булып китте. Материал укырга дигән була. Дөрес әйтә үзе, нәләт, ялганламый. Чыгып киткәндә Карип үзе дә күрде: газетка әзерләнгән бөтен материаллар Алиш өстәлендә өелеп калды. Ул укымыйча торып, берсе дә типографиягә китми. Алиш та хәзер Муса белән әллә кая китә алмый, кайтып материал укырга тиеш ул. Бәс, шулай булгач, фәкыйрегез Ишбулдин монда әле бик рәхәтләнеп күңел ача ала! О, теге әйткән фрейлиннары да килеп чыкса? Ә шул утырган арада боларыннан берәр сер дә алып булса?.. Шәп булыр иде!

Алиш белән Муса инде әллә кайчан чыгып киткән, ә Карип, калганнар алдында сынатмас өчен, коньяк китерткән һәм, алар белән чәкәшеп, шушы рәхәт хыялында йөзеп утыра иде. Рюмка артыннан икенчесе, өченчесе күтәрелде. Ишбулдин сәрхушланып һәм юмартланып китте:

— Күтәрик әле, дуслар, әйдә, кыстатмагыз! — диде ул һәм, тегеләр берне эчеп бетергәнче, икенчесен дә кәгеп куйгалады. — Што-то сезнең фәрештәләрегез килеп житми, ә?

Рюмкаларга ирен тидереп кенә утырган егетләр дә борчылган булдылар. «Нигәдер соңладылар, әллә алдадылар инде?» — дип куйды Фоат.

Карип тагын кыстады, хәлләрен, ничек яшәүләрен сораштырган булды. Хәтта үзенең бер мөнәҗәтен дә укып җибәрде. Залда халык күбәя төшкәч, музыка башланды. Карип тагын ишеккә карады:

— Што-то күренмиләр, ә?..

Дөньяда юк немкалар, әлбәттә, килмәделәр. Симаев пошынган кыяфәт белән урыныннан ук кузгалды.

— Әйдәгез, эзләп барабыз, мин аларның торган җирен беләм,— диде ул. Күрәсең, берәр хәйлә белән чыгып таймакчы булды егет.

— Хәзер, хәзер, сабыр ит,— дип мыгырдады Карип, бөтенләй мәлҗерәп төшеп.— Җитешербез. Эчеп бетерик. Кәүсәр шәрабы әр-рәм калмасын!

Шулай тагын берәр сәгать юанганнан соң, алар чыгып киттеләр. Ләкин баскыч төбенә чыгу белән көтелмәгән хәл булып алды: кафега өч немец офицеры кереп килә иде. Унтер киемендәге Ишбулдин кызмача баштан аларга честь бирмичә узып китте. Усал күзле яшь оберлейтенант кире борылды да:

— О, һунд! Нигә честь бирмисең? — дип, Ишбулдинның колак төбенә берне чалтыратып та җибәрде. Карип аркасы белән стенага килеп бәрелде һәм, чайкалып, чак кына егылмый калды.— Җитмәсә исерек!— дип зәһәрләнде обер.— О, швайн! Патруль! — дип кычкырды ул аннары.

Өч минут та үтмәгәндер, беләкләренә чүпрәк бәйләгән ике немец унтеры килеп житте һәм Карипне җилтерәтеп алып та киттеләр...

— Килеште моңа,— диде Фоат метрога кереп барганда.— Үз хуҗалары биетәләр.

— Ничава,— дип көлемсерәде Гариф.— Озак тотмаслар егетне, Алмаз агай тырышыр әле...

Яшерен оешманың беренче утырышы шулай узды.

## ДҮРТЕНЧЕ БАШЛАМ

### I

Бүген якшәмбе булганлыктан, иркенләп йокларга мөмкин иде. Шулай да «шыпырт Фәтхи» (Мусалар аны шундый кушамат белән йөртәләр иде) түзмәде, сәгать җиделәрдә үк торды да, тиз-тиз генә юынып, бик ашыгыч эшле кешедәй чыгып китте. Гадәтенчә, кая барганын да әйтмәде. Хәер, аның әйтмәве, аралашырга тырышмавы яхшырак та иде, чөнки Муса белән Алиш аны һаман өнәмиләр һәм сөйләшергә уртак тел дә таба алмыйлар иде. Муса аның бөтен хәрәкәтләрен үз почмагыннан күзәтеп ятты: «Кем соң бу? Акмы, кызылмы бу карбызның эче?..» Бер уйласаң, мондый сорау үзе үк гаҗәп. Ул бит партияле булган кеше. Ә менә хәзер җаны ачык түгел. Күрәсең, партбилет кына кешенең күңелендә ни ятканын сөйләп бирә алмый икән әле. Бөтенләй чит кеше төсле ич... Ул чыгып китсә, бүлмәнең һавасы иркенәеп калгандай тоела. Хәзер чыгып китүе дә яхшы булды әле. Чөнки Мусалар бүген яңа бер урынга барырга, яңа кешеләр белән танышырга җыеналар иде. Әйдә, белмәве, иярмәве хәерлерәк...

Кайдагыдыр «Аккүл» буенда көнчыгыш эшчеләреннән якшәмбе саен күп кенә кеше җыела, имеш. Анда һәркем ишеткән-белгәнен сөйли, ди, яңа хәбәрләр дә була, ди. Кайберәүләр хәтта үз якташларын да очраталар икән. Күреп кайтырга кирәк. Үз туган илең кешеләре белән бер сөйләшеп утыруы да ни тора бит мондый җирдә. Дөрес, Мусаның күңеле бер дә тыныч түгел. Аңа әллә кайчан инде легионга чыгып китәргә, анда эш башлап җибәрергә кирәк. Ләкин Шәфи һаман тоткарлап килә, икәү бергә чыгарбыз, имеш. Ашыкма, анда әле батальоннарны оештыралар гына, имеш...

Сәгать сигезләр дә тулып җитмәгәндер, ишек кактылар. Фрауны тынычсызлау булса да, кузгаласы килмичә:

— Ачык! — дип кычкырды Муса.

Һәрвакыт басынкы чырайлы, хәтта бер караганда астыртын кеше сыман күренгән Гариф Шабаев белән очлы иякле, ядрә күзле Фоат

Булатов килеп керде. Фоат беренче хәрәкәтләре белән үк, гадәтенчә, уенчак кәефле, шат күңелле булып күренде.

— Э-э, егетләр, — диде ул сузып, — сез һаман әле йоклап ятасыз икән! Кызларның матурыннан колак кагасыз бит! Алиш, тор давай тизрәк! — Һәм барып өстери дә башлады.

Алиш, авыр йокысыннан арына алмагандай, салмак кына кузгалып, идәнгә басты. Майка һәм трусиктан гына булган Муса, койкасыннан ялт сикереп төшеп, зарядкасына тотынды. Фоат команда биреп торган булды. Аннары юынып керделәр. Алишның кәефе шәп түгел иде.

— Нәрсә булды, челемен югалткан чирмеш агай шикелле, һаман исеңне җыя алмый торасың? — дип бәйләнде Булатов.

— Һай, әгәр челем генә булса-а! — дип көйде Алиш үкенечле тавыш белән. — Зуррагы-ы, туганкай... — Һәм ул үзенең төш күрүен, Агыйдел пароходында бик матур гына сәяхәт иткәндә кинәт Өркыясын югалтуын сөйләп бирде. Бар да тын калып һәм моңаешып тыңладылар. Мондый төшнең һәрберенә дә керүе мөмкин иде.

— Шунсы гаҗәп, — диде Алиш, — нәкъ тормышта булганча бит: хәтта балан чәчәге исенә хәтле! Хәтта сандугач сайравы да шулай!.. Без, чынлап та, яшь чагыбызда, бәхетле чагыбызда, шулай сәяхәт кылган идек. Балан чәчәгенең хуш исе шулай исертерлек куәтле иде, сандугачлар да шулай, флаг мачтасына тезелеп баскан кебек, якында гына сайраган иде. Ах, ул сандугачлар минем тормышымның берәүгә дә сөйләнми торган иң кадерле сәхифәләре иде. Тик Өркыяны югалту гына...

Моңарчы шаяртып сөйләү гадәте булмаган Гариф елмаеп көйде:

— Хәрап, дустым, эшең,— диде ул.— Усман мөфтигә барып төш юрат, фал ачтыр. Ул булмаса, үзем генә юрап бирим: Вайсензеегә барасы булганга кергән сиңа мондый төш. Өркыяңның сине ятлар янына җибәрәсе килмәгән, шуңар күрә качып, үзеңне шомга төшергән!

Холкы буенча иң элек Булатов көләргә тиеш иде, ләкин ул да көлмәде. Киресенчә, көрсенеп алды да:

— Эх, егетләр, сез әле бәхетле, сез әле төштә булса да күрә аласыз икән! — дип сүз башлады. — Ә мин менә Сәгадәтемне бер генә тапкыр да күрә алганым юк! Эсфирамны әйтәсе дә түгел инде, ул миннән алты гына айлык булып калган иде. Нәкъ үзем төсле буласы иде. Әллә, мин әйтәм, баткан кешеләр төшкә кермиләр микән? Ә үзләрен бер генә минутка да оныта алмыйм, бер генә минутка да истән чыкмыйлар... Төшкә керсәләр, ичмаса, бер юаныч булыр иде. Иллюзия!.. Әйт әле, Муса, төш гыйльмендә, бәлки, син көчлерәктер, дин мәктәпләрендә дә укыган кеше бит, ничегрәк икән ул?

— Ә син аларны исән дип уйла, Фоат, — диде Муса. — Бәлки, алар, чыннан да, исән котылганнардыр. Күңел түреңдәге иң кадерле урында сакла, алар белән һәрвакыт сөйләшеп йөр, үзеңә зур бер юаныч булыр, көчең артыр һәм илгә кайтып көрешү юлы да кыскарак тоелыр.

— Рәхмәт, агай-эне, әйбәт вәгазьлисең син, — дип көлгән булды Фоат. — Шулай итеп үз-үземне алдаштырыйм әле. Кара диңгез төбеннән Сәгадәтем калкып чыкмасмы, Эсфирамны күтәреп...

Алишның кәефе әле һаман төзәлеп җитмәгән иде, аннан әзрәк көлеп тә алдылар. Бигрәк тә Гариф Шабай, аның белән Седельце лагеренннан ук дус булганлыктан, үзенчә үртәштереп, аның күңелен табарга тырышты:

— Кайгырма, дускай, салындырма борыныңны! Вайсензеедә менә дигән кызлар бетәсе түгел ди. Иң кәттәләрен табып бирербез үзеңә! — диде ул. — Нишлисең бит, син инде Өркыяң өчен, бәлки, әллә кайчан череп туфрак булгансыңдыр. Сугыш. Хәбәрең юк. Плен калганыңны берәү дә кайтып әйтмәгән. Димәк, син үлгән. Ә яшь хатын сине кыяматкә хәтле ничек көтсен? Үпкәләмә син аңар... Мин үземнең хатынга рөх-

сәт биреп киттем: «Алай-болай була калсам, гомереңне заяга уздырма», — дидем. Менә шулай. Кырын тизрәк. Мондый сакаллы бәрәңгеләрне кабул итмиләр ди анда!

Алишның куе сакалы, чынлап та, яңакларын кап-кара итеп тора иде. «Көн саен кырынырга кирәк, шайтан алгыры», — дип мыгырданды ул.

Ишекне дәррәү ачып Әхмәт Симай килеп керде. Керде дә егетләрнең һәммәсенә житез генә күз йөртеп чыкты. Ул нидер әйтергә ашыга иде кебек. Муса гаҗәпләнә төште: аның болай килеп керүе көтелмәгән хәл, чөнки «Аккүл»гә бару турында аңа әйтергә өлгермәгәннәр иде.

Симаев, чынлап та, ниндидер тантаналы тавыш белән юри мишәрчәләтеп сүз уйнатырга кереште:

— И цугынган татар лөхырләре, цуп тә белми ятацыздыр әл-дә сез!.. — диде. — Афләт баскан сезне! Ә дөньяда әләмәт хабәрләр бар, ниндәен красота маршлар уйный!

— Нәрсә бар ул хәтле куанырлык? — диештеләр егетләр.

— Бар шыл вота! — диде Әхмәт жиңүле тавыш белән. Һәм чалбар кесәсеннән ниндидер бөгәрләнеп беткән кәгазь кисәге чыгарды. — Мынавыл, Муса абый! — Кәгазьне аңа сузды. Ләкин шунда ук кире алды. — Йак, сез аннан цуп тә аңламаячак, анда сыйфырлар гына. Үзем сүлием. Баштан ук. — Һәм тагын тегеләргә күзен ялтыратты да:— Бу цугынганнарга ышанырга ярыймы соң? — дип, Мусага пышылдаган булды.

— Үзеңә ышанмасаң да була, но безгә ышан! — диде Булатов. — Бигрәк тә миңа. Сүзең ялган булса, хәзер дөресләп бирермен!

— Беләсезме, ун көн эзләдем мин бу хәбәрне! — диде Әхмәт Симай, кинәт саф татарча сөйләүгә һәм житди тонга күчеп. — Борынгы китапларда гына калган мәгъшука кызның жиде төн уртасында торып, Жидегән белән Иләк йолдыз араларыннан, Киек каз юлы өсләреннән үз бәхет йолдызын эзләгәне кебек, мин дә ун төн буена салкын эфир бушлыгыннан шушы жылы сүзләрне эзләдем. Хәтерлисезме, Фон Менде әфәнде Шәфиләрдәге мәжлестә «Шталинградны алдык!» дип шапырынган иде. Ә минем аңа шул минутта ук: «врешь!» дип кычкырасым килде. Ләкин кычкыра алмадым... Шуннан соң иртәгесен үк сер яшергән эфирны айкый башладым. Үземнең бер ышанычлы егетне ишек төбенә сакка куйдым. Эфирдагы тавышны ерып чыккысыз: әле генә ата чучка чикылдап туктаса, шунда ук шашкын тавыш белән ишәк акыра башлый. Әллә нинди бегемотлар үкерә, әллә ниткән сыбызгылар колакны тондыра. Ниһаять, табам: «Сталинград урамнарында һәр йорт өчен сугыш бара...» Бер дә күңел кутәрер нәрсә юк. Теге каһәрләрнең сүзләре дөрескә чыга, күрәсең... Соңга табарак хәтта: «Сталинград районында... аннан көньяктарак Туапсе, Нальчик тирәләрендә...» дип сөйли башладылар. Минем кәеф, футбол тубы тигән тәрәзә пыяласыдай, кырылып төште. Болай булгач, бөтенләй хәрап икән эшләр, мин әйтәм. Нальчикларга барып житкәч, Сталинград немец тылында калган була инде. Ләкин соңгы берничә көндә фрицлар кинәт авызларына су каптылар, эфирда бүрек чөю бетте: Корыч каланы телгә дә алмый башладылар. Әмма Мәскәү хәбәрләрендә дә «вак-төяк бәрелешләр» генә... Нәрсә икән соң?.. — дим. Ә менә кичә, вдруг шушындый сводка! Безнекеләр 19 нчы ноябрьда Сталинградның төньяк-көнбатышыннан һәм көньягыннан һөжүм башлаганнар. Иң элек сиксән минут буенча меңнәрчә-меңнәрчә туплар артподготовка ясаган. Исегездә тотыгыз: әле сугышлар тарихында мондый күләмдә һәм болайга сузылган туп хәзерлеге булганы юк! Аннары авиация. Аннары танклар һәм пехота бер яктан 30 километр, икенче яктан 20 километр киңлектә фронтны өзеп, һәр ике тарафтан 60—70 чакрымга эчкә кереп киткәннәр!..

— Дөресме синең бу хәбәрең? — дип сорады, нык әсәрләнүдән күз-

ләре тагын да зурая төшкән Булатов. Егетләр бар да Симай тирәсенә җыелдылар.

— Син мине әллә Һеббельс хәзрәтләренең информбюросы дип белдеңме ялган сөйләргә? — диде ул, ачулангандай итеп.— Бүлдермә, май кап, авызыңны чайкап! Дальше тыңла! Дүрт көнлек һөҗүм барышында Калач, Кривомузгинская, Абганерово, Чернышевская, Перелазовск, Погодинский, Тундутово, Аксай дигән шәһәр, станция һәм пунктларны алганнар. Әсирләр саны — 24 мең; үтерелгәннәр саны — 23 мең; кулга төшерелгән орудие — 557; автомашина — 2826; тимер юл вагоны — 1200; пулемет — 2625, төзек самолет 32, төзек танк 35, тагын әллә нихәтле башка трофей алынган. Һөҗүм дәвам итә!

— Да-а-а, — дип куйды Гариф Шабаев, — бу инде, күрәсең, уенмуен түгел, чуен муен, ә!

Симайның бөгәрләнеп беткән кәгазе кулдан-кулга китте. Аны һәрбере үз күзеннән кичереп чыгарга теләде.

— Исегез китмәсен, юри бөгәрләдем, — дип акланды ул. — Янәсе, алай-болай каптыра калсалар, хаҗәт эш өчен кесәгә тыгылган чүп-чар кәгазь генә. Берние дә юк...

Егетләрнең кәефләре кинәт күтәрелеп китте. Алар, үзләре дә сизмәстән, биегәндәй җитез хәрәкәтләр белән бөтерелеп алдылар, килеп Симайны кочаклап үптеләр. «Молодец, кәбәм, олы бүләк алып килгәнсең!» — диештеләр.

— Димәкки, болай булгач, Сталинград юнәлешендәге немецларны ике яктан камап алу башланган, — диде Муса. — Бик шәп. Бирсен ходай, шулай уңышлы дәвам итә генә күрсен! — Аннары ул Алишка борылды. — Өйдә кәгазь бармы безнең, Абдулла? — дип сорады.

— Нигә ул? Бар бугай әзрәк...

— Минемчә, — диде Муса, — бу сводканы һәркайсыбызга күчереп алу кирәк. Басма хәрефләр белән языгыз, кул танырлык булмасын. Ышанырдай кешеләр очраса, шуларга биреп китәрбез. Безне Розенберг әфәнде пропагандистлар итеп тота ич, эш күрсәтик.

Муса, башын түбәнрәк төшереп, маңгай астыннан Симайга карап алды. Ул аны кыюлыгы һәм тапкырлыгы өчен ярата иде. Теге көнне Фон Мендегә каршы нинди хәйлә тапты бит егет. Бүген дә әнә ничек әйбәт хәбәр алып килгән, молодец!

— Мондый егетлегең өчен, Әхмәт, — диде ул, — без сине бер җиргә кунакка алып барабыз, ризамы?

— Ә кая, кая? — дип сорады Әхмәт дәртсенеп. — Әйтсәгез, барам.

— Анысы инде сер. Баргач белерсең...

Алиш, үтмәс пәке белән щетина кырган шикелле, шытыр-шытыр кырына торгач, ниһаять, эшен бетерде.

— Бер тавык суйган хәтле кан бар тамак астында, — дип көлде Фоат. — Бар, тизрәк юын инде!

— Син, Әхмәт, киләчәктә дә шушындый хәбәрләр китереп тор, — диде Муса. — Корыч кала һөҗүмен өзлексез күзәт, син хәзер безнең информбюро!

— Есть, иптәш капитан! — дигән булды Әхмәт шаян честь биреп. — Ватанга хезмәт итәм!..

Ишектә шыпырт Фәтхи күренде. Култык астына ниндидер иске күлмәк кыстырган һәм кулына немец газетасы тоткан иде ул. Бу кешенең песием генә килеп керүеннән кинәт куркып киткән Әхмәтнең күзләре чокыр хәтле булып уйнаклый һәм иптәшләренә карый иде: ишетмәде микән, янәсе.

Муса, шыпырт Фәтхинең газетасын сорап алып, тиз-тиз генә күз йөгертте. Немецлар Сталинград фронты хакында бернәрсә дә язмаганнар иде. Әһә, су капканнар икән... Газетаны кире бирде дә ишеккә юнәлде.

— Я, булдыгызмы, егетләр, әйдәгез! — диде ул, тупсадан атлап.

## II

Вайсензее Берлинның төньяк районындарак икән. Мусалар анда метро белән килеп чыктылар. Гади генә түгәрәк бер күлнең карт каштанлы ярларында күп кенә кешеләр кайнаша иде инде. Алар һәммәсе дә диярлек бер чама киенгән фәкыйрь өс-башлы яшь хатын-кызлар һәм егетләр. Урта һәм олы яшьтәгеләре дә сирәк-мирәк күренгәли. Хатын-кызларның төсләрендә гадәттәге яшьлек чаткылары уйнаган кебек тоелса да, Муса аларның хәсрәт чиккән кешеләрчә боек чырайлы, басынкы булуларын күрми кала алмады. Кайберләренең чәчләрендәге сирәк чал бөртекләре дә ялтырап күзгә чалына иде. Монда Берлинның төп халкы — ыспай киемле, эшләпәле немкалар һәм аларның юан таяклы ирләре яки хәрби немецлар — бөтенләй күренми. Бары тик аллеяларның ике ягында кыркылган агачлар белән берничә почмакка баскан полицайлар гына бу урынның да немец җире икәнен белдереп тора иде. Ярыйсы ук аулак почмак икән бу, дип уйлады Муса. Төрле кыяфәттәге кешеләрнең беркадәр ашыгып, әрле-бирле йөрүенә карагайда, бу урынны ниндидер бер базар дип уйларга да мөмкин, ләкин берәү дә, бернәрсә дә тәкъдим итми, алмашмый, кул сугып сатып җибәрми. Юк, монда кешеләр михнәт сатарга гына чыга икән... Әле берсе, әле икенчесе төрле телдә якташ килеп сорый, тартырга юкмы, ди. Мусалар, шундый ыгы-зыгы арасында икегә бүленеп, гомуми агым эченә кереп киттеләр.

Алиш та бүген, җанын кысып торган гаскәри кабыгын салып ташлап, Муса белән бер очтан киенеп чыккан иде. Алар күл буен әйләнеп, мондагы кешеләрне күздән кичереп килгәндә, каршыларына бер кыз килеп басты.

— Здоровеньки булы, дядьки! — диде ул, әллә кайчангы танышларын күргәндәй елмаеп. — Вы не з Харькиву буте?..

Бу кызга Алишның куе кара кашлары һәм алар астындагы текә ярдан караган коңгырт күзләре, куш ияген матур гына итеп икегә аерып торган җәплекә уентыгы кайчандыр күргән сыман, ничектер таныш сыман булып тоелды. Болар, ахры, украин кешеләре булса кирәк, дип уйлады ул һәм шуңа күрә кыю эндәшергә җөрьәт итте. Алиш белән Муса исә русча җавап бирделәр һәм, кул сузып күрешкәннән соң, сөйләшеп киттеләр:

— Кызганычка каршы, аннан түгел шул, — диделәр. — Сез Харьковтан, украин кызы буласызмыни?

— Алай ук дип әйтмәс идем... Мин үзем Мәскәү тирәсеннән... Техникум бетергәч, Харьковта эшләдем, китә алмыйча калдым... Быел җәен немецлар монда китерде... — Кыз үзенең кызыксыз язмышын күп нокталар белән аралашкан өзек җөмләләрдә генә әйтеп бирде. Бу хакта озын сөйлисе килмәве күренеп тора иде аның. — Болай борчуым өчен гафу итегез... — дип өстәде ул.

— Гафу сорарлык һич гаебегез юк! — дип җавап бирде Алиш, кызны сүзгә җәлеп итәргә теләгәндәй канатланып. — Киресенчә, сезнең сүз кушуыгыз өчен без шат кына! Безнең әле бу күл буена беренче чыгуыбыз. Һичкемне белми идек, ә менә хәзер танышыбыз булды, ичмаса! Исемегез ничек, әгәр сер булмаса? — Алиш менә дигән тапкыр егетләр шикелле, кызның култыгыннан алып, аның авызына, күзләренә карады, аннан җавап көтте, аның сүзләре белән генә мавыгып, алга таба атлады. Муса әкренләп артка калды, ләкин Алиш моны сизмәмешкә салынды. Әйтерсең, дөньяда аның өчен бары тик шушы сөйкемле кыз гына бар! Аның сөйләгәне, сандугач сайравы кебек үк булмаса да, үзе шикелле ирексез бер кешенең тирән аһ-зары буларак кадерле иде. Алар гәпләшә-гәпләшә шактый алга киткәч, Муса аллеядагы зәңгәр эскәмияләрнең бер бушына килеп утырды. Гаҗәп күл буе иде бу: ти-

рәсендә бер бала-чага юк. Бәлки, бүген генә шулайдыр бу? Күл тирәсен шушы михнәт базары сарып алганлыктан, югары мәдәниятле немкалар үз балаларын чыгармаганнардыр? Бик ихтимал. Һәм шул балалар булмагангадыр инде, күл өсте, үз тирәсендә йөргән кешеләр төсле үк, авыр сулышлы, боек чырайлы булып күренә иде. Муса озак карап утырды. Ул инде әллә кайчаннан бирле өзелеп-өзелеп Чулпанын сагына, менә тагын күз алдына кызчыгы килеп басты. Казан читендәге Займище күле комында уйнап яталар, имеш, алар. Нинди рәхәт булган ук чаклар! Хәзер ул көннәрне искә алуы да газап кына китерә...

Бу вакытта Гариф, Фоат һәм Әхмәт күлнең аргы кырыеннан әйләнеп баралар һәм беренче мәхәббәт хикәяләрен сөйли иделәр. Араларында иң озын буйлы Гариф уртага баскан да Әхмәт белән Фоатны, йотылырдай итеп, үз авызына караткан.

— Шуннан?... Шуннан? — дип сорый алар бик кызыксынган йөз белән. — Дәвам ит инде!

Гариф ашыкмый, ияк очына гына үсеп чыккан төкле миңенең әллә кайчан йолкынган бөртеген тырнак очы белән яңадан чеметеп маташкан була, ә төк әләкми дә әләкми.

— Шуннан, — ди Гариф тегеләргә җавап биреп, — мин бу кызга тәмам гашыйк булдым. Минем өчен дөньяда аннан да матур кыз юк. Аның әз генә елмаеп карый торган сыек зәңгәр күзләре, аның тыгызлап үргән алтын-сары толымнары, аның сөйкемле җилкәләре, аның әз генә бөятләнеп килгән бәләкәй генә аяклары мине тәмам әсир итәләр. Мин дәрестә аның артындагы партада утыра идем. Шуңар күрә аның шул алтын толымнарына, шул ефәк чәчләре астыннан әз генә күренеп торган алсу колак яфракларына туйганчы-туйганчы карый идем. Чөнки монда мине оялта торган беркем юк, бер күз юк...

Шул чагында аның сүзен бүлделәр:

— Абыйлар, туктагыз әле! — дип татарча эндәшкән тавыш ишетелде. Егетләр, ялт борылып, тирә-якка күз салдылар. Биек бер карт тирәк төбендә бернечә хатын-кыз басып тора иде. Шуларның берсе боларга таба юнәлде.

— Гафу итегез, — диде ул саф татарча. — Үзебезнең ана телендә сөйләшүчеләрне ишеткәч, түзмәдек, якташларыбызны очратырбыз төсле, танышасыбыз килде... Сез кай яклардан буласыз? Нинди җилләр ташлады монда?..

— Җил генә түгел, сеңеле-ем! — диде Фоат зарлырак тавыш белән сузып. — Шайтан өермәсе, аждаһа давылы!..

Танышып, сөйләшеп киткәч, кызлар да үз хәлләрен кыска гына әйтеп бирделәр: алар Донбассның Макеевка шәһәрендә яшәгәннәр, берсе «Ветка» дигән шахтадан икән. Немецлар монда куып алып килеп, завод эшенә тыкканнар. Снаряд кабыклары шомарталар икән...

Үзара җанлы гына әңгәмә башланды. Бер-бере белән очрашуларына, күптән күрешмәгән туганнар шикелле, бар да сөенештеләр. Егетләр дә үзләренең кай яктан булуларын сөйләп бирделәр. Кызларның күргәнкичергәннәренең бөтен эзләре каш араларына, күз төпләренә генә түгел, яңаклары, ияк аслары, бит түгәрәкләре кебек бер дә кителмәгән урыннарга да «җеп елан» шикелле сарылып яткан иде. Ә күзләре, шул көзге күл өсте төсле боек, моңсу, хәтта җансыз сыман карыйлар иде.

— Бик моңайган сыман торасыз, кызлар, бирешмәгез! — дигән булды Әхмәт Симай, шаян тон белән. — Без бит әле яшь кешеләр!

— Моңаерсың, абый!.. — диде бер олырак кыяфәтлесе. — Үндүртүнбишәр сәгать исле, сөремле цехта баш та күтәрми эшли башласаң... Хәер, безнең хәлләрне, бәлки, үзегез дә беләсездер инде...

— Ә сезнең, абыйлар, өс-башларыгыз бик тәти күренә, — дип куйды Сания исемле иң яше. — Сез әллә... тегеләр... ниләрме?..

— Юк, сеңелем, «ниләр» түгел без!— диде Симаев ашыгып.— Монда Гаптрахман дигән бер татар бае бар икән. Безне ул үзенең фрукты бакчасында эшләтте җәй буе. Шул киендергән булды...— Әхмәтнең шундый кыен чакта тиз генә тапкыр җавап таба белүе бу юлы да бик урынлы булып чыкты. Дөресен әйтсәләр, бу саф күңелле бичаралар шунда ук сөйләшүдән туктар һәм җирәнеп китеп тә барырлар иде. Ә хәзер исә Сания Әхмәтнең бу нәни ялганына шөбһәсез ышанды һәм хәтта ягымлы гына елмаеп та куйды. Аннары үз хәлен сөйләп бирде. Әтисе пенсиядәге карт шахтер булган икән. Санияне Германиягә куа башлагач, каршы төшкән. «Муены астына килсен Гитлерыгызның! Бирмим кызымны!» — дип кычкырган. Картны урамга сөйрәгәннәр дә электр баганасына күтәргәннәр. Әнисе, шул багана төбендә елый-елый, акылдан язган, ә Санияне кызыл вагонга кертеп бикләгәннәр... Кыз, тотлыга-тотлыга сөйләвеннән туктап, кечкенә яулык кисәге белән күзләрен сөртте. Әхмәт Симай, аны ничек юатырга белмичә, янында бөтерелде. «Саниякәй, кирәкми, тынычлан зинһар», — ди иде ул, үзе дә елагандай булып. Ләкин бу яшь кызның бәгыре инде янасын янып, көясен көеп беткән булса кирәк, ул үзен бик тиз кулга алды.

— Юк, мин җыламыйм! — диде Сания, батырайган шикелле. -- Миңамы җылап торырга? Ут булып атылырга кирәк миңа!..

— Саниягү!.. — диде Мәрьям исемле олысы, аны искәрткән тавыш белән. — Хискә биреләсең. Бар, күл буена төшеп, салкын су белән авызыңны чайкап кил, кайнар сүзләрне суытырга әйбәт була ул.

— Гел без сөйлибез дә, без такылдыйбыз, — диде дүртенчесе. — Үзегездә ниләр бар соң, абыйлар? Ил якларыннан хәбәрләр ишетелмиме? Хат-фәлән килгәне юкмы? — Ул үзе генә көлеп куйды. Егетләр арасында олырак күренгән Гариф Шабаевка төбәп мөрәҗәгать итте: — Сез, абый, безгә караганда күбрәк беләсездер. Безнең бер җүнле хәбәр ишеткәнебез юк. Сталинград, Кавказлар киткәнен заводта бик яхшы аңлатканнар иде, ә менә бүген мондагы хатын-кыз әллә нинди имеш-мимеш хәбәрләр сөйләгән була. Һич ышанырлык түгел... Моңаюлар ул якларга да барып тоташа безнең... Мин әле, гел-гел шулай моңая торгач, куана белү гадәтебезне бөтенләй онытмасак ярар иде дип куркам...

— Онытмагыз, былбылларым! Куана белү әле безгә бик кирәк булачак! — диде Шабай олыларча итеп. — Чөнки бик матур хәбәрләр килүе дә мөмкин бит... Без аны сезгә дә ирештерербез...

— Әйе, әйе! — дип дәртләнеп сөйли башлады Әхмәт Симай.— Әле без сезгә «кызлар хаты» алып килгән идек, гыйшкыбызны аңлатып, янәсе... — Һәм ул куен кесәсен актарырга да тотынды.

— Әхмәт дус, — диде Гариф сабыр гына тавыш белән. — Син ашыгасың бугай, ахры. Кызларга язган хатны алай бөтен кеше алдында тапшырмыйлар аны! Әдәп, инсаф дигән нәрсәне яшьләргә дә онытырга ярамый лабаса... Һәр нәрсәнең үз урыны, үз җае бар дигән кебек түгелме?..

Һәммәсе дә көлешеп куйдылар. Симай гына авызына су капкандай шып булды, хәтта кызарып китеп, маңгаенда тир бөртеге дә күренде.

— Ә-ә, әйе шул... — дигән булды ул битләрен сөртеп. — Фу-у, чорт возьми, көн эсселәнеп китте, ахры... — Симай, үз хәлен шундый сүзләр белән яшерергә маташса да, эчтән бик борчылды. «Шушы булдымы синең конспирация саклавың? Көрәшчелегең? Шушы ахмаклыгыңны Муса белсә?.. Юк, шапылдык малай син! Тиле бәрән орлыгы ашаган нәрсә!..» — дип тиргәде ул үзен.

Алар янына тагын ике кыз килеп туктады, болар да татар кызлары иде. Берсенең төпсез түгәрәк күлдәй тирән һәм зур зәңгәр күзләре нидер ягы белән Фоатка үзенең Сәгадәте күзләрен хәтерләткән төсле булды. Янәшә бастырып карасаң, бәлки, охшашлык та юктыр, әмма шулай да ул күзләрнең зурлыгымы, керфекләренең шулай сыгылыбрак ки-

лүеме, әллә каш көянтәсеме — кайсыдыр бер нечкә сызыгы Сәгадәтне искә төшерде. Бу инде сагыну бәласедер, күрәсең. Мәңге күрешмәячәк кешеңне, һаман күз алдыңнан җуя алмыйча, өзлексез юксынудан килә торгандыр... Фоат ул кызның исеме Фәридә икәнен белде һәм аңа сүзсез карап калды...

Ә Гарифның, оясын саклаган лачынныкы шикелле, уяу күзләре якын борылмадагы немец полицаена төбәлгән иде. Ул җирән «фәрештә» һаман бу төркемне күзәтә. Күп җыелып торуларына эче поша булса кирәк, бая бер тапкыр читләтеп узып та китте, тик бәйләнер сәбәп тапмады, ахры — эндәшмәде. Хәзер дә, әнә, күзләрен чәйнектәй итеп болай карап тора. Юк бит, бер генә почмакта да иркен сулыш ала алмыйсың! Күзгалырга кирәктер... Бәбәген киермәсен...

Әхмәт Симайның хат мәсьәләсе белән уңайсыз хәлгә калуына байтак минутлар үтте. Бар да диярлек үзара вак-төяк сүз белән мавыккан булдылар. Әмма кызларның күңелен һаман бер нәрсә кытыклап тора иде: «Нинди хәбәр икән ул?..» Ниһаять, теге олы хатын түзмәде, Гарифка карап, көлә-көлә әйтә куйды:

— Сез, егетләр, безгә конфетыгызның чугын гына күрсәттегез дә яңадан кесәгезгә яшердегез. Кызларны алай алдау бер дә килешми инде ул...

— Ә-ә, конфет яратасыз икән, хуп мәйле, үзбәк әйтмешли, рәхим итегез! — дип җавап бирде Шабаев һәм, кесәсенең әллә кайсы почмагыннан гына чыгарып, Мәрьямгә бер конфет кисәге сузды.

— Фу-у, мондый эрзац кирәкми лә безгә, — дип кире какты Мәрьям назлы тавыш белән. — Аннан әрем тәме килә. Безгә чын конфет кирәк. Бая вәгъдә иткән туган як күчтәнәче...

— Шулаймыни-и? Мин тагы аңламыйча да торам, — дигән булды Шабай. — Аз гына сабыр итегез. Безнең әле тагын иптәшләр бар, әйдәгез, аларны да күрсәтик үзегезгә. Шунда берьюлы күчтәнәчтән дә авыз итәрсез...

Алар, аллы-артлы ике төркемгә бүленеп, күл әйләнә йөри башладылар. Хәзер инде кызларның да күңеле күтәрелеп киткәндәй булды: уен сүзләр дә табылды, елмаю һәм көлү тавышлары да ишетелгәләде. Егетләр артык мавыгып киткәннәр идеме, нәрсә булгандыр, тик Мусаны икенче әйләнүдә генә күрделәр.

— Әнә безнең бер сандугач эскәмиягә кунаклаган, — дип көлде Шабай. — Күрәсезме, ничек моңаеп утыра ялгыз, бичаракай...

Алар бар да Муса каршына килеп туктадылар.

— Карале, Муса дус, без нихәтле якташлар таптык! — дип мактанган булды Шабаев. — Искиткеч гүзәл кызлар!

Муса, Гумеров фамилиясен әйтеп, аларның барысы белән дә күрешеп чыкты. Берлинда шулкадәр якташ кызлар булуына гаҗәпләнде. Кайда һәм ничек яшәүләрен сораштыра башлаган иде:

— Ә без инде аларның җиде буыннан килгән бөтен биографияләрен беләбез! — диде Фоат шаяртып. — Үзебез генә сөйләп бирербез, кич утырып.

— Дөрес, Гумеров абый, мин дә Санияне бик яхшы беләм, — дип сүз кыстырды Симаев, Мусаның каршына ук килеп. — Комсомолка булган, шахтер кызы! Тик әнә Гариф абый гына... — Ул кинәт пышылдауга күчте һәм, шаярган булып, Мусаны читкәрәк алып китте, — хатны һаман бирдерми... Минемчә... куркырлык кызлар түгел...

Муса рәхәтләнеп көлеп куйды.

— Әй, Әхмәт, Әхмәт, синең, чынлап та, йөрәк ялкынланган, ахры,— диде ул, кире борылып. — Әйдә, бирегез, укысын кызлар ераклардан килгән сәламне!..

Симаев Сания янына очып кына килде дә, аның белән күрешкән сыман итеп, кызлар хатыча төрелгән әлеге сводканы учтан учка күчер-

де. Кыз шунда ук агачлык арасына йөгерде. Аның яшь һәм хыялчан йөрәге, күп газаплар кичергән булса да, барыбер үз җилкенчәклеген әле җуймаганлыктан, әллә нинди куанычлы яңалыклар көтте, ул шуларны тизрәк укып белергә ашыга иде. Һәм өч минут та узмагандыр, кабынган чырай белән әйләнеп тә килде.

— Бу, чынлап та, әткәй-әнкәйдән килгән төсле ин кадерле хат икән, абыкаем, честный комсомольски... Ой, ялгыш! — дип авызын каплады ул учы белән. — Һаман өйрәнеп булмый бит шайтан теле белән сөйләшергә...

Сания Әхмәткә сабыйларча гашыйк күз белән карый һәм аңардан тагын әллә ни төрле шатлыклар көтә иде. Ул аны үзе култыклап, тагын йөрергә алып китте.

Бу хатны башкалар да шулай яшерен-пошырын гына укып, иң ышанычлы ерак кесәләренә яшерделәр. Аларның да күңелләре ачылды, инде сүнә язган өметләре яңадан терелде.

— Яхшы кешеләр икәнсез, изге хәбәрләр алып килгәнсез! — дип рәхмәт укыды кызлар.

Көн кичкә авышып бара иде инде. Егетләр кайтырга кузгалдылар.

— Сак булыгыз, кызлар, — дип, тагын бер искәртеп куйды Муса.— Иң белгән, сыналган кешеләргә генә укытыгыз. Кайбер кешеләр белән күзгә-күз генә калып, телдән генә әйтеп бирегез, шаһитсез булсын.

— Шулай итәрбез, абый, — диде кызлар, кул биреп. — Тагын килегез, яме! Без көтәрбез! Бөтенләй җаннарыбыз рәхәтләнеп китте.

Алиш белән теге «украин» кызы әйләнеп килделәр.

— Ба! — диде кыз, матур күзләрен киң итеп ачып. — Минем подружкаларым да кавалер тапканнар икән!

— Син дә йокламагансың икән лә!.. — дип көлде иптәшләре.

Аннары Алиш аны калган иптәшләре белән таныштырды. Кыз һәммәсенә дә, Фая дип, кул биреп чыкты. Муса аны белә иде инде, дусларча шаян сүз кыстырган булды:

— Сезнең серләр бик килеште, ахры, көн буе югалып йөрдегез.

— Яшь чакта була инде ул! — дип, ягымлы күксел-соры күзләрен уйнаклатып алды Фая. — Үзебез ямь-яшел яшьләр, үзебезнең кәефләр шәп, үзебез Европа үзәгендә туристлар, наци могҗизаларын карап тик йөрибез, уртаклашыр өчен впечатлениеләр күп!..

Егетләр яңадан саубуллаша башладылар.

— Әле китәсез дәме? — дип гаҗәпләнде Фая.

— Бүгенгә җитәр, Фаечка, — диде Алиш сабыр гына. — Бәхетле минутлар кыска була, дигәннәр. Тагын килербез әле...

— Киләсе якшәмбегә көтегез! — диде Гариф барысы өчен дә. — Шуннан да калмабыз, шәт иншалла!..

Әхмәт Симай аларны, «ах-ух» килеп, куып җитте.

— Сиздегезме, егетләр, безнең Әхмәтне? — диде Фоат. — Саниягә чистый гашыйк булды бит.

— Кара, Симай, башың әйләнеп, Аккүлгә тәгәрәмәсен! — дип көлделәр аңардан.

Әхмәт, чынлап та, Санияне бик ошаткан иде. Аның күңелендә әллә нинди үзе дә аңламаган хисләр уянып китте. Тик ул моны сиздермәскә тырышты.

— Берцәк кенә ярый инде ул, кәбәм! — дигән булды егет, уен сүз белән котылмакчы булып. — Андый гына мулла кызында да була, дигәннәр, түгелме?..

### III

Берлинның озакка сузылган көзе узып китте. Декабрь урталарында Балтыйктан искән үтләшмә суык һәм чи җил, бала чактагы кауры мылтыктан ясмык аттырган төсле, битләрне, яңакларны чеметтереп ала

торган тыгыз бөртекле яңгырлар алып килде. Кичкә таба ул яңгыр очлы вак бозга әйләнә һәм колак яфракларына, борын өсләренә аеруча зәһәр ук булып кадала. Немецлар хәзер урамнарда шактый азая төште. Күренгәннәренең дә башлары элекке шикелле күккә чөелмәгән. Эшләпәләрен басып, якаларын күтәргәннәр дә пошынулы гына атлый бирәләр. Йөзләре, иртәнге соры томан сыланган төсле, җансыз булып күренә...

Рәссам белән язучының уртак бер гадәте бар: кайда гына йөрсәләр дә, күзгә чалынган күренешне нинди буяу белән, нинди сүз белән биреп булу турында уйламыйча калмыйлар. Иртә-кич урамнардан узган Алиш та Берлиндагы төс, буяу, күренеш һәм кәеф үзгәрешләренең хәзер никадәр сизелеп торганын язучы күзе аша кичереп йөрде. Ләкин йөрәге үз хисләрен дә өстәде. Әче җил белән сибелгән чи ясмык шикелле яңгыр аның битләрен талаcа да, егет елмаеп бара иде. «Икенче кыш боектыра, ахры, немецны, — дип уйлады ул. — Сталинград калтырата. Әйтерсең, эченә боз туңган... Юк, моның аңа никадәр каты удар булуын һәм психологиясенә нинди тирән яра салуын аңлау өчен, ихтимал, бер генә минутка немец булып карау кирәктер. Ул бит инде, җиңдем дип, шушы авыр сугышларда исән калдым дип, шулай булгач мин бәхетле, дип уйлаган иде, әллә нинди матур планнар да корган иде. Ә хәзер бары да җилгә очып бара. Басып алу хыяллары белән саташкан кешеләр өчен тәмам бер фаҗига инде бу. Немецларның бу көннәрен онытмаска, күңел дәфтәренә теркәп куярга тиеш Алиш. Килер бер көн, боларны бөтен тирәнлеге белән язасы булыр. Балалар өчен генә түгел, бөтен халыкка сөйләп бирергә туры килер...»

Алишны уйлар ерак алып китте. Менә ул, шушы шомлы ояның тыштан һәм эчтән пира-зара килү көннәрен үзе күреп, шуңа ярдәм итешеп, Казанга кайткан да үзенең Черек күл буендагы кечкенә генә бүлмәсендә, таң аткан вакытларда беренче романын төгәлләп утыра. Ни өчендер шул чагында Пушкинның «Борис Годунов»ындагы карт монах Пимен аның күз алдына килә. Ул да шулай үзенең кечкенә генә хөҗрәсендә, төннәр буе Мәскәү патшалыгы һәм аның сугышлары, патшаларының җинаятьләре тарихын язып, «Еще одно, последнее сказание — и летопись окончена моя!» — дип, тәмамлау куанычын тизрәк татырга ашыга бит. Әйе, андый зур бер иҗат эшен уңышлы тәмамлый алсаң, куанычы да, бер үзең бер шәһәр алгандай, олы булырга тиеш!.. Ул китапның иң беренче укучылары аның сөекле уллары булыр, алар хәзер икесе дә урта мәктәп шәкертләре бит инде! Ә беренче тәнкыйтьчесе, әлбәттә, Өркыякай булачак. Чөнки ул, элек аның нәниләр өчен язган нәни хикәяләре белән бик үк кызыксынмаса да, бу зур романын, әлбәттә, укымыйча калмас! Ил халкының, шул исәптән үзенең дә, Алиш белән иптәшләренең дә һәм, гомумән, бөтен сугышчыларның да никадәр авыр газап, михнәт чигүен, нинди түзгесез мәхрүмлекләр кичерүен һәм нинди баһадир йөрәкле батыр булуын шул китаптан укып белер ул. Һәм шуннан соң үзенең тыйнак кына, юаш кына Алишына да бөтенләй икенче күз белән карый башлар: «Тукта әле, минем шушы юаш бәтием эчендә дә арыслан ята икән ләбаса!» — дип уйлап куяр...

— Әй, абзый, узып киттең бит! — дип кычкырды кемдер, шаян тавыш белән.

Кинәт иң татлы төшеннән аерылырга мәҗбүр булган кеше төсле, Алиш та матур хыялыннан уянып, артына карады. Ул, чыннан да, «Дойчеферлаг» бинасын узып бара икән. Ә кычкыручы кеше баскыч түбәсе астына яңгырдан ышыкланып торучы Әхмәт Симаев булып чыкты.

— Бик тирән хыялларга чумган идең, ахры, — дип көлде ул, Алиш килеп җитүгә. — Алай каты уйланма, куаныр чаклар хәзер, анда безгә юл салалар!

— Нәрсә сайрыйсың, урам авыз. Нинди юл, асфальт та җәяләрме?— диде Алиш әкрен тавыш белән. — Бик кычкырмасаң да буладыр бит.

— Кычкырмыйм ла! — дип кул селтәде Симай. — Туйдым инде гел «пышын-чышын» яшәүдән. Әйтерсең, борынгы яшь килен! Я, ярар, эш анда түгел, эш, Абдулла абый, зур вакыйгаларда! Шафист (бу аларның фашист дигән сүзне ялгыш әйтүләре иде) сөякләрен булыжник итеп түшиләр анда! Ә син асфальт дисең!

— Кубызыңны бик дыңгыратма инде, «кәнгрит» әйтеп бир.

— Соң менә, мә, ышанмасаң, үзең укы! — Симай кесәләрен капшана башлады, ләкин эзләгән нәрсәсен тиз генә таба алмады. — Әй, шайтан төкергән, мин аны ыштан балагына ук төшергәнмен икән! Монда алырлык түгел инде, ярар, телдән генә әйтим, — һәм, күзләрен йомып, сабак тыңлаткандай, тезеп китте: — Корыч кала тирәсендәге шафист гаскәрләрен безнекеләр тәмам боҗрага алып, кырып яталар. Шул ук вакытта икенче төркемнәр Төньяк Кавказдан кысрыклап киләләр; Көньяк фронт Донны кичеп, болай таба ябырылган. Бөтен дала кинлекләре буйлап үкчә ялтырату уены гаять матур бара. Ул алынган кала һәм авылларның, безнең кулга төшкән туплар, танклар һәм башка кораллар шикелле трофейларның, әсирләрнең чуты юк; кырылганнарның санына чыга торган түгел! Аларын кәгазьдән карамыйча, төгәл әйтә алмыйм инде. Юл менә шулай салына, Алиш абыкаем!

— Авызыңа баллыяу! — диде Алиш. — Син, Симай дус, тәмам безнең информбюрога әйләнеп беттең хәзер, име! Төннәрдә приемнигыңны кочаклап кунасың, ахры, молодец.

— Юк, мин Саниямне кочаклар өчен тырышам, — дип җавап бирде Әхмәт, сер итеп кенә әйткәндәй. — Мин яңа хәбәр алып килсәм, ул мине ныграк ярата. Без бит аның белән чынлап... Икебез бергә җиңү юлларыннан кайтачакбыз. Вәгъдәбез шулай... Ярый, мин китим, ашыгам, эшем күп... Иртәгә бу хатлар кулыңда булыр...

Аның кар катыш яңгыр астында чап-чоп атлап күздән югалуын Алиш карап калды. Әйе, ил якларыннан шундый әйбәт хәбәрләр килә башлавы бик күңеллегә әйләнде хәзер. Мондагы һәр ирексезне уятып, дәрт кабызып җибәрде. Кайчандыр очраклы гына башланган «кызлар хаты» Көнчыгыш эшчеләре арасына өзлексез таралып тора. Ул хатлар хәзер өч телдә басыла: татарча, русча һәм полякча. Бу эш биш кешенең баш бәясе белән бәйләнгән, ләкин егетләр аның белән исәпләшмиләр. Чөнки ил хәбәренә сусаган кешеләр арасында ниндидер изге «бөтинамә»дәй булып китте ул хатлар. Бер якшәмбедә Фая белән күрешергә баргач, Алиш моны үзе күреп исе китте. Фая шактый олы яшьтәге бер хатын белән сөйләшеп утыра иде. Кыз аны «тетя Дарья» дип таныштырды һәм Алишның да якын кеше булуын әйтте аңа. Алар өчәүләп байтак сөйләшеп утыргач, тетя Дарья китәргә җыенды да: «Ә беләсезме, балакайлар, сөешү анысы яшь чакта ярый торган эш, әмма күзколакларыгыз гел үк томаланган булмасын иде... Дөньяда менә мондый хәлләр дә бар икән, аңлап торыгыз...» — дип куйды һәм, як-ягына каранып, муенындагы нечкә чылбырын өскә таба тартты да күкрәгеннән шомарып беткән көмеш медальон чыгарды. Аны тиз генә ачып, эчендәге бик кечкенә бөти сыман нәрсәне Фаяга сузды. «Үзең таныш та иптәшеңә бир. Әмма закон шулай: мин сиңа бирмәдем, син миннән алмадың! Ярый, мин китим, хушыгыз...» — Һәм ул халык арасына кереп югалды. Алиш кабаланып Фая кулындагы нәрсәне үзенә алды. Ул йөзгә бөкләнеп, таушалып, тапланып беткән бер кәгазь кисәге иде. Сак кына сүтеп карагач, шәмәхә карандаш белән вак кына итеп чалыш хәрефләр белән язылган ниндидер язу килеп чыкты. Алиш аны шулай ук кабаланып укый башлады... Я алла, ни күзе белән күрсен: бу бит аларның үзләре алып килгән беренче «кызлар хаты», күчереп язганнар!..

— Уф! — дип куйды Алиш.— Менә бит, ә! — һәм хатны Фаяга сузды. Кыз да, укып карагач, көлеп җибәрде. «Үз хатыгыз, йөрәкләр аша әйләнеп, үзегезгә кайтты, диген. Аңласаң, мәгънәсе бар инде моның...»— диде ул.

Ул көнне алар күп нәрсәләр турында сөйләштеләр, хатларны эшчеләр арасында ничек тарату юлларын билгеләделәр. Соңрак килеп чыккан Мәрьям белән Сания дә бу киңәшкә катышып, үз фикерләрен әйттеләр. Алиш бу өч кызны иптәшләре арасында пропаганданы киңәйтеп җибәрү өчен оешма исеменнән «җитәкче өчлек» итеп билгеләде. Шуның өстенә Сания, Симайны күрергә килү сылтавы белән, ике арада элемтәче булырга һәм Алиштан хатлар алып китәргә тиеш булды. Сания моңа бик шатланып ризалык бирде, әлбәттә. Чөнки ул үзенең Әхмәтен ешрак күрә алачак иде. Шулай итеп, «ост»лар арасында «кызлар хаты» регуляр йөри башлады.

Шул ук очрашуда Алиш кызлар күңеленә икенче бер яңа орлык та салды. «Ничек соң, сезнең эшләргә әзрәк «чөй» кыстырып булмыймы? — дип башлады ул. — Әйтик, цехларда кайбер вак диверсияләр, ясаган детальләрегездә «сизелмәс» дефектлар, ярылмый торган снарядлар, очраклы янгын чыгу һәм башкалар».

Кызлар башта куркып калган төсле күренделәр. Фая, хәйләкәр генә көлеп: «Куда ты нас толкаешь, бес!» — дигән булды. Ә соңыннан исә сүз үтәрдәйләр белән үзара сөйләшкәннәр булса кирәк, теге яки бу эшченең заданиене аңлап җиткермәү сылтавы белән цехларда һәртөрле деталь бозулар, иясез браклар ешаеп китүен үзләре әйтеп бирделәр. Күптән түгел генә хәтта зуррак бер хәл дә булып алган: Фаялар цехындагы автомат станокларны юа торган бензин багы ничектер авып киткән дә, эчендәге сыекча бөтен идәнгә җәелеп тә өлгергән. Шунда анымоны уйламыйча, корыч деталь ышкылап яткан бер немецның калын игәве астыннан инә күзедәй генә очкын чәчрәп төшкән дә, станоклар арасыннан гөлт итеп ялкын күтәрелгән. Шунысы гаҗәп, «ост»лар арасыннан берәү дә зарарланмаган. Алар бик тырышып сүндерешеп йөргәннәр, ләкин янгынга каршы баллоннарның борыла торган нәни капкачлары кайчандыр бушатылган килеш калдырылганлыктан, сүндергеч күбекләр чыгып беткән булган. Ул арада, янгынчылар килеп җиткәнче, озын цехның бер башын ялкын чорнап та алган...

Әле өченче көн генә Аккүл буенда Алиш бу хәбәрләрне бик рәхәтләнеп тыңлап утырды. «Сез, зинһар өчен, саграк кыланыгыз, — диде ул, Фаяны җәлләп. — Бармакларыгыз пешмәсен. Итәкләрегезгә ут каба күрмәсен!..»

Алиш баскыч төбендә Симайны озатып калган килеш озак басып торды. Әле генә хәтереннән кичергән уйлары белән мавыгу аңа күңелле булса да, редакциягә кереп, яңадан шул чиркәнеч язмаларга тотыну чамадан тыш авыр иде. Ул дошман пропагандасын мичкә тутырып, ут төртергә генә кирәк югыйсә, янсын иде шунда дөрләп, көле җилгә очсын! Әмма, юк, син шуларны төзәтеп, стилистик ягы, җөмлә кытыршылыгы, әдәбилеге һәм башкалары дигән хәйлә белән агулы укларын чүпләп, оятсыз ялаларның, пычрак ялганнарның зәһәрен, яман шештәге үлекле эреннәрне әрчүче хирург шикелле, хәреф-би-хәреф чүпләп утырырга тиешсең. Ә аның әшәкесе, күпме тырышсаң да, барыбер кала. Син төзәтсәң, Шәфи кодрәте белән яңадан кыстыралар. Моннан да кабахәт эш булуы мөмкинме?.. Җитмәсә бит, аның, үләт тигере, Карип Ишбулдин шикелле, һәркөнне Шәфигә кереп елаучылары да бар: «Алиш минем әйберләрне юри басмый, большевикларга каршы булганга, үз милләтемне сөйгәнгә күрә генә, юктан гаеп таба, минә дигән әсәрләремне дә «чиле-пешле» дип бракка чыгара, газетта урын бирми...» имеш. Дус киселеп йөргән була бит әле үзе, серләрен сөйләгән була. «Син минем җан дусым», фәлән дә төгән. Ничек ул аны элегрәк белмәгән. Ла-

герьда чакта ук башын комга тыгасы булган икән! Ә шулай да бер бик өркетеп алмыйча булмас әле аны. Бер караңгы почмакта яхшы гына җилпеп алсаң — акыл кермәсме әзрәк... Муса дөрес әйтә: газета саен татар классикларының әсәрләрен икешәр-өчәр бит тутырып бирергә кирәк. Шулай итсәң, Кариплəрнең һәм Геббельснең юынтык суларына урын калмас!..

«Дойчеферлаг» чатыннан ике немец патруле килеп чыкты. Ярый әле Абдулла вакытында абайлап өлгерде: немец офицеры якынаю белән, ялт борылып, үрә катты. Шулай да аның документын тикшереп уздылар. Алар артыннан ук өстенә солдат плащы бөркәнгән тагын бер кеше күренде. Биек түбәле матур хәрби фуражкасын яңгырга чылатмас өчен башлыгын да күтәргән. Алиш аны кара тирәчле күзлегеннән таныды — Ишбулдин үзе булып чыкты ул. «Үлмәс, каһәр суккыры, йөз яшәр, — дип уйлады Алиш. — Эткә талау тияме соң! Нәкъ үзе хакында уйлаганда гына килеп чыга бит!..»

— А, исәнме, коллега, — дип эндәште Карип югартын тавыш белән генә. — Ниләр бетереп тору?

— Минә үзебезнең Казан кышларын сагынып тора идем әле, — диде Алиш. — Боларның кышлары да үзләре төсле черек икән...

— Да-а, — дип куйды Карип, — бу инде чәчәкләр иле, монда кырык градуслы кышлар юк...

— Ах, атаң башы! — дип көлде Алиш. — Гүяки гомер буе шушы Берлинда яшәгәнсең — шулай сөйлисең.

— А что же, майн фроенд!

Алиш бүтән сүз дәшмәде. Аның тагын ачуы килде бу адәмгә. Коллега дип эндәшкән булуы да, хәтта немецча сөйләшеп маташуы да җирәнгеч тоелды. Чөнки ул аның үзен әллә кемгә куюыннан килә иде. Шулай итеп, монда эшли башлагач, Алиш аның күп кенә сару кайнаткыч яңа сыйфатларын ачты. Тик ул аның төп сыйфатын гына һаман белми иде әле...

Алиш шул ачулы кыяфәте белән «Дойчеферлаг»ның калын ишеген каерып ачты да эчкә кереп китте. Шул ук ярыкка Ишбулдин да кысылды.

## БИШЕНЧЕ БАШЛАМ

### I

Муса легион частьларының кайда урнашуын Берлиннан ук белә иде. Шәфи белән бергә килү исә аның юлын тагын да җиңеләйтте. Алар туптуры Польшаның Радом шәһәренә килеп төшteләр дә машина белән Едельня авылына юнәлделәр. Легионның беренче батальоны шул авылның урман читенә урнашкан иде. Легион башлыгы — олы яшьләрдәге майор фон Зикендорф — аларны кунак йортының аерым бүлмәләренә куйды. Хуҗа һәм хезмәткәр мөнәсәбәтләрендә ара сакланырга тиеш, немец шул кагыйдә буенча эш итте. Ә бу хәл Муса өчен яхшы булып кына чыкты. Шәфинең туктаусыз лыгырдавын тыңлаудан, аларган күзләренең һаман капшап торуыннан котылды.

Шәфи, килү белән үк дәртсенеп, лекциягә тотынды. Әле бер ротада, әле икенчесендә, туктаусыз, борчак сиптергән шикелле, солдатлар алдында сайрана башлады. Муса да, «Берлиннан килгән Гумеров» буларак, үз хезмәте буенча рота һәм взводларга йөреп, мәдәни агарту эшләре белән танышты. Бер сәгать газета укып фашист пропагандасы таратудан башка, бер төрле дә агарту эшләре юк иде. Мусаның моңа ачуы килде.

— Ни өчен солдат арасында һичбер төрле мәдәни күңел ачу, уйнау, җырлау, бию шикелле сәнгать эшләре юк? — дип сорады ул Зикендорфтан.

Бу кеше — элекке сугышта Россиядә пленда булып, әз-мәз русча өйрәнгән, үзен көнчыгыш халыкларының дусты итеп күрсәтергә маташкан җир хуҗасы, Гитлер партиясенә кергәннән соң Дрезден тирәсендә яңа биләмәләргә тиенгән, хәтта алпавыт исеме алган ярыйсы ук хәйләкәр немец иде. Мусаның шулай кырт соравына да төс бозарга тырышмады.

— Гаеп бездәдер инде, сугыш вакыты бит, барына-югына житешеп тә булмый... — диде ул юаш кына сыман. — Аннары, үзләре дә сорамыйлар, майн һер... Бәлки, араларында һөнәр ияләре дә юктыр. Музыка белү — бәрәңге ашау гына түгел бит...

— Гафу итегез, әфәндем, сез сәеррәк сөйлисез: татар булгач — бәрәңге ашый гына белә, янәсе! Каян музыка белсен ул? Кая аның Шуман, Рейхард, Гендель һәм башкалары...

— Юк, майн һерр, сез инде арттырасыз, — диде Зикендорф җәберсенгән булып. — Мин татар халкына исключительно уважением карыйм. Менә монда хезмәт итүем дә тикмәгә түгел минем.

Бу сүзләр барганда Шәфи дә шунда иде. Ул да Зикендорфка тел тидерү ягында түгел, килешү ягында булды. Әмма Муса үзен курыкмый сөйләшергә өйрәтә иде. Ул юри ныграк бәйләнде:

— Музыка белү — бәрәңге ашау гына түгел дигән сүзен Зикендорф әфәнде кире алсын! Ул сүзләр минем халкымны мыскыл итә. Мин гаять дәрәҗәдә милләтче кеше, андый хурлыкны күтәрә алмыйм. Ә җыр, музыка, бию һәм сәнгатьчә сүз остасы булган кешеләр батальоныгызда илледән артык! Менә аларның исемлеге, рәхим итеп таныш булыгыз... Әле мин бар бүлекчәләрне дә йөреп чыга алмадым, алар тагын да күбәячәкләр!..

Гитлер ясаган алпавыт ык-мык итте, уңга-сулга боргаланды, әмма үз гаебен танымыйча булдыра алмады.

— Мин алай начар мәгънәдә әйтергә теләмәгән идем, Һумероф әфәнде, русчаны яхшы белмәү аркасында төгәлсезлек киткәндер, зурга җибәрешмик инде, — дигән булды ул. — Беренче очрашуда ук сездәй кадерле кунаклар белән ямьсезләнешәсе килми... Яхшы, рәтлибез аны, солдатлар өчен уен кораллары алыйк, җырласыннар, биесеннәр... Ә сез беренче ярдәмне күрсәтерсез...

— Менә монысы башка сүз! — диде Муса, кинәт ачылып. — Күптән шулай кирәк иде. Юкса, солдатны шул көйгә генә сугышка илтеп тыгарга, сугымлыкка куыла торган сарык түгел ич ул! Ә инде миннән ярдәм кирәк икән, рәхим итегез. Анысы белән мин көн-төн шөгыльләнергә дә әзер!..

«Тәки теш төбенә төште бит немецның!..» — дип куанды Шәфи Алмаз. Сәер кеше инде ул: бер караганда немецның табанын яларга әзер тора, икенче карасаң — шул сыйфатларын бөтенләй онытып җибәрә, хәтта аны яратмый кебек тоела. Мусага карата да шулай: аның үткен сүзе үзенә килеп кадалса, Мусаны пәри урынына күрә башлый; әгәр инде шул әче теле белән башкаларны чыбыркылаunion, рәхәтләнеп китә, «Һай, маладес!» дип куя.

Мәсьәләнең болай хәл ителүе Муса өчен бигрәк тә уңай булып чыкты. Ул хәзер бөтен батальонны айкап йөри, үзенә кирәкле кешеләрне сайлап ала. Аларны җырлатып, уйнатып карый; төркем-төркем солдатлар белән әңгәмә уздыра. Кайберләре белән аерым сөйләшеп, кылларын тартып карый. Беренче карашка кешеләрнең күңелләре әле агуланып җитмәгән сыман күренә. Югарыдан килгән кеше булгач һәм легион башлыгы да шулай киң юл ачкач, аның солдатлар белән болай якынтын аралашуына батальон һәм рота командирлары да каршы килә алмады.

Муса икенче көнне ук Зикендорф белән Шәфи алдына яңа конкрет тәкъдимнәр куйды. Төрле музыка коралларында яхшы гына уйный белүчеләр уникe кеше. Болардан музыкаль капелла төзергә һәм хәзер

үк уен кораллары белән тәэмин итәргә; җырчы һәм биючеләр, сүз осталарының сайлап алырдае ундүрт кеше. Болардан артистлар труппасы оештырырга. Ә шуларның барысын бергә җыеп культвзвод төзергә, аларга яшәү һәм репетицияләр алып бару өчен аерым бина бирергә!

— Шушы көчләр белән минем җитәкчелектә хәзер үк эш башлап, тиз арада солдатлар өчен беренче концерт куярга; тынчып ятмасыннар, халык җырларын тыңлап, сугышчан рухлары күтәрелсен! — дип бетерде ул сүзен.

— Бәрәкалла, бу бик мәслихәт эш булыр! — диде Шәфи дә аны куәтләп һәм, булачак президентларча елмаеп, Зикендорфка карады.

Легион башлыгының борылыр җире калмаган иде. Мусаның тәкъдимнәре гөнаһсыз сыман күренде, хәтта алай эшләгәндә, чынлап та, ул азиатларның күңеле ачылып китәр, моңарчы сизелеп килгән ниндидер туң җансызлык эрер төсле тоелды һәм ризалык бирергә мәҗбүр булды. Иртәгесен үк Радом каласыннан музыка кораллары кайтартылды. Күрсәтелгән кешеләрне сайлап алдылар һәм Муса алар белән репетиция башлады.

Монда җыелганнар арасында Мусаны электән белгән кешеләр килеп чыкмады. Шуның өчен ул үзен Гумеров дип кенә йөртте. Егетләр арасында талантлы гына кешеләр барлыгы күренде. Аларның берничәсе тальян гармунда оста уйнауларын әйттеләр. Ләкин монда андый гармунны табу мөмкин түгел иде. Муса аларны аккордеонда уйнарга өйрәтте. Аны үзләштерү читен түгел иде. Кыллы коралда уйнаучылар мандолинга өйрәнделәр. Муса аларга мандолинда уйнауның «могҗиза»ларын үзе күрсәтеп бирде. Уртача тавыш белән җырлаучылардан хор оештырып, «Тәфтиләү» көен Тукай сүзләре белән җырларга өйрәтте. «Кара урман», «Кыр казы», «Күзгә ачы җилләрдә» көйләрен дә бик матур җырлый башладылар. Шуннан соң ул аларга «Иршат белән Гөлшат» көен өйрәтте. Егетләр, бу көйне һәм аның сүзләрен ишеткәч, коелып төштеләр. Әйтерсең, андагы һәр сүз аларга әйтелгән, ә алар аны тота алмаганнар. Менә шуңа күрә дә ул сүзләр егетләрнең бәгырен яралап узгандай булды. Ул җырны аерым бер көчле моң белән башкарырга өйрәнделәр.

Суфиянов фамилияле бер яшь кенә егет Муса каршына килеп басты. Аның битләрендә бала чак сипкелләре дә бетеп җитмәгән, беренче сызыклар да төшмәгән иде әле.

— Абый әфәнде, мин берәр аерым җыр да җырлап карарыем, әгәр рөхсәт булса, — диде ул, оялып кына. — Мине үзебезнең клубта җырлаталарые...

Кинәт кенә Муса күз алдына Сайкичү авылы һәм аның суык клубы килеп басты. Менә бу яшь кенә малай да бөтенләй әсир түгел, ә бөтеркә мангайлы, саф күңелле, шундый ук гади сүзле Нәсимә кебек тоелды. Шуннан соң анда булган бөтен матур истәлекләр, Гөлшикәр әби белән Алыпкул бабай, бүрек иснәүче шаян һәм эшчән җиңгиләр, китапханәче Фатыйма һәм гармунчы малай, бөтен авыл белән уздырган күңелле кичә һәм күңелле итеп озату, Нәсимә бүләк иткән матур пирчәткәләр — бар да бер-бер артлы тезелеп китте. Бу бик күптән-күптән күргән бер вакыйга, әллә төшкә генә кергән бер матур хыял шикелле ерак булып күренде. Бар да калды, бар да бетте... Ул истәлекләрнең берсен дә яңадан кайтарып алу, ул көннәрнең бер генә минутын да яңадан күрү мөмкин түгел. Ничек яши икән ул әйбәт кешеләр хәзер? Матур яшиләрдер, күңелләре шаттыр, алар хәзер җиңү хәбәрләрен ешрак ишетәләр бит инде. Тик алар оштатып калган Муса гына менә кайларда йөри хәзер... Үзенең өзгәләнеп беткән күңел кылларын яңадан ялгаган булып, бу мескен җаннарның да рухларын әз генә булса да терелтер өчен Сайкичү көен алар арасында яңгыратмакчы була... Эх, аяныч язмыш...

Муса, эчке өзгәләнүләрен алып ташларга теләгәндәй, ничектер сул кулы белән селтәнеп куйды да каршында торган яшь егеткә эндәште:

— Яле, тыңлап карыйк, дус егет, нинди һөнәрең бар икән?..

Күптән җавап көтеп торган Суфиянов көчле хәтфә баритон белән сузып җибәрде:

Агыйделкәй алкын, сулары ла салкын,
Каекларны дулкын кагадыр.
Туган ягым калды, сөйгән ярым калды,
Шуның өчен йөрәк янадыр...

Агыйделгә безнең, һай, яр якын.
Яр якынга күрә су салкын.
Алтын да ла көмеш чыккан җирдән
Туган гына үскән җир якын...

Операда күп ел эшләгән Муса тавышның нәрсә икәнен яхшы белә иде. Әмма бу егетне ишеткәч, башын чайкап куйды: нинди йомшак хәтфә тавыш, нинди сафлык, нинди киң күкрәк, киң сулыш! Күрәсең, бу бала үзенең никадәр зур байлыгы, зур таланты барлыгын уйлап та карамый. Эх, менә хәзер үк Казанга, опера театрына җибәр иде ң моны! Укысын иде, өйрәнсен — нинди шәп җырчы чыгар иде. Кошлар гына итеп очрасыңмыни соң?

— Тавышың әйбәт яңгырый, исемең ничек синең? — дип сорады Муса, уйларыннан арынып.

— Ник, исемем Мирәсгать инде, үзем Кенә иленеке, — диде егет кабаланыбрак. — Молотов үблысы, может, белә торгансыздыр да әле... Хәер, бу немес ягында көн күргәч, сез каян беләсез инде аны... — Мусаның яхшы өс-башына карап, аны күптәннән монда яшәүче, туган илен әллә кайчан оныткан кеше дип аңлаганга шулайрак әйтте ул һәм артыграк ычкындырып ташлавын үзе дә сизенеп алды. Мусаның ачулануын көтеп, кыяр-кыймас кына аның күзләренә карады.

Ләкин бу бәләкәй генә буйлы кешенең шактый ук караңгы күзләрендә усал очкыннар түгел, киресенчә, яшертен генә көлемсерәү чаткылары күреп, хәйран калды. «Кара, ачуланмады бит, әллә аңламадымы икән минем сүзне?.. Әллә ул да плен төшкән кеше генә микән?..»

Ә Муса, һични булмаган кеше кебек, баягы тавыш белән сүзен дәвам итте:

— Җырларың да сәер генә синең... Көеңне дә ишеткәнем юк иде...

— Җырлый башлагач, сүз минем телгә үзе килеп тора ул. Ә көен фронтта чыгардык без аның, абый... әй, гафу итегез: әфәнде абый.

Муса кычкырып көлеп җибәрде:

— Көчәнмә инде! Ярар бу юлга «әфәнде»сез дә. Шәп җырлаганың өчен кичерәм!

Шуннан соң ул аның белән аерым шөгыльләнеп, Җәүдәт Фәйзинең «Гайнавал» җырын һәм Заһид Хәбибуллинның «Сагыну» көен өйрәтте. Моның сүзләре үзенеке икәнен, әлбәттә, әйтмәде. Егетнең үз көен «Яңа Агыйдел» дип атадылар. Муса бу көйләрнең өчесен дә ялгыз җырларга рөхсәт итте. Алдан икесен җырларсың, ә инде «бис»кә чакырсалар — өченчесен җырларсың, диде.

Курайчы һәм җырчы башкорт егетләре дә табылды. Алар башта язылмаган булганнар. Ләкин репетицияләр башланып, концерт куеласы хәбәр таралгач, үзләре килеп чыктылар. Шадра гына, бүрәнкә авызлы гына иде берсе. Муса аны күргәч, кире взводка кайтарып җибәрә язды, чөнки бөтен тышкы кыяфәтләре сәхнә өчен бер дә отышлы түгел иде. Шуңар күрә, башта курайчының «Сакмар су» көен рәхәтләнеп тыңлап туйгач кына, теге егетне дә бөтенләй җәберсетеп ташламас өчен сорап куйды:

— Нинди һөнәрең бар соң синең?..

— Үнәр?.. Нимә тим?.. Үнәрем юк ла.

— Соң алай булгач, нигә килдең?..

— Башкорттың «Азамат»ын әйтеп бирсәм тигәйнем...

— Соң шул һөнәр була ич инде, шул хакта сорыйм ич! — диде Муса бу шадрадан рәт чыкмас, ахры, дигән уй белән.

— Ерлаумы?.. Һә-әй, — дип көлеп куйды башкорт егете, тезеп куйгандай ап-ак тигез тешләрен күрсәтеп. — Ул да үнәр булса!.. — Аннары, кинәт житдиләнеп, бил каешын рәтләде дә, тамак кыргалап алгач, «Алыслардан балкып, һай, күренә»не жырлап жибәрде. Аның калын һәм күкрәүле тавышына тәрәзә пыялалары калтыранып киткәндәй булды. Репетициягә жыелган егетләр авызларын ачып, шаккатып калдылар. Муса үзе дә, күзләрен очлайтып, аңа текәлде. «Карасана бу шадракайны!..» дип гажәпләнде ул.

— Ярыймы? — дип, исе китмәгәндәй генә сорады егет байтак тын торганнан соң.

— Һе, ярый инде болай булгач, — дип көлемсерәде Муса. — Исемең ничек синең?

— Киекбаев Кылычбай.

— Бусы да бик хәтәр икән! Киеге дә, кылычы да, эләгә калсаң, алла сакласын!.. Тавышың да хәтәр. Куркам әле, немецлар Берлинга алып китмәгәйләр үзеңне.

— Бармаем, — диде егет, горур гына кырт кисеп. — Нимес аңлаймыный ул яхшы нәмәне?..

Муса сүзне икенчегә борды:

— Тагын нинди көйләр жырлыйсың?

— «Һандугас», «Ашказар» и телә ниндәйне!

— Уһу, — дип куйды Муса Кылычбайның үзенә ышануына сокланып. — Ярар, «Сандугач» белән «Азамат»ны ялгыз жырда башкарырсың. «Ашказар»ны курайчыга бирик. Су буе, камышлар шаулавы, киек кош тавышы дигәндәй, курайда шәбрәк яңгырар...

Егетләр өйрәнә калдылар. Өч-дүрт сәгатькә сузылган беренче танышулардан соң шактый талчыгып, Муса урамга чыкты. Аның бу концертны оештырудан максаты солдатларга туган илне, якыннарыңны һәм сөйгәннәреңне сагыну хисен житкерү һәм шул юл белән, бәйләнчек колакларга сизелмәслек итеп, солдат күңелендә патриотизм тойгылары уяту иде. Әмма бу хисләр үзләре үк солдат йөрәгендә кайнап яталар икән. Беренче репетиция үк моны ачык күрсәтте. Һәркайсы үз туган ягын, үзенә кадерле кешеләрне сагынып жырлый, сагынып уйный. Бик яхшы! Алар, Муса белән бергә үк торып, иптәшләре күңеленә сабан чәчәләр.

Сүз осталары да Мусаны бик куандырдылар. Актаныш районыннан Габделмән Бикчәнтәев дигән олырак яшьтәге бер укытучы Тукайның «Пар ат»ын бик кызыклы итеп укый белә икән. Аның «һайт!», «на-на!» дип кычкырып һәм сызгырып жибәрүләре өстәмә бизәк булып яңгырый иде.

Аннары Аюков Нурук дигән мишәр егете Такташның «Мокамай»ын сөйли. Муса аңа аеруча әсәрләнеп карап торды. Ул Такташныкы төсле үк сары чәчле, зәңгәр күзле һәм акценты, уку манеры да шагыйрьнең үзен бик хәтерләтә иде. Бу утыз бишләр тирәсендәге солдат үзен Такташның авылдашы дип таныштырды, кайчандыр Казанда укуын һәм шагыйрьне яхшы белгәнлеген сөйләде. «Мине дә белгән булса соң... — дип елмайды Муса. — Бәлки, таяныр кеше булыр иде!»

Ул аларның берәр генә шигырь укуын әзсенде. Ә башкаларын өйрәтергә Тукай да, Такташ китаплары да юк иде. Уйлап торганнан соң Нурукка үзенең «Кызыл ромашка»сын, ә Габделмәнгә «Дару» исемле шигырен өйрәтте. Шигырьләрне яратып өйрәнделәр, тик кемнеке икәнен Муса аларга әйтмәде.

Концерт әйбәт булыр сыман күренә иде, аны тиз-тиз хәзерләп, үзе

монда чакта куеп китү яхшы булачак. Немецларны да чакырырга кирәк, күрсеннәр. Безнең халыкны азиатлар дип кенә йөрмәсеннәр!

Муса батальон кухнясына таба юнәлде, аның бик ашыйсы килгән иде. Кизү немецка үзенең язуларын күрсәткәч, аңа аш бирергә куштылар. Муса өстәлгә юып өелгән табак-савыт арасыннан бер тирәнрәк алюмин тәлинкә алды да, жетоннарын салып, кухня тәрәзәсеннән эчкә сузды. Аның савытын кемдер алып, аш салырга команда бирде. Озак та үтмәде, мәһабәт гәүдәле, Мусадан олырак яшьтәге бер солдат тәлинкә тутырып аш китереп, аңа сузды. Сузды да, кинәт сискәнгән төсле, күзләрен зур ачып һәм шул ук вакытта икеләнгәндәй челт-челт йомып, аптырап калды:

— Я, алла! — дип кычкырып җибәрде ул, — әллә саташам үзем, әллә алдаша күзем? Бәләкәчем, бу син түгелме соң?!

Мусага аш бирүче — аның Двина лагеренда бергә яткан иске дусты Арыслан Алыпкулов иде. Ул йөгереп кухнядан чыкты, ике дус кочаклашып күрешкәннән соң, гадәттә була торганча хәл-әхвәл сорашырга тотындылар: кайларда булдың, ниләр күрдең һәм башкалар һәм башкалар?.. Аннары гына алар бер-беренә күз төшерделәр.

— Әт-тә-тә! — дип сокланган булды Арыслан, Мусаның костюм җиңеннән чеметеп. — Гүпчи кәлтәфи егет булгансың икән син хәзер; әллә берәр мимеч баена перкәшшек-фәлән булып ялландыңмы?

— Әт-тә-тә! — дип, нәкъ Арысланның үзенчә үк җавап бирде Муса да, аның яшькелт-зәңгәр мундир җиңеннән чеметеп. — Син хәзер гүпчи тегеләрчә киенеп җибәргәнсең! Биек түбәле картузың да бардыр әле синең. Анысын да кигәч, гел фрицнең үзе буласың инде, ә? Ас-кис, берни юк. Дөнья рәхәте!

— Үзем дә шулай дим, Муса туган. Шуның өчен ялландым да бит... Синнән аерылганда Дрезденгә дип киткән ием бугай, ул Демблингә булып чыкты. Аннары сугышка тазаларны монда җыя башладылар. Мин дә килдем. Олы яшьтә дип рабучи командага дигәннәрие дә, риза булмадым, «Юк, мин әйтәм, фүриргә хезмәт итәсем килә. Солдат булып. Сугышка барам!»

— Ай-я-яй! — дип сокланды Муса, озын өстәлнең башына утырган килеш кәбестә шулпасы ашый-ашый. — Шәп иткәнсең бит... Ишеткәнең бар микән: бишектәге баланы пәри-җен алмаштыра, имеш...

— Бар, бар, сигезенче брат. Әмма минем яшьтәгеләрне алыштыра алмый, имеш. Мин бит инде бишеккә чүтки гел сыеп ук бетмим дигән шикелле сыман... Күтәреп китәргә көче җитмәс... Ә менә синең үзеңне нишләтте икән ул? Син бит, чынлабрак салсаң, бишеккә дә сыярсың...

— Мин дә синең шикелле инде, брат. Кәчтүмем әйбәт ич... Аңлашылмыймыни?

— Фәрштәйн [1] инде анысы, кәнишне, — дип куйды Арыслан, булмаган мыегын сыпырып.

— Тагын берәр нәрсә ашатасызмы?

— Солы буткасы бар, кая, бир мискиеңне, хәзер апчыгам.

— У-һу, мае да бар, — дип куйды Муса, миски тулы бутканы күргәч. — Сезне начар ашатмыйлар икән монда...

— Ул кунак хакына гына. Мимечнекен чәлдердем. Монда китергәч, үземне бик нык сикертә башлаганнарые, сөякләр шылтырап коелыр хәлгә җитте. Тукта, мәйтәм, бик сикермә, Арыслан, эчең эчкә ябышкан... Сугыш уенын болай да бик шәп беләсең, ә менә пубыр булып кара, тамагың туймасмы, кешеләргә дә файдаң булмасмы. И һәм ничек итсәм иттем, кухнәгә килеп эләктем.

— Монысына да кул куям, — диде Муса. — Дөрес эшләгәнсең. Ә ничек, безнең яктан белгән-күргән кешеләр очрамыймы соң монда?

[1] Аңлашыла.

— Минем якташ егетләр, белгән-күргәннәр байтак анысы. Түлке син аларны белмисеңдер, — дип җавап бирде Арыслан. — Ә менә син Казандагы Кабан арты лагеренда булмаганыеңмы?

— Булган идем, айдан артык булган идем әле... Нигә? — дип сорады Муса.

— Мин дә булганыем. Шунда өйрәтеп җибәрделәр сугышка, — диде солдат. — Менә шунда бер патпалкауник барые, лагерь башлыгы. Ә монда нәкъ шул кешегә ошаулы бер старши унтерәфисәр йөри, беренче ротада. Фамилиясе дә шуныкы төслерәк бугай...

— Кем булыр икән ул? — дип гаҗәпләнде Муса. — Фамилиясе ничегрәк дисең?

— Актабановмы, Актагановмы — шундыйрак...

— Искиткеч бу! — диде Муса. — Неужели Актабанов монда икән? Хәер, булмас ла. Ул бит Казанда калды. Начлагерь җитмәсә... Шулай да хәзер үк табарга кирәк аны!

— Сабыр ит, — диде Арыслан тыныч кына. — «Сабыр иткән — өенә кайтып җиткән» — диләр бездә. Монда әле тагын бер кадерле таныш бар безнең...

— Анысы кем тагын?

— Улмы?.. Көзге әфәнде...

— Кит аннан!

— Китми торыйм әле. Ул монда «Кис-тапта» булып эшли.

— Әкәмәт сүзләрең бар синең. Монысын ничек аңларга соң?

— Тоймастан каптырып бугазлаучы дип аңларга. Кешеләргә йөргән чагында карда куян эзе калмасын. Юкса, хәзер ау этләре «һау да һау!» — үкчәңнән кабып та алырлар.

Муса озак кына башын кашыды. Каһәр генә суккан икән. Димәкки, Шпигель монда гестапо булып эшли. Аңардан котыла алмассың, әләгеп кенә кара!

— Үзем дә шуны уйлап пубыр булганыем, — дип куйды Арыслан бик әкрен тавыш белән. — Мин аның яхшылыкларын бер дә оныта алмыйм. «Бәйрәм ашы — кара каршы» дигән шикелле, үзем дә берәр яхшылык итә алмаммы дип йөрим...

— Ничек? — диде Муса кызыксынып.

— Бау муенны авырттыра, диләр. Пычакның эзе кала, каны-фәләне әрәм була тегенең... Ә менә берәр әйбәт дару, үлән сыгынтысыннан, әйтик... Тик әле менә градусын җиткереп булмый...

— Юк белән маташасың бугай. Бер этне генә дарулап...

— Фүрирне җиңә алмассың дисеңдер инде. Алай түгел. Әткә эт үлеме. Мин сугышта. Мәргән берәмләп чүки...

— Алайса, ашыкма! — диде Муса, аның белән килешеп. — Җиде үлчә, бер кис. Бу эштә промах ярамый. Ялгышу — үз башыңа җитүе бар.

Кухнядан Арысланның фамилиясен кычкырдылар.

— Алыпкулов! Кайда ишәк сугара ул?

— Ярый, — диде солдат. — Мине сагыналар, сау бул. Калганын үзең чамала, бәләкәчем...

— Мин кунак йортта, — диде Муса. — Булдыра алсаң — кер. Булмәдә үзем генә хәзергә... Йомышлар да булыр, бәлки...

Арыслан кухня артына чапты. Муса, тамак туйдырып чыккач, батальон мәйданы буенча уйланып йөри башлады.

## II

Едельнядәге кешеләр Седельце, Демблин шикелле хәзерлек лагеренда чакта ук әсирлек хәленнән чыгарылып, ант кабул итеп, иске немец формасына киендерелеп, Дойчлянд солдаты исәпләнәләр иде. Тик җиң-

нәрендә легион билгесе булу гына аларның ниндидер аерымрак бүлекчә икәнен аңлата. Хәер, бәлки, ул билге солдат күзенә тотен җибәрү өчен генә кирәк булгандыр, чөнки легион частьларындагы бөтен тәртип немец казармаларындагыча урнаштырылган. Взвод, рота, батальон командирлары немецлардан, аларның ярдәмчеләре һәм отделение командирлары гына шул легиондагы халыклардан куелган. Бөтен нәрсә бары тик немец штабыннан чыккан боерык буенча гына эшләнә. Әмма шулай да бу инде әсирләр лагере түгел. Дөньяны андагы шикелле чәнечкеле тимер чыбык камап алмаган, почмакларда пулеметлы машлар һәм капкаларда коралы сакчылар да юк. Немецлар үзләре көчләп җыйган кешеләргә ничек тә «яхшы» күренергә, ышаныч күрсәткән булып кыланырга яраталар. Бу режим буенча солдатка лагерь эчендә кичке отбойга чаклы йөрергә ярый, рөхсәт белән батальоннан тышкары чыгарга да мөмкинлек бирелә. Карт хәйләкәр Зикендорф бу өлкәдә аеруча тырышлык күрсәтә, татар солдатларын кайгыртучан кеше булып кылана, хәтта кайберәүләр аны яхшы немец дип тә уйлыйлар иде. Шулай итеп, бөтенесе дә «әйбәт», тик ун күзле гестапо гына көн-төн уяулыкта тора...

Бу тәртипләр белән танышып алу Мусаның үзе өчен дә уңайлы булып чыкты. Ул теләгән казармага теләгән вакытта кереп йөрде һәм теләгән солдаты, «якташы» белән сөйләшә алды. Аннары, Берлиннан килгән вәкил кешегә, гомумән, үзен бәйсез, хәтта түрәчәрәк тотарга кирәк иде бит әле. Муса ул мөмкинлекләрдән дә тулы файдаланды. Казармалардагы шапшаклык, культурасызлык турында немец фельдфебельләре һәм рота командирлары белән бик һавалы һәм бәйләнүчән төстә генә сөйләшкәләп алды. Немецның үзеннән дә болай вакчыл, педант күренеп, казармаларда мәдәни тәртип һәм чисталык таләп итте. Шуның өчен бу Һумероф дигән кешене тиз танып алдылар һәм беразшүрләбрәк тә карый башладылар.

Концертка хәзерлек репетицияләреннән соң солдат арасында да аның исеме тиз таралып китте. «Бу Гумеров дигән кеше гел шулай легион частьларында кәнцирт куеп йөри икән, ди...» «Уйнамаган уен коралы, җырламаган җыры юк икән, ди». «Элек үзе дә әртист булган, ди». «Немецлар аны бик күп акча биреп кенә тоталар икән, ди...». «Иртә белән үзем күреп тордым, ну фитфибельнең бирде кирәген! Утлы табада биетте!..» дигән шикелле имеш-мимеш сүзләр казармалар буйлап аның хакында кабатлана иде.

Муса беренче рота казармасына килеп җиткәндә, инде тәмам караңгы төшеп өлгергән булса да, сәгать кичке алтылар гына иде әле. Тигезләп корәлгән җир өстендә кемнәрнеңдер басып торганы күренде. Ә, ике солдат сөйләшеп тора икән, Муса алар яныннан узып китә башлады...

— Бәй, үзе түгелме соң? — диде берсе кычкырыбрак. — Әнә бит, сибилни киемнән... Агай-эне, туктале, мөмкин булса.

Муса тукталып артына борылды.

— Нәрсә, миңа әйтәсезме? — дип сорады ул.

Әлеге солдат, җәһәт кенә аның янына килеп, җентекләбрәк карады да:

— Әйттем бит! — диде.— Нәкъ сезнең хакта сөйләшеп торадырыек, Муса туган. Теге кеше — Уничим Гурнич ул... Кил бирегә, таптым! — дип кычкырды аңа Арыслан. — Ходай күктән эзләгәнне җирдән бирде!

Килеп җиткән кеше Мусага кул суздьг:

— Исәнмесез. Тау белән тау гына... диләрме? Менә бит тагын очрашырга туры килде.

— Шулай шул, иптәш... начлаг... — диде Муса, аптырабрак аның кулын кысып. — Обстановкалар бөтенләй табигый түгел...

Алар юл өстендә сөйләшеп тора башладылар. Ләкин күптән күреш-

мәгән кешеләр, бер-берсенең төс-битен ачык күрмәгәнгәме, әллә иялә-шеп җитмәгәнгәме, сүзләре ябышмый иде. Муса моны аңлап алды. Аннары, гомумән, казарма юлы өстендә, кышкы кичтә күпме сөйләшеп тору мөмкин?

— Әйдәгез, минем бүлмәгә барыйк, — дип тәкъдим итте ул.

— Юк, мин кухнәгә чабам, әфисәрләрне ашатмаган әле, — диде Арыслан. Ул аларның икесен генә сөйләштерү өчен хәйлә таптымы, әллә чынлап та эше бар идеме, тиз генә китеп югалды. Муса белән Онисим, вак-төякне сөйләшә-сөйләшә, кунак йортка кайтып керделәр.

Бүлмәгә ут яндырып, тәрәзәгә газета каплау белән үк Муса үзенең кунагына күз төшерде. Онисим Гуриевичның элекке дулкын чәчләре, мәһабәт саргылт-кара мыегы хәзер юк иде инде. Чыраена ниндидер басынкылык, хафалылык эзләре яткан. Теш кысып яшәргә мәҗбүрлек-нең һәм эчкә яшерелгән уйларның тирән сызыклары ияк тирәләренә сугылганы, хәрәкәтләренә салмаклык керткәнлеге күренде. Аерылулары-на ел ярым чамасы гына булса да, аларның һәркайсы бер-беренә бик нык үзгәргән төсле тоелды.

Кешеләр үзләренең гадәттән тыш хәлләрдә һәм көтелмәгәндә очра-шуларына гаҗәпләнмәскә күнеккәннәр иде инде.

— Таныш булыгыз, иптәш начальник, сез курска җибәргән рядовой Муса Җәлил, ә хәзерге көндә Гумеров, менә шушы була инде, — диде Муса шаян тавыш белән. — Курслар бик шәп булды, Минзәләдә тәмам-ладык. Тик фронтта гына эш күрсәтеп булмады. Өч ай да узмастан, немец колына әйләндек... Волхов, Икенче удар армия, капчык, Власов... бәлки, үзегез дә ишеткәнсездер.

Олы яшьтәге подполковник та үз башыннан кичкәннәрне кыска гына сөйләп бирде.

— Без Казаннан октябрь урталарында чыгып киттек, — дип башла-ды ул. — Сугышның Мәскәү өчен иң куркыныч көннәре иде. Можайски юнәлешендәге бер прорывны томаларга куелдым. Минем полк килгән шәпкә бик каты сугышты, әмма гомеребез кыска булды. Өч көннән соң немецларның яңа прорывы башланды һәм без окружениедә калдык. — Онисим Гуриевич хәзер татарчаны шактый чиста сөйли. Элекке керә-шенчәлеге бөтенләй диярлек сизелми иде. Муса елмаеп куйды:

— Сезнең тел шомарган хәзер, Онисим Гуриевич, теге вакыттагыча түгел...

— Мин бит татар солдатларын өйрәтүче унтер хәзер. Татарча гәзит тә укыйм, чөнки пропагандист та, — дип аңлатты ул.

— Сүзегезне бүлдердем, дәвам итегез, — диде Муса, гафу үтенеп.

— Шул. Окружениенең хәле билгеле инде... Күпме тырышсак та, ерып чыга алмадык. Безнең гаскәрләрнең декабрьдагы һөҗүме баш-ланганда без инде боевой единица булудан бигрәк, өшеп беткән ач мескеннәр идек. Һәм немецка безне тар-мар итеп, лагерьларга тутыру кыен булмады. Эх, үзебез гаепле инде: сугыша белмәдек ул чакта... Менә хәзер булса!..

— Ә хәзер булса, нишләр идегез? — дип сорады Муса кинәт кенә.

— Хәзер булсамы?.. Һем... Ә сез, Муса туган, любопытныйга әйлән-гәнсез...

Икесе дә, бер-беренә карап, көлешеп алдылар.

— Менә нәрсә, Онисим Гуриевич, — диде Муса, җитди төскә ке-реп. — Сез яшегез белән дә, дәрәҗәгез белән дә миннән олы кеше. Әмма без икебез дә коммунистлар идек һәм хәзер дә шулайдыр дип ышанам...

— Әлбәттә, шулай! — дип куйды Актабанов.

— Димәкки, без «сукыр тәкә»сез генә дә сөйләшә алабыз? Шуның өстенә күзгә күз генә тагы.

— Ие, — диде командир, — качышлы уенсыз гына мөмкин...

— Әйтегез әле, ни өмет, ни теләк белән яшисез?

— Өмет бер генә, — диде подполковник. — Алла кушып батальонны тизрәк сугышка җибәрсәләр, үзебезнең якка ычкынам!

— Үзегез генәме?..

— Окружениедән күпләп чыгарга маташтык — булмады...

— Бик бәләкәй түгелме соң бу теләк? — диде Муса аңа төбәлеп. — Сез командир кеше ич... Күрәм, монда да сезне унтер мундирына тыкка初ар иде. Димәкки, солдат өйрәтәсез...

— Взвод командирының помошниге.

— Шулай булгач?.. Солдатларыгызны ташлап, япабаш качарга җыенасызмы?..

Актабанов эндәшмәде. Бу сорау аңа әллә ничек урынсыз сыман тоелды. Камалыш турында әйтте бит инде... Пычранмастан элек, саф вөҗдан белән үз ягыңа чыгу бәләкәй була микәнни?..

— Ә кайчанрак җибәрүләре мөмкин сезне? — дип сорады Муса.

— Минемчә, озакламаслар. Тегеннән бик кысалар бугай. Офицерларның сөйләшүе шактый борчулы...

Муса уйга калды. Гаҗәп бер хәл: бар да үзләре качу турында гына уйлыйлар. Хәтта менә бу өлкән командир да шуннан уза алмаган. Ә ул кешенең никадәр сугыш тәҗрибәсе һәм хәрби белеме булырга тиеш. Гомумән, теге вакытта төн уртасында танышкан Онисим Гуриевич хәзер бик үзгәргән, ватылган, картлык баса башлаган күренә. Хәер, күп булса кырык алты, кырык җиде яшьтер әле аңа. Ә шулай да тар гына бер эздән атлаучы аерым шәхес кенә калган төсле. Нишләргә соң? Бу кешедә командирлык утын ничек кабызып җибәрергә?..

Сүзсез утыруы белән Актабановны пошындыра башлаган Муса, үз-үзенә сөйләгәндәй, хәрби фәлсәфәгә бирелде:

— Камалыш, «капчык», «кләшшә» һәм тагын әллә нәрсәләр дибез... Хәтта бу мәсьәләдә мәгълүм бер нәтиҗә дә ясый алабыз хәзер: Гитлер гаскәренең моңарчы тоткан тактикасы фронт сызыгын аннан-моннан ертып, безне камап алуда булды. Ә безнең өчен характерлы һәм укенечле як — шул камалышта калуда һәм аны оешкан рәвештә өзеп чыга белмәүдә иде. Дөрес, аерым командирлар ул камалышны җимерә белделәр, ләкин алар күпчелек түгел...

— Сез инде миңа да суктырасыз булса кирәк, — дип куйды Актабанов. — Аны бит әйтүе генә ансат. Бу сугышның масштабы, техника хәрәкәте — бөтенләй башка!..

— Юк, сезгә генә суктырмыйм, — дип бүлде аны Муса. — Бик күп генералларыбыз, хәтта маршалларыбыз да шул хәлдә калдылар. Кайсыдыр маршаллның кырык икенче ел башларында, крестьян чикмәне белән оек-чабата киеп, камалыштан чыкканлыгы һәм Мәскәүгә япаялгыз җәяүләп кайтып кергәнен сөйләгәннәр иде. Без сугышка әзер булмаганбыз. Гражданнар сугышындагы батырлыклар белән күбрәк мавыгып яшәдек шикелле...

— Анысы булды инде булуын. Ул хакта бик күп җырладык һәм «Дошманны бары тик үз җирендә генә тукмарбыз!» — дип кычкырдык... Әмма сугышның яңа хәйләләрен табуда йоклабрак калганбыз, бугай.

— Ә кырык өченче ел нинди яңалык алып килә кебек, сиздегезме? — дип елмайды Муса. — Сталинград тирәсендә фюрер гаскәренең үзен моңарчы күрелмәгән колачлар белән камап алу төгәлләнеп бара төсле...

— Ие, анда дошманны үз тактикасы белән кыйный башлау сизелә... Тик мин андагы хәлләрнең барын да белмим, бик өстән генә таныш, — диде Актабанов.

Муса аның күзләренә озак карап торды. Алар һаман салкын кебек иде әле. Ниһаять ул, Онисим Гуриевичнең ачылып җитмәгән эчке дөньясына дөрләткеч ут атарга теләгән шикелле, күкрәк кесәсеннән бер кәгазь чыгарды да аңа тоттырды.

Актабанов бу юка кәгазьне тиз-тиз генә сүтте дә, аркасын бөкрәйтә төшеп, анда язылганнарга текәлде. Шактый озак укыды, әйләндергәләп карады, тагын аерым урыннарга текәлде, аннары, тынгы таба алмаган шикелле, урыныннан кузгалды да:

— Әттә-тәтә! — дип, малайларча шаккаткан тавыш белән сузып куйды. — Шулай укмыни?!.

— Моннан соң инде биш тәүлек узды, — диде Муса. — Хәзер яңарак хәбәрләр булуы мөмкин.

— Ә бу... бу «ил хатлары»... — дип сорады подполковник пышылдап һәм Мусага якын ук килеп, — ничек?..

Муса аз гына көлемсерәде дә Актабановның үзенә бөтенләй көтелмәгән сорау бирде:

— Онисим Гуриевич, сез берәр музыка коралында уйный беләсезме?

— Монысы ниткән сүз тагы? — дип аптыраашта калды командир.

— Юк, мин чынлап сорыйм! — дип, бастырыбрак әйтте Муса.

— Ник, кайчандыр тальянка сайратадырыек сайратуын. Маржый түтәгез артыннан йөргән чакларда...

— Алайса, сез тиз арада аккордеонда өйрәнегез һәм без сезне культвзводның командиры итеп куйыйк, — диде Муса бөтенләй җитди төс белән. — Ризамы?

Актабанов озак итеп аңа карап торды. Муса әйтеп бетермәгәннәрнең байтагысын үзлегеннән аңларга тырышып бакты. Әмма башын чайкап барыбер сорарга мәҗбүр булды:

— Нәрсә соң бу?

— Шулай кирәк, иптәш Актабанов, — диде Муса шул ук җитдилек белән. — Алда зур эшләр тора... Актык сүзегезне көтәм.

Онисим Гуриевич солдатча гадәт беләнме, китәргә җыенырмы аягүрә басты. Ике кулын артка куеп, тәрәзә яныннан әйләнде дә:

— Әллә ниткән серле кеше сез, Җәлил иптәш, — диде елмая төшеп. — «Алтынчәч» белән мине гашыйкъ иткән идегез, ә хәзер бөтенләй куркыныч. Әллә ниткән чародейга әйләнгәнсез, ахры...

Муса, көлемсерәгәндәй итсә дә, һаман җитди хәлендә калды. Актабанов, шул сыгылмас ихтыяр көченә бирелгәндәй, аның каршына солдатча килеп басты да:

— Яхшы, шулай булсын, — диде. — Кайчандыр мин сезнең командир идем, хәзер киресенчә булып чыга, күрәсең... Буйсынам һәм тыңлыйм. Боерыгыз, иптәш генерал!

Икесе дә көлешеп алдылар. Тик шуннан соң гына Муса Берлинда «Дүртенче комитет» барлыгын һәм нинди максатлар өчен көрәшүен сөйләп бирде.

— Сез хәзергә культвзвод командиры буласыз, — диде ул. — Андагы кешеләрнең иң ышанычлыларын сайлап алып, шушы максатны аларга да җиткерәсез. Солдат арасында көн-төн аңлату алып барсыннар. «Ил хатлары» килеп торыр. Аларны тарату, ябыштыру зур саклык белән эшләнсен. Ил хатлары әсир күңеленә терәк булачак: «Әһә, үз кешеләр бар икән әле!» — дип уйлар ул. Шулай итеп, сезнең батальонның бер генә солдаты да туган илгә каршы атмаска тиеш! Алай гына да түгел: батальонны, фронтка барып җитү белән, тулы составында үзебезнең якка алып чыгарга! Бу эш оешма тарафыннан сезгә тапшырыла. Шуның өчен бүгеннән үк үзегезне батальон командиры санагыз. Взвод һәм ротадагы кече командирлар белән якын элемтәгә керегез. Алар бит барысы да әсирләрдән куелган. Ышанычсыз күренгәннәрен алыштырыгыз. Батальон тулы хәзерлектә торсын!

— Әттә-тәтә, бик зур эшләр йөкләдегез бит әле сез! — дип куйды подполковник. — Җырып чыгып булыр микән соң?..

— Һи-и, иптәш подполковник, — диде Муса аның кулын кысып, — сезгә батальон түгел, дивизия бирергә кирәк! Бер дә хафаланмагыз! Уңыш телим, хушыгыз!

### III

Шпигель икенче күрүендә үк Мусаны танып һәм аның артыннан үзенең «күз»ләрен куеп өлгергән иде инде. Моңарчы тын гына укмашып яткан азиатлар батальонына кемдер килеп, концертлар кузгатып йөри башлавы, җитмәсә, ул кеше күптәнге «таныш» булып чыгуы бу ата бүренең тынычлыгын җуеп ташлады. Ниндидер эт сизгерлеге белән шикләнә башлады ул аннан. Ләкин ачыктан-ачык бәреп ташларга бу инде Двински лагере түгел, һәм Шпигельнең хезмәте дә башка иде хәзер. Шуңар күрә ул, кулы бик кычытып та, асып үтерергә хәтта мәче дә тапмаган җәллад пошынуы белән, Зикендорф кабинетына килеп керде. Легион башлыгы үзе генә иде. Шпигель, кабинет ишеген ябу белән:

— Ферфлюгте тартарен! [1] — дип кычкырып куйды. — Яратмыйм шуны. Әллә нәрсә генә эчемне тырный. Әллә нинди шикле кеше шул! Кай җиреннән йолкып алырга шуны!

— Туктагыз әле, әфәндем, — диде хәйләкәр Зикендорф. Бу гестапочыдан ул үзе дә шактый шүрләп, абайламастан каптырып алмагае, дигән эчке бер сагаю белән яши һәм шунлыктан аның белән мөмкин кадәр йомшак телле булырга тырыша иде.

— Беренчедән, исәнмесез, майн һерр; икенчедән, битешөн, утырыгыз; өченчедән, кемгә карый бу хәтле кайнар патетика? Кемне шулай нык яратмыйсыз?

— Һайль!.. — диде Шпигель һәм дәвам итте: — Мин аны Двина ярында ук агач ботагына элеп куя идем, ярый, бәхете, «юде түгел» дип, якташлары алып калды...

— Майн Готт, кем соң ул? — дип ялварган булды Зикендорф. — Һични аңламыйм!

— Кем булсын, шул инде — Һумиароф! — диде гестапочы шакмак күзләрен әйләндереп. — Шул швайн килгән бит.

— Ах, майн Готт, — дип көлде карт немец. — Шул хәтле куркынычмыни ул?

— Минемчә, астыртын ут җибәреп йөри. Двина лагеренда да аның чокыры тирәсендә һәрвакыт җыелып яталар иде. Ул аларга күзләрен йома-йома нәрсәләрдер көйләп сөйли иде. Ә хәзер, Берлиннан килеп, азиатлар арасында музыка, җыр, бию кузгатып җибәрде, концерт, имеш! Ә сез, аның таләбе буенча, хәтта уен кораллары китерткәнсез икән! Монда хәзер батальон түгел, ә зельбештвиркенд балаган! [2]

— Хөрмәтле әфәндем, бу сүзләрегез мине җәберли, — диде Зикендорф, төсен үзгәртеп. — Батальон бүген үк сугышка хәзер дияргә була. Ә Һумероф — татарның зур шагыйре. Министр Розенберг әфәнде аны үзе кабул иткән, исегездә тотыгыз! Һумероф безгә эшли, моны да онытмагыз. Әйдә, куйсын концерт, якташларының күңелен күтәрсен, яхшырак хезмәт итәрләр. Культура кирәк, майн һерр, цивилизация!

— Ә минемчә, аларны Берлиннан алып фронт сызыгына чаклы агач ботакларына элеп чыгарга кирәк! Иң яхшысы шул!..

Алар сөйләшеп бетерә алмадылар. Кырт кына шакыган тавыш ишетелде дә ишек ачылып китте, һәм аннан алтын пенснеле, матур портфельле Шәфи Алмаз килеп керде. Аның артыннан Муса да күренде. Шәфи Зикендорфны үз кеше саный иде. Аның белән байтак мәҗлестәш

---

[1] Каһәр суккан татар!
[2] Үзешчән балаган.

булганы да бар, аңа батрак итеп дистәләп татар егетен дә бүләк иткән. Шул сәбәпле аның кабинетына да тәкәллефсез генә килеп керде. Ләкин анда чит кеше барлыгын күргәч, уңайсызланып артка чигенә башлады.

— Гафу итегез, мин, ахры, вакытсызрак кердем, сездә кеше бар икән, — диде ул, ишек төбеннән.

— Юк, юк, битешөн, — дип урыныннан торды легион башлыгы. — Һични түгел, рәхим итегез. Таныш булыгыз: Шпигель әфәнде...

Гестапочы да аягүрә баскан иде инде. Мәҗбүри йоланы үтәгәндәй генә Шәфи белән бер сүзсез танышып алды да ишеккә юнәлде. Зикендорф аны калырга кыстамады.

— Ярый, хәзергә хушыгыз, майн һерр; йомышларыгыз булганда керә йөрегез, — дип кенә калды.

Шпигель, ишектән чыкканда, шакмак күзләрен очлайтып Мусага карады. Муса да боз шикелле үтә тишәрдәй күзләрен аңа чекерәйткән иде. Бу күзләр сугышы секундның ниндидер бер өлеше генә сузылды. Куркытып өйрәнгән Шпигель, Муса күзләрендә курку шәүләсе урынына ниндидер дуамал кыю һәм хәтта мыскыллы нәфрәт очкыннары күргәч, арка сөякләрендә суык сизеп, карашын читкә борды һәм ишекне ачулы ябып чыгып китте. Аның шәүләсе күмелгәч, Зикендорф белән Шәфи иркенрәк сулагандай булдылар.

— Безнең берничә тәкъдим бар, әфәндем, — дип башлады Шәфи. — Солдатлар арасында мәдәни агарту эшләре моңарчы бер дә алып барылмаган икән. Хәтта лекция дә тыңлый белмиләр...

— Без инде аның чараларын күрдек, майн һерр, — дип җавап бирергә ашыкты легион башлыгы. — Моннан соң андый хәлләр кабатланмас. Батальон һәм роталарга муллалар куйдык, гәзит укучылар билгеләдек, менә сезнең һәм Муса әфәнденең киңәше белән культвзвод оештырабыз...

— Муса әфәнде пропагандистлар да билгеләргә куша, — диде Шәфи. — Рота саен икешәр-өчәрне. Мин аның фикеренә кушылам. Ул сезгә аларның исемлеген бирер, үзегез карап тәгаен кылырсыз. Янә килеп культвзвод командирлыгына Онисим Гуриевич Актабанов дигән өлкән унтер офицерны тәкъдим итәм. Дөрес, аның керәшен булуы миңа ошап бетми бетүен, кайчандыр дин саткан кешеләр. Әмма хәзер, ул мәсьәләдән бигрәк, кешеләрнең ышанычлы булуы кыйбат: лагерьдан үзе теләп килгән, музыканы да әйбәт белә икән. Турылыклы күренә...

— Беләм ул кешене, — диде Зикендорф. — Без дә аңа ышанабыз, солдатны яхшы өйрәтә. Кыска гына вакыт эчендә без аны оберунтер итеп күтәрдек. Тәкъдимегезне яклыйм.

— Бик хуп, — дип елмайды Шәфи. — Алайса, Берлинда без чыгарган гәзит-журнал һәм китапларны легионга тизрәк алып кайту өчен өч кеше билгеләү кирәк, әфәндем. Юкса, моңарчы алар почта аша йөреп, искереп беткәч кенә киләләр икән...

— Яхшы, уйлашырбыз, әфәнделәр, — диде немец. — Тагын ни боерасыз?

— Безнең озакламый концертыбыз өлгерә, майн һерр, — диде Муса тәмле тел белән. — Сезне шунда беренче кунагыбыз итеп чакырасыбыз килә һәм бик ихлас күңелдән! Шулай бит, Алмаз әфәнде?

— Әлбәттә, шулай, — дип җавап бирде Шәфи кунакчыл елмаеп. — Халкыбызның чын профессионал милли талантларын хәзергә күрү һәм тыңлау мөмкин булмаганлыктан, ичмаса, һәвәскәр көчләрен күрегез.

Зикендорф та шундый ук әдәпле сүзләр белән генә ризалык бирде. Аннары концертның көнен билгеләделәр. Парлап татарча бию өчен хатын-кыз киемнәре кирәк иде, Зикендорф ярдәме белән Муса аны булдыру юлларын да тапты. Аны батальон тегүчеләре әзерләп бирергә булдылар.

Гомумән, Муса үзенең эшчән, хәрәкәтчән кыяфәте һәм ярыйсы ук йомшак якка үзгәрә барган теле белән Зикендорфта яхшы тәэсир тудыра башлады. Ә Мусага иркен хәрәкәт өчен шул гына кирәк тә иде. Дошманның башына татлы сөрем җибәреп, күзләрен йомшак ефәк белән бәйли алсаң — иң яхшысы шул инде!.. Ул, үз йомышларын бетергәннән соң, аларның үзләрен генә калдырып чыгып китте.

## IV

Муса дусты белән яңадан очрашкач, Арыслан бөтенләй канатланып йөри башлады. Әмма шул ук вакытта хафага да төште: Муса тикмәгә генә йөрмәс, һаман да шул шигырьләрен башкаларга укый торган булса, Шпигель аны харап итәр. Тәки әрәм булыр егет. Юк, аны моннан тизрәк коткарырга кирәк!..

Ул әллә нинди матур планнар корды һәм хәзер инде бу планнарны җиренә җиткерергә дә мөмкин булып күренде. Чөнки хәзер кирәк хәтле ризык та хәстәрләп була, аякта агач башмак та түгел, шулай булгач, моннан шома гына ычкынырга җай да бар шикелле. Үзенең шушы кызыктыргыч уе белән мавыгып, Едлино тирәсендәге урманга да чыккалап йөрде ул. Шактый эчкәре кергәч, урман куеланып китә икән. Монда хәтле имин килеп җитсәң, юлыңнан инде чыпчык та аркылы үтмәячәк... Шунда ул бик юан бер куш юкә очратты, аның җәп арасында кечкенә генә черек куышы да бар икән. Ул аның череген кулы белән тазартып, куышны шактый иркенәйтте. Анда хәзер берәр пот ризык сыярдай булды. Һәм Арыслан, кухняда нинди азык булса, шуны киптереп, әз-мәз шушында ташый башлады. Әмма шул ук вакытта аның җилкәсендә икенче бер кайгы да утыра иде. «Валлаһи, шул нәләт суккан Көзгене ватмыйча калмам!» — дип ант иткән иде ул. Шул антын үти алмыйча китсә, ул үзен кешегә дә санамаячак. Әмма ничек үтәргә? Булсын иде ачык мәйдан: ул аны бер селтәүдә юк итәр иде. Ләкин андый мөмкинлек юк, яшерен эш итәргә кала. Нindидер әче биреп чәнчелдерергә туры килә ул үләксә козгынын!..

Бу тирәләр Польшаның шактый көньягында булганлыктан, кыш үтә чыккан җылы килү сәбәпле, хәтта урман эчендә дә кар юка кырпак кына булып яткан иде. Ул үзе белгән агулы үсемлекләрнең кышкы калдыкларын эзләргә кереште. Берничә урында «шайтан таягы» табып, пычак белән аларның тамырларын казып алды. «Пәри тигәнәге» орлыгын кәгазьгә коеп, куен кесәсенә тыкты. Эзли торгач, кар өстендә кызарып, тирбәлеп утыра торган «бүре җиләге» дә табылды. Зелпе агачы тамырындагы кара үзәкне ярып алды. Мүкле җирдә кар астында череп яткан имән яфракларын да, мүге-ние белән учлап алып, иснәштереп карагач, кесәсенә тутырды. Тагын нindидер үзе генә белгән әкәмтөкәм мөгезләре, каеры асты кортлары, баткак җирдән «бака чәчләре» актарып чыгарды. «Әллә ниткән сихерче карчыктай йөрим, җык тигере!» — дип борчылды ул. Чынлап та, моңарчы ашарга һәм дәвага ярый торган үләннәр генә җыеп, кешеләргә җиңеллек эзләүче Арыслан иде бит ул. Ә хәзер шул дошманын бетерер өчен агу эзләргә тиеш...

Шулай да Арыслан үз ниятеннән кайтмады. Шушы җыйган нәрсәләреннән әллә нинди сыгынтылар ясап, барысын бергә кушып, бер пыяла банкада әчетте. Немецларның бәйсез йөри торган бер овчаркасы бар иде. Ул кешегә сыена, уйнаган-шаярган була да, тоймастан гына берәр җиреңнән кабып, яралап китә. Солдатларның моңа бик ачуы кызса да, немецныкы булгач, һични эшли алмыйлар иде. Үзе ясаган дару тәмам әчеп җиткәч, Арыслан бер сынык икмәкне шуңа манды да, өстенә шикәр комы сибеп, овчаркага сузды. Тәмле яраткан эт Арыслан кулыннан төшкән ипине «һалп!» итеп кенә авызына чумырды һәм йотып та җибәрде. Аннары Арыслан үз эшендә булды, ул әйләнеп чыкканда

овчарка каядыр китеп югалган иде инде. Икенче көнне ул этне яр астындагы чишмә янында таптылар. Арыслан үзе барып карады. Этнең эче янган булса кирәк, чишмә кырыендагы юка карларга басып, төрле урыннан су эчкән, аннары шул тирәгә ятып аунаган, аксыл-көрән ябагалары карга ябышып калганчы озак аунаган, ахры. Андый урын өчәү иде, ә дүртенче урынга яткач, тора алмаган, күрәсең; телләрен аркылы тешләгән дә каткан. Арыслан бик кызганды бу этне. Шпигель белән Зикендорф та килгән иде, алар алдында бигрәк тә өтәләнеп, тирән кайгы күрсәтте.

— Ах, — диде, — жалкы сабакы, — диде. — Харуши был с-сабакы, умный был с-сабакы, кәк хәҗәен, — диде русчалатып.

Шпигель, русчаны аннан-моннан гына сукалаганлыктан, солдатның сүзләренә каршы: «Да, да, кароши биль пьес», — дип кенә торды. Бу татарның немец эте үлгән өчен шулай кайгыруы аңа бик ошый иде.

Әмма Зикендорф әфәнде Арысланның ватып-җимереп әйткән сүзләрендә икенче мәгънә дә барлыгын сизенде. Бигрәк тә аның «с-с-с»ларны көчәйтеп әйтүе һәм этне хуҗасы белән тиңләве нindидер астыртын мыскыллау булып ишетелде. Карап торуга байгыш кына күренгән бу гади солдатка Зикендорф әфәнде күзләрен усал гына итеп бер текәде дә китеп барды. Легион башлыгы түзем булырга, олы күңелле күренергә тиеш. Әнә Шпигель шөгыльләнсен алар белән! Ә ул тинтәк шул хәйләкәр тартарен сүзләрен җөпләп тора. Үзеңне дә утыртыр ул казык башына!..

Ә «тартарен», чынлап та, Шпигельне казык башына утыртырга җыена иде хәзер. Эткә ясаган тәҗрибәсе шулай уңышлы чыккач, Шпигель белән дә һәйбәт узуына шиге калмады. Ул аны нәүбәттәге якшәмбедә җиренә җиткермәкче булган иде һәм, якшәмбе килеп җиткәч, «сынауны» уздырып та карады. Якшәмбе көннәрдә Шпигель, гадәтенчә, шнапс төшереп килүчән иде. Бу юлы да ул шактый ук кызмача булып чыкты. Арыслан сөенеп куйды: бигрәк яхшы, аны-моны сизми дә калыр...

Кәрбән генә эмаль табада, бөтен хәсиятләрен җиткереп, май һәм йомырка белән кыздырылган итне Шпигель алдына китереп куйды. Тиешле «соус»ларының һәммәсе дә кирәгенчә салынган, ят тәмнәр яшерелгән иде. Комсыз иштиһалы гестапочы табадагы ризыкны күз ачып йомганчы сыпырып та өлгерде. Арыслан, бу шушында ук бөгәрләнеп төшмәгәе дип, берхәтле шигәя калды һәм стакан белән сөтле кофе китерде. Шпигель аны да ялт кына эчеп җибәрде дә, сигара кабызып, кулындагы камчысын уйната-уйната чыгып китте.

Арыслан солдат көтә башлады. Бер чиләктән артык бәрәңге әрчеп бетерде, аны юып, турап куйды. Андый-мондый хәбәр ишетмәмме дип, ишек алдында утын ваклап керде, бакларга су тутырды, тагын әллә ниләр эшләде — вакыт бер дә узмый кебек тоела иде. Кичке караңгы төшә башлагач та көтелгән хәбәр һаман килмәде. «Тукта, соңгарак тотар ул аның кендегеннән, төнгә табарак!» — дип уйлады Арыслан. Әнә бит, овчарка телен ничек тешләгән иде, бу да озакламас, овчарка булыр!..

Ниһаять, кичен солдатларны ашатканнан соң, бушанып, һавага чыкты, беркадәр йөргәч, Шпигельнең бернichә тапкыр бәдрәфкә чыкканын күрде. «Әһә, барып җиткән икән, тиздән капут...» дип куйды ул эченнән һәм тыныч кына үз казармасына юнәлде. Иртәгә Шпигельнең үле гәүдәсен күргәч, һични сиздермәскә кирәклеген уйлый-уйлый, талчыккан эш кешеләречә изрәп йокыга китте. Иртәгесен биштән үк яңадан кухняга чапты, солдат туйдырырга кирәк иде. Сәгать җиделәр дә тулмагандыр, Шпигель үзе килеп керде һәм аш тәрәзәсенә тыгылып:

— Ике стакан кара кофе! — дип кычкырды.

Арыслан кул аркасы белән күзләрен ышкып, маңгаен сыпырып куйды. «Өрәге күренә мәллә?..» — дип уйлады ул. Ләкин аның каршында

бер дә өрәк түгел, ә шул ук шашкан күзләрен акайтып, Шпигельнең тере башы тора иде. Арысланның куллары калтырап киткәндәй булды. Стаканнардагы кара кофе чайкалып, тәлинкә төбенә җәелде, чистасы белән алыштырырга туры килде. Кофены Шпигель алдына илтеп куеп, кухня артына кергәннән соң гына аңына килгән кебек: «Сыеклап кына калган икән, нәгаләт!..» — дип үкенде ул. Аның кәефе бөтенләй кырылып төшкән иде. Нәрсәдә промах бирде соң? Кай төше килеп җитмәде?.. Күпме уйласа да, үз «даруы»ның гаебен таба алмады.

Кухня эшләреннән әзме-күпме бушану белән, Мусаны эзләп китте Арыслан. Ул ничек йөрергә белә иде: аның кунак йортка Муса булмәсенә килеп кергәнен берәү дә күрмәде.

— Эш харап, Муса туган! Качыйк моннан тизрәк! — дип кайнар пышылдады ул аның колагына ук килеп. Һәм Мусаның соравын да көтмичә, үзенең ачы үкенечен сөйләп бирде. — Эт булып эткә талау тиде, ә бу нәгаләт фашистка пычагым да булмады! — дип өзгәләнде Арыслан.

Муса бу сүзләрдән рәхәтләнеп көлде дә кинәт җитдиләнеп, аңа шелтә белән карады:

— Нигә үз белдегең белән әллә ниләр эшләп йөрисең? Ни өчен ашыктың?..

— Тизрәк эшен бетерәсе килгән иде лә... — дип Арыслан башын түбән иде. — Гаеп миндә инде... Әләктерсә, үз башым белән түләргә туры килә...

— Анысы өчен алдан ук үлмә әле, — дип куйды Муса. — Синнән шикләнсә, инде кичтән үк яптырган һәм җиде кат тиреңне таң атканчы салдырып аткан булыр иде. Димәкки, синнән шикләнмәгән, нәрсәдер килешмәгән дип кенә уйлаган. Гадәттәге салкын канынны җуйма, һични булмаган кебек, эшеңдә бул.

— Ә качарга барыбер кирәк, — диде Арыслан. — Монда күпме ятасың тагы? Мин инде икебезгә җитәрлек юл ризыклары да хәстәрләп куйдым... — һәм ул урмандагы куышы турында аерым бер горурлык белән сөйләп бирде.

Ә Муса бу эшне дә шәп дип тапмады. Тагын күзләрен алартып Арысланга карады:

— Баш катты инде сезнең качуларыгыз белән! — диде ул. — Син дә, брат, ялгызак крестьян икәнсең әле, гел үзеңне генә кайгыртасың!

— Ничек инде үземне генә. Икәү качыйк, дим ич!

— Ә калганнар? Ә батальон?

— Батальо-он? Әй-й, туганкай, булмый торган эш ул! Мең ата баласын бер авызга күндереп кара син!..

— Булырга тиеш! — диде Муса һәм үзенең монда ни өчен килүен, нинди эшләр башлап йөрүен кыска гына аңлатып бирде. Кечкенә генә чемоданының аскы катыннан бер кәгазь тартып чыгарып, Арысланга сузды.

— Латинча укый беләсеңме? Мә, укы, — диде. — Үзеңдәй ышанычлы иптәшең булса, аңа да укыт... Сүз бетте. Минем тирәдә бик кирәк чакта гына күрен...

## V

Шәфи Алмазның бу сәфәрдәге көннәре күңелсез үтә дип әйтү мөмкин түгел иде. Һерр Зикендорф аңа киң күңел белән сый-хөрмәт күрсәтте. Үзендә кунак итү белән генә чикләнмичә, еш кына Радомга да алып барды. Ә Радомда инде «зәңгәр оҗмах» бар иде. Ә зәңгәр оҗмахта зәңгәр күзле, алтын чәчле, сөңгедәй озын кара керфекле поляк кызы «изге Магдалина» бар иде. Дөресен генә әйткәндә, аның маңгаена язылмаган: әллә ул поляк кызы, әллә немец кызы, әллә итальян кызы.

һәм анысы мөһим дә түгел, чөнки Шәфинең ул кыз теле белән сәүдә йөртәсе юк лабаса! Әмма ләкин ул кыз, егетнең яшьме-картмы булуына карамастан, кочакта бик оста иркәләнә белә! Оҗмах еланы шикелле синең муеннарыңа сарыла, күкрәкләреңә уралып бетә, култык асларыннан нәни генә башын китереп чыгара, тамак асларыңны үбеп кытыгыңны ярсыта, ияк очындагы түгәрәк керпе төкләргә мамыктай шыгырдап торган ап-ак алсу битләрен назлы гына ышкып: «Мили мой, позальста!» — дигән була. Шул чагында инде, бөтен дөньяларыңны онытып, җиде кат күк капуглары ачылгандай тирә-юнеңә рәхәт тулып, фирдәвес оҗмахының түрендә кәүсәр шәрабе генә эчеп утырган шикелле сәрхүш булып китәсең. Менә шунысы мөһим аның! Һай, ул изге Магдалина, һай, ул рәхмәт фәрештәсе! Илледән узып киткән Гаптрахман абзагызны да нинди итеп яшәртә белә бит ул!..

Әмма шулай да Шәфи, айнык эш кешесе буларак, «зәңгәр оҗмах»тан бөтенләй чыкмыйча гына ятмады. Радом спекулянтлары белән итәк астыннан гына коммерция ясарга да өлгерде, лекцияләрен дә эштер-өштер китергәләде. Теге көнге башбаштаклык өчен беренче ротаны строй белән өч сәгать йөгерткәч, лекция тыңлаучы солдат арасында үлем тынлыгы урнашты. Әз генә акылга утырту ярый икән ул. Мусаның нишләп йөрүенә күз-колак булырга да җитеште. Ә Муса даһи эшлекле егет булып чыкты тагы. Берлинда чакта гел кадалып торучан шырпы телле, галәмәт усал малай булып күренсә дә, юлга чыккач бик күңелле кеше икән. Һәнүз көлдерү дә җор сүз икән телендә. Оештыру сәләтенә килгәндә дә бик тере кылана. Немецларның калын тиресен шәп кенә кыргычлап алды. Юк, әйбәт егет...

Шулай итеп, моңарчы гел Мусадан куркып, шигаеп йөргән Шәфи Алмаз хәзер аңа кинәт кенә ышана башлады. Муса әле моны үзе дә белми иде. Шуңар күрә ул, бүген икенче батальонга китәсе булгач, Шәфи Алмазны үзе чакыра керде. «Бу инде барыбер минем арттан калмас, әйдә, үзем сөйрәп алып барыйм моны», — дип көлде Муса. Бүлмәсендәге диванда кырын ятып кына сөйләшкән Шәфинең кәефе башкачарак булып чыкты. Күзләре шактый майланып елтырыйлар иде аның.

— Син инде, энкәш, үзең генә барып кайт анда, — диде ул. — Минем Радомда гаять кичектергесез йомышларым бар, шунда йөреп килермен дигән идем, әйе... Вә дәхи килеп, мин сиңа тулы ышаныч игълан итәм, Муса әфәнде. Күрәсең, хәтта «син» дип эндәшә башладым. Бу инде Гаптрахман абзаңның дус итү билгесе...

Муса, ярый алай булгач, нишлисең инде дип, үзе генә барырга бик тиз риза булды. Шәфинең эт эчәгесе шикелле аякка чорналып йөрмәве бигрәк тә яхшы булачак иде...

Муса Крушино станциясенә төштән соң килеп җитте. Алдан өйрәтүләре буенча, тимер юл хуторының көньягындагы «Кысла күле» дигән урынны эзләп китте. Хуторның иң соңгы өйләрен узып, ялан кырга чыккач та, байтак атлыйсы булды әле. Әмма Муса моңа иренмәде. Юк, киресенчә, Польшага килгәч аны ниндидер яңа дәртләр, яңа ашкынулар чорнап алды. Әйтерсең, аның беренче яшьлек еллары яңадан кайтты. Әйтерсең, ул дала бураннарында, крестьянның олау чанасына яткан килеш Орск өязендәге авылларга йөри, ат булмаганда җәяүләп атлый. Аның кайгысы — авыл яшьләреннән комсомол ячейкасы оештыру, булган урыннарда аның эшен рәткә салу...

Тик ул үзенең ярым хыял, ярым төш шикелле бу уйлары эчендә озак югалып кала алмый. Әйләнә-тирәсендәге табигать үзгәлеге, шакмак-шакмак киртәләнгән басулар, ярым-ялгыз калгаеп утырган утарлар, әллә нидә бер күренеп калучан урман кештәкләре һәм шул бүлемтекләр чаты саен аркылысына Гайса сурәте кадакланган озын-озын тәре баганалары аның күңел күзен рәхәт кенә каплап алган уйлар пәр-

дәсен читкә чөереп ташлыйлар. Юк шул, Җаек буе далалары түгел бу. Монда — тимерләгән олтаннар таптап узган Польша җирләре икән...

Батальон, чыннан да, бер кештәк нарат урманы буенда, итәкләре салам матица белән төрелгән палаткаларга урнашкан булып чыкты. Алар тирәсендә шул ук наратларның чи такталарыннан вакытлы бараклар корыла башлаган иде. «Кысла күле» дигәне шул урман кештәге читендә җәелеп яткан бер сазламакка охшый. Хәзер аның өсте соры боз белән капланган, солдатлар шуннан су алалар, ул су тимер чәйнектәге иске чәй төсле кызгылт-җирән булып тора иде.

Ул үзенең «кодрәтле» командировка язуларын батальон командиры Фирцихман әфәндегә тапшырды. Һауптман дәрәҗәсендәге бу немец төпсә генә буйлы, соры-яшькелт күзле, ак керфекле мөлаем генә бер кеше иде.

— Безнең әле кунак йортыбыз юк, — диде ул борын тавышы белән. — Мулла әфәнде белән пропагандистлар аерым бер палаткада торалар. Рәхим итеп шунда барырсыз инде, Һумероф әфәнде.

Ул тиз генә мулланы чакыртып китерде. Бу олы яшьләрдәге кешенең башында чалма, өстендә чапан булмаса да, аягында читек-кәвеш, ә биле каешсыз иде. Капитан аларны таныштырды. Берлиннан килгән һерр Һумерофны яхшы кунак итәргә, җылы урын бирергә кушты. Хәзрәт кеше Мусаның кечкенә чемоданын үзе алды һәм: «Әйдәгез, әйдә», — дип, кунакка юл күрсәтә-күрсәтә алдан атлады.

Палаткада дүрт кенә койка булып, аның да берсендә коры матрас кына ята иде. Мулла абзый Мусаның чемоданын, бисмилла әйтеп, шул койкага куйды һәм тиз генә каяндыр салам мендәр кисәге, җәймә һәм одеаллар табып, урын-җирне корып җибәрде.

— Рәхим итегез, әфәндекәем, — диде ул койка тирәсендә эше беткәч. — Урыныгыз бик тә ямьле булыр, йокыгыз бик тә тәмле булыр, аллаһе боерса!..

Муса урынга килеп утырды һәм, өс-башларын салып, бераз ял итәргә уйлады. Мулла хәзрәт, кунакка ходайдан тыныч ял теләп, чыгып китте.

— Нинди зат икән соң бу? — дип уйланып ятты Муса. — Бер дә хәрап суфый күренә, гел укынып кына тора... Кайсы мәхәллә имамы булды икән?.. Ничектер эченә керәсе иде монын!..

Ул күз йомарга да өлгермәде, юешкә каткан ишекне кыштырдатмый гына ачып, мулла яңадан килеп керде. Аның кулында нindидер төргәк бар иде, ул аны өстәлгә куйды, сүтә башлады.

— Йокыгыз тәмле булыр, дигән идегез, хәзрәт. Ай-һай, болай булса, шулай булыр микән? — диде Муса, сүз уйнатыбрак.

Мулла елмаеп куйды.

— Җавап өчен кесәгә керергә туры килә инде болай булгач, — диде ул һәм, эчке кесәсенә тыгылып, нәзек озын бер шешә тартып чыгарды. — Йокы тәмле булмаса, дарулабрыз аны... Менә ул — пульшинский чөгендер җимешеннән ясаган әгъля «бембер» шәрабе! Нәкъ безнең яклардагы ар күмүшкәсе инде, ифрат дәрәҗәдә һәйбәт...

Хәзрәт кешенең бу хәтле «әбрисез» кылануы Мусаны бөтенләй гаҗәпләндереп җибәрде. «Нишли бу суфый?..» Ә хәзрәт исә, һични булмагандай, сүзендә дәвам итте:

— Менә монысы бик ләззәтле зәкүси булыр, — дип төргәк эченнән бер үрдәк тартып чыгарды һәм аны, ботыннан гына тоткан килеш югары күтәреп, Мусага күрсәтте.

— Собханалла, хәзрәт, сездә оҗмах нигъмәтләре бар икән! — дип кычкырды Муса аның үз теле беләнрәк. — Кайлардан ходай мондый ризыклар бирде сезгә?

— Җан биргәнгә — җүн бирермен, дигән бит... Күл читендә яши-

без... Пульшә җирләрендә, һи-һи... Алар безнең ише дин ияләрен бик ихтирам кылалар. Мөселманнары да очрый, әйе...

Шуннан соң аларның сүзләре ялганып китте, Мусаның йокысы да ачылды, һәм алар иң гади рәвештә бер-бере хакында сорашырга тотындылар.

Бикмулла хәзрәт Җиһаншин Татарстанның Чирмешән ягында егерме сигезенче елларга хәтле мәхәллә имамы булып торган икән. Аннары мөгаллим булган... Сугышка алынып, плен төшү белән үзенең изге хезмәтенә тагын тотынган, һәм менә легион төзелә башлагач, Бикмулла хәзрәт өчен киң мәйдан ачылган... Мондый сыйлар өчен хөрмәтле әфәндененң исе китмәсен инде. Хәзрәт кеше андый «ябалак шулпасы»ның тамчысын да үзе татып караганы юк. Ул аны тик Гумеров әфәнде шикелле кадерле кунаклар өчен генә таныш-белешләреннән табып ала икән...

Хәзрәт үзе сөйләгән арада тик тормады, үрдәкне юып, эчләрен тазартып кискәләде дә, кәрбән генә бер корымлы кәстрүльгә салып, тимер мич өстенә куйды. Берлин кунагы да үзенең кем икәнен хәзрәттән яшереп тормады. Ул — Оренбург шәһәренең зур гына фрукты сәүдәгәре Зәкәрия әфәнде Гумеровның Муса исемле уртанчы улы булып чыкты. Аларның алма, лимон, әфлисун кибетләре бер Оренбурда гына түгел, хәтта Казан һәм Чистай ише җирләрдә дә булган икән. Заманасында сәүдәләр гөрләп барган, дан вә мөлкәт иясе булганнар... Сугышлар яхшы гына, ягъни фюрер коралының җиңүе белән тәмам булып, исән-сау илгә кайта калса, Муса әфәнде ата-бабадан калган шул изге кәсепкә яңадан тотыначак икән...

Алар шулай сайрашып утырганда, шыштырдавык палатка ишеген күтәреп һәм әз генә бөкрәя төшеп, бер кеше килеп керде. Турайгач, аның шактый калку буйлы, калын кара кашлы, маңгаеннан коела башлаган сирәк чәчле, киң ачык йөзле икәнлеге күренде. Чишенгән арада аның күзләре моңарчы буш торган койкада аяк салындырып утыручы яңа кешедә булды. «Кем соң бу?» дигәндәй, байтак кына карап торды да алга атлады һәм, очарга хәзерләнгән сыман, ике кулын җәеп:

— Муса Җәлил?! — дип кычкырып җибәрде.

Муса, ачулы сискәнеп, аңа таба борылды, ләкин тиз генә төсмерли алмаганлыктан, кем дип әйтергә белмичә торды һәм шул чакта аның күзләре Бикмулла хәзрәт күзләре белән очрашты: мулла карашында тирән гаҗәпләнү иде. Муса, шушы көтелмәгән кыен хәлнең һәм фаш булу куркынычының икесеннән дә берьюлы котылырга теләгәндәй, «Шаярмагыз, әфәндем!» диде дә яшен тизлегендә урын эченә чумды, иске көрән одеалны баштан-аяк бөркәнеп куйды. Янәсе, йоклый ул, бәйләнмәгез.

Әмма теге кеше эт әрсезе бер нәмәстә булып чыкты: Муса алда нишләргә кирәген уйлап та өлгерә алмады, теге аның янына килде дә өстендәге одеалын сыдырып та ташлады:

— Качалмыйсың! Комга башны тыгып кына тәвә кошы да котыла алмаган! — диде ул дөбердәтеп көлә-көлә. — Мин бит сине, мичкә керсәң... укчаңнан таныйм!

Ялангач калган һәм кая керер тишек таба алмаган кеше хәлендәге Муса, көләргә дә, еларга да белмичә, күзләрен аңа текәде һәм тагын да ярсыбрак әйтә салды:

— Әфәндем, сез артык фамильяр кыланасыз! Эт әрсезе булу, әллә нинди кушаматлар тагу — мәдәниятсезлек! Мин сезнең белән дуңгыз көткәнем юк ич. Мин Берлин вәкиле!..

— Беләбез, беләбез, һе-һе-һей! Ник белмәскә? — диде теге кеше Мусаның каты сүзенә һич кенә дә җәберләнмичә. — Әгәр җен алыштырган булмаса... — Бөйрәкләренә таянып Муса каршына баскан бу кеше әле һаман авыз ерып, күзләрен челт-челт йомгалап тора иде.

Мусаның кинәт исенә төште: әйе, шул бит бу, каһәр суккыры! Шуның «челт-челт» күзләре, шуның үпкәсез көлүе, шул үзе — Уразаев!..

Кайчандыр Уразаев ИКПда укыганда, алар яхшы дуслар һәм икесе дә сазаган егетләр иде. Муса фатирсыз йөргән чакларда еш кына аның янына, тулай торакка барып куна, бергәләп консерва ашыйлар һәм суык чәй эчәләр иде. Шуннан соң Уразаевны Чаллы политбүлегенә җибәрделәр. Муса утыз дүртенче елны күчмә редакция белән шул ук районга килеп төшкәч, алар тагын күрештеләр. Аннары Уразайны кайсыдыр районга секретарь итеп җибәрделәр. Сарман иде бугай, ахры. Шуннан бирле ул аның язмышыннан хәбәрдар түгел иде.

Беравык эчендә шуларны хәтереннән кичергән Мусаның ачуы инде тәмам язылып, йөзенә елмаю чыкты.

— Харис! Синме, шайтан таягы!.. — дип кычкырды ул һәм, ялан аяк идәнгә басып, Уразаевны кочаклап алды. Шул арада Муса пышылдарга да өлгерде: — Ачык авыз син һаман. Әллә кем алдында фаш итәсең...

— Куркыныч юк! — диде Харис кул селтәп.— Минем икенче секретарь ул!

— Ничек инде алай? — дип гаҗәпләнде Муса, җилкәләрен куырып.

— Шулай,— дип куйды тегесе тыныч кына.— Сарманда минем икенче секретарем иде, монда да шул чамарак, ягъни мәсәлән...

— Ах, сез шайтан төкергән нәрсәләр! — дип бот чапты Муса.— Утыртасыз кешене! Бикмулла хәзрәт, имеш! Чирмешән ягыннан, Кара песи авылыннан... Каркарый ишан малае... Ах, Алдартазлар!..

— Ә сез үзегез? — диде Җиһаншин, авызын колак артларына әлгәндәй итеп.— Оренбурның атаклы фруктычы Гумеровлар малае, имеш, ха-ха-ха!

— Шулай таныттымыни? — дип сорады Харис та, кукрәтеп көлеп.

— Шулай ди шул. Ә мин сизеп торам — куык шартлата! Чөнки мин кырыгынчы елны гына заочно пединститут бетергән кеше. Җәйге сессиядә чакта без язучыларны институтка чакырдык. Шунда сез дә бар идегез һәм шигырьләр укыдыгыз!

— Абау, бөтенләй чыгырымнан чыгардылар! — диде Муса, зарланган булып.— Вәт йөр инде: мине беркем дә белми дип!

Алар хәзер, шул элекке тормышларында гүяки һични булмаган кебек, өчәүләшеп гамьсез көлешә иделәр. Аннары гына Муса үз эшенә керește.

— Ярар, егетләр,— диде ул.— Сезне монда очратуыма бик шат. Әле куркып килгән идем: кемне табармын, ничек башлармын, дип. Болай булгач, зерә шәп килеп чыкты: берегез батальонның главный пропагандисты, икенчегез главный мулласы икән — тыңлагыз! — һәм Муса яшерен оешманың төп максатларын аларга да сөйләп бирде. Нидән башлап җибәрергә, солдатны ничек оештырырга кирәклеген әйтте. Бу сүзләр нииндидер якты өмет уятучан кызыклы булып, батырлык һәм фидакарьлеккә чакыручы серле булып, төн уртасына хәтле сузылды. Уразаев белән Җиһаншинның бу көтелмәгән яңа бурычны җентекләбрәк төшенәселәре килде. Палаткада алар өчәү генә иделәр. Үзләре белән бергә торучы Әминев дигән егет Варшавага пропаганда материалларына җибәрелгән икән, ул кайтып җитмәде, шуңа күрә иркенләп сөйләштеләр. Бөтен мәсьәләләр кат-кат кузгатылып, җентекләп аңлашканнан соң, Уразаев белән Җиһаншин, гвардия байрагын үпкәндәге шикелле, бер аяклары белән генә идәнгә тезләнделәр һәм Муса артыннан ант сүзләрен кабатладылар.

— ...Актык тамчы канымача!..

Иртәгесен Муса үзенең рәсми эшләрен тиз-тиз башкарды да, кабат килергә вәгъдә итеп, беренче батальонга кайтып китте.

## VI

Беренче февральдә фюрернең туган көне булгандырмы, әллә эш башына менгән көне иде микән,— немецлар шул көнне аңа багышланган бәйрәм ясадылар. Таң тишегеннән солдат уенына куып чыгару булмады, мәйданнар, казарма тирәләре һәм эчләре бик шәпләп чистартылган, бөтен җир балавызлагандай ялтыратып куелган иде. Радиодан иртәдән үк иң фанфарлы музыкаларны гына яңгырата башладылар. Роталар саен фюрернең даһилыгы, оста полководецлыгы турында әңгәмәләр уздырылды. Бу эштә Зикендорф әфәнде турыдан-туры үзе җитәкчелек итеп, пропагандистларның занятиеләрне ничек уздыруларын күзәтеп йөрде. Күп урында үзе тылкышып, ватык-җимерек рус теле белән озын речьләр сөйләп күрсәтте. Солдатлар хәзерләгән концертны да шушы ук көннең кичәнә билгеләде. Шуңар күрә Муса икенче батальоннан кайту белән репетицияләр үткәрергә керешге. Аның җитәкчелегендә хәзерләнгән беренче концертның профессиональ югарылыкта узуы бик мөһим иде. Ул көчен һәм сәләтен җәлләмәде: үзе дә тирләп, егетләрне дә тирләтеп өйрәтә торгач, максатына ирешкәндәй булды, шәт, кызыллык китермәсләр йөзенә.

Шул кызу эш арасында почтальон аның кулына телеграмма китереп тоттырды. Муса, бераздан гына эшеннән бүленеп, аның адресына күз салды: телеграмма аңа түгел, Шәфи Алмазга, һәм өстенә «дрингенд»[1] дип язылган иде. Ә почтальон ни өчендер аңа китереп тоттырган да үз юлына китеп тә барган... Муса, репетициядән кайткач, Шәфи бүлмәсенең ишеген какты, җавап булмады. Фон Зикендорфтан сорагач, ул аның кичәдән бирле Радомда булуын һәм әле һаман да кайтып җитмәвен әйтте.

— Аның исеменә ашыгыч телеграмма бар, майн һерр,— диде Муса кәгазьне аңа сузып.—Нишләрбез икән?

Легион коменданты, тиз генә машинасын китертеп, Мусага тәкъдим итте һәм Шәфинең кайда булу ихтималын өйрәтте.

Гаптрахман агаең, өстенә романтик чигүле Иран халаты салып, башына Бохар кәләпүше киеп кенә алгы бүлмәгә чыкса — аптырап калды: каршында мәгънәле генә көлемсерәп Муса тора иде.

— Сезгә ашыгыч телеграмма бар, әфәндем,— диде ул, җитди булырга тырышып.

Шәфи, кәгазьнең печәтен кубарып, укырга тотынды. Кинәт аның йөзе яшелле-күкле булып китте, мыек очлары тартылып куйды, баскан урыныннан кузгалып, күзләре белән нәрсәдер эзләнә башлады. Эзләнү генә түгел, күзләрең маңгаеңа менәрлек иде шул: «Гемайнһайт![2] Бүген кайтып җитмәсәң, иртәгә үзем килеп җитәм»,— дип язылган иде анда.

— Ах, һем-һем,— дип кабатлады ул.— Маһия апагыз чакыра, ашыгыч кайтырга куша... Һем-һем, менә син, ә?..

Һәм Шәфи Мусаның күз алдында коелып төште. Ниндидер каты кырау суккан әрекмән яфрагы шикелле, шәлберәп калды.

— Сез машина беләнме? — дип сорады картлач, ниһаять, Мусага күз калкытып.— Бик яхшы. Киттек...

Булачак мәмләкәтнең булачак президенты батальонга кайткач тизтиз җыенып алды да, Зикендорф белән хушлашып, юлга ашыкты.

— Бүгенгә калу кирәк иде, майн һерр,— диде немец.— Үзе бәйрәм көн, кунак булыр идек. Ә кичен сезнең солдатлар концерт бирә, бергәләп тыңлар идек.

— Рәхмәт, әфәндем. Чакырталар... Сез инде үзегез генә. Муса әфәнде белән. Хушыгыз. Берлинда көтәм үзегезне! — Зикендорфның шул ук машинасы Варшавага алып китте аны...

[1] Ашыгыч.
[2] Безобразие!

Кичен немецлар бәйрәм ашы ясадылар. Үзләре кәефләнү генә түгел, хәтта батальон солдатларына да фюрер исәнлеге өчен йөзәр грамм шнапс бирделәр. Мондый хәлнең әле бервакытта да булганы юк иде. Солдатлар, әлбәттә, кыстатып тормадылар: «Фурирга байлык, әзгә саулык!.» — дип капладылар да куйдылар. Аннары баш бармаклары белән мыек очларын гына сыпырып җибәрделәр. Кәефләре шәбәеп китте.

Аштан соң халык концертка җыела башлады. Немецлар, урман авызынарак кертеп, гаражмы яки склад өченме, озын гына бер бина салып бетергәннәр иде. Муса теләве буенча концертны шунда уздырырга булдылар. Анда тиз генә такта сәхнә корып, такта эскәмияләр тезеп, әмәлләп чыктылар. Тыгызлап утырта торгач, биш йөзләп кеше сыйды. Пәрдә ачылганын көткәндә була торганча, үзара әкрен генә гөжләшү башланды. Әсирлеккә төшкәч гел явызлык кына күреп өйрәнгән кешеләрнең күңелләрендә беренче тапкыр, бүген монда җыелгач, әллә кайчангы кадерле хатирәләре, инде мәңге кайтмас төсле матур истәлекләре уянып китте. Һәркем үзенең колхозы клубында яки шәһәр театрында, яшьлек шатлыгы белән шау-гөр килеп, үз сөйгәненең күзләренә туймастай карап, сөйләшеп утыруларын, я булмаса ул шаян кызны читтән генә күзәтеп, аның бер кәлимә сүзенә зар-интизар булып йөргән чакларын исенә төшерде. Кайчан иде соң әле бу?.. Йөз ел элек булгандыр кебек тоела шулар. Мең ел элек!.. Төштә генә күргән кебек...

Немецның камуфляжлы плащ-палаткаларыннан корылган чуар чаршау ачылып китте. Сәхнә уртасына өч рәт булып тезелгән егетләр ирләрчә көр һәм моңлы тавыш белән «Тәфтиләү»гә Тукайны җырлап җибәрделәр.

Галибанә яктырып, әкрен генә ал таң ата;
Моңланып, хәсрәтләнеп, ялкау гына ак ай бата...

Солдат күңеле кинәт йомшап, мөлдерәмә булып китте. Һәркемнең үз туган ягындагы таңнар, яр өсте талларында өзеп сайрый торган сандугачлар, үз инеше буендагы чыклы болыннар, шул болыннардан таңнарда күтәрелә торган исерткеч хуш исләр, үз авылы күгендәге әз генә кителә башлаган түгәрәк ай һәм аның, таң атканга чынлап та хәсрәтләнгәндәй, әкрен генә сызып югала баруы күз алдына килде. Җыр туктауга гөр күтәреп кул чаптылар. Сәхнә артында җитәкчелек иткән Муса моның беренче кайнар тамыр тибеше булуын сизә иде. Шул киеренкелекне суытмас өчен Тукайны дәвам иттерергә булды. Программа номерларын тиз генә күчергәләп, «Шүрәле» белән «Пар ат»ны башкарырга әлеге укытучыны чыгарды. Бу егет, чынлап та, сәнгатьчә һәм юмор белән укый белә торган кеше иде. «Шүрәле»не өзлексез көлдерүләр һәм алкышлар белән алып барды. Ә инде һәркем диярлек яттан белгән «Җиктереп пар ат...»ны укый башлагач, зал, сулыш алудан туктагандай, хәтта керфек тә какмады; ярату яктысы белән күзләре нурланган һәркем ул шигырьнең һәр сүзен әчennән кабатлап барды. Ниһаять, укучы кулын күтәрде дә: «Тор, шәкерт, җиттек Казанга, алдыбызда бит Казан!» дигән сүзләрне әйтте. Шунда ук берничә тавыш берьюлы кабатлап: «Җиттек Казанга, алдыбызда бит Казан!» дип кычкырып җибәрде. Гүяки алар бу юеш стеналы салкын сарайда утырмыйлар, ә яшь Тукайның үзе белән шул ук атта бергәләп Казанга, газиз туган җирләргә, күңелләренә тулган өзелеп сагынуларны сөйгәннәренә сөйләргә, бишектә калган бәгырь кисәкләрен кочып үбәргә кайталар иде. Шуңа күрә әле һаман тыела алмыйча: «И Казан! Дәртле Казан! Моңлы Казан! Нурлы Казан!»ны тагын кабатладылар.

Дымга сусаган иген туфрагына тирән үткәзеп ява торган эре тамчылы яңгырны күзаллап куйды Муса. «Әле бездә монысы да, монысы да бар!» дигән төсле, яңадан-яңа көчләрне сәхнәгә чыгара торды ул. Теге

бәләкәй генә, бүрәнкә авызлы гына, шадра гына башкорт егете Кылычбайның үз эченә бөтенләй сыймастай, хәтта күкрәк сөякләрен каерырдай калын һәм гайрәтле арыслан тавышы белән:

«Алыслардан балкып һай күренә
Ирәмәлкәй таудың ак ташы...
Кайларда гына йөрмәй, нидәр күрмәй
Ир егеткәй менән ат башы!..» —

дип, шаңгыратып җибәрүе залдагы бөтен кешене таң калдырды. Башы күкләргә чыккан таулар һәм яшерен тарлавыклар арасында кинәт кузгалган давыл, Урал кабыргаларындагы меңәр еллык имәннәрнең серле куышларын курай итеп, ак таш кыя өсләреннән ыргыла торган «очансу»ларның көмеш толымнарын арфа кыллары итеп, болын һәм далалар буйлап аккан Ашказар, Сакмар, Җаек ярларындагы зифа камышларны мең тавышлы сорнай итеп уйнап узгандай булды.

Кайларда гына йөрми, нилэр күрми
Ир егеткәй белән ат башы...

Бу сүзләр, һәркемнең үз хәлен аңлатып, колак төбендә озак яңгырап торды. Соклану һаман сүрелмәде. «Юктыр, моның үз тавышы гына булмас, көчәйтә торган микрофоны бардыр берәр җирендә!..» — дип пышылдашты солдатлар. Алдагы рәттә, махсус креслода утырган фон Зикендорф әфәнде дә уйланып алды: «Әгәр бу азиатны өйрәтеп, дөнья буйлап җибәрсәң, миллионнар ясап булыр иде»,— дип куйды ул, эченнән генә.

Концерт, ахырынача шундый ук пафос белән барып, зур шатлыккуаныч эчендә тәмам булды. Чуар чаршау шыштырдап ябылганнан соң да барлык «артист»ны кат-кат чакырып алкышладылар. Солдатлар бөтенләй терелеп, җанланып китте. Һәркемнең күңеле күтәренке, йөзе якты елмаюлы, бәйрәмчә ягымлы иде. Әйтерсең, алар бөтен бәлаләрдән мәңгегә котылып, үз туган илләренә кайтканнар да Октябрь бәйрәме кичәсенә җыелганнар!

Шушы ук көр кәеф белән төнге урамга чыктылар, кыш салкыны күкрәкләренә кагылды, ләкин берәү дә корышып, үз казармасына тизрәк йөгерү ягын карамады, һичбер төрле әйтү булмаса да, иптәшләре янына тезелде. Берәүнең дә командасын көтмәстән, шул строй кинәт кенә уңга борылып, меңләгән үкчәне бердәй «шап!» итеп орды да урыныннан кузгалды. Кемдер солдатча кыю тавыш белән сузып җибәрде:

Расцветали яблони и груши,
Поплыли томаны над рекой,
Выходила на берег Катюша,
На высокий берег на крутой...

Кайсы җирдән чыкты бу тавыш? Сафның башыннанмы, уртасыннанмы, әллә ахырыннанмы? — берәү дә абайлый алмый калды. Аңа, «эһ» дигәнче, бөтен колонна кушылып, гөрләтеп алып китте. Гүяки коры салам түбәгә яндыргыч «дум-дум пулясе» җибәрделәр. Нечкә генә бер камылга килеп тию белән аның кисәкләре күз ачып йомганчы әллә кайларга чәчрәп киттеләр дә, кинәт бөтен түбәдән гөлт итеп ялкын күтәрелде. Колонна өстендә дә нәкъ шуның шикелле җыр янгыны айкала иде.

Концертның болай узуына һәм куелган максатка бу кадәр уңыш белән ирешүгә шагыйрьләрчә эчке яктылык һәм иҗади горурлык белән куанган Муса иң ахыргы кеше булып караңгы залдан чыгып килгәндә бу җыр тавышын ишетсә дә артык игътибар бирмәде. «Әһә, концерт дәвам итә, ахры...» дип кенә елмайды ул. Ләкин шул ук минутта әче яңгыраган сыбызгы тавышы һәм Шпигельнең колонна тирәсендә утка

баскандай йөгергәләп «Һальт! Ауфһөрен!» [1] дип кычкырулары ишетелде. Муса баганадагы ут яктысынарак атлады. Шпигель әфәнде, нишләргә дә белмичә, һаман чапкалый, һаман кычкырына, хәтта кабурындагы парабеллумын суырып чыгармакчы була иде...

Ә колонна исә, аны бөтенләй күрмәгәндәй, һичнигә исе китмәгән салмак һәм куәтле адымнар белән һаман атлый һәм җырлый бирә. Мусаның күз алдына мәһабәт гәүдәле фил белән чәрелдек тавышлы бәләкәй мәчкәй килеп басты. «Таныш картина!» дип көлемсерәде ул. Әмма бу мәчкәй монда гына шулай ачык һөҗүм ясый алмый, көчсез булып кылана. Чөнки мәҗбүр. Эх, әгәр Двина ярларында булсагыз, ашатыр иде ул сезгә кургашын буткасын!

Сафка тезелгән егетләр, үзләренең шул ышанычлы адымнарын бозмыйча, җырлый-җырлый казармаларына килеп җиттеләр дә, шып туктап, үз бүлекчәләренә таралыштылар. Шпигельгә игътибар итүче яки сүз әйтүче булмады, ул берни дә эшли алмыйча калды һәм шул ачудан Зикендорф янына йөгерде.

— Нәрсә бу, майн һерр? Бунт? Пропаганда, коммунистлар җыры!— дип кычкырды.

Мусаны чакырттылар. Аның ирен почмакларындагы шаян елмаю чаткылары сүрелмәгән иде әле.

— Без бит концертка гына рөхсәт биргән идек, хөрмәтле Гумеров әфәнде,— дип сүз башлады Зикендорф.— Ә килеп чыга нәрсә? Зольдатлар «Катюша» белән маршírен?..

Муса кырт кына итеп Шпигельгә борылды.

— Сезнең агентлар репетицияләрне, әлбәттә, күзәткәннәрдер, һерр гестапо! Безнең «Катюша»ны өйрәткәнебез юк һәм ул программага да кертелмәгән,— диде Муса кыза төшеп.— Ләкин һәр яшь кеше бездә аны үзе белә. Өйрәтүнең кирәге юк. Ул яшьләрнең иң яраткан җыры.

— Коммунистиш! — дип куйды Шпигель, авыз читен почмаклап.

— Туктату кирәк иде алай булгач,— диде Муса, һәр сүзенә басым ясап.— Ә сез шул коммунистиш җырны казармаларга хәтле җырлап кайтырга мөмкинлек бирдегез... Без моны... истә тотарбыз, һерр Шпигель!..

Кинәт мәсьәләнең болайга борылуына гестапочы немец бер агарынды, бер күгәренде. Гадәттән тыш гаҗәпләнгән һәм убыр уты янган күзләре белән Мусага текәлде. Ул аны хәзер үк чәйнәп ташлар иде, ләкин булдыра алмый, ферфлюхте! — Югарыдан килгән.

— Сез?..— диде ул ярсуын йотарга тырышып.— Минем бит атарга хакым юк!.. Ә ул швайн азиатларны болай гына туктату мөмкинмени?..

— Атып карагыз, алар хәзер фюрер солдаты! — дип җавап бирде Муса.

— Шулай да концерт бәласе бу,— диде пошынып әрле-бирле таптанган Зикендорф.

— Юк, әфәнделәр, шнапс биреп, солдатның күңелен үзегез котырткансыз,— диде Муса таш салкынлыгы белән.— Гаепне шуннан эзләгез...

Шпигельнең убырлы күзләре сүрелә төште: ул хәзер шактый ук шүрләп калган иде. Хәйләкәр Зикендорф та аңына килә башлады.

— Ярар, Шпигель әфәнде, юктан мөгез чыгармыйк әле,— диде ул урынына утырып.— Ул җырда әллә ни юк, мин беләм аны... Аннары инде төн дә бит соң... Муса әфәнденең ашыйсы да килгәндер. Ә мин тыйнак кына ужин да хәзерләткән идем, әйдәгез булмаса, чыгыйк теге якка. Утырыйк бераз. Кичтән иртә хәерлерәк, диләр. Калганын иртәгә карарбыз...

[1] Тукта! Туктатырга!

## VII

Иртэгесен Муса торып ишек алдына чыгуга, һәр бинаның стеналарына, капка һәм тәрәзә башларына кара каймалы кайгы флаглары эленгән иде. Нәрсә булды икән, дип гаҗәпләнде Муса, әллә Гитлер кәкрәйгәнме?..

Солдат кухнясында Арыслан аңа бик мәгънәле генә елмаю белән бутка китереп бирде. Тәлинкәсен куйды да ипигә китте, ипи китергәч, кашык алып килде. Нишләгән бүген бу? дип аптырый калды Муса. Ә Арыслан шул киләп сарган арада яңалыкларны учлап-учлап кына ыргыта торды:

— Күрдеңме кара чүпрәкләрне?.. Матур бит! Корыч кала...— Әйтеп бетермәде, ниндидер йомыш табып, кухнядан әйләнеп килде.— Башы беткәннәрнең саны өч йөз мең диме шунда... Безнең грамыт җитми. Тучнысын үзең белерсең әле...— Тагын китеп барды. Горчица белән тоз савыты күтәреп килде. Тары буткасына — горчица! Юри кылана, ахры, бу усал!..— Дистәләп генерал диме... Палкауник-майор, капитаннарның чуты-ние юк ди... — Тагын кухняга кереп, ике стакан күтәреп чыкты.— Чәй эчәсеңме, куфиме?.. Яңа пушты да алып кайттык. Алиш дус сиңа сәлам әйтте... Мине хәзер пуштыга куялар...— Муса нәрсәдер сөрамакчы булып авыз ача гына башлаган иде, Арыслан кофе стаканын күтәреп, китеп тә барды.— Тагын чәй китеримме? — диде ул әйләнеп килүенә.— Ничек, «Кәтүшия» ошадымы? Тәртип бар идеме?.. Кәнсиртне урамда тәгәллик, диде бит кайбер егетләр...

— Рәхмәт,— диде Муса урыныннан кузгалып,— буткаң бик майлы, чәең бик баллы булды. Хәбәрләрең дә шуңа охшаган... Андый киңәшелмәгән чыгышлардан саграк булу яхшы. Күзгә әфәнде кичә төкерткечена тотына башлады. Кешеләрне юкка әрәм итүе мөмкин...

— Ярый, әйтермен үзләренә,— диде Арыслан, тыйнак кына тавыш белән.

Муса, аш блогыннан тышка чыгып, якын тирәдә кешеләр кайнашмавын күргәч кенә җәелеп, елмаеп җибәрде. Каһәр суксын бу буйсынып яшәүне! Кая борылсаң да шул дошман күзләре сине фокустан ычкындырмыйлар кебек. Хәтта чынлап көләсең килгәндә дә качып кына көләргә кирәк. Бик зур сөенеч әйтте бит әле бу Арыслан! Димәкки, Сталинградта немецларга әбиләрен танытканнар! Димәкки, бөтен Германиядә мондый кара чүпрәкләр җилфердәтергә калгач, шап-шактый булып чыккан инде бу эш. Тәбрик итәбез, иптәшләр! Үлем читлекләреннән кулларыбызны чыгарып тәбрик итәбез!..

Мусаның күңеле нечкәреп китте, ике күз төбен ике тамчы яшь пешереп алды, ул аларның очкын бөртегедәй елтырап торуын үз күзләре белән күргән төсле булды һәм тиз генә эчкә куып, күңел төбенә яшерде. Күрмәсен, кайгы яшьләремне күрә алмаган фриц сөенеч яшьләремне дә күрмәсен! Һәм шунда ук бөтенләй икенче төрле кәеф белән үзүзенә сөйли башлады: «Ярамас. Легион шефының хәлен белик, кайгылы чагыдыр — уртаклашыйк. Кичәге ужинда немец коралының куәте өчен күтәрткән француз винолары да бик шәп иде, рәхмәт әйтергә кирәк...»

Штабтагы кабинетка ул килеп кергәндә, Зикендорф үзенең тар яңакларын ике учына кысып, терсәкләре белән өстәлгә таянган иде. Аның ике терсәге арасында иллюстрацияле ниндидер журнал җәелеп ята, битләрендә зур-зур портретлар, һәм шеф әфәнде шуларга күз теккән иде.

— Исәнмесез,— диде борчылган тавыш белән Муса һәм, якын ук килеп, кул бирде.— Бу нинди хәвефле яңалыклар тагын, нинди кара флаглар җилферди тышта, майн һерр?..

Зикендорф, башын күтәрә төшеп, сәлам кайтарды. Муса аның ите кипкән маңгай сөягендәге ике чокырдан караган ике күзендә өметсез

кайгы һәм тәшвишле куркыну шаукымнары күрде. Шеф, сул кулын селтәгәндәй итеп, журнал битендәге портретка күрсәтте.

— Шталинград...— дип куйды ул тирән офтанулы сулыш белән.— Менә, фельдмаршал Паулюс, тагын күпме генераллар, офицерлар, өч йөз меңле зур бер армия группасы, танк, артиллерия дивизияләре һәм, шайтан белсен, тагын нәрсәләр — пленга төшкән, юк ителгән... Мәскәү, коточкыч дәһшәтле һөҗүмгә күчеп, безнең гаскәрләрне Дон аръягына алып ыргыткан. Шулкадәр зур югалту, бөтен Германия күләмендә шундый кайгы, матәм! О, майн Готт! Я не могю!

— Да-а-а, күңелсез хәбәрләр икән шул...— диде Муса, чын кайгыртучы төсле күрсенеп.— Әмма һичнн аңламыйм: хөрмәтле фюрернең шәүкәтле гаскәре Кавказ тауларына басып, гайрәтле пантерадай, Һиндстанга сикерергә тиеш чакта гына... шушындый хәл?..

Зикендорф аңа шөбһәле караш ташлады: нәрсә сөйләнә бу азиат?.. Безнең бәхетсезлектән көләргә маташамы?..

Бу кешеләр һәр икесе дә бер-береннән тизрәк арынырга тели иде. Мусаның тиз генә рәсми сүзләрне бетереп, юлга китәсе һәм шунда берүзе куанып барасы килә; Зикендорфның исә, бу татар чыгып китү белән, өенә кайтып бикләнәсе һәм бер ялгызы гына шешә төбендә уйланасы килә иде. Кая бара бу сугыш? Әгәр алар һәрвакыт шундый югалтулар ясый башласа, нәрсә белән бетәр бу?..

Муса, немецның җанын тырнаган уйларны күзе белән үк укып, сүзен кыска тотты: Берлинга китешли Демблиндәге легион резервына кагылырга теләвен әйтте. Төзелеп ята торган өченче батальонда культура көчләре юк икән. Бәлки, андый егетләр Демблиндә бардыр. Ул аларны өченче батальонга җибәрер, һәм шефның кабул итеп алуына да ышанасы килә...

Немец, урыныннан кузгалып, аның сүзләрен хуплаган кыяфәт белән озатып куйды:

— Яхшы, шулай итәрбез, хушыгыз...

Мусаның китәчәген алдан белгән Актабанов бүлмә ишеге төбендә көтеп утыра иде. Муса аңа сүзсез генә кул сузды да эчкә алып керде. Бүлмә ишеген ныклап япканнан соң гына шат елмаеп җибәрде.

— Я, хөрмәтле Онисим Гурич, нихәлләрегез бар? Кара чүпрәкләр белән котлыйм үзегезне! Ошыймы сезгә?

— Бик ошый! — диде подполковник.— Немец кан йота. Рәхмәт илнең батырларына!

— Бу инде Мәскәү яны гына түгел, ә? Монда колач башка! Немецның өч йөз меңлек армиясен камап алып юк итү һәм берничә фронт буйлап Көнбатышка ыргылу — ничек дип атала инде ул, иптәш Актабанов, сезнең телдә?

— Стратегик һөҗүмгә күчү дип атала, Муса туган!

— Димәкки, немец арт ягына борылды! Моннан соң ул инде яңадан безнең өскә ябырыла алмастыр. Чөнки хәзер безнең чират җитте!.. Болай булгач, сезне озак тотмаслар, халыкны астан хәзерләгез, батальон әзер булсын!

— Тырышырбыз,— диде Актабанов.— Солдат арасында кәеф шәп. Кайбер кече командирларның да кылларын тарткаладым, сүз үтәр сыман. Аннары культвзвод егетләренең берничәсен кабул итәсе иде. Мин алар белән ныклап сөйләштем дә инде — ышанычлы егетләр, таянырга була.

— Ә ничек эшлибез аны? — дип сорады Муса.

— Ансы җайсыз. Аулак урын юк. Мин аларны хәзер клубта калдырдым. Җыр, музыка өйрәнәләр, янәсе. Олы ишектә безнең сакчы булыр, аңа күренмәсәгез дә ярый. Сәхнә артында кинобудка ишеге бар, күз бәйләнә башлагачыннанрак шуннан килеп керегез дә тыңлагыз. Калганын үзем башкарырмын...

— Алайса, ярый,— диде Муса.— Сез хәзер анда йөгерегез. Җыр һәм музыка тавышы клубның тышына да яңгырап торсын. Мин ике минуттан килеп җитәрмен.

— Есть! — диде подполковник солдатча честь биреп һәм ишеккә атлады.

— Бер генә минут,— дип туктатты аны Муса.— Мин сезгә, Онисим Гурнич, менә мондый «хат»лар калдырам.— Ул чемоданыннан алып аңа бер кечерәк төргәк листовкалар бирде.— Яхшы саклагыз. Мин китеп бер атна узгач, солдат арасына таратыгыз, кеше укырдай җирләргә ябыштырыгыз. Моның өчен махсус ышанычлы кешеләр билгеләү сезнең өскә төшә. Караңгы төндә эшләнсен! Яхшы, барыгыз.

Актабанов чыгып китүгә, Арыслан килеп керде. Авызы колакларына җиткән иде аның.

— Шәпме, бәләкәчем! — дип куйды ул.

— Әллә сез минем ишек төбендә чират торасызмы? — дигән булды Муса ачуланган тавыш белән.— Мин министр түгел ич.

— Министрча сөйләшәсең! — диде Арыслан.— Үзе китәргә җыена, үзенә саубуллашырга керү дә ярамый... Мә, менә чүт кенә ризык хәзерләгән идем юлыңа, ач йөрмә тагын.— Ул шинель куеныннан бәләкәй генә төргәк чыгарып, Мусаның чемоданына салды.

— Рәхмәт төшкән кеше син,— диде Муса аны кочаклап.— Онытмам, дускай! Бар, хәзер клубка чап. Анда сине Актабанов көтә. Бик мөһим эш бар....

Арыслан хушлашып чыгып китте. Муса, сабын-сөлге шикелле вак-төякләрен чемоданына салып бикләгәч, өс-башын киенеп, үзе дә клубка юнәлде.

Аның арткы ишектән шым гына килеп керүен берәү дә сизмәде. Актабанов тырышып-тырышып аккордионда уйный, ә калганнар: Кылычбай Киекбаев, Мирәсгать Суфиянов, Арыслан Алыпкулов «Галиябану» көен җырлыйлар иде. Бераздан Актабанов сәхнә ягына күз кырыен гына төшереп алды да көйне өзмичә тегеләрне бер сафка бастырды. Алар, үзләре үк аңлап, култык аша бер-берсенең кулларын кысышып, бик дәү һәм тәвәккәл эшкә тотыныр алдыннан бергә береккәндәй тыгызланышып, тантаналы бер хәлгә килделәр. Муса сәхнә ярыгыннан аларга сокланып карап торды. Җыр әкрен генә тынуга, басынкы һәм киеренке тавыш белән Актабанов кайнар сүзләрен бер-бер артлы тезәргә тотынды:

— Мин — Ватан солдаты — ант итәм: үтерсәләр дә, туган илемә атмам! Ант итәм: явыз дошман кулыннан якташларымны коткаруда җанымны аямам! Ант итәм: тотыла калсам, серемне чишмәм, дусларымны әйтмәм! Яшәсен туган ил!..

Бу соңгы сүзләрен егетләр йөрәк ярсуларын тыеп кына әйттеләр. Шулай да ашкынулы тавышлары, клуб стеналарын җимереп чыгып, ерак урман эчләренә яңгырап киткәндәй булды. Шуңа кушылган кебек, яңадан гармун сайрый һәм җыр түгелә башлады. Муса аларның күз төпләрендә яшь бөртекләре җемелдәвен күрде, үзенең дә күңеле нечкәреп китте: ул аларның һәммәсен дә кочаклап үбәрдәй булып, кыен юлына ашыкты.

Аның серле сукмак буйлап ераклаша баруын тәрәзәгә күзе төшкән Арыслан гына шәйләп калды.

— Сизенгән идем аны...— дип кенә куйды ул.

*(Дәвамы бар.)*

Юстас Палецкис

Литва шагыйре

## Аббас Алеев

1918 елда монда эшче Аббас Алеев атып үтерелде. *(Куйбышев шәһәрендәге бер мемориаль тактага язылган сүзләрдән.)*

Котырырлар дип аклар җиңеп алгач
Самарлылар каушап көттеләр.
Син төрмәдә үлем көттең, Аббас,
Аклар сине алып киттеләр.

Көрәш кызган еллар Россиядә.
Ачлык, юклык хуҗа чакларда
Яшь Советлар иле, һәрбер кала
Чолганышта калды акларда.

Затвор, «пли!» тавышларын түгел,
Син Куйбышев тавышын тыңладың:
— Халыклар төрмәсен итәрбез көл!
Без табарбыз ирек юлларын!

Үзеңә төбәп торган көпшәләрне,
Палачларны түгел, аңында
Яңа дөнья, азат таңнар ямен
Күрдең, Аббас, үлем алдында.

Чирек гасыр узды хезмәт белән,
Тагын сугыш уты илемдә.
Дошман инде шактый үтеп кергән,
Фашист һөҗүм итә Иделдә.

Күтәрелде, Аббас, зур көрәшкә
Синең кебек Иван, Кәримнәр...
Халык, партизаннар, бөтен гаскәр,
Ватан өчен чыкты бар ирләр.

Ватан улы иштер, бер көн монда
Җиңү тавышы килер кырлардан,
Хәбәр итәр: — Идел якларында
Ут боҗрага Берлин чолганган!

Татлы хыял өчен сугышмый ир.
Өмет нуры күктән килмәсен
Бик белә ул,
анын йорты — бу җир,
Ул — тынычлык, бәхет иясе.

Без гашыйклар инде туган илгә
Изге хисе белән күңелнең,
Катнашасың, Аббас, безгә син дә
Зур язмышың белән үзеңнең.

Син яшисең, Аббас, син мәңгелек,
Җыр — дастаннар саклар хәтердә.
Мин Неманнан синең янга килеп
Баш иргә булдым кабреңә.

Ерак түгел, килер җиңү көне,
Балаларга сөйләрбез шунда
Бөек ядкәр итеп Иделдәге
Сугышны һәм синең турында.

Куйбышев — Москва — Вильнюс.

1942.

## Яңа ел

1

— Житте микән әллә безнең вакыт? — диде
Егет шыпырт кына кызның колагына.
Яңа елда бу чак мәҗлес кызган иде.
— Житте микән әллә безнең вакыт? — диде,
Кызның җаны рәхәтләнеп тетрәп китте,
Алсуланды йөзе шатлык нурларында.
— Житте микән әллә безнең вакыт? — диде
Егет шыпырт кына кызның колагына.

2

— Житте микән әллә безнең вакыт? — диде,
Моңсу гына ул чал кергән иптәшенә,
Яңа елда бу чак мәҗлес кызган иде.
— Житте микән әллә безнең вакыт? — диде,
Хатын бу сүзләрдән кинәт тетрәп китте,
Тамып төште ике бөртек күз яше дә.
— Житте микән әллә безнең вакыт? — диде,
Ире моңсу гына гомер иптәшенә.

Рига.
1924.

## Кояш һәм син

Кояш нур сибә, иркәләп сөя,
Кояш җан өрә һәм кояш үбә, —
Кояшны сөям.

Син кояш миңа,
Мин үбәм менә, иркәлим менә
Тик сине генә.

Рига.
1932.

## Җыр

Яшь-яшь сеңелем рута гөлен
Үстерә сулар сибеп,
Чәчәк ата минем сеңелем
Үзе дә рута кебек.

Рута кызлар гөле генә —
Ул әйбәт таҗ үрергә,
Килер сеңелемне күрергә
Егет капка төбенә.

Тик бер кем дә клеверга
Су сипмәс багып, сөеп.
Кызарып кояш баткан кырда
Ул елар башын иеп.

Мин еракта туган җирдән,
Иркен тугайларымнан,
Яшь гомер үтә әрәмгә
Сугыш мәйданнарында.

Тиз көндә чалгыга очрар
Клевер да, ромашка да.
Ә монда чыңлар кылычлар,
Ялтырап чыклы таңда.

Клеверның, бичаракайның,
Чалгы җитәр башына,
Кылычтан алган ярадан
Аврмын мин дә шунда...

Рига.
1919.

*Риза Халид*
Кырым шагыйре

## Идел

Идел дип азмы соң
Шагыйрьләр җырлаган,
Сиңа ул илтифат бик лаек.
Берәүләр шатланган,
Берәүләр моңайган,
Дәртләндер — без дә җыр башлаек.

Әй Идел, урманнар,
Яр-таулар эченнән
Ашкынып һәм шаулап агасың,
Илемдә игелек —
Кодрәтең-көчеңнән,
Халкыма шәфкатьле анасың.

Иге юк, чиге юк
Суларның, ярларның...
Бу сиңа килешә, килешә.
Агалар күз яше
Кебек саф суларың:
— Юл бир, әй! диешә-диешә.

Яшь идем, тарихың
ишеттем, тыңладым,
Күп иде кайгылы җырларың.
Син бездән яшерми
Барын да сөйләдең,
Тирәндә сакланган серләрең.

Күп еллар көчеңне
Эчеңдә тупладың,
— Бумагыз, юл бирмәм, — дидең син.
Шулай да күр, безне
Сөйдең дә хупладың,
Һәм безгә башыңны идең син.

Күрәм мин:
Манзараң мәһабәт, үзгәргән,
Яшәргән кодрәтле күкрәгең.
Җырлар да
Яңгырый яңа шат көйләрдә,
Үзеңдәй киң, ачык күкләрең.

## ӘРМӘН МӘКАЛЬЛӘРЕ ҺӘМ ӘЙТЕМНӘРЕ

Бөртек капмаган тавык йомырканы күп салмый.
Юлга юлдашсыз чыкма.
Дөя кашыктан су эчми.
Бәла белдекле итә.
Бишмәтлек биргәч — эчлек тә сорый.
Хезмәт җимеше — иң татлы җимеш.
Юлдан язган — күзсез калыр.
Йомырка урлый белгән — ат та урлый.
Бабасы яшел җимеш ашаганга, оныгының теше камашкан.
Талашкан этәч симез булмый.
Учында тәбә пешереп ашатсаң да, анаңа син барыбер бурычлы.
Озын юлны энә белән үлчәмиләр.
Тәбә яратам диеп, таба тоткасын үбә.
Авыз иткән эче катык күз күрмәгән майдан артык.
Ничек әйтсәң, шулай ишетерсең.
Теш казып тамак туймый.
Башы авырткан елан юл уртасында ята.
Ауган агач янында урман кисүчеләр күп.
Иртәгә эшләрмен димә, һәр көннең үз эше бар.
Томанлы көн — бүрегә шатлык.
Утны утын җиңә алмый.
Бер чәчәктән яз булмый.
Кимәгән кием үзе туза.
Кара постауны кызартып булмый.
Бер чәчәктән елан агу ала, ә бал корты бал җыя.
Кылыч алынып өлгергәнче, тел башны кисеп ташлый.

Хәтеремдә калырсың:
Үз иттем, бик сөйдем,
Гаҗәеп суларның колачын.
Бер күргән онытмас,
Әй, гүзәл, Иделем,
Синең күк елгалар елгасын!

## Бу гөлне

Үз кулым белән мин утырттым бу гөлне,
Кадерле яздан бер хатирә булсын дип.
Бизәсен яныннан узган һәр күңелне,
Йөрәккә татлы, хуш исләре тулсын дип.

Әй гөлем, чәнечке сабаклы булсаң да
Юмарт син: елмаеп нурларың чәчәрсең,
Көз килгәч — моңаеп, саргаеп сулсаң да,
Йөрәктә һаман да чәчәкләр ачарсың.

### ӘРМӘН МӘКАЛЬЛӘРЕ ҺӘМ ӘЙТЕМНӘРЕ

Үгезенә күрә чыбыркысы.
Бүре даны телдән төшми, ә зыянны төлке эшли.
Кунак — хуҗаның чәчәге: кая тели, шунда куя.
Ишегеңне бикләп йөрсәң, күршем карак димәссең.
Чәчсәң — урасың, күрсәң — беләсең.
Тату яшәү, тыныч тору — барча яхшылыкка анкә.
Ерак туганың булганчы, яхшы күрше белән тор.
Ояла белсә, эт тә ыштан кияр иде.
Намуслы катыйль дә була, намуссыз хаким дә була.
Бүре оясы сөяксез булмас.
Дөя үз өркәчен күрми.
Язын бәрән, көзен чебеш яхшы.
Авызыңны ачканчы, күзләреңне ача бел.
Агып чыккан җирендә агымны туктату җиңел.
Үз кетәгендә чакта, һәммә әтәч тә каты кычкыра.
Курку бар җирдә оят та була.
Чүлмәкче булган кеше — барча чүлмәк патшасы.
Иртә өлгергән җимеш көзне күрмичә кала.
Биргән чагында курыкма, ә алганда оялма.
Бала өчен ата малы — көя төшәр йон кебек.
Озын тел гомер кыскарта.
Хатынсыз өй — сусыз тегермән.
Җәен ирләр ял итсә, кышын терлекләр үлә.
Авыздан кергән аракы эчтән серне чыгара.
Бүредән курыксаң — сарык асрама.
Балта йөзенә суксаң — үз кулыңны кисәрсең.
Диңгез кичкән — елга суында батмый.
Ялкау кул буш корсак сыйпар.
Тинтәк белән типтергәнче, аңлы белән таш ташы.

## Күренмәс җепләр

Әгәр яшь ай кебек елмаеп көлсәң син,
Һәм кояш нурында янса шат күзләрең,
Сиңа дип, кадерлем, әгәр дә белсәң син,
Түгелә күңелемнән мәхәббәт сүзләре.

Я кинәт болытлап, чытылса чыраең, —
Күңелеңне юату минем бар теләгем.
Белмим бу чакларда ничек мин чыдаем:
Мәрмәр таш түгел лә дулкынлы йөрәгем!

Әгәр син моңайсаң — авыр йөк алам мин,
Куансаң — очам мин, арынып йөкләрдән.
Кайчакта ләззәтле уйларга талам мин:
Арынмас идем шул күренмәс җепләрдән.

Н. Арсланов тәрҗемәләре.

### ӘРМӘН МӘКАЛЬЛӘРЕ ҺӘМ ӘЙТЕМНӘРЕ

Аю урманга үпкәле, ә урман берни белми.
Диңгез суын кашык белән түгеп бетереп булмый.
Ике ахмакка бер акыл җитә.
Беренче күкәен күреп тавык үзе дә көлә.
Көн белән алмашынмаган төннәрнең булганы юк.
Дошман китергән хәбәргә колак салма.
Беренче кабым тәмлерәк була.
Җыйган чакта кашыклап, өләшкәндә чүмечләп.
Йөрәк әрнемәсә — күз еламый.
Әбәт үткәч, ботка бәя булмый.
Кызы китеп югалгач — муенсасын кызганып елый.
Агым суда пычрак җыелмый.
Балык кармакка каба, ә кеше — төче сүзгә.
Чучкага йолдыз күренми.
Карга күзенә күренсә, бөртек шытып чыга алмый.
Үчле кеше иртә картая.
Малга — хуҗа, улга ата кирәк.
Авыздагы сүз — синеке, авыздан чыкса — илнеке.
Юаш ат каты тибә.
Этнең аксап йөрүе бүре күргәнче генә.
Гадел кеше кыл булса да өзелми, бүрәнәдән юан ялганчы да сынмыйча калмас.
Тешләгәннең артында тор, типкәннең алдында бул.
Җирнең дә колагы бар.
Күз күргәнне йөрәк тә тели.
Кипкән кизләүнең суы кадерле.
Кара хәреф ак бәхетле итә.

Сайлап тәрҗемә итте: Зәки Нури.

# АФРИКА ХИКӘЯЛӘРЕ

*Көньяк Африка әдәбияты, бигрәк тә аның прогрессив прозасы икенче бөтен дөнья сугышыннан соңгы чорда, милли азатлык хәрәкәте киң җәелгән илләрдә аеруча уңышлы үсә башлады. «Каршылык күрсәтү әдәбияты» сафларына баскан прогрессив язучылар үз илләре алдында торган төп тарихи проблеманы: туган халыкларының бәйсезлеккә омтылышын, гаделсезлеккә каршы көрәшен чагылдырган романнар, повестьлар иҗат иттеләр.*

*Шулай да «Каршылык күрсәтү әдәбияты»нда хәзерге вакытта хикәя — киңрәк җәелгән жанр. Прозаның иң оператив һәм сугышчан жанры — кыска хикәя һәм новелла язучыга көн үзәгендә торган актуаль проблемаларны хәл итәргә, бөтен халык көрәшендә турыдан-туры катнашырга, колониализмның ерткычлыгын, расачылыкның кыргый хорафатларын ачып салырга мөмкинлек бирә.*

*Милли азатлык хәрәкәте көчәя барган саен, Африка әдәбияты белән кызыксыну да елдан-ел арта; колониаль халыкларның көрәшен чагылдырган әсәрләр төрле телләргә тәрҗемә ителеп киң таратыла.*

*Татарстан китап нәшрияты быел Африка язучылары хикәяләрен һәм новеллаларын татар теленә тәрҗемә итеп чыгарырга әзерләнә. Журналыбызның бу санында укучыларга шул китаптан Көньяк Африка язучыларының ике хикәясен тәкъдим итәбез.*

*Элфред Хатчинсон*

Көньяк Африка Союзы.

## Лиззиның гаебе

Каршы искән каты җил Нкоси Лиззиның битенә коры үлән бөртекләре китереп бәрә. Лиззи аларны буш кулы белән сөртеп ала. Башын күтәреп югары карасаң, күк читендәге тар гына болыт артына баеп барган кояшның кансу-кызгылт нурлары аның күзләрен чагылдыра.

Күксел чаерлы агачлар үсеп утырган әрәмәгә житкәч, ул түмгәккә абынып туктады. «Юк, мин гаепле түгел»,— дип уйлады ул. Аңа җавап биргәндәй, җил тирән сулап куйды, агачлар биек ябалдашларын чайкадылар.

Әнә алар икесе дә шунда, ул калдырып киткән җирдә торалар. Баягынак Лиззи бу ханымның берни күрмичә, берни ишетмичә, коты алынган хәлдә йөгергәнен күргән иде. Хәзер аларны эзләп тапкач, аның күңелен тагын кызгану хисе тетрәтте. Кечкенә кыз, әнисенең тезләренә сыенып, үксеп тора, әмма аның елаганы ишетелми, коры яфракларны кыштырдатып искән җил тавышында югалып кала иде. Лиззиның күз алдына кайчандыр журналда күргән аяныч балалар сурәте килеп басты.

Ак тәнле хатын озак елап кызарган күзләрен күтәреп Лиззига карады һәм хәлсез тавыш белән африканс телендә:

— Ул һаман елый да елый,— диде.

Лиззи алып килгән әйберләрен салам өстенә куйды. Баеп барган тонык кояш нурлары яктырткан соргылт тузанлы агачлар арасында

бу хатын бигрәк тә моңсу һәм кызганыч иде. Сәләмә күлмәк, тузып беткән чалыш туфли кигән. Кызының аяклары былчырак... Лиззиның йөрәге кысылгандай авыртып китте. Ханымның сул яңагындагы кан инде кибеп каткан, кара көйгән төшләре куксел төскә кергән иде.

Лиззи баланы кулына алды да иркәләп тирбәтә башлады һәм базмыйча гына:

— Ханым, мин сезгә ашарга алып килдем. Менә монысы кызыгызга сөт,— диде.— Ханым, менә бу күлмәкне киегез... Салкынайта төште.

Җил аның сүзләрен читкә алып китә иде.

— Мин ничек киим инде... Ә син нәрсә киярсең?

— Минем өчен борчылмагыз... Миңа болай да җылы,— диде Лиззи елмаеп. Ак тәнле хатынның әле һаман икеләнеп торуын күреп өстәп әйтте: — Чиста ул, мин аны бары бер генә кигән идем.

Лиззи ханымның баягынак ире белән әрләшкәнен хәтерләде һәм баеп барган кояшка борчулы карап алды: гадәттә бу вакытта баас[1] үзе кайтып җитә торган иде.

— Ханым,— диде ул акрын гына,— мин хәзергә китим, бераздан сезне алырга әйләнеп килермен... Тиздән баас кайтып җитүе бар.

Дала буйлап барганда ул Морокодагы өйләрендә үзен ни көткәнен күз алдына китерде... Иске калай түбәле иске өйнең стена ярыкларыннан сызгырып җил өрәдер. Әнисе каты йөткерә-йөткерә учак янында кайнашадыр. Былчыранып беткән энесе белән сеңелесенең күз төпләре батып кергән... Һәм менә шулар янына теге, берни дә күрмичә, берни дә ишетмичә куркып йөгергән ак тәнле хатынны ничек алып кермәк кирәк.

Бу күренешне онытырга теләгәндәй, Лиззи башын кагып куйды, авыру әнисенең: «Акылдан яздыңмы әллә?.. Акчаңны да, күлмәгеңне дә биргәнсең»,— дип әйткән сүзләрен ишеткәндәй булды. Ярар инде, зыян юк. Лиззи аңа: «Их, әни, аңларга гына теләмисең, минем урында булсаң, үзең дә шулай итәр идең. Минем өчен алар да шулай итәрләр иде»,— дип җавап бирер. Моңа каршы әнисе: «Мохтаҗлыклары төшкән чакта гына без аларга кирәк булабыз»,— дип күңелсез генә елмаеп куяр...

Биек агачларның тынгысыз күләгәләре кояшның соңгы нурларын, комсыз бик зур мәче ялап алгандай, сүндерде. Агачлар очында йолдызлар чайкала башлады.

— Ханым, менә мин килеп тә җиттем. Озак көттергәнем өчен гафу итегез инде,—диде Лиззи.

Өйгә кайтып барганда, Лиззи кечкенә кызның салкыннан тешләре шак-шак килүен ишетте. Ә ханым аның җылы күлмәген кигән иде. Лиззи шуңа бик шат иде.

Ишек төбенә килеп җиткәндә, Лиззи кинәт куркуга төште. Әйтерсең лә, ул сөяркәсен яшертен генә өенә алып керә. Ханым белән кыз кергәч, үз куралары аңа бигрәк тә ярлы һәм кызганыч күренде. Бу хәерчелек өчен гафу үтенергә теләгән сыман, Лиззи уңайсызланып кулларын уып алды һәм кечкенә кызга ягымлы елмаеп карады. Ләкин кызчык кашларын җыерган көе тик утыра бирде. Лиззи примуста аш җылытып алды. Кухнядан пычак, чәнечке алып чыкты. Ханым аңардан:

— Ә син нәрсә ашарсың соң? — дип сорады.

— Ханым, мин кич белән ашамыйм... Юаная башладым, гәүдәм ямьсезләнүдән куркам,—дип, Лиззи таза ботларын сыйпап алды һәм күзләрен кыса төшеп оялчан елмайганнан соң: — Мин кухняда бераз капкалап алган идем,— дип җитди генә өстәп куйды.

[1] Хуҗа, түрә.

Ятакта утырган ак хатын белән кызчыкка карауга, аның тамагына төер тыгылгандай булды. Кыяфәтләре бик тә бәхетсез, боек, кайгылары йөзләренә чыккан иде. Африкалылар иң авыр бәла-каза килгән чакларда да болай булмый. Кара тәнлеләр кайгы-хәсрәтсез тормыш бардыр дип уйламыйлар да бит. Гәрчә ара-тирә кайгыдан качып котылырга тырышсалар да, барыбер булдыра алмыйлар.

— Әни, бу безнең белән бергә йокларга җыенамыни? — дип сорады кызчык.

— Әдәпсезләнмә, Мэри!

Лиззи кая карарга белми уңайсызланып калды.

Төнлә белән ак тәнле хатын еларга кереште. Башта ул үксеп кенә елаган иде, аннары кычкырып еларга тотынды һәм идәндә йоклап яткан Лиззины уятты. Лиззи аны тынычландырырга, кайгысын онытырырга теләп:

— Ханым, еламагыз...— дип юатырга тырышты.

Төнге тынлыкта Лиззи — Вреддедорп, Мейфер, Браамфонтейн, Ньюлендс йортларында яшәүче бәхетсез хатын-кызларны хәтерләде... Үзләре ише ак тәнлеләрчә яшәр өчен алар күпме газап чигәләр. Шулай да кара тәнлеләрне күрә алмыйлар, үзләренең бозыклыгын белгән өчен аларны икеләтә дошман итәләр. Ак тәнле булулары белән борын чөеп йөриләр. Ул йортлардан еш кына шәһәр паркындагы эскәмияләргә барып җитәләр, сукырлыкка, бозыклыкка баталар. Һәм аннары — бөтенләй хәрап булалар.

— Ул мине чак кына үтермәде бит,— диде ханым еламсырап.— Мин урамда барганда, әйтерсең лә...

— Үтәр-китәр, ханым.

Тагын шул коточкыч күренеш күз алдына килеп баса.

— Иртәгә барысы да җайланыр.

Коты алынган хатын берни дә күрмичә... кара тәнлеләрне күрмичә чаба... көндәгечә — күрмичә... Лиззины өметсезлек баса... Әнисе авыру, әнисе белән сеңелесе ач... Аларга ярдәм итмәкче булып бар көченә тырышып карады ул, ләкин бар да юкка гына булды. Бу ак тәнле хатын белән бергә үзен дә кызгана башлады.

Каты итеп ишек шакый башладылар. Лиззи куркып сикереп торды.

— Ачыгыз! Полиция!

Лиззи куркынып ханым яткан караватка карады.

— Ванг Хом.

Ишеккә тагын бәрделәр, буылган тавыш белән:

— Кара шайтан, кит аннан! — дип акырдылар.

Лиззи ишекне ачуга бүлмәгә полицейский атылып килеп керде. Кул фонаре белән яктыртып карады да:

— Дуңгыз кебек йокы симертеп ятасың! — дип сүгенде.

Лиззины читкә кагып караватка ташланды. Ачуыннан сулышы кысылып одеалны тартып алуга, кинәт хәрәкәтсез калды. Акрын гына сузып:

— Я аллам... Я рабби...— диде.

Тагын бер ак тәнле полицейский килеп керде. Ау эте кебек еш-еш сулый-сулый:

— Әһә, эләктердекме! — дип шатланып кычкырып җибәрде.

Ятакка, идәнгә карап алды... Эчке газаплану һәм түбәнчелек белән диярлек әйтеп куйды:

— Я аллам... Я рабби...

Лиззига алар бөтенләй игътибар итмәделәр. Коты очкан һәм моның ни белән бетәсен белмәгән Лиззи дер-дер калтырый иде.

Тышкы яктан аяк тавышы ишетелде.

— Баас...

— Бар, чык та машинада көт! — диде ул түрәләрчә кырыс кына итеп, аның тавышы янаулы яңгырый иде.

— Тыңлыйм, баас...

Полицейскийлар карашып алдылар. Аннары караватка, идәнгә карадылар. Ишек янында басып торган Лиззи баасның:

— Барысы да аның эше... Бу кара хәшәрәтләр тиздән безнең бөтен шәһәребезне үзләренең локациясенә әверелдерәчәкләр,— дип әйткәнен ишетте.

Бүлмәдән сөйләшкән тавыш ишетелә иде. Лиззи ак тәнлеләрнең күзләрен, чәнечкеле салкын карашларын һич тә онытa алмас. Баас сержантны урамга дәшеп чыгарды. Алар анда акрын гына сөйләшә башладылар.

— Шайтан белсен...

— Менә кая барып җиттеләр... Түзәр хәл калмый инде...

— Шайтан белсен, ниләр генә эшләмиләр... Үзләрен безнең белән тиң санныйлар да...

— Ә бу кара шайтаны ник бер сүз әйтсен, ичмасам...

Лиззи калганын ишетә алмады, куркудан һәм хурлыктан аның шаулап башы авырта башлады. Һәм кинәт бик якты ут балкып киткән кебек, ул барысын да ачык күрде, үзенең ак тәнлеләр законын бозганлыгын аңлады. Ак тәнле хатынны кызганды бит ул... Бу ак тәнле ирләрнең күзләре әнә шуның өчен боздай салкын карыйлар. Ниндидер гыйфрит Лиззига: «Әйттем мин сиңа... әйттем...» — дип пышылдый, ә төнге җил шул ачулы сүзләрне бөтереп йөртә иде.

Баас караватта яткан ак тәнле хатынга:

— Синең монда икәнеңне белмәдем мин... Бу кара шайтан миңа әйтмәде,— диде, Лиззига ачулы караш ташлап.— Әгәр син булмасаң, безнең илдә кара тәнлеләрне нишләткәннәрен күрсәтер идем мин аңа...

Полицейский аның сүзләрен җөпләп башын селкеп куйды. Баас үпкәләгән җылы тавыш белән:

— Син — ак тәнле хатын, монда калырга тиеш түгел,— диде.

Алар ханымны үзләре белән алып киттеләр. Машинага утыртырга алып чыкканда полицейский кечкенә кызның кулыннан сыйпады. Ак тәнле хатын ишектән чыгып барганда борылып карамакчы булган иде. Әмма баас аны Лиззидан яклап калырга теләгәндәй:

— Кирәк түгел!.. Кирәк түгел!..— диде.

Куркудан коты очкан Лиззи көчкә аңына килде. Йөрәге өзелгәндәй сызлый башлады. Аның күңелен җәберләп киттеләр. Ул таланган, анадан тума чишендерелгәндәй калды. Иелеп урындыкка утырды да куллары белән йөзен каплады. Гыйфрит тагын пышылдарга тотынды.

Лиззи ярсып үз гаебен акларга дәлил эзләргә кереште. Аңа бу эшкә җил һәм куаклар фатиха бирде бит. Һәм аның күз алдына тагын әлеге таныш күренеш килеп басты: әнә коты очкан ханым берни дә күрмичә, ишетмичә чаба... Лиззи хәзер ул очрашуны онытырга маташмый, тагын да ачыграк итеп күз алдына китерә генә... Һәм шунда ук ул уянып киткәндәй булды, һәрнәрсә үз урынына барып урнашты һәм аның күңелен изрәткеч чиксез-кырыйсыз хәсрәт басты. Йокларга ятарга әзерләнгәндә үзенә-үзе:

— Ничек кенә булмасын, хәзер мин җиңеләеп калдым,— дип әйтеп куйды.

Менә ул урынсыз да калды. Иртәгә тагын эш эзләп чаба башларга туры киләчәк.

*Филис Альтман*

Көньяк Африка Союзы.

# Шимбә көн кич белән

Йапи Грейлингка унтугыз яшь инде. Шимбә көн житкәнне атна буе түземсезләнеп көтә.

Бүген ул эштән төш вакытында кайтты. Ашык-пошык кына аш капкалап алды да, әнисе белән апасыннан ишетелер-ишетелмәс кенә гафу үтенеп, тизрәк ванна бүлмәсенә кереп китте. Анда эш киемен салып ташлады, трусик һәм майкадан гына калгач, әйбәтләп битен юды, тешләрен чистартты, тамагын чайкады. Аннары акрын гына сызгыра-сызгыра үз бүлмәсенә керде, буй-буй кара сызык төшкән уттай кызыл күлмәген сайлап алды, ботларына ябышып торган тар яшькелт-кара чалбар, аксыл шәмәхә оек, сары туфли киде. Муенына салынып төшкән һәм нык кына майлап йөрткән аксыл куе чәчен тараган вакытта ишектән әнисе күренде.

— Тагын киногa жыенасыңмы? — диде ул үпкәле тавыш белән.

— Әни, шимбә көнне кинога барганымны беләсең ич инде.

— Кино, уф, бетмәс кино булды инде ул. Шайтан уйлап чыгарган ул нәрсәне. Кызу көндә караңгы залга жыел да язык картина — шәрә хатыннар карап утыр, имеш.

Йапи, берни дә әйтмичә, көзгегә таба борылды да игътибар белән тешләрен карарга тотынды. Әйе, хатын-кызлар. Бөркү, караңгы зал, экранда мәхәббәт мажаралары, янәшә утырган кызның шома боты, йомшак калку күкрәге.

Йапи әнисенә аркасы белән тора бирде. Ләкин әнисе әле һаман чыгып китәргә жыенмый иде.

— Мәрхүм әтиең исән булса... Ул сине адәм рәтле, динле кеше итеп үстерергә тырышкан иде.

— Ни пычагыма ул, әни?! Ә кинонын нәрсәсе начар соң?

Әнисе үпкәләп елап жибәрде:

— Шулаймыни, син әле көфер сүзләр әйтәсеңмени! Ник ходай мине шулай газаплый икән?

Йапи ачуы кузгалуын сизде, ризасызлык белән әнисенә борылып карады. Тагын шул бер балык башы дип уйлап куйды. Әнисенең ишеккә сөялеп акрын гына елаганын күргәч, ачуы басылды, күңелендә кызгану хисе уянды. Әнисе аның бик ябык, чырайсыз һәм кызганыч иде. Ябык гәүдәсенә озын кара күлмәк кигән... Йапи, аның янына килеп, иңбашыннан кочаклады:

— Әни, я, елама инде,— дип юатырга керешге.— Кинога бару бер дә язык түгел ич. Минем дусларым барысы да йөриләр.

— Ә син әниеңне оныттыңмыни? Миңа ни эшләргә? Өйдә бер үзем утырыргамы? Хендрина Летти янына китте. Әтиең исән булса, болай булмас иде. Хәзер мин бер ялгызым, ә әниегезне бар дип тә белмисез.

— Әни, һич тә алай түгел,— диде Йапи уртәлә башлап.— Я, без нишләргә тиеш соң? Син беркая да барырга теләмисең ич. Нигә менә әбиләргә барып кайтмыйсың?

— Мин анда көн саен йөри алмыйм бит инде.

— Я, ярар, әни. Ә Хендрина ник китте соң? Синең янында утыра алыр иде ләбаса. Ул кыз кеше, һәрвакыт әнисе янында булырга тиеш.

— Хендринага кеше арасында күбрәк булырга кирәк. Аңа инде

егерме биш яшь, әле һаман кияүгә чыкмаган. Гел өйдә утырып кеше күзенә кайчан күренсен ул?.. Ә болай аңа мин комачаулый дип беркем дә әйтә алмый.

— Я, ярар. Анысы да дөрес! Ләкин, әни, мин дә егет кеше бит. Минем дусларымның берсе дә өйдә утырмый.

— Ярар, алайса, бар. Бер үземне генә калдыр да кит,— дип анасы күз яшьләрен сөртеп алды, тамагына тыгылган үпкә төерен йотып җибәрде.— Мин өйрәнгән инде... Бар, кинонда бар.

— Әни, кара әле,— диде Йапи теләр-теләмәс кенә,— иртәгә иртән бергә чиркәүгә барырбыз.

Ананың күзләре яктырып китте:

— Балакаем, тәүфыйклы шул син,— дип пышылдап улын кочаклап алды.

Бу иркәләүгә Йапиның кәефе генә кырылды. Әнисе аны менә тагын үз тозагына эләктерде. Һәр шимбә саен диярлек шул хәл кабатлана: әнисе елый башлый, һәм Йапи аның белән чиркәүгә барырга сүз бирә. Фу, шайтан белсен инде. Хәзер менә соңга кала бит ул. Йапи тиз генә әнисен үбеп, урамга атылып чыкты да шәһәр үзәгенә бара торган трамвайга йөгерде.

Трамвайга кереп утыргач, ул әнисе белән сөйләшкәнен шундук онытты, бүген кич булачак рәхәт дөньясына чумды. Дусы Дэниел Босхофф белән алар гел шулай итәләр: бер кергән кызны икенче тапкыр кинога чакырмыйлар, шуңа күрә башта касса янындагы чиратны бик җентекләп карап чыгалар. Җәйге җиңел күлмәк кигән саф күзле кызларга тартынмыйча карап арлы-бирле йөриләр, каш сикертәләр. Үзләренә ошаганнарны сайлап алгач, алар инде сыналган, ышанычлы алым белән эш итәләр.

— Гафу итегез, хөрмәтле ледилар,— дип эндәшә аларның берсе, ә кызлар хихылдап көлә башлыйлар.— Үзегез күрәсез, без соңгарып килдек, урынсыз калабыз бугай... Безгә дә билет ала алмассызмы?

Кызлар бик теләп риза булалар. Янәшә дүрт урын. Ут сүнү белән барысы да бик җиңел башлана. Башта бераз кулыннан тотып торасың, сыйпаган буласың, аннары кул үзеннән-үзе ботка шуып төшә... Ул нәкъ шул моментны ярата: кыз кинәт сискәнеп, читкә тайпылып куя. Кайвакыт, әлбәттә, күпне күргәненә дә эләгәсең. Бер көнне әнә кара кучкыл тәнле кыз аның кулына хәтта үзе башлап тотынган иде... Андыйлар янына һәркайчан барырга була, шуңа күрә алар аны кино тирәсендә күрергә теләмиләр. Йапи белән Дэниел кызларны бик ирексезлиләр дип әйтеп булмый, әлбәттә. Юк, алай түгел. Нәкъ эти-әниләре уйлаганча, алар — әдәпле кешеләр бит, хатын-кызны ихтирам итәләр.

Йапиның уйлары тагын әнисенә әйләнеп кайтты һәм ул горурланып куйды. Әйе, ул ана җанлы кеше, әнисе белән чиркәүгә йөри, аның күңелен күрә. Шул ук вакытта ул егет кеше, үзенең егетлек хокукын, кызлар янына бару хокукын да саклый белә. Чынлап та, көннең-көн буе әнисенең итәгенә тотынып кына утырырга ул бала түгел ич инде. Ул үзен шатлык дулкыннарында тибрәнгән кебек хис итте, йодрыклары белән күкрәгенә суккалап аласы килде. Ул егет кеше, яшь бит әле, яшьлеге ташып тора. Һәм алда аны шатлык тулы озын гомер көтә.

Тукталышта аны Дэниел түземсезлек белән көтеп тора иде. Трамвайдан сикереп төшкәч, алар бер-берсен күздән кичерделәр. Йапи кебек үк, Дэниел да ак тәнле егет — озын буйлы, киң җилкәле, тик чәче белән кашы гына аксыл түгел, коңгырт. Ул алсу күлмәк, күгелҗем чалбар, яшел оек һәм кара туфли кигән. Озын бөдрә чәчләре маңгаена салынып төшкән.

— Соңга каласың, картлач,— дип ачуланып каршылады аны Дэниел.

Аның сүзләренә ышанырга теләгәндәй, Йапи әйләнә-тирәгә карап алды. Һәр шимбә көндәге кебек, Иоганнесбург бүген дә бушап калган иде. Тыгылышып җәяүлеләр йөрмәгәч һәм машиналар агылып тормагач, шәһәр үзәге ничектер сәер тоела. Кибет ишекләре ябык, авыр йозаклар элеп куелган. Ювелир магазиннарының тәрәзәләренә тимер челтәр ябылган, сакчы негрлар үз постларына баскан. Ике-өч машина үтеп китте. Маркет-стригтан шаулап трамвай узды. Туктalышта караңгы чырайлы кешеләр тора. Якында гына ак тәнле яшь егет белән бер кыз витрина карый, почмакта берничә негр сөйләшеп тора иде.

— Ачуланма инде. Тагын әни аркасында соңладым,— диде Йапи.

Алар ашыгып кинога таба киттеләр. Алардан алда култыклашып бер ир кеше белән бер кыз бара иде. Озын зифа буйлы, бөдрә кара чәчле кыз, ботларын уйнатып, бөгелә-сыгыла бара. Ләкин ир кеше дусларның икесенә дә килбәтсез күренде. Аның муены да, куллары да көрәнсу-соры иде.

— И ходаем! — дип кычкырып җибәрде Йапи.— Я аллам! Син күрәсеңме?

— Күрәм,— диде Дэниел караңгы чырай белән.

— Ак тәнле кафр[1] белән...— Йапи үз күзенә ышанмыйча аптырап калды. Менә шунда, Иоганнесбург уртасында, бөтен кеше алдында... култыклашып баралар...

Дэниел Йапига башын гына кагып куйды.

— Киттек.

Ир кеше белән кызны алар тиз генә узып киттеләр дә чат башына барып җиткәч, туктап, тегеләр якынайганны көтә башладылар. Ялгышу мөмкин түгел: кызы — ак тәнле, ир кеше — ак тәнле дә түгел, кафр да түгел, ә көрәнсу-соры тәнле кабахәт мулат[2] иде. Күрче бозыкларны, култыклашып киләләр бит!

Көтмәгәндә кузгалган ярсудан Йапига кызу булып китте. Күңелендә ят тойгы — бу фахишәгә каршы кыргый ачу кузгалды, башка кызларны ярсып яклыйсы килде. Күз алдына хәлсез, ябык әнисе килеп басты һәм тамырларында каны бозланып туңгандай булып китте. Бу көрән куллар кызның ак тәнен иркәли, күкрәкләренә кагыла, Йапи һәм Дэниел үз кызлары белән эшләгәннәрнең барысын да эшлиләр бит... Йапиның тешләре шыкырдап куйды.

Тегеләргә юл бирмичә, дуслар тротуар уртасында тордылар. Дүртесе дә бер-берсенә карап калдылар.

— Гафу итегез,— диде ир кеше.

— Гафу итәрмен мин сине, бозык җан,— дип Йапи йодрыгын күтәрде дә мулатның битенә кундырды. Хурлыгына түзә алмыйча бөтен ачуына сукты ул. Мулат куллары белән йөзен каплады. Кызы каты кычкырып җибәрде:

— Туктагыз! Туктагыз! Сез аңа ни өчен тиясез?

— Менә шуның өчен,— диде Дэниел мулатны бугазыннан эләктереп. Аннары бар көченә яңагына сугып җибәрде, мулат, башы белән чакылдап, бетон стенага бәрелде.— Монысы аңа ак тәнле кыз белән сөйрәлгән өчен.

Әле генә буш күренгән урамда шулкадәр халык каян килеп чыккандыр: алар тирәсендә вагон вожатыйлары, кондукторлар, ак тәнле яшүсмерләр, өлкән яшьтәге ак тәнле ханым һәм бер төркем өнсез негр җыелып өлгерде.

Дэниел мулатны тотып алды да кулларын артка каерды. Йапи аңа тагын сукты һәм мулатның йөзе канлы җәрәхәткә әверелгәнен күрде.

---

[1] Кафр — Көньяк-көнчыгыш Африкада яшәүче халыклар.

[2] Мулат — ак тәнле белән кара тәнле кушылудан туган кеше.

Суккан саен ул зәһәрләнә бара, колагында кан катырак шаулый иде. Әнә ул нинди баһадир икән, исең китәрлек, көче дә аның — утыз кеше не җиңәрлек икән...

Кондукторлардан берсе йодрыгы белән әсәрләнеп учына суга-суга:

— Шулай кирәк! Бир үзенә! Тагын берне! Акылга утырт! — дип акыра иде.

Кыз колак тондыргыч ачы тавыш белән:

— Туктагыз! Мин үзем дә сары тәнле! — дип өзлексез кычкыра иде.— Туктагыз! Ләгънәт төшкән ерткычлар! Сезгә әйтәләр бит: мин үзем дә сары тәнле

Әсәрләнгән ханым үз янындагы бер ачык авызның кулын тартка-лый-тарткалый:

— Полиция чакырырга кирәк. Тотарга да полиция чакырырга ки-рәк,— диде.

Әмма тегесе аның кулын кагып кына җибәрде. Негрлар бу тама-шага тирән борчылу белән сүзсез генә карап торалар иде. Йапиның күз янына кара әйбер килеп бәрелде. Кыз аның каршында сумкасын бол-гый-болгый:

— Мин сары тәнле ич!! — дип кычкыра иде. — Мин сары тәнле! Тук-тагыз!

Ул Йапиның иңбашына тотынды да:

— Мин сары тәнле бит! Сары тәнле! — дип чәрелдәп кычкырып җибәрде.— Мин сары тәнле!..

Йапиның куллары салынып төште, ул тәмам хәлсезләнеп калды. Дэниел кулыннан ычкындыргач, мулат тротуарга ауды. Кыз иелеп аның башын саклык белән иңенә салды да битендәге канны сөртә башлады. Аның күзләре йомык, кабагы шешкән, авызы-борыны җимерелгән, үзе аңын югалткан диярлек иде.

Төркем тарала башлады. Ак тәнле ханым гына әле һаман:

— Чынлап та полиция чакыртырга кирәк,— дип әйтеп тора иде.

Ләкин аны беркем дә тыңламый иде. Вожатыйлар һәм кондуктор-лар көлешә-көлешә вагоннарга таралыштылар. Теге бик кызыксынып күзәткән ачык авыз гына калды һәм акайган күзләре белән әле Йапи-га, әле Дэниелга диванадай карап тора бирде. Бөтен төркемнән бары ул гына һәм бераз читтәрәк борчылып торган негрлар гына калды.

Тезләнеп торучы шашкан кызга Йапи төштә күргәндәй гаҗәпсенеп карады. Аннары ул үзенең күгәреп чыккан канлы кулларын, канга буялган күлмәген күрде. Дэниел көчкә тын ала, ул да канга буялып беткән иде. Йапиның күңелендә кинәт зәһәр ярсу кузгалды, ахмаклык белән шушы сары сөйрәлчекне ак тәнле кыздан аера алмаган өчен үзенә бик каты ачуланды. Әмма мисез аңгыралар да соң алар икесе дә! Ул да, Дэниел да. Аның сары тәнле икәнлеге бер чакрымнан күре-неп тора бит. Иреннәре калын, янбашы нинди киң сары сөйрәлчекнең! Берне кундырырга иде дә, анасы-атасы белән сүгеп, тротуарда ук көч-ләргә иде үзен!

Кыз тиз генә сикереп торып аның иңбашына тотынды да:

— Сез, азгын ак хайваннар, моның өчен җавап бирәчәксез,— дип кычкыра башлады.— Мин сезне утырттырачакмын. Без сезне судка би-рәчәкбез, бөтен зыянны түләтәчәкбез!

Йапи аның кулын этәреп җибәрде. Кара син аны, сары сөйрәлчек-не, куллары белән кагылмакчы була бит!

Дэниел чак кына башын кагып:

— Әйдә, тайыйк,— диде.

Алар ашыкмыйча гына китәргә кузгалганнар иде, кыз тагын Йапи-га ташланды:

— Юк инде, ычкына алмассыз! Мин сезне яптырачакмын! — дип тагын кычкырырга тотынды.

Йапи кире борылып, каты кизәнеп күкрәгенә сукты, кыз стенага барып бәрелде. Йапи тизрәк китеп барды. Дэниел инде почмакка борылган иде. Йапи килеп җиткәч, алар бар көчләренә чаба башладылар.

Ике квартал чапканнан соң, бәдрәфкә кереп канлы кулларын юдылар. Күлмәк һәм чалбарларындагы тапларны да бетермәкче булып маташканнар иде, әмма берни дә чыкмады.

Моңарчы бер сүз дә дәшми торган җирдән кинәт икесе берьюлы сөйләргә тотындылар:

— Соңга калдык инде...

— Бу кыяфәт белән ничек барабыз?..

Алар күлмәк-чалбарларын тагын чистартырга керештеләр. Ләкин чыланган таплар тагын да киңрәк җәелде генә.

— Чыгабызмы? — диде Йапи, аның тавышыннан шимбә киче әрәм булганга ачуы чыкканлыгы сизелеп тора иде.

— Кафега керик,— диде Дэниел.

Алар кызлар белән кереп утырырга яраткан кафе якында гына иде. Йапи белән Дэниел килеп кергәндә радиола янында берничә таныш егет басып тора иде. Радиолада кызыл ут кабынуга төрле тавышка барабан, рояль, тромбон һәм башка авазлар шаулый башлады. Йапи белән Дэниел берни булмагандай өстәл янына үттеләр. Шул чак егетләрнең берсе аларны күреп музыканы туктатты:

— Әй, сез нишләдегез болай!? — дип кычкырып сорады.

Кинәт тынлык туды; барысы берьюлы аларга текәлеп карады. Буфет артыннан хуҗа килеп чыкты, әмма аның карашы да ачулы иде. Кызарынган, буялып беткән Йапи белән Дэниел борылып чыгып киттеләр. Урамда бер-ике минут ни эшләргә белми торган арада, кешеләр аларга карыйлар да шелтәле сүзләр әйтеп үтәләр иде.

— Я, ярар, — диде Дэниел. — Иң яхшысы — өйгә кайту булыр.

Берни дә әйтмичә, алар, әйләнеч ясап, тукталышка киттеләр. Йапи, әнисенә күренмәс өчен, үзенең ничек посып кына өйгә керәчәген күз алдына китерде; билгеле инде, барыбер җавап бирергә туры киләчәк. Я рабби, ичмаса күлмәкне дә юып булмый бит: әнисе, әлбәттә, аның тирәсендә әйләнәчәк-тулганачак, барысына тыгылып сораштырачак. Әйе, әрәмгә киткән көн, әрәмгә.

Аның трамвае беренче булып килде. Вагонга утырганда ул каты ачу белән Дэниелга:

— Теге әшәке сары сөйрәлчек тагын очрамасмы! Мин аның танавын җимерәчәкмен! — дип кычкырды.

*С. САБИРОВ тәрҗемәләре.*



# Очерклар

*Җәмил Мостафин*

## КАЗАНДА ҮСКӘН БАТЫР

### Аның исеме

Аның исеме безнең гасырның иң атаклы исемнәре белән янәшә языла. Аның тыныч шартларда башкарган батырлыгы аяусыз сугыш учакларын үтеп чыккан кешеләрне дә таң калдыра. Аның һөнәре җир һөнәре түгел, һәм ул үз һөнәренә чиксез турылыклы. Тоташ мускулдан гына торган тыгыз гәүдәле, биек маңгайлы, киңчә битле, урта яшьләрдәге бу кеше җирдә яши һәм үзен үстергән җирне өзелеп ярата.

Сез аны беләсез. Ул — Георгий Константинович Мосолов. Очучы-сынаучы ул, коммунист, Советлар Союзы Герое. Туган елы — 1926, үскән җире — Казан каласы.

Мин сезгә аның соклангыч зур батырлыгы турында сөйләп бирергә телим.

### Батыр яуда чыныга

1942 ел. Казанга сугыш кырларыннан борчулы хәбәрләр килеп тора. Радио тәлинкәләреннән хәрби маршлар яңгырый, дикторның салмак-салкын тавышы тәннәрне чымырдатып уза. Георгий ул чакта сигезенче класста укый иде. Салкын зәңгәр биеклектән, каты гөрелдәп, көнбатышка самолетлар оча. Әнә фронтларга ашыккан шул дәһшәтле кошлар аның адымнарын әкренәйтеп, юка ботинка эчендә аяк бармаклары туңа башлаганчы күккә карап торырга мәҗбүр итә иде.

Георгийның әнисе мәктәптә укыта, ул сигезенче класста укучы улы алдында беркайчан да сугыш чоры авырлыкларыннан зарланмый иде. Күрәсең, укытучы белән укучы арасында булырга тиешле тотнаклылык аларны бер-беренә иң тирән тойгыларын ачып салырга комачаулый иде булса кирәк. Георгий ничектер шулай бервакыт яшүсмерләрне аэроклубка язганнарын белеп алды. Өйгә ул беркайчан булмаганча шатланып, сикергәләп кайтып керде һәм очучы булырга теләвен әнисенә яшерми әйтеп бирде. Фелицата Павловна аның сүзләрен тын гына тынлап утырды, улының теләгенә каршы килмәде. Улының хыялы әле тиз генә булмый торган бик ерактагы бер нәрсә булып тоела иде аңа.

— Син борчылма, әни, — диде улы, — өйрәнсәм, мин йөзгә кызыллык китерерлек итеп өйрәнмәм инде аны. Күрерсез әле менә, сине дә күктә очыртып йөрермен...

Һәм Георгий үзенең сүзләрен расларга теләгәндәй, шундый ярсып биеп китте, Фелицата Павловна улының балаларча калкып, калак сөякләре беленеп торган аркасына аналарга гына хас бер якынлык хисе белән елмаеп карап куйды...

Мәктәптәге дәресләр белән аэроклуб дәресләрен бергә алып бару җиңел булмады Георгийга. Кар бураннары күмгән юллар буйлап күбесенчә җәяү барырга кирәк. Бәхетенә юлда машина туры килсә, машина кузовына сикереп менеп утырып, ул аэродромга соңармыйча килеп җитә иде. Очарга өйрәтүче инструктор Валентин Федорович Хапов инде шул чакта ук пумала чәчле бу малайның тырышлыгына, үҗәт бер ныклык белән үз максатына баруына бәя биреп җиткергән иде. Һәм шуңа күрә дә ул булачак лачынга көчле канатлар бирү өчен тәҗрибәсен дә, көчен дә кызганмады, аның бер генә хатасын да шул килеш үткәреп җибәрмәде. Шулай бер мәртәбә Георгий иптәшләре алдында осталыгы белән мактанмакчы булды. Самолетын җиргә гадәттән тыш очракларда гына рөхсәт ителә торган ысул белән утыртты. Өйрәнчек очучыга мондый кылтаюның бик кыйммәткә төшүе мөмкин иде.

— Нәрсә, якты дөньядан туйдыңмы? Кардебалетлар маташтыра башладың? — дип, караңгы чырай белән каршы алды аны инструктор. — Әйтмәде дип әйтмә, икенче шулай кылансаң, очудан бөтенләй мәхрүм итәм.

Кичкырын аэродромнан өйгә кайтып барган чакта, Хапов аңа якын бер дустының шундый «остаруы» аркасында яп-яшь көе җир астына кереп ятуын сөйләп бирде.

— Очучы өчен иң мөһим нәрсә — дисциплина. Батырлык ул, туганкай, башсызлык дигән сүз түгел... — дип өстәде ахырдан.

Мосоловның күңеленә бик нык сеңеп калды бу сөйләшү. Аэроклубтан Георгий үзенең беренче укытучысына карата рәхмәт хисе белән китте.

Авиация училищесында да тырышып укыды. Отлично билгеләренә генә училищены тәмам итеп, хәрби очучы-истребитель исемен алды. Иң яхшы курсантларның берсе булганга, аны инструктор итеп билгеләделәр. Хәзер инде Георгийның үзенә яшьләрне өйрәтү эше тапшырылды. Менә монда инде яшь укытучыга тәҗрибәле өлкән иптәшенең, өлкән авиаторның киңәшләре бик кирәк булды. Дүрт мәртәбә очучы-истребительләр әзерләп чыгарды Георгий Мосолов. Уннарча егеткә күккә юл ачты. Яшь офицерларны оста өйрәтеп чыгарган өчен училищега, Мосолов исеменә ничәмә-ничә мәртәбә авиачастьлардан рәхмәт хатлары килде.

Очучы осталыгын күтәрүгә Георгий бик зур игътибар бирде. Аның соклангыч очу техникасын күрми калмадылар. Бервакыт аның белән бергә күккә атаклы очучы-инспектор Михаил Васильевич Котельников күтәрелде. Мактауга саран кеше ул. Хәтта инде исемнәре билгеле булган очучылар да «авиация бүреге» алдында каушап калалар. Самолетны җиргә утырткannан соң Михаил Васильевич акыл сатып тормый, нинди кимчелекләре булганын очучының үзеннән таптыра башлый иде. Ә Мосолов белән очып кайтканнан соң, ул: «Я, бүгенге очуда нәрсә ошамады?» — дип гадәттәге соравын биреп, төпченеп тормады, киресенчә, гади генә итеп:

— Ярыйсы очасыз, чибәр егет, ярыйсы, — дип куйды.

Ә кичен Мосоловны училище директоры үз янына чакырды.

— Менә нәрсә, Георгий Константинович... безгә... күрәсең, аерылышырга туры килер, — диде ул.

Сүзгә тәрәзә буенда басып торган Котельников кушылды:

— Сынаучы булып китәсезме?

— Сынаучы?! — диде Мосолов, гаҗәпләнеп.

— Нәрсә, куркып калдыгызмы әллә? Ул эштә алланың кашка тәкәләре эшләми...

Һәм шул көннән Мосолов тормышында яңа, романтикалы, авыр һәм ашкындыргыч көннәр башланды. Сынаучы булып эшли башлагач, ул яңадан үзенең беренче киңәшчесе Валентин Федорович Хапов белән очрашты. Ул хәзер яңа самолетларны сынау белән мәшгуль иде.

— Молодец, Георгий! — диде остазы, үзенең шәкертенә сөенеп. — Син күктә очар өчен яратылган кеше. Бергә булырбыз!

СССРның атказанган очучы-сынаучысы Григорий Александрович Седов та Мосоловның якын дустына әйләнде. Георгий һәр адымында аның иптәшләрчә сузган җылы кулын тойды, күк йөзендә аның кебек кыю һәм тыныч хәрәкәт итәргә өйрәнде.

Мосоловка егерме җиде яшь тулганда аның таныкламасында: «Бүгенге заманның барлык самолетларында очарга рөхсәт ителә», — дигән кыска һәм төгәл сүзләр барлыкка килде.

Биеклеккә пилотлар, әкрен-әкрен, эзлекле рәвештә, соңгы чикне уза-уза күтәреләләр һәм шул рәвештә «практик түшәмгә» чаклы менеп җитәләр. Хезмәт чорында Мосолов дистәләрчә самолетка күчеп утырды. Аңар гел яңа, гел камилләшкәнрәк самолет бирделәр. Очкан саен совет пилотының очу түшәме гел югарырак күтәрелә барды. Ниһаять, житте бер көн — очу тизлеге тавыш барьерын үтеп китеп, сәгатенә меңнәрчә километр белән исәпләнелә башлады. Әнә шундый сокланггыч очу тизлегенә ия булган машиналарны сынау гади очучы-сынаучы гына булдыра ала торган эш түгел, инженер очучы-сынаучы булдыра ала торган эш булып чыкты.

— Нәрсә, интегралларга тотыныргамы?

— Әйе, Георгий, укырга кирәк, — диде аңа Седов.

Һәм менә атаклы очучы-сынаучы Мосолов — Мәскәү авиация институты студенты. Кичке институтка йөреп укыды ул, ял сәгатьләрен, йокысын онытып, төннәр буе китаплар белән утырды, приборлар белән шөгыльләнеп, физика һәм газ динамикасы законнарын аңларга, гаять зур тизлектә һәм әле моңарчы кеше акылы ирешмәгән биеклектә очкан машиналарның чыдамлыгын һәм идарә итәлә алу күренешләрен үзе өчен ачыкларга тырышты.

Инженерлык белеме Мосоловка практик эшендә бик күп ярдәм итте. Ул чакта Георгий яңа маркалы тиз очышлы самолетта оча иде. Мосолов институтны бетергәннән соң, Григорий Александрович Седов аны кайнар рәвештә котлады һәм елмаеп:

— Ну, егетем, интегралларны җиңеп чыктың. Бәлкем, хәзер Ирвин белән ярышып карарсың, — диде.

— Ә нигә ярышмаска? Бу самолетта американың дөнья күләм рекордын узарга мөмкин. Ышанам мин бу машинага. Ике мең ярым тизлекне уйламый да бирә ала ул, — диде пилот.

Мосолов җаваплы старт алдыннан бик күп күнегү очулары үткәрде. Кайвакыт җирдә үткәрелгән исәп-хисаплар, күккә күтәрелгәч, яраксыз булып чыга, ләкин очучы-инженер беркайчан да чигенми, һәрбер яңа очыш аны максатына якынрак китерә. Барлык коллектив, хезмәттәш иптәшләре — техника фәннәре кандидаты Васильченко, инженерлар — Зотов белән Комаров, самолетның механигы Кичев һәм башкалар Мосоловка рекордлы очышка әзерләнергә һәрьяклап ярдәм иттеләр.

Самолет стратосферада снаряд сыман очты. Хәлиткеч минутлар якынлашты. Мосоловка очкычын максималь тизлек белән алып барырга кирәк иде. Очу запасы ерак түгел: нибарысы 25 километр. Ләкин участокның бу өлешен үтү — җиңел эш түгел, чөнки халыкара авиация федерациясе билгеләгән кагыйдәләр буенча йөз метр киңлектәге коридордан чыкмый очарга кирәк иде. Башта төрле кыенлыклар да чыгып торды. Очыш «җылылык барьеры» дип аталган барьер шартларында узды. Самолет температурасы 60 градус салкын булган һаваны ярып оча, шуңа карамастан самолетның япмасы гаять нык кыза. Бу барьер да артта калды. Очучы ихтыярына буйсынып, самолет зыңгылдап торган ук сыман, әлеге билгеләнгән араны узып китте. Тизлек сәгатенә 2400 километрга җитте. Бу тавыш тизлеген ике мәртәбә арттыру дигән сүз иде! Америка очучысы Ирвин рекорды җиңелде.

Самолет кайту юлына борылды. Георгий очкычны тагын сынау участогына ташлады. Ул самолетның зуррак тизлеккә дә ирешәчәгенә ышана иде. Дөрес, бу очыш гаять зур көч сорый иде аңардан. Аның йөзенә салкын тир бәреп чыкты, кислород бугазын кыса башлады. «Машина гына түзсә ярар иде», — дип уйлады Мосолов, идарә итү тоткасын шытырдатып кыскан килеш. Приборның теле әкрен генә уңга таба авыша. Менә ул 2 500 санын узды. Әле җир йөзендә берәүнең дә шул тамаша тизлек белән очканы юк иде!

Шлемофонда очыш белән җитәкчелек итүченең:

— Режим бетте! — дигән тавышы яңгырады.

Мосолов идарә рычагын борып, двигательнең тизлеген киметте. Очкычны посадкага алып барырга кирәк иде.

Беренче булып самолетка Кичев йөгереп килде. Хәтта аның кебек тәҗрибәле механикның да бу очкычны мондый хәлдә күргәне юк иде: машинаның тышкы кыяфәте танымаслык булып үзгәргән, металл бик көчле кызу сәбәпле, очкычның буяулары бөтенләй эреп төшкәннәр иде.

— Молодец, дустым! — диде Мосолов, самолетның фюзеляжына уч төбе белән шапылдатып сугып. — Без синең белән мондый сынауларны бер генә мәртәбә үтмәбез әле.

Озакламый аэродромга шатлыклы хәбәр килде: сынау очышлары үткәрүче Георгий Мосоловка Советлар Союзы Герое дигән мактаулы исем бирелде. Конструкторлар, инженерлар, техниклар, гомумән, Мосолов белән эшләүче барлык иптәшләрнең моңарчы күрелмәгән тизлекләргә, биеклекләргә омтылышы моның белән генә чикләнмәде. Ә Георгий бу сынау көнекмәләреннән сугышчан машинаның яңадан-яңа мөмкинлекләрен эзләп, ачып тора иде. Шундый бер уңышлы сынау очышларыннан соң, баш конструктор белән Мосолов арасында менә шундый бер сөйләшү булып алды:

— Георгий Константинович, бәлки, американың икенче рекордын да тартып алыр вакыт җиткәндер, ә? — диде конструктор, бармагы белән күк йөзенә таба күрсәтеп. Очучы, башын артка ташлап, зәңгәр биеклеккә карап торгач, кыю гына:

— Мин әзер, — диде.

Һәм менә тагын киеренке эш башланды. Үз илебездә ясалган самолетта моңарчы күрелмәгән биеклеккә күтәрелү — космос чигенә кадәр барып җитү бурычы алда тора иде.

Язгы җылы көннәрнең берендә, бөтен дөньяны таң калдырган вакыйга булды: Мосоловның сугышчан иптәше, совет очучысы майор Юрий Гагарин тиңдәше булмаган батырлык эшләде. «Восток — 1» кораблендә ул йолдызларга юл салды һәм шуның белән бөтен дөнья алдында гаять зур ихтыяр көче, батырлык һәм чыдамлылык үрнәге күрсәтте.

Бу батырлык Мосоловны һәм аның иптәшләрен гаять дәрәҗәдә дулкынландырды. Георгий космос каһарманын котлау өчен шундук телеграфка йөгерде. Бу көнне ул күкрәгендә көчнең тыелгысыз бер ташкын булып ташуын тойды, барлык белемен, ихтыярын, көчен туган иленә, халкына бирергә ашкынды.

Һәм менә самолетта моңарчы күрелмәгән очыш көне якынайды. Коммунист Георгий Мосолов беренче омтылыштан ук Америка очучысы Джо Джордин куйган биеклек рекордын узып китәргә карар кылды. Ракетаны хәтерләткән көмеш канатлы очкыч ашкынып күккә күтәрелде. Ул тавыш тизлеген ике тапкыр арттырганнан соң, җирдән команда тавышы ишетелде:

— Горка!

Мосолов идарә тоткасын үзенә таба тартты. Самолет аягүрә басты һәм, көмеш канатларында кояш нурларын җемелдәтеп, бик текә югары менеп китте. Тизлек шулкадәр зур иде, күк йөзе күзгә күренеп төсен үзгәртә барды: зәңгәр төстән ул көлсу соры төскә әйләнде, аннан соң корымдай кара төскә керде. Горизонт бөтенләй күренми иде. Тик күзләрне камаштырырдай якты кояш кына биткә бәрә дә коточкыч зур басым гәүдәне утыргычка ябыштыра иде. Әмма очучы самолетны баллистик траектория буенча һаман биеккә алып менде. Самолетта очу космик корабльдә очуны хәтерләтә башлады.

— Биеклеккә таба очуны дәвам итәм! — диде пилот радио буенча. — Кабина эчендә басым атмосфера басымыннан биш процентка аерылды.

Шулай булуга карамастан, Мосолов үзен яхшы сизә иде. Космонавт скафандрына охшаган махсус костюм кигәнгә, бу очышның кыен яклары, һаваның сирәкләнгән булуы пилотның эшләү сәләтенә зыян китерә алмады.

Биеклек 34 000 метрдан артып китте. Мосолов каешларда асылынып калды. Космик очышта Юрий Гагарин кичергән хәл — авырлыкны югалту халәте килеп җитте.

— Режим бетте! — дип хәбәр иттеләр самолет бортына.

Самолет алка ясап борылды да, җирнең тарту көченә буйсынып, түбән атылды. Мосолов баллистик траектория буенча нибарысы 107 секунд очты. Ул аның югары ноктасында 34 200 метрга кадәр җитте. Абсолют дөнья рекорды иде бу. Җир йөзендә әле бер генә кеше дә самолетта андый биеклеккә күтәрелмәгән иде.

Биеклек! Кайда соң аның чикләре? Совет кешеләре аның чикләрен киңәйткәннән-киңәйтә баралар. Очучы-новаторлар кешелек тарихында күрелмәгән очышларга менәргә дип канатларын нygыталар. Юрий Гагаринның космик рейсы, Георгий Мосоловның моңарчы күрелмәгән рекорды — болар мәңге әйдәп, мәңге кызыктырып торган күккә әле бары тик беренче очышлар гына иде...

## Мәхәббәт үлемне җиңә

Бу гадәти бер очу иде. Гадәти дип әйтүем шуңа, Георгий Константинович бу юлы көн саен башкара торган гадәти эшен башкара — ул самолетны очарга өйрәтә, ачыграк итеп әйткәндә, сыный иде. Бу юлы очыш режимының шартлары бик катлаулы булып чыкты. Конструкторлар өчен дә, Мосоловның үзе өчен дә бу очышта бик күп табышмаклы нәрсәләр бар иде.

Башта барысы да әйбәт кенә барды. Самолет аның һәр хәрәкәтен тыңлап, буйсынып очты. Әмма гаять зур биеклеккә менгәч, тавыш тизлегеннән югарырак тизлектә оча башлагач, һич көтмәгәндә, самолет

күрелмәгән бер киртәгә килеп бәрелгәндәй булды да, гөлт итеп кабынып, сул канатына ауды. Һәм менә шунда акыл җитмәслек хәлләр булды. Машина кинәт тарала башлады, җир белән элемтә өзелде (очучы шулай да самолетны ташларга мәҗбүр булуын хәбәр итәргә өлгерде), прибор ватыклары аның сул кулын һәм сул як кабыргасын сындырдылар, аннары нәрсәдер аның башына китереп бәрде... Коточкыч бер ихтыяр көче куеп, очучы кызыл тотканы үзенә тартып китерә алды һәм үзен самолеттан ыргыттыруга иреште. Аңына килгәндә, Георгий Константинович баш өстендә зәңгәр күкне күрде. «Аркам белән төшәм!» — дигән уй күңеленнән узды. Ә бу үлемгә тиң иде. Җир гаять тиз якынлаша... Очучыга парашют бауларына буталган уң аягын коткарырга кирәк. Ләкин ничек? Моны бит исән-сау кешегә дә эшләве бик кыен. Ә монда сынык кул, сынган аяк, миңгерәүләнгән баш. Ләкин шушы гаҗәп шартларда да, Георгий Константинович көрәштән җиңүче булып чыкты: ул уң аягын парашют бауларыннан коткара алды һәм шул аягы белән җиргә төште. Тик аның уң аягы җиргә бәрелүгә чыдамады, ул да сынып чыкты. Инде кешенең чыдамлылыгына чик булырга тиеш бит. Акыл бер генә нәрсәне тукыды: «Аңны җуймаска. Ярдәм килергә тиеш!»

Көзге саргылт урман өнсез иде. Ара-тирә генә баш өстендә тукран тукылдап куя да, астан ниндидер дөбердәү тавышы ишетеп, ихтыярсыз түбән карый иде.

Менә, урман кикрикләрен тарап, вертолет узып китте. Мосоловны күрмәделәр. Тагын тынлык. Хәтта тукран да гигант чикерткәнең тавышыннан куркып очып китте.

Георгий аңын югалта башлады. Аның инде өч сәгать буена таянып яткан кулы оеды. Мосолов ярдәмгә кешеләр чакырырга кереште. Ләкин аның тавышы бик зәгыйфь иде. Урман әүвәлгечә үк өнсез иде. Юк, очучы үлемнән курыкмады. Ул башкалар авариясез, тыныч очсын өчен машинада ниләр булганын, аның конструкциясенә нинди үзгәрешләр кертергә кирәк икәнен иптәшләренә әйтеп калдырырга тырышты. Әгәр ул сөйләп калдырмаса, аварияның сәбәпләрен бер генә прибор да сөйләп бирә алмаячак бит. Урманда үлем белән күзгә-күз очрашкан чакта да ул әнә шул хакта, иптәшләре турында, аларның алга таба хәвеф-хәтәрсез очулары турында уйлады. Ә ярдәм килеп җиткәннән соң, беренче эше итеп, җитәкче инженерны чакыруларын, ә җитәкче инженерның хәзер үк катастрофаның ничек килеп чыгуын язып алуын таләп итте...

...Георгий Константинович бер ел чамасы больницада ятты. Аның гомерен саклап калу өчен илебезнең иң атаклы хирурглары көрәште. Үлем берничә мәртәбә батыр очучының баш өстендә асылынып торды һәм теләр-теләмәс кенә кире чигенде. Мосоловның хәлен белергә дуслары — космонавтлар, очучылар, очучы-сынаучылар, бергә эшләгән иптәшләре, пионерлар килеп торды.

Һәм Мосолов үлемне җиңде.

* * *

Мосолов турында мин күптән ишеткән идем. Аның хакында миңа А. Федотов белән П. Остапенко сөйләгәннәр иде. Ул чакта әле алар өйрәнчек очучы-сынаучылар гына иде, инде хәзер дөнья күләмендәге рекордларның ияләре булып киттеләр. Бу яшь очучы-сынаучыларның Георгий Константинович турында гаҗәеп бер якынлык һәм туганнарча җылылык белән сөйләүләре миндә данлы очучы белән якыннан танышу теләге тудырды. Аннан соң газета-журналларда Мосолов турында туган ил авиациясендә үсеп чыккан самородок-талант дип, бүгенге заманның

уннарча төр самолетларына гомер биргән очучы дип, очышта үзенең почеркын тапкан кабатланмас кеше дип яздылар. Һәм менә, ниһаять, мин аның белән, безнең яшьләребез өчен легендар шәхескә әйләнгән кеше белән танышу бәхетенә ирештем.

Георгий Константинович — бик гади кеше. Аның яңак сөякләре калкыбрак торган мөлаем йөзенә, якты зәңгәр күзләренә карыйсың да, аның салмак гөлдерәвек тавышын тыңлап утырасың да, үз алдыңа уйлап куясың: «Менә хәзер син бернинди үлем дә кичермәгән, бернинди батырлык та эшләмәгән кеше кебек сөйләшеп утырасың, ә бит кешелек дөньясы өчен нинди кадерле кеше син!» Ихтыярсыз күңелдә аның өчен горурлык хисләре уяна. Аны шундый итеп партия тәрбияләгән, аның беренче хыял-омтылышларына пионерия, комсомол дәрт биргән, чыныктырган. Аның янына өзлексез пионер дружиналары агылып торуы юкка гына түгел бит.

Георгий Константиновичның больница палаталарыннан китүенә әле берничә ай гына иде. Ләкин ул инде үзен әйбәт хис итә, яңа хыял, яңа омтылышлар белән яши иде. Дөрес, аның әле кулы бөгелми, гәүдәсендә дә элеккеге сыгылмалык юк, озаграк йөрсә, аягы да аксый башлый, шулай да аның үлемне җиңүе үзе үк адәм әйтеп адәм ышанмаслык батырлык ич!

Бассейнда көн саен үткәргән күнекмәләр, урмандагы кросслар очучы организмын ныгыта, чыныктыра баралар. Аның янә дә штурвал артына утырып, туган илне яңадан-яңа уңышлар белән шатландырыр сәгатьләре якыная. Ул моңа ирешер. Ә аның шәкертләре, кайнар бер горурлык хисе белән әйтәләр:

— Безне Мосолов үзе өйрәтте. Аның батырлыгы алдында хәтта данлыклы Совет космонавтлары да баш ия! — диләр.

Әйе, без, Совет кешеләре, аның сокландыргыч батырлыгы алдында баш ибез. Без аның организмының коточкыч сынаулардан исән чыгуына таң калабыз. Ә аны якыннан күреп белгән кешеләр аның гаиләсенә булган ягымлылыгын, иптәшләренә карата якынлык тойгысын, бөтен барлыгы белән тоташтан фәнгә омтыла белүен, ә балаларны өзелеп яратуын, алар белән бик катлаулы нәрсәләр турында гади һәм җитди итеп сөйләшә белүен күреп, аңа охшарга, аның төсле булырга омтылалар...

*Мөдәррис Мостафин*

# БАРЫР ЮЛЫБЫЗ

*(Журналист язмалары)*

Партиябез Үзәк Комитетының быел булып үткән март Пленумы, СССР авыл хуҗалыгын тагын да үстерүнең кичектергесез чаралары турында анда тикшерелгән мәсьәләләр һәм Пленум кабул иткән карар көнүзәккә күп нәрсәләрне тергезеп җибәрде, яңартты, искә төшерде...

Хәтеремдә, мин 1963 елның декабрь ае ахырында Актаныш районының (ул вакытта Минзәлә идарәсе) Нур Баян исемендәге колхозына барган идем. Ашханә янында бураннан ышыкланып басып торам. Менә бервакыт түбәсе брезент белән ябылган өч йөк машинасы килеп туктады. Машинаның көпчәкләренә хәтле җепшек кар сыланган. Бер машина кузовыннан кожан кигән ике таза ир кеше сикереп төште. Артларыннан, борчак коелган кебек, җиргә берничә дуңгыз баласы атылды. Әйе, атылды, чөнки алар шундый ваклар иде. Моңарчы тын торган кузов эче дә җанланды — дуңгыз балалары «чи-чи» килделәр. Әлеге ике агай көрт ера-ера дуңгыз балаларын куалап тоттылар һәм кузовка ыргыттылар.

— Кая илтәсез боларны?

— Дәүләткә тапшырабыз. Минзәләгә юл тотабыз. Нигә гаҗәпләнәсез?

— Гаҗәпләнерсең дә. Дәүләткә тапшырыла торган дуңгыз кимендә 80 килограмм авырлыкта булырга тиеш бит. Бу һәркем өчен закон.

Яңа танышым көрсенеп куйды.

— Син, агай-эне, шәһәрдәнме әллә? — диде бу, миңа текәлеп карап.— Фураж калмады. Сыерларга башакка сибәрлек тә юк. Ачтан үтерәсеңмени аларны! Менә особый рөхсәт белән илтәбез.

Мин аларның «Коммунизмга» колхозыннан булуларын белдем. Яхшы колхоз ул. Кырларында мул уңыш үсә. Дуңгыз үстерү осталары бар. Бер елны кайсыдыр бригадасында һәр ана дуңгыздан 23 бала алып үстерделәр. Ит өчен дөньяга килгән шул хайваннарны 5—6 килограммлы чагында ук йөк-йөк төяп ит комбинатына озатуның зур мәгънәсезлек һәм хуҗасызлык икәне аермачык күренеп тора иде. Ләкин ул чагында «Нигә бу шулай эшләнә?»—дип беркем фикерен ачыктан-ачык әйтә алмады. Янәсе, өстән кушылган — эше беткән.

Менә икенче бер күренеш... Мөслим районы 1958 елда дәүләткә 170 мең центнер ашлык тапшырырга тиеш иде, ул аны 228 мең центнер итеп үтәде. Ә 1959 елда план тагын да арттырып җиткерелде — район дәүләт амбарына 376 мең центнер ашлык озатты. Шул ук җирдән, кешеләр дә, машиналар да шул ук. Дөрес, җирдән яхшырак файдалану һәм агротехника таләпләрен яхшы үтәү хисабына ашлыкны елданел күбрәк җитештерергә һәм дәүләткә дә күбрәк сата барырга тиешбез. Монысы һәркемгә мәгълүм хакыйкать. Ләкин ике елда планны ике өлештән дә күбрәк арттыру чыннан да үтәү өчен кыен иде. Мин моның нәрсәгә китергәнен яз көне үз күзләрем белән күрдем. Алдынгы хуҗалыклардан исәпләнгән Киров исемендәге колхоз җитәкчеләре язын терлекләргә ашату өчен абзар түбәләрен ачарга, түләү шарты белән колхозчылардан ашлык җыярга мәҗбүр булдылар. Никадәр сарык һәм бәрән азык җитмәүдән кырылды, дуңгызлар саны кимеде. Артель председателе Лотфулла Мусин — тәҗрибәле җитәкче, кыю, тәвәккәл кеше. Ә шулай да ул бик куркуга төшкән, борчулы иде. Ак чәчләре дә күбәйгән төслә күренде. Мин аны правлениедә очраттым. Ул тәрәзәдән бик озак фермаларга таба текәлеп карап торды һәм кинәт өстәленә сугып:

— Вот чорт возьми, ашлык үстереп, колхоз терлегенә кирәк кадәре генә булса да фураж калдырырга хакың булмасын инде,— дип куйды.— Ә сөтне, итне нәрсә белән арттырырга? Анысы да күктән яумый бит аның.

Дөрес, бу вакыйгадан соң колхоз аякка басты. Уңышны нык күтәрү хисабына, бераз фураж да калдыра башлады. Хәзер ул — районның алдынгы хуҗалыкларыннан берсе. Ләкин үсеше никадәр тоткарланып торды.

Производствоны, продукция җитештерүне һәм аны дәүләткә тапшыруны дөрес планлаштырмау, түбәннән булган фикергә колак салмау бик эчне пошыра иде.

Бөек юлбашчыбыз Владимир Ильич Ленин партияне теге яки бу чорда туган хәлгә һәрьяклап анализ ясарга, уңышларга һәм кимчелекләргә объектив бәя бирергә, кыенлыкларны һәм хәл ителмәгән проблемаларны вакытында күрә белергә өйрәтте. «...Хәтта ачы һәм авыр хакыйкатьне дә туп-туры әйтүдән курыкмасак, — диде В. И. Ленин — без барлык һәм һәртөрле кыенлыкларны җиңәргә өйрәнербез, әлбәттә, һәм һичшиксез өйрәнербез».

Совет кешеләре колхоз һәм совхоз производствосын үстерүдә 1953—1958 еллар чорында ирешелгән уңай нәтиҗәләрне яхшы беләләр. Партиянең 1953 елгы сентябрь Пленумы билгеләгән чаралар авыл хуҗалыгын үстерүгә көчле йогынты ясадылар. Без ул чордагы күтәрелешне һәм энтузиазмны яхшы хәтерлибез. Саннар бу турыда бик ачык сөйлиләр. Ләкин шуннан соңгы елларда авыл хуҗалыгының үсеш темплары акрынайды. Авыл хуҗалыгы продуктлары җитештерүне һәм хәзерләүне арттыру планнары үтәлми килде. Бу хәл илебез экономикасын үстерүдә мәгълүм кыенлыклар тудырды. КПСС Үзәк Комитетының март Пленумында болар турында, даһи Ленин өйрәткәнчә, ачыктан-ачык әйтелде.

Социалистик производствоны үстерүнең экономик законнарын санга сукмау; җәмәгать хуҗалыгын үстерү белән колхозчыларны һәм совхоз эшчеләрен материаль кызыксындыру, җәмәгать интересларын шәхси интереслар белән дөрес бәйләү принципларын бозу артта калуның төп сәбәпләре булды.

Соңгы елларда авыл хуҗалыгы алдына куелган зур һәм катлаулы бурычлар экономик һәм материаль-техник характердагы чаралар белән бик йомшак беркетелде: игенчелек культурасын күтәрү турында карарлар күп чыгарылды, урыннарда бик күп күтәренке социалистик йөкләмәләр кабул иттеләр, ә шул ук вакытта колхозлар һәм совхозлар иң кирәкле авыл хуҗалыгы машиналары белән һич тә тулы тәэмин ителмәделәр. Кайбер хуҗалык җитәкчеләре кыр эшләренең иң киеренке, көчне иң күп таләп итә торган чагы язгы чәчү яки урак өсте якынлаша башласа, тәмам аптыраштa калалар иде. Тракторлар җитми, комбайннар аз, запас частьлар җитәрлек кайтмый. Чәчү машинасы, культиватор кебек тагылма коралларга кытлык бигрәк тә сизелә иде. Партиябез шушы ачы хакыйкатьне халыкка яшермичә әйтеп бирде.

Тагын бер гыйбрәтле вакыйганы искә төшереп үтәсе килә. 1960 елның кышында Актаныш районының «Авангард» колхозында булуым вакытында артель председателе Хәйдәр иптәш Галиев бик рәхәтләнеп, эшенең барып чыгачагына күңелен утыртып, тавыкчылыкны үстерергә ниятләнүләре турында сөйләде. Яхшы гына ферма бинасы бар, тавык караучы кызлар да һәм аларның эш нәтиҗәләре дә әйбәт иде. Күңеле канатланудан, шатланудан председательнең йөзе балкып, яктырып китә иде.

— Без киләсе елга ук тавыклар санын 10 мең башка җиткерергә исәп тотабыз, — диде ул, фикерен уртаклашып. Мондый нәрсәгә кем генә шатланмас соң! «Чын күңелдән уңышлар телибез сезгә. Хыялларыгыз чынга ашсын!» — дидем мин. Яңадан бу колхозга килергә туры килмәде. Әмма иптәш Галиев белән без Минзәләдәге бер киңәшмәдә һәм Казанда уздырылган киңәшмәләрдә очрашкаладык. Мин аның әлеге хыялы ничек тормышка ашуы турында сораштырмыйча калмадым. Икенче елны: «680 мең йомырка тапшырдык», — диде ул шатланып. Бу, әлбәттә, бик яхшы үсеш иде. Ә шуннан соң аның бөтен планнары чәлпәрәмә килгән. Минзәлә производство идарәсеннән (колхоз ул чакта шул идарәгә карый иде) планны 780 мең итеп җиткергәннәр. Ә колхоз, бердән, тавыкларга фураж калдыра алмаган, икенчедән, ишле тавыкларга бина салып өлгермәгән. «Планны үти алмыйбыз гына бит, менә тотындылар район җитәкчеләре суганлапборычлап тәнкыйтьләргә. Тавыкларны бетерүдән, дөресрәге, баш санын кыскартудан башка чара калмады» — дип сөйләде иптәш Галиев. 1964 елда инде колхозның 1300 баштан аз гына артыграк тавыгы булып, ул дәүләткә 100 меңләп йомырка сатты. Планын, әлбәттә, үтәде. Председательне дә борчучы булмады, киресенчә, ул герой иде инде, колхоз да алдынгылар рәтендә телгә алынды. Ә хуҗалык үз производствосын үзе теләгәнчә планлаштырса,

ул дәүләтебезгә ким дигәндә ярты миллион йомырка артыграк тапшырган булыр иде.

Авыл хуҗалыгы продукциясен хәзерләү һәм сатып алуның моңарчы яшәп килгән практикасы колхоз һәм совхоз производствосын тагын да киңәйтү өчен кирәкле шартларны тудырмады. Колхозларга һәм совхозларга, урындагы табигый һәм экономик шартларны исәпкә алмыйча, югарыдан катгый планнар җиткерелде. Ел башлангач, ә еш кына уракка төшкәндә, район, колхоз һәм совхоз дәүләткә күпме ашлык тапшырачагын, фуражга һәм хуҗалыкның эчке ихтыяҗларына күпме калдырачагын алдан белми иде. Ә ашлык тапшыру башлангач, планга кат-кат төзәтмәләр кертелде.

Мондый кимчелекләр республика масштабында да үзен нык сиздерде. Җидееллыкның беренче елларында колхозлар һәм совхозлар игенчелекне һәм терлекчелекне үстерүдә яхшы гына темп алганнар иде. 1961 елдан башлап республика хуҗалыкларына, хәлне тирән анализлауга нигезләнмәгән, күтәренке планнар җиткерелә башлады. Бу саннар колхозларның һәм совхозларның реаль мөмкинлекләренә һич тә туры килмиләр иде. Нәтиҗәдә күпчелек хуҗалыклар, хәтта уңай килгән елларда да, кирәк кадәр фураж калдыра алмадылар, кондициягә җиткерелмәгән аз үлчәүле терлек тапшырырга мәҗбүр булдылар. Шуна карамастан, терлекчелек продукциясе тапшыру заданиеләре бер елны да үтәлмәде.

Производствога партия һәм хуҗалык җитәкчелеген һичбер нигезсез күп санлы үзгәртеп корулар, шулай ук колхозлар һәм совхозлар өстеннән командалык итү үзен тискәре яктан сиздерми калмады.

Эштә булган җитди кимчелекләр турында сөйләгәндә, субъектив факторлар, үзебезнең эш дәрәҗәбезгә бәйләнгән сәбәпләр турында дәшми узу һич дөрес булмас иде. Әйтик, берәүләр җиң сызганып, тир түгеп сабан сөрәләр, җирдән мөмкин булганның бөтенесен алырга тырышалар. Ә икенче берәүләре табигатьтән шәфкать көтеп, ваемсыз гына яши бирәләр. «Ярлылыкка» ташлама алучы кайбер хуҗалык җитәкчеләре хәтта «герой» булып та йөрделәр, ә җитештерүне арттыру турында башларын әллә ни ватмадылар. Беркемгә дә сер түгел, бер үк табигый шартларда игеннәрдән төрле уныш үстерүче ызандаш колхоз, хәтта бригадалар да еш очрый әле бездә. Март аенда Казанда узган республика партия активы җыелышында шундый берберсенә терәлеп торган ике хуҗалыкның— Азнакай районы, «Авангард» колхозы белән Әлмәт районы, Калинин исемендәге колхозларның уңыш алу дәрәҗәсе чагыштырылды һәм моның сәбәпләре күрсәтелде. «Авангард» колхозында соңгы дүрт елда бөртекле культураларның уңышы 13 центнер булды. Бер үк туфрак-климат шартларындагы Калинин исемендәге колхозда ул 6,9 центнер тәшкил итте. Моның берничә сәбәбенә күз салыйк. Бу еллар эчендә «Авангард» колхозында һәр шартлы тракторга 872 гектар эш башкарылса, Калинин исемендәге колхозда ул 478 гектардан артмады. 1964 ел уңышы өчен «Авангард» колхозында августта җирләрнең 41 проценты, ә Калинин исемендәге колхозда 0,3 процент тунга сөрелгән. Нинаять, «Авангард» колхозында тунга сөрелгән җирләрне яз көне тырмалау 4 эш көнендә үткәрелгән булса, Калинин исемендәге колхозда бу эшне 9 көнгә сузганнар. Әйтелгәннәргә тагын шуны өстәргә мөмкин: Калинин исемендәге колхозда туфрак эшкәрткәндә һәм чәчү алдыннан агротехниканы тупас бозуга юл куйганнар, орлык сортлы һәм югары кондицияле булмаган, кыр эшләре озакка сузылган. Әлбәттә, җиргә тиешле ашын бирмәгәч һәм кирәкле хөрмәтен күрсәтмәгәч, аннан ни намусың белән югары уңыш көтәсең.

Мондый характердагы чагыштыруларны һәм эшебездә турыдан-туры үзебезгә бәйләнгән кимчелекләрне башка районнардан һәм башка тармаклардан да китерергә мөмкин.

«Мөслим» совхозында 1964 елда 596 сыер кысыр калган. Бу — мең тоннадан артык сөт һәм никадәр бозау, ит дигән сүз. Бу тармактан совхоз 102 мең сумнан артык зыян күргән. Яхшы хуҗа мондый нәрсәгә юл куямыни!

Пленумда соңгы вакытта сарык асрауга игътибарның кимүе һәм ит җитештерүдә бу зур резервның, халык сүзләре белән әйткәндә, сандыкта күгәреп ятуы күрсәтеп үтелде. Бу безнең республикага да төбәп әйтелгән кебек булды. Кайчандыр татар халкының табынын бизәгән сарык ите безнең көннәрдә бик аз җитештерелә башлады. Авылларда, колхозларда сарык көтүләре сирәгәйде. Лаеш районында 1959 елда 18,6 мең баш сарык бар иде, хәзер 4,2 мең генә исәпләнә. Сарык асраучылыкны үстерү өчен уңай шартлары булган Бөгелмә, Баулы районнарында бу төр терлек соңгы өч елда 17,6 мең башка азайды. Ә бу бит

соңгы ике район кайчандыр Татарстанда үзләренең сарыклары белән дан тоталар иде. Кайбер хуҗалыкларда моны специаллаштыру лозунгысы астында эшләделәр. Сарыкларны бик тиз һәм күпләп киметтеләр, ә менә сыерларны яки кошларны аз арттырдылар. Лаеш районында эш нәкъ менә шулай торды.

Мөмкин булганны алып җиткермәү, эшләмәү — байлыкны таптап йөрү белән бер ул. Янәсе, сарык доход бирә алмый, хуҗалык өчен рентабельле түгел. Кайчаннан бирле?! Мондый «дәлилләрнең» нигезсезлеген күрсәтү өчен бер мисал китереп узу да җитәр кебек. Октябрь районының «Дружба» колхозы узган ел сарык асраудан 52 мең сум саф табыш кына алды. Чөнки колхозда булсынга йөрүче, кайгыртучан хуҗалар эшли.

Март Пленумы авыл хуҗалыгындагы бик күп мәсьәләләрне яңача, эшлекле һәм принципиаль төстә тикшерде, үз урынына куйды. Карабодай һәм тары кебек ярма культураларының безнең кырлардан бөтенләй диярлек кысрыклануын, табигый болыннарны һәм көтүлекләрне карамау нәтиҗәсендә күп кенә урыннарда аларның ташландык хәлгә килүен генә алып карагыз. Иптәш Л. И. Брежнев докладында Татарстанда да карабодай җитештерүнең кимегәнлеге бик дөрес күрсәтеп үтелде. Карабодай мәйданы 143 мең гектардан 40 мең гектарга кадәр кимегән. Бәхетебезгә каршы, ул елларда да хуҗалыкны ничек алып барырга кирәген аңлап, кыю эш итүче җитәкчеләребез дә булды. Мәсәлән, Азнакай районының «Алга» колхозы председателе иптәш В. Хаҗиәхметов шундыйлардан берсе. Биредә, аерым алганда, карабодай чәчүгә игътибарны йомшартмадылар. Узган ел 20 гектар мәйданның һәр гектарыннан 13,9 центнер карабодай уңышы алынган. Иске сатып алу бәяләре белән дә аның гектары колхозга 228 сум саф табыш биргән. Быел колхоз бу кыйммәтле культура мәйданын 63 гектарга җиткерде.

Татарстан колхозларында һәм совхозларында производствоны үстерү темплары илебездәге уртача темплардан бераз югарырак булды. Агротехниканы камилләштерү, чәчүлекләрнең тагын да яхшырак структурасын кертү һәм пар җирләренә борчак чәчү исәбенә бөртекле ашлыкның тулай җыемы бездә шактый арттырылды. Без борчак үстерә белүче республика буларак бөтен союзда танылдык. Бәрәңге һәм шикәр чөгендере мәйданнарын киңәйтеп, алардан мул уңыш үстерүгә сәләтле булуыбызны тәҗрибәдә күрсәттек. Узган ел республикабыз игенчеләре, Казан тирәсе районнарында корылык булуга, эссе җилләр хакимлек итүгә карамастан, кырларда мул гына уңыш үстерделәр һәм дәүләт амбарларына 56 миллион поттан артык ашлык озатып, ил алдындагы беренче изге бурычны үтәү турында партиябезгә, хөкүмәтебезгә рапорт бирделәр. Болар барысы да куанычлы фактлар. Һәм республикабыз колхозчыларының, совхоз эшчеләренең, колхоз һәм совхоз белгечләренең, җитәкчеләренең тырыш хезмәт җимешләре турында әйтмәү дөрес булмас иде. Безнең горурланып телгә алырлык, игеннәрдән һәрвакыт, елның-елында югары уңыш үстерүче мастерларыбыз, механизаторларыбыз, фермаларда җиңү яулаучы, батырлык үрнәге күрсәтүче кайнар йөрәкле, талмас бәләкле терлекчеләребез бар. Узган ел кырларыбыздан мул уңыш үстергән өчен байтак хуҗалыкларның республика Почет тактасына кертелүе, өч йөздән артык алдынгы игенченең ТАССР Верховный Советы Президиумы Почет грамоталары, КПСС өлкә комитеты һәм ТАССР Министрлар Советы грамоталары белән бүләкләнүе, алдынгылардан да иң уңганнарының СССР Халык хуҗалыгы казанышлары күргәзмәсенең алтын, көмеш һәм бронза медальләренә лаек булулары шул турыда сөйләмимени!

Җиңүләр, уңышлар барыннан да бигрәк безнең мөмкинлекләребезне күрсәтәләр. Дәүләт каршындагы бурычларын намус белән үтәп баручы алдынгы хуҗалыклар белән рәттән «арттагы», «фәкыйрь» ярлыгын йөртүче хуҗалыкларның булуы күңелне борчый әле.

Соңгы биш елда авылда туган хәлне КПСС Үзәк Комитеты Пленумы шау-шусыз, эшлекле төстә тикшерде һәм ярым чаралар белән генә чикләнмәде, мәсьәләләрне һәрьяклап, төптән, нигезле хәл итте. Теге яки бу зона, хуҗалык өчен иң файдалы тармакларны үстерү юлында туды-рылган ясалма киртәләр алып ташланды. Пленум, гүя, буылып, тыгылып торган чишмәне ачты һәм ул ургылып ага башлады.

Бөртекле ашлык сатып алуның алты елга билгеләнгән даими, үзгәрмәс планы, гадәттәгедән кечерәйтелгән план, планнан тыш тапшырылган ашлык өчен өстәмә түләү, игенчелек һәм терлекчелек продуктларына дәүләтнең сатып алу бәяләрен шактый күтәрү һәм аларның стабиль булуы, капитал

салуларның гаять зур күләме, авыл хуҗалыгы өчен машиналар, аларга запас частьлар, минераль ашламалар, гербицидлар һәм агу-химикатлар эшләп чыгаруны бик нык арттыру, колхозларның, совхозларның финанс хәлләрен яхшырту... Болар бөтенесе авыл хуҗалыгын һәркайда һәм һәрьяклап үстерү өчен гаять яхшы шартлар тудыра торган чаралар.

Күп тә узмады, КПСС Үзәк Комитеты һәм СССР Министрлар Советы Пленум күрсәтмәләре нигезендә яңа карарлар чыгардылар.

Колхозларның дәүләткә бөтен бурычлары бетерелә, доход налогы күләме киметелә, совхозларның бөтен табышы производствоны тагын да киңәйтү, эшчеләрнең тормыш-көнкүреш хәлен яхшырту өчен үзләрендә калдырыла, ачы туфраклы җирләрне известьлауны һәм мелиорация эшләрен, җирнең уңдырышын күтәрү юнәлешендәге башка эшләрне дәүләт үз җилкәсенә ала. Болар — гаять зур эшләр.

Пленум карарлары авыл, колхоз һәм совхозлар тормышының бер генә әһәмиятле ягын да читләтеп үтмәде. Ул партия, совет һәм авыл хуҗалыгы органнарын колхозларны идарә итүнең демократик нигезләрен ныгытырга, колхоз производствосының төп мәсьәләләрен хәл итүдә колхозчыларны киң катнаштырырга мәҗбүр итте. Үкенечкә каршы, без бу яктан күңелсез хәлләр белән очраштыргалыйбыз әле. Кайбер җитәкчеләр, председатель постына менеп утыргач, үзенең халык тарафыннан сайлап куелганлыгын һәм отчет бирергә тиешлеген оныта һәм командалык итә башлый, колхозчыларны хуҗалык кая таба баруы белән таныштырмый, алар белән киңәшми, фикерләренә колак салмый. Янәсе, ул боерык бирергә, ә башкалар аны күндәм тыңларга һәм боерыкны җиренә җиткереп үтәргә тиешләр. Мондый урында, кагыйдә буларак, колхоз демократиясе бозыла, коллегиаль җитәкчелек аяк астына салып таптала, артель членнары производствоның әһәмиятле мәсьәләләрен хәл итүдән читләшәләр, пассивлашалар. Мина быел комиссия составында шундый бер колхозда — Зеленодольск районының «Совет» артелендә булырга туры килде. Аның председателе Госман иптәш Тимершин колхозчылар өстеннән коры администраторлык юлы белән командалык итүче җитәкчегә әйләнгән иде. Җыелышлар уздырылмый, кешеләр белән киңәшеп эшләү гадәткә кермәгән, алар хуҗалыкның торышы белән таныштырылмый. Хәтта быелгы отчет-сайлау җыелышы да артель Уставын тупас бозып үткәрелгән иде. Җыелыш яңадан үткәрелде. Колхозчылар председательнең һәм правлениенең житди кимчелекләрен кискен тәнкыйть иттеләр.

Ә бит һәркемгә билгеле: колхоз — иҗтимагый-кооператив оешма, аның демократик нигезләре бозылса, ул нормаль яши һәм үсә алмый.

Шушындый күңелсез хәлләр булмасын өчен, март Пленумы авыл хуҗалыгы артеле Уставын үтәүнең һәр җитәкче өчен закон булуын күрсәтте. Колхозчыларның Бөтенсоюз съездын чакыру күздә тотыла. Анда авыл хуҗалыгы артеленең яңа, үрнәк Уставы кабул ителәчәк.

Ә кешеләргә, авыл кешеләренә нинди зур ышаныч күрсәтелде! Беркемгә дә сер түгел: соңгы елларда үз эшен яхшы белүче хуҗалык җитәкчеләре һәм белгечләр дә чынлыкта югарыдан күрсәтмә көтеп ята башлаганнар иде бит.

— Юк! — диде партия, — мондый юл белән барырга ярамый!

Авыл хуҗалыгында белгечнең дә роле ачык күрсәтелде. Хәзер алар колхозда һәм совхозда производствоны оештыру мәсьәләсен үзләре хәл итәргә, һәр басу өчен агротехниканы үзләре билгеләргә һәм тормышка ашырырга, чәчү әйләнешләрен үзләре эшләргә тиешләр. Ә бит безнең республикабызда авыл хуҗалыгы белгечләре шактый — 3 меңгә якын кеше.

Кешеләрдә хәзер үз көчләренә ышану артты, иҗат энергиясе күтәрелде, гүя, яңа, колачлырак һәм куәтлерәк канат чыкты. Республикабыз хуҗалыклары март Пленумы карарларын тормышка ашыру юлында беренче язда ук югары темп алу өчен язгы кыр эшләренә бик җентекләп әзерләнделәр. Башка еллардан аермалы буларак, һәр урында да орлыкны калибрлап, иң яхшы фракцияләрен генә чәчүгә һәм кырларда эшләячәк, уңышның нигезен салачак кешеләрне — тракторчыларны, чәчүчеләрне, прицепщикларны — алдынгы эш алымнарына өйрәтүгә зур игътибар бирелде. Яхшы орлык — ярты уңыш ул. Ни чәчсәң, шуны урырсың, ди халык. Бу акыллы сүзләр нык искә алынды. Җир куенына начар, зәгыйфь, көчсез орлык салу — үз-үзеңне алдау гына ул. Ә көчле орлык тиз тишелеп чыга, яшәүчәнрәк була һәм нык үсә. Әлбәттә, аннан уңышны да күбрәк аласың.

Быел җирләргә, органик ашламалар белән бергә, минераль ашламалар да күбрәк

кертелде. Кыр эшләре зур оешканлык, тыныч, иҗади эшләү һәм сыйфатка, агротехникага беренче дәрәҗәдәге игътибар белән аерылып торды.

Бөртекле ашлык җитештерүне арттыру безнең республика өчен төп бурыч булып килде һәм шулай булып кала да. 1965 елда бөртекле культуралардан, ким дигәндә, 12 центнер уңыш җыеп алу күздә тотыла. Бу — һәр игенченең намус эше. Безнең якларда үзләрен таныткан бәрәңге һәм шикәр чөгендере шулай ук төп культуралар булып калды. Ярма культуралар мәйданы киңәйтелде. Төп юлыбыз — һәр гектардан күбрәк уңыш алуны тәэмин итү.

Пленум карарлары илебез өстеннән узган сафландыргыч яңгыр кебек булды. Без инде аның беренче матур нәтиҗәләрен үз күзләребез белән күрәбез. Әйтик, элек без терлекчелек продуктлары җитештерү һәм аны дәүләткә сату, тапшыру планнарын үти алмыйча иза чиксәк, быел аны беренче кварталда ук срогыннан алда үтәдек. һәм РСФСР автономияле республикалары, крайлары һәм өлкәләре арасындагы ярышта Идел буе экономик районы буенча икенче бүләкне алуга ирештек. Аннан соңгы чорда да продукция җитештерү темпы кимемәде, киресенчә, үсә барды. Дәүләткә ит, сөт, йомырка узган елның шушы чоры белән чагыштырганда күп артык тапшырылды.

Партиябез Үзәк Комитетының ноябрь Пленумы карары нигезендә республикабызда 15 яңа район төзелү, район җитәкчелегенең халыкка, производствога якынаюы да, авыл җирләрендә колхозчыларга һәм совхоз эшчеләренә шәхси хуҗалыкларында терлек асрау буенча соңгы елларда кертелгән чикләүләрнең бетерелүе дә яхшы эшләү өчен бик әйбәт җирлек булдылар, хезмәт ияләренең күңелләрен күтәрделәр. Яхшы туфракка утыртылган гөл дә әйбәт үсә бит! Моның өстенә, быел ук инде колхозларыбыз һәм совхозларыбызның дәүләттән күп кенә яңа машиналар, шул исәптән, чәчү машиналары һәм культиваторлар алуларын да әйтергә кирәк.

Колхозлар һәм совхозлар тапшырылган терлекчелек продукциясе өчен акчаны яңа бәяләр белән алалар инде. Игенчелектән, планнан тыш ашлык тапшырудан да күпме доход керәсен һәм аларны нинди ихтыяҗларга тотарга икәнен исәпләп куйдылар. Югарыда телгә алынган «Авангард» (Азнакай) колхозына тукталыйк. Ул дәүләткә ашлыкны узган елгы кадәр (30.500 центнер) тапшырса да, планнан тыш сатылган ашлык өчен өстәмә рәвештә 43 мең сум, тары, карабодай культураларының бәясе күтәрелү хисабына 14 мең сум артык доход алачак. Колхоз дәүләткә итне узган елгыдан 14 процент, сөтне 5 процент күбрәк сатачак. Элекке бәяләр белән хисаплаганда колхоз кассасына бөтен терлекчелек продукциясе өчен 483.200 сум керер иде. Ә яңа бәяләр белән ул 90 мең сум чамасы артык алачак. Ә доход налогын саф табыштан гына түләү хисабына күпме файда калачак. Авыл хуҗалыгы машиналарын арзанрак бәягә сатып алу да иш янына куш була.

Март Пленумы йомгакларына багышлап уздырылган республика партия активы җыелышында КПССның Минзәлә райкомы секретаре Мәгъсүм иптәш Хөсәенов, үзләренең башлангыч исәп-хисаплары турында сөйләп, болай диде:

— Бәяләр күтәрелгәч, безнең район колхозлары һәм совхозлары дәүләткә терлекчелек продуктлары сатудан һәм тапшырудан өстәмә рәвештә берничә миллион сум доход алачаклар. Ә элек күпчелек хуҗалыклар зыянга эшли иде.

Доходларның артуы колхоз һәм совхозларда производствоны киңәйтергә, җитештерүне арттырырга зур мөмкинлек тудырачак. Март Пленумы карарларын тормышка ашыру — кешеләр хезмәтенә мул түләү, яңа мәктәпләр, больницалар, клублар, колхозчыларга һәм совхоз эшчеләренә яңа өйләр, гомумән, мул тормыш дигән сүз ул. Азнакай районының «Авангард» колхозы һәм Минзәлә районы буенча әйтелгән саннарга күз салыгыз. Нинди зур суммалар җыела. Республика буенча күпме булачак ул!

Әйе, партия һәм дәүләт авыл хезмәт ияләре кулына куәтле экономик рычаг бирделәр. Ләкин эш үзеннән-үзе генә барыр дип уйлау, тынычлану зур ялгыш булыр. Шул куәтле рычагны хәрәкәткә китерергә кирәк. Теге яки бу колхозның һәм совхозның уңышы хәзер тулысы белән җитәкчеләргә, белгечләргә, иген игүчеләрнең һәм терлекчеләрнең үзләренә, партия, совет һәм хуҗалык органнарының эшчәнлегенә, аларның үз вазифаларына мөнәсәбәтләренә бәйләнгән.

Табигать тик кыюларга һәм тырышларга гына үзенең тылсымлы серләрен ача, җимешләрен мул итеп бирә.

Партия Үзәк Комитетының март Пленумы илебездә гүзәл һәм кодрәтле орлыклар чәчте. Һич шик юк, бу орлыклар яхшы шытым бирерләр һәм гөрләп үсәрләр.

СОВЕТ ВЛАСТЕНЕҢ 50 еллыгына

*Азат Әхмәдуллин*

# КӨРӘШ һӘМ МӘХӘББӘТ

*(Татар совет әдәбиятында революцион аскетизмның чагылышы)*

1920 елның 8 ноябре. Казан халкы Бөек Октябрь социалистик революциясенең өч еллыгын бәйрәм итә. Нәкъ шул көнне татар театры сәхнәгә Галимҗан Ибраһимовның «Яңа кешеләр» исемле драмасын чыгарды. Спектакльне әле Октябрьдан соң гына әдәбиятка килгән яшьләр дә һәм өлкән язучылар да зур түземсезлек белән көтеп алдылар. Чөнки һәркемнең яңа дәвернең яңа кешеләрен сәхнәдә күрәсе, заман героен аңлау һәм аны иҗат итү юлындагы эзләнүләргә җавап табасы килә иде.

Тәҗрибәле каләм тарафыннан иҗат ителгән бу пьеса — бөек язучының беренче һәм бердәнбер сәхнә әсәре — төрлечә бәяләнде, күп төрле капма-каршы фикерләр кузгатты.

«Яңа кешеләр» драмасы татар телендә язылган һәм инкыйлаби, һәм милли пьесалар тезмәсенең бисмиллалык хезмәтен үтәргә, инкыйлаб әдәбияты нигезендә зур бер таш булырга яраклыдыр»,— дип язды тәнкыйтьче Галә Ходаяров [1]. Күренекле язучы Фатих Сәйфи-Казанлы әсәрнең яшь һәм яңа әдәбият өчен зур әһәмиятен билгеләп уза [2]. Ә менә Шәриф Байчура исә «Яңа кешеләр»не каты тәнкыйть итә [3]. Рецензент фикеренчә, авторның төп кимчелеге әсәрдә чорның яңа геройларын күрсәтү максаты куелып та, аларның революциягә килү юллары «чиста» булмавында. «...Пьесаның каһарманы итеп шәхси пакъ булган, матуррак, гомумирәк теләкләр наменә газапланган берәү» сурәтләнергә тиеш иде, ди ул. Г. Ибраһимов бу тәнкыйтькә каршы матбугатта махсус мәкалә белән чыга [4]. Бәхәскә Фәтхи Бурнаш та катнашып китә һәм Ш. Байчура фикерләрен яклый [5].

---

[1] Г. Ходаяров. «Яңа кешеләр». «Эшче» газетасы, 1920 ел, 16 ноябрь.

[2] Ф. Сәйфи-Казанлы. «Яңа кешеләр» драмасы. «Татарстан хәбәрләре» газетасы, 1920 ел, 14 ноябрь.

[3] Ш. Байчура. «Яңа кешеләр». «Кызыл армия» газетасы, 1920 ел, 379 сан.

[4] Г. Ибраһимов. Кара интригаларга юл бирелмәсен. «Эшче» газетасы, 1921 ел, 141 сан.

[5] Ф. Бурнаш. Артык кызарга ярамый. «Кызыл армия» газетасы, 1921 ел, 419 сан.

Урыны белән бер-берсенә карата артык катырак та әйтелгән сүзләр астында, әлбәттә, шәхси симпатия-антипатияләр, үпкәләшүләр генә ятмый иде. Моның сәбәбе тирәндәрәк: мәсьәләнең асылы яңа геройны аңлауга кайтып кала. Әдәби персонажларның тормыш юлларын «саф һәм пакъ» итеп кенә күрсәтүне, геройларның «матуррак, гомумирәк теләкләр» хакына газаплануын сурәтләүне таләп итүнең асылы чорның эстетик принципларына барып тоташа. Бу — чорның уңай героен тудыру өчен барган бәхәснең, төрле карашларның үзара бәрелеше иде.

Фридрих Энгельс «Германиядә крестьяннар сугышы» исемле хезмәтендә: «Үзенең революцион энергиясен үстерү өчен, җәмгыятьнең барлык башка элементларына карата үзенең дошманлык хәленә төшенү, үзен сыйныф буларак берләштерү өчен, түбән катлау яшәп килүче җәмгыять строе белән аны татулаштыру мөмкинлеге булган барлык нәрсәне кире кагудан, аның изелеп яшәвен вакытлыча түзәрлек итә торган һәм алардан аны иң авыр коллык та мәхрүм итә алмый торган аз санлы рәхәтлекләрдән баш тартудан тотынырга тиеш», — дип язган иде [1]. Бу күренешне ул «пролетар аскетизм» дип атый.

Шуңа охшаганрак үзенчәлекле бер күренешне гражданнар сугышы һәм егерменче еллар татар әдәбиятында да очратырга мөмкин. Бу еллар әдәбиятында үзенчәлекле бер тема — яңа тормыш төзү хакына бар нәрсәдән ваз кичү, шәхси тормыштан, аерата мәхәббәттән баш тарту темасы игътибар үзәгендә булды. Әдәбиятта совет властеның беренче елларында ачык төсмерләнгән бу нәрсәне, ягъни эшче сыйныф файдасына шәхси мәнфәгатьләрдән баш тартуны без Ф. Энгельс ачкан аскетизмның икенче бер шартларда — социалистик революция чорында үзенчәлекле кабатлануы дип карыйбыз. Һәм аны, шартлы рәвештә, «революцион аскетизм» дип атыйбыз.

Революциянең тәүге елларында мондый аскетизмның чыннан да булуын раслаган мәкаләләр соңгы елларда үзәк матбугатта да басылды. А. Турков, мәсәлән, «Профессионализммы әллә яңалыкмы?» [2] исемле мәкаләсендә бу мәсьәләгә карата күп кенә кызыклы, әһәмиятле фикерләр әйтә. Авторның дөрес фикерләре белән килешмәскә мөмкин түгел. Чыннан да, илнең хуҗалык һәм культура ягыннан артталыгы, хәрби коммунизм чорындагы тигезләү политикасы, озак елларга сузылган сугыш нәтиҗәсендә хасыйл булган җимереклек, соңра ачлык, тагын да соңрак нэп буржуазиясенең черек тормышы — болар барысы да андый аскетизмның сизелерлек төс алуына һәм шактый вакытлар яшәвенә нигез була. Совет дәүләтенең яшәү-яшәмәү мәсьәләсе көн тәртибенә куелган бер вакытта һәрнәрсәне р е в о л ю ц и о н к ү з л е к т ә н к а р а п х ә л и т ә р г ә тырышу, әлбәттә, табигый иде.

Аскетизм карашлары татар әдәбиятында, нигездә, революцион бурыч һәм шәхси мәнфәгать, аларның үзара мөнәсәбәте рәвешендә чагылды. Бу һәм политик, һәм эстетик проблема иде. Дөрес, мондый проблема татар әдәбияты өчен бөтенләй үк яңа түгел иде инде. Халык файдасына шәхси теләкләрдән баш тарту Мирхәйдәр Фәйзинең «Кызганыч» драмасында һәм Г. Ибраһимовның «Безнең көннәр» романының беренче вариантында, шулай ук, татар әдәбиятындагы кайбер башка әсәрләрдә дә бар иде.

Әмма проблеманы традицион сызыкта алганда, шул нәрсә күзгә ташлана. Әгәр элеккеге әсәрләрдә герой, халык файдасына үз мәнфәгатьләрен корбан итеп, үзен бәхетсезлеккә дучар итсә, совет чорында иҗат ителгән әсәрләрдә инде ул шәхси теләкләреннән баш тартудан бәхет, яшәү тәме таба. Бу — традицион проблеманың яңаруы дигән сүз,

[1] К. Маркс и Ф. Энгельс. Сочинения. Том VIII. Рус телендә, 1930 ел, 144 бит.
[2] А. Турков. Профессионализм или новаторство? «Вопросы литературы» журналы, 1962 ел, 3 сан.

аның революцион аскетизмга хезмәт итүенең җирлеген дә без шунда күрәбез.

Әдәбиятта революцион аскетизм принципларын тормышка ашыруда иң кулай конфликтларның берсе булып бурыч һәм мәхәббәт каршылыгы хезмәт итте. Андый әсәрләрдә, кагыйдә буларак, үзәк уңай герой гомуми эш файдасына үзенең эчке тойгыларын баса, мәхәббәтенә «йөгән кидерә». Моның ачык чагылышын Шамил Усманов әсәрләрендә күрергә мөмкин. Мисал өчен язучының «Ил кызы» [1] исемле хикәясен алыйк (1923 ел).

Кызыл сугышчылар көрәш һәм шәхси тойгыларның үзара мөнәсәбәтләре турында бәхәсләшәләр. Күпчелек ата-ананы, баланы сагыну, кызларга мәхәббәт тоту кебек хисләр революцион көрәшкә комачаулый дигән фикерне яклый. Командир Кәбир, мәсәлән, татар хатын-кызлары кияүгә чыгу, гаилә кору турында гына уйлыйлар, тормышта алар үзләренә башка, югарырак берәр максат тапсыннар иде, ди. Аның бу сүзләрен комиссар Әхмәт тә күтәреп ала. «Эх, күрәсе иде тормышны аңлаган матур җанлы кызларны! Әгәр дә үзенең рәхәтен ташлап, безнең арага килеп, шул авыр тормышыбызны уртаклашучы бер кыз булса иде, мин аның каршында тезләнеп, гыйбадәт кылыр идем», — ди ул (372 бит).

Озакламый Әхмәт үзе хыялланган, ир йөрәкле батыр кызга тап була да. Рауза Әхмәтнең күңелен биләп алырга да өлгерә. Ләкин аларның бу тойгысы без аңлаган мәхәббәттән үзгәрәк. «Минем гомеремдә берәүне дә сөйгәнем юк, — ди Әхмәт кызга. — Сезне дә хәзер сөям дип әйтә алмыйм. Аңа көчем җитми. Бары сезнең каршыгызда сәҗдә кылырга, сезне, бөтен нәрсәдән югары күреп, ихтирам итәргә әзерлегемне белдерәсем килә...» (385-386 битләр).

Егетнең бергә булыйк, дигән тәкъдимен ишеткәч, Рауза аны шунда ук оялтып ташлый: «Ни өчен табигать сиңа шулкадәр көч биреп тә, үзеңнең тойгыларыңа хуҗа булырлык ирек бирмәгән! — ди ул. — ...Син мине сөям дисең! Мин дә сине сөям; әмма синең төсле түгел, бәлки синең көрәшкә атылып торган гайрәтеңне, халык хезмәте юлына багышланган яшьлегеңне сөям» (386-387 битләр). Әхмәткә булган «үзенчәлекле мәхәббәтен» Рауза болайрак дәлилли: «Әйе, егет, көрәш юлында йөргән кешеләр һичбер вакыт тойгы корбаны булырга тиеш түгелләр! Син мине хәзер генә үзеңнең сөюең хакына эштән читкә китеп, бурычымны онытып, рәхәт гомер итәргә чакырдың. Мин ул юлдан бармам! Ул тойгы хакына юлымнан, бер генә карыш булса да, читкә чыкмам! Мин сине сөям икән, синең миннән еракларда, дошман белән көрәштә күрсәткән гайрәтләрең миңа юаныч булыр!» (387 бит). Ә бит бу образлар Ш. Усманов хикәясенең уңай геройлары. Бер бу хикәядә генә түгел, язучының башка әсәрләрендә дә мәхәббәт конфликты шундыйрак яссылыкта хәл ителә.

Ш. Усманов әсәрләрендәге бу үзенчәлекне әдәбиятчылар төрлечә атыйлар һәм төрлечә бәялиләр. Г. Халит, мәсәлән, аны «шәхси теләк һәм хисләрнең тормыш, көрәш чынлыгыннан өстен була алмаганлыгын раслау» дип билгели [2]. Язучы иҗатын махсус өйрәнгән А. Яхин, бу мәсьәләгә тукталып: «Мәхәббәтне кешенең бөек көрәш хисенә каршы куеп, Ш. Усманов зур хата ясый. Шунысы бар, бу каршылыкны язучы проблема итеп күтәрә һәм мәхәббәттән ваз кичкән көрәшчене яңа кеше итеп тәкъдим итә» [3], — ди. А. Яхин бернәрсәне истән чыгарган, бу — Усманов хатасы түгел. Бу тормышта, революцион чынбарлыкта туган һәм яшәгән аскетизмның әдәбиятта чагылуы иде, бу — зарурият иде. Әгәр дә

---

[1] Ш. Усманов. Сайланма әсәрләр. Татарстан китап нәшрияты, Казан, 1964 ел.
[2] Татар совет әдәбияты тарихы. Очерклар. Казан, 1960 ел, 10 бит.
[3] А. Яхин. Ш. Усманов иҗаты (кандидатлык диссертациясе). Казан, 1964 ел.

тормышта киң таралган фикерләрне аерым әсәрләрдә очрата алмасак, без бу чор татар әдәбиятын тормышны бөтен тулылыгында һәм каршылыгы белән чагылдыра алмауда гаепләр идек. Ярар, ә ни өчен каһарман нәкъ менә мәхәббәттән баш тартырга тиеш соң? Ф. Энгельсның алда китерелгән, түбән катлау баш тартырга тиеш булган аз санлы рәхәтлекләр турындагы сүзләре, безнеңчә, моны аңлау өчен дә ачкыч була алалар. Мәхәббәт бернинди изү, кысу һәм чикләүләр белән дә юкка чыгарып булмый торган шундый рәхәтлекләрнең берсе. Әмма мәхәббәт, революцион аскетлар күзлегеннән караганда, азатлык көрәшенә комачауларга мөмкин, ул кешене гаиләгә бәйли, сазлыкка өстери, димәк, туздырылган иске тормышның кайсыдыр ягын кире кайтара. Инде сөешүчеләрнең берсе элекке милекле сыйныфтан да булса, ул чагында эш бөтенләй харап! Менә ни өчен, безнеңчә, бу тойгыны аңлау революциянең беренче елларында шулкадәр катлауланды, зур каршылыклар тудырды. Берәүләр мәхәббәтне гомумән кире кактылар, аны мещанлык, буржуйлык, буржуаз сентиментальлек һ. б. дип атадылар, эшчегә бу хис гомумән ят дип чыктылар. Сыйныфлар арасындагы аерымлыкны, чикне билгеләүдә ул күпмедер күләмдә ярдәм итте. Ул заманнарда көндәлек тормышта шактый киң таралган мондый карашлар, билгеле, матур әдәбиятта да чагылмый кала алмады. Гомәр Галинең «Беренче мәхәббәт»[1] исемле хикәясендә (1924 ел) сөю мещаннарга гына хас дигән караш үткәрелә. Әсәрдәге үзәк герой Әкрәм үзенә мәхәббәт белдергән кызга: «Син алай беркемне дә сөймә, сөюче дә эзләмә. Кирәк икән, иптәш эзлә. Мәсьәлә миңа калса инде, завод трубалары арасында туып, станоклар арасында үсеп, сугышта тәрбияләнгән минем табигатькә син «сөю» белән дә, «иптәш эзләү» сүзләре белән дә якын килә алмыйсың. Тагын бер кат әйтәм: сөймә син, иптәш эзлә, ләкин миннән башканы», — дигән киңәш бирә.

Икенче берәүләр (Ш. Усманов, Ф. Бурнаш) мәхәббәтне бөтенләй үк кире какмаган хәлдә, бу хиснең кысаларын киңәйтергә омтылдылар. Мәхәббәт хисе үз эченә мәҗбүри төстә революцион намусны да алырга тиеш, аларча. Әгәр дә шулай булмаса, мәхәббәт яраксызга чыгарыла һәм һичсүзсез гаепләнә иде. Ш. Усманов, мәсәлән, кешенең барлык шәхси тойгыларын сыйнфый максатка яраклаштыру ягында торды. «Памирдан радио» исемле фантастик повестьтан кыска гына бер эпизод китерик:

«...Аерым гаиләдә үскән балада ата-ананы сөю була. Сездә, алар ата-аналарыннан аерым тәрбияләнеп үскәнгә күрә, ул тойгы көчле түгелдер.

— Әйе, бездә ул тойгыны үстерү алга сөрелми, безнең баланың якын кардәшләре ата, ана, сеңел, туганнары белән генә чикләнми, бәлки бөтен яшьтәшләренә җәелә. Аның гаиләсе — бөтен кешеләр. Ул үз йорты, үз рәхәтеннән бигрәк, кешелек дөньясының рәхәтен кайгырта, шуны алга сөрә...»[2] Күрәсез, авторның әдәби-эстетик карашлары да, тормышка мөнәсәбәте дә шул заманча, «революцион аскетизмча».

Мәхәббәтне, гаилә коруны хайвани мөнәсәбәтләргә генә кайтарып калдырып, бу изге хисләрне тупас төстә бозып аңлатулар да бу елларда шактый киң таралган иде. 1923—24 елларда Казанда «Күмәк тормыш пионерлары Союзы» төзелү, «Өйләнмәүчеләр һәм кияүгә бармаучылар» җәмгыяте оешу, «гаиләгә һөҗүм»нең көчәюе, «бер стакан су» һ. б. теорияләрнең баш калкытуы да аскетизм карашларының шактый киң таралган булуын күрсәтсә кирәк. «Үзен пролетариатка хезмәткә багышлаган ир кеше, бала тугач, чүпрәк, кибет, жалованье артыннан йөреп ваклана. Хатын-кыз да шулай, шуңа күрә дә «ирекле семья кирәк», —

[1] Г. Гали. Сайланма әсәрләр, Татарстан китап нәшрияты, Казан, 1957 ел.
[2] Шунда ук, 254 бит.

дип язып чыга Ш. Усманов «Гаилә турысында» исемле бер мәкаләсендә («Татарстан» газетасы, 1924 ел, 27 сан).

Мәхәббәтне өлешчә кире кагу, күбрәк, революционер белән бай кызы арасындагы мәхәббәтне күрсәтү аша гәүдәләнде. 1920—30 еллар әдәбиятында бу тапталган темага әверелде. М. Горький аны «ходячая тема» дип атады. Андый әсәрләр татар әдәбиятында гына да берничә дистәгә тула. Ф. Сәйфи-Казанлының «Дошманнар», «Зәкван мулла шәҗәрәсе», «Зәңгәр алан» пьесалары, «Хатын», «Елан токымы» хикәяләре, Г. Гали, Г. Толымбайский хикәяләре, Ш. Усманов, К. Әмири, Ф. Бурнаш, Ш. Камал пьесалары һ. б.

Әлбәттә, әдәбият гаять катлаулы процесс, аңарда һәммә нәрсәне бер кагыйдәгә генә сыйдырып бетереп булмый. Бу очракта да шулай. Аерым язучылар бай кызы һәм ярлы егете мәхәббәтен традицион рәвештә тасвирлауны дәвам иттерделәр. Мәсәлән, Мирхәйдәр Фәйзи «Урал суы буенда», «Асылъяр», «Ак калфак» драмаларында көчле романтик мәхәббәтне сыйнфый тигезсезлеккә каршы куя, мәхәббәт ярдәмендә капитал җәмгыятенә ләгънәт укый.

Мәхәббәтне олылау, аны башка көчләргә каршы кую Ф. Бурнаш романтизмының бер чыганагын тәшкил итә. Ф. Бурнашның беренче, әле Октябрьга кадәр үк иҗат иткән әсәрләрендә мәхәббәт дөньядагы барлык нәрсәдән өстен куеп сурәтләнә, геройлар яшәүнең тәмен бары тик сөю-сөешүдә генә күрәләр иде. Социалистик революция булгач, язучы халыкның азатлык өчен көрәшкә күтәрелүен, аның арысландай улларының бу юлда үз-үзләрен аямауларын күрде. Революциянең — халыкның гасырлар буе хыялланган көрәшнең — язучы әллә нинди гүзәл һәм саф мәхәббәтләрдән дә мөкатдәсрәк нәрсә булуын аңлады. Аның геройлары инде азатлык сугышы хөрмәтенә тормыш рәхәтлекләреннән, шәхси мәнфәгатьләрдән баш тарталар, мәхәббәтләрен дә корбан итәләр. Ф. Бурнаш иҗатына революцион аскетизмның үтеп керүен «Хөсәен Мирза» әсәре мисалында күрергә мөмкин. Аның 1918—19 елларда язылган вариантында[1] үзәк персонажлар Муса һәм Сара бертуганнар итеп бирелә. Мусаның изелгәннәр хакын даулаучы булуы бернинди шәхси тойгылар белән дә каршылыкка кертелми. Инде әсәрнең соңгы, 1926 елда сәхнәгә куела башлаган вариантында ике арадагы кан якынлыгы калмаган. Монда Муса мирза кызы Сараның мәхәббәтен кире кага. Ул моны кызны сөймәгәннән түгел, ә гыйшкы гомуми эшкә зарар итәр дип уйлаганга шулай эшли. Ф. Бурнашның башка әсәрләрендә дә уңай геройлар итеп нәкъ менә шундый кешеләр — көрәш юлына нык иман, какшамас ихтыяр белән килеп кергән каһарманнар алына («Чәчәктән һәйкәл», «Сахра каны» поэмалары, «Кайт кызыл гөлләр белән» шигыре һ. б.). Мондый геройлар хәтта беркадәр заманның эстетик идеалына әверелделәр. Икенче төрле әйткәндә, чорның эстетик карашларын билгеле бер дәрәҗәдә революцион аскетизм фикерләре билгеләде.

Чынбарлык тормышта гел шулай була килгән: бер хәрәкәт үзенә каршы икенче хәрәкәтне тудырган, бер күренеш икенче бер күренешне — үзенең антиподын барлыкка китергән. Бу — аскетизмга да карый. Янарыш чорындагы дини аскетизмга каршы гуманистик индивидуализм туса, совет әдәбиятының беренче елларындагы революцион аскетизмга да реакция булды. Без, мәсәлән, Гали Рәхимнең «Идел» повестен өлешчә шул нигездә барлыкка килгән әсәрләрдән дип карыйбыз. Әгәр дә гуманистик индивидуализм кешене, аның талантын дини аскетизмның черек фәлсәфәсенә каршы куеп, кеше шәхесенең азатлыгын якласа һәм шуның белән алдынгы роль уйнаса, Гали Рәхим алга сөргән индивидуализм исә реакцион рухта иде. Чөнки заманы башка, иҗтимагый шартлар башка, максат башка. Никадәр генә каршылыклы, берьяклы

[1] Әсәр бу вакытта сәхнәгә «Җирсезләр» исеме белән куела.

булмасын революцион аскетизм нигездә халыкны коллыктан азат итү эшенә хезмәт итә иде һәм шуңа күрә дә андый әсәрләр, сәнгатьчә эшләнешләре ягыннан һәр очракта да тиешле дәрәҗәдә тормасалар да, Совет властеның беренче елларында шөһрәт казандылар. Һәм алар бер никадәр әле хәзер дә үз кыйммәтләрен саклыйлар. «Идел» повестенда Ильяс образы аша үткәрелгән индивидуализм исә һәртөрле көрәшкә каршы чыгу рәвешендә, ялгызлыкка дан җырлау төсендә яңгырады. Һәм мондый әсәрләр җәмәгатьчелек тарафыннан, бик хаклы рәвештә, кире кагылдылар.

Революцион аскетизмның үз чорында уңай роль уйнавы бәхәссез. Ләкин, ди Ф. Энгельс, пролетар аскетизм акрынлап югала, масса аңардан арына. «Берьяктан хәзерге житештерү көчләренең үсүе куллануның материаль средстволарын чиксез киңәйтә, шуның белән спартанлык тигезлеген кирәксез иткән саен һәм, икенче яктан, пролетариатның тормыш шартлары, ә шуның белән бергә пролетариатның үзе дә һаман революционлашкан саен... бу плебей-пролетар аскетизм үзенең революцион сыйфатын югалта»[1].

Бу кагыйдәнең әдәбият өчен дә уртак булуын «Яңа кешеләр» тирәсендәге бәхәс ачык күрсәтә. Ш. Байчураның драмага һәм аның авторы алдына куйган таләпләре революцион аскетизм принципларына нигезләнгән. Пьесадагы үзәк уңай герой Батырханның бай кызы Зәйниягә булган мәхәббәте, көрәшнең кызган бер чорын күрсәткәндә бу мөнәсәбәтне уңай яктан алып, алга чыгарып сурәтләү, кызыл көрәшче Камәрнең томанлы үткәне революцион аскетизм тарафдарларына ошамый иде. Күренекле, зур язучы буларак, Г. Ибраһимов шәхсинең һәм иҗтимагыйның бер җирлектә сыеша алу мөмкинлеген һәм тиешлеген күрсәтеп, гражданнар сугышы темасына багышланган әдәбиятка яңалык алып килде. Чөнки алга барган саен революцион аскетизм әдәбиятны ярлыландырачак иде. Революцион бурыч бәрабәренә шәхси мәнфәгатьләрдән баш тарту яңа чорның уңай героен бары тик иҗтимагый эшчәнлек яссылыгында гына сурәтләүгә, әсәрдә шәхси интриганың булмавына китерде.

Революцион аскетизм биреп калдырган бу «мирас» аерым язучылар иҗатында шактый вакытларга житте әле. Яңа җәмгыять төзү өчен көрәшүчеләрне иҗтимагый яссылыкта гына тасвирлауга, геройның шәхси тормышына игътибар итү әдәби әсәрдә алынган материал нигезендә соралган сурәттә дә моның бөтенләй эшләнмәве яки өлешчә генә эшләнүенә бу чордагы татар совет әдәбиятыннан күп мисаллар табарга була. Бу яктан революцион аскетизм фикерләре вульгар социологизм таләпләре белән бик тә аваздаш яңгырыйлар, әдәби иҗатта һәм тәнкыйтьтә алар бер-берсенә керешеп китәләр, бер-берсен көчәйтәләр иде.

1921 елны Ф. Бурнаш «Шәмсия» исемле романтик драмасын язды. Һәм пьеса 1922 елны сәхнәгә дә куелды. Кызыл партизан Габбасның, көрәштән баш тартып, мулла кызы Шәмсиягә өйләнүен, мещанлык баткагында үзенә урын таба алмый җәфалануын һәм яңадан да иптәшләре янына кайтуын сурәтләп, автор мәхәббәтне һәм тыныч тормыш рәхәтлекләрен көрәш хакына корбан итүне алга сөрде. Бу әсәр һәм аның куелышы турында беренче һәм бердәнбер бәяне — уңай бәяне Ш. Усманов бирүе дә тикмәгә булмаса кирәк[2]. Соңгысы бай кызы һәм ярлы егете мөнәсәбәтен реалистик сурәтләгән «Бай кызы» пьесасын язып, мәсьәләне Ф. Бурнашча хәл итүне яклап һәм үстереп чыга.

Ф. Бурнаш «Адашкан кыз» драмасында да (1926 ел) «Шәмсия» һәм «Хөсәен мирза» әсәрләрендәге сызыкны дәвам иттерә. Дөрес, мәхәббәт

[1] Шунда ук, 114 бит.
[2] Ш. Усманов. Үткән кышкы сезонда татар театры. «Татарстан» газетасы, 1923 ел, 156 сан.

һәм революциянең үзара мөнәсәбәтен чагылдыру бу әсәрдә үзенчәлекле. Пьесаның уңай герое Латыйф мәхәббәтне кире какмый, ул хәтта аның өчен көрәшә дә. Шулай да аның бай гаиләдән чыккан Хәдичәне кызыл көрәшчеләр сафына тартырга тырышуы юкка гына була. Шуның белән язучы соң чиктә барыбер революцион аскетизмны яклый.

Ф. Бурнашның 30 еллардагы әсәрләрендә революцион аскетизмның йогынтысы геройларның эш-хәрәкәтләре һәр очракта да психологик дәлилләнмәүдә, шәхси тормышлары тиешенчә яктыртылмауда күренде. Җәгъфәр («Олы юл белән» драмасы 1929—30), Гольман («Тукучы Әсма» пьесасы, 1931), Сафаров («Лачыннар» романтик драмасы, 1932—33), Таймасов («Таң» героик драмасы, 1934—36) ныклык, эшчәнлек сыйфатлары белән генә тасвирланалар һәм сыйфатланалар. Автор аларны «күрә торып» рухи байлыкларыннан мәхрүм итә. «Күрә торып» дибез, чөнки геройларны бу яктан да җанландыру һәм тулыландыру өчен мөмкинлекләр була, ләкин язучы алардан файдалануны кирәксенми. Хәтта, киресенчә, булган кадәресен дә кимчелек төсендә билгели. Үзенең бер чыгышында Ф. Бурнаш элегрәк язылган әсәрләрен дә шул күзлектән карап тәнкыйть итә. «Хөсәен мирза» исемле пьесамның, — ди ул, — төп бер җитешсезлеге бар, ул — аерым моментларда индивидуаль психологизмны алга сөрүдә».

«Адашкан кыз»га да ул шундый ук кимчелек тага: «Бу әсәремнең дә төп җитешсезлеге — шул ук психологизм басымының күбрәк урын алуы дип беләм». «Лачыннар» турында сөйләгәндә тагын да ачыграк итеп: «Кара-кызның шәхси психологик моментлары беркадәр социаль моментларга комачаулыйлар», — ди ул.

Революцион аскетизмның Ф. Бурнаш иҗатына аерым очракларда тискәре йогынты ясавын тәнкыйть тә күрде. Г. Нигъмәти аның «Миңлекәй белән Данбулат поэмасы»на (1933) нәкъ шул ноктадан якын килә. «...Бөтен поэмадан күренүенчә, Ф. Бурнаш колхоз тормышында шәхси, бытовой интересларны бергә җыю турында зур киртәләр күрә һәм шәхси, бытовой интересның иҗтимагыйга яраклаштырылуын ачык, дөрес итеп куя алмый» [1], — дип язды күренекле тәнкыйтьче.

Чыннан да, әсәрнең беренче вариантында эш шулай тора. Данбулат исемле егет алдынгы колхозчы кыз Миңлекәйгә өйләнергә тели. Тегесе, егет алдында яңадан-яңа бурычлар куеп, туйны кичектерә. Данбулат башта алдынгы бригадир булырга тиеш, аннан соң кыз «син алдынгы председатель булгач, туй ясыйбыз» дип ышандыра. Ләкин, инде Миңлекәйнең бөтен теләкләре җиренә җиткерелеп үтәлгәч, егет үзе үк кушылудан баш тарта. «Бик күп әле алда көрәш юлы барырга», — ди ул. Г. Нигъмәтинең урынлы тәнкыйтеннән соң Ф. Бурнаш әсәрнең ахырын үзгәртә. Вакыйгалар Миңлекәй һәм Данбулатның кушылуы, туй булу белән тәмамлана.

Без һич тә революцион аскетизм идеяләре барлык язучылар иҗатында да өстенлек итте дип расларга уйламыйбыз. Көрәшче намусы каршында шәхси теләкләрнең чигенүен сурәтләү иң таралган чорда да мәхәббәтне һәм иҗтимагый бурычны үзара яраштырырга, татулаштырырга омтылып әсәрләр язылды. Шундыйлар рәтенә, мәсәлән, К. Әмири әсәрләрен кертергә була. «Казан кызы» комедиясендә ул бай кызы белән коммунист мөнәсәбәтен инде мәгълүм төстә кире кагу белән янәшә үк, чагыштыру төсендә, партия-совет эшчесе Закир белән Мәрьямнең таза, сәламәт нигезләрдә төзелгән гаилә тормышын тасвирлады. Г. Ибраһимов «Безнең көннәр» әсәренең икенче вариантында иҗтимагый һәм шәхсинең табигый берлеген күрсәтүдә «Яңа кешеләр»дәге башлангычны үстерде. «Ул (ягъни Нина — А. Ә.) мин бер генә сөюче, мин

[1] Г. Нигъмәти. Әдәбиятта тәнкыйть, юлбашчылыкны көчәйтергә, аның сыйфатын күтәрергә. «Совет әдәбияты» журналы, 1934 ел, 1—2 саннар.

үз гомеремдә бер генә ирне сөя алачакмын дип карый иде. Дөньяда партия өчен торам, революция өчен торам, дип ышана. Ләкин шул ышануны мәхәббәт белән нурландырмасам, минем канатларым хәлсезләнә. Минем өчен партия бар. Революция бар. Шулар белән бергә бәгланып кайнашкан Коля бар. Үзем бар. Болар бер-берсенә башка әйбер түгел. Һәммәсе бер процесс, һәммәсе бер көрәшнең төрле күренешләре генә дип матурлап уйлый» («Безнең көннәр» романы, II басма, Казан, 1935, 412 бит).

Бу — революцион аскетизм тарафдарларына туры һәм дөрес җавап иде.

Шагыйрь Һади Такташ та совет кешесе образын тудыруда иҗтимагый бурыч һәм шәхси теләкне аерылгысыз сурәтләү кирәклеген аңлап эш итте («Камил» драмасы, «Алсу», «Мәхәббәт тәүбәсе» поэмалары һ. б.).

Шулай итеп, татар совет әдәбияты революцион аскетизмнан әкренләп һәм уңышлы төстә арына барды. Социалистик реализм методын үзләштерүнең олы юлына чыккан әдәбият өчен бу зарурый нәрсә иде, әлбәттә.

Бу күренешнең заманы өчен котылгысыз булуын, билгеле бер уңай роль уйнавын алдан әйткән идек инде. Революцион аскетизм фикерләренә таянган эстетиканың аерым уңышлы яклары (әйтик, монументаль герой иҗат итүдәге әле хәзер дә әһәмиятен җуймаган иҗади табышлар һ. б.) хакында һәм аларның алга таба ничек итеп үстерелүе турында да сөйләргә мөмкин булыр иде. Әмма соңгылары бу мәкалә күләменә сыймыйлар һәм максаттан читтәрәк торалар. Ә асыл теләгебез исә, тормыш үзе куйган проблеманың — революцион көрәш призмасы аркылы гаять үзенчәлекле чагылган аскетизмның яшь татар совет әдәбиятына үзенә бертөрле тәэсир ясавын күрсәтергә тырышу иде. Бу проблема белән безнең хәзерге әдәбият арасында бәйләнеш бармы? Әйе, бар. Шундый катгый җавапны биргәндә без, иң беренче, күренекле язучы Мирсәй ага Әмирнең «Хөррият» исемле героик драмасына (1960 ел) таянабыз.

Әсәр үз вакытында әдәби тәнкыйть күзенә эләкмирәк калды. Аерым әдәби фактларны бәяләгәндә безгә үткәнгә әйләнеп карау, аларга шул вакыттагы әһәмиятле мәсьәләләр яктылыгында карый белү җитми, күрәсең. Югыйсә, бу пьесадагы зур яңалык тиешенчә бәяләнер иде. Ә ул яңалык Совет властен урнаштыру елларында туган революцион аскетизмны күреп алудан, бүгенге көн югарылыгыннан торып, тиешенчә яктыртудан, бу проблеманың тормышчан нигезләрен тирән һәм ышандырырлык итеп ачып салудан, тасвирлаудан гыйбарәт.

Ярлы крестьян малае Таһир һәм кулак кызы Бибисара бер-берсен яраталар. Ләкин заманалар шундый ки, яшьләрнең керсез мөнәсәбәтләре я революция, я мәхәббәт дигән сынау — сайлау алдына куела. Һәм Таһир, батыр һәм тәҗрибәсез көрәшче Таһир, карун атасы өеннән качып, үзе янына яклаучысын эзләп килгән кыздан катгый төстә баш тарта. Хәер, егетне бу очракта тәҗрибәсезлектә гаепләп буламы икән әле?! Әнә бит, авыл Советы председателе, коммунист, авылның намусы Гариф та, башкалар да аның бу адымын хуплыйлар.

Бәхеткә каршы, Бибисара акыллы булып чыга, һәртөрле үпкәләүләрне, хәтер калуларны читкә атып, олы мәхәббәтенә турылык саклый һәм бу хәл Таһирны үлемнән коткаруда, хыянәтче Чамайны фаш итүдә һәм башка бик күп нәрсәләрдә (әйтик, Тимергалинең соңыннан «контр» төсендә гаепләнүен булдырмый калуда һ. б.) хәлиткеч роль уйный.

Әйе, тормыш гаҗәп ул. Анда һәрнәрсә үзенчәлекле, һәр күрнеш, һәр вакыйга, һәр кеше үзенә, кем әйтмешли, «индивидуаль подход» сорый. Ярлы егете һәм бай кызы мәхәббәтенең гомуми эшкә зарар китерү мөмкинлегенә икеләнү-шикләнүнең, «ышан син кулак кызына!» дигән ка-

рашның тормышчан нигезе юкмыни? Бар, әлбәттә. Шул ук вакытта конкрет кеше — Бибисараның ярлы егеткә булган мәхәббәте көрәшкә зур ярдәм итмимени? Ярдәм итә. Шуның белән, ышандырырлык итеп, бу карашның һәр очракта да нигезле була алмавы раслана. Тормыштагы шушы проблема, шул каршылык пьесаның нигезенә салынган конфликт аша ачыла. Әсәрнең новаторлыгы да шунда.

М. Әмир заманыбызның үсеш тенденцияләрен гаять тирән аңлый һәм сурәтли белүче язучы булуын тагын бер кат күрсәтте. Драмада шул вакыттагы тормыш диалектикасы тулы чагыла.

Шушы җәһәттән караганда, Фатих ага Хөснинең «Утызынчы ел» исемле романы да яңа яктан ачылып китәчәк, аның идея-эстетик әһәмиятен билгеләү тагын да тулыланачак.

Хәзерге әдәбиятыбызда шәхсине һәм иҗтимагыйны ясалма төстә бер-берсенә каршы куеп, берсе файдасына икенчесен корбан кылуны хуплаган әсәрләрне күрсәтүе кыен. Шулай да, бүгенге аерым әсәрләрдә кайвакыт иҗтимагый интересларны күрсәтү белән артык нык мавыгып китеп, кешегә җанлы шәхес буларак әһәмият биреп җиткермәү очраштыргалый әле. Дөрес, совет кешесе иҗтимагый теләкләрне беренче урынга куя, ләкин шәхси мәнфәгатьләр дә аның аңында һәм тормышында каядыр читкә тибәрелмиләр. Әсәрдәге герой производствога бирелгән, эшкә чумган хәлдә күренеп тә, укучы-тамашачы алдында үз характерындагы эш сөючәнлек билгесеннән тыш якларын ачарга вакыт тапмаса, бик үк шәп түгел, әлбәттә. Мондый очракларда совет кешесен ярлыландырып сурәтләү килеп чыга. Герой тормышындагы шәхсинең һәм иҗтимагыйның үзара бәйләнеше мәсьәләләре бүгенге әдәбиятта тагын да әһәмиятлерәк төс ала. Сүз һәрьяклап үскән кеше шәхесен, ягъни коммунизм кешесен тәрбияләүне төп максат итеп куйган әдәбият турында бара бит. Бу әдәбияттагы үзәк герой хезмәттә генә түгел, көрәштә дә, мәхәббәттә һәм дуслыкта да бөтен тулылыгында, рухи яктан бай булып чагылырга тиеш. Чөнки яңа җәмгыять төзүче совет кешесе тормышта шундый күпкырлы һәм бай ул!

●

Язучының иҗат портреты

*Рафаэль Мостафин*

# АЛГА БАРЫШЛЫЙ

Хәсән Туфанның ул вакыттагы чыгышын беркайчан да онытмам мин. 1957 елда, ул ерак Себер сөргененнән кайткач булды бу.

Нигездә студентлар җыелган кичерәк кенә залдагы трибунага, ул вакытта миңа шулай күренгәнчә, бик тә ябык, бик тә йончылган, бик тә карт һәм бите җыерчыклар белән телгәләнгән бер кеше күтәрелде. Аның бөтен кыяфәтендә нык арыганлык сизелеп тора. Әйтерсең, ниндидер чиксез зур авырлык аның иңнәренә басып, җиргә кыскан, күз нурларын сүндергән, ирен читләреннән хәсрәт сызыклары уздырган иде. Куллары белән трибуна читенә тотынып һәм башын аска иеп, Туфан берничә минут дәшми торды. Нинди уйлар кичерде икән ул бу минутларда? Юеш, салкын казаматларны, Себер карлары балкышын, җанны өтеп ала торган «халык дошманы» дигән кушымтаны, үлеп калган иптәшләрен хәтерләде микән әллә?.. Зал, аның хәлен аңлап, тып-тын калган иде.

Кинәт караңгы, авыр көннәрдә күргәннәрен читкә алып ташлагандай итеп, Хәсән Туфан башын күтәрде, яшьләр җитезлеге белән озын чал чәчләрен селкеп артка ташлады һәм балаларча ягымлы елмайды да шигырь укырга кереште.

Аның укуы үзенчәлекле иде. Әйтерсең, аның каршында йөзләгән күзләр белән текәлгән зур аудитория түгел, бәлки бердәнбер иң якын, иң зур дусты утыра, һәм ул әнә шул дустына үз күңелендәге иң нечкә хисләрен сөйли шикелле иде.

Шигырьләрен укыганда Туфан безнең каршыбызда күзгә күренеп яшәрә дә барган кебек тоелды: җилкәләре языла, күзләре яшьләрнекечә очкынлана, башта саңгырау һәм хәлсез булып ишетелгән тавышы көчәйгәннән-көчәя бара иде аның. Бу инде әле моннан берничә минут элек кенә башын иеп торган ябык Туфан түгел иде. Безнең алдыбызда хәзер яшьләрчә көчле һәм сизгер җанлы, бөтенләй башка кеше басып тора иде. Һәм ул безне, сихри талантына буйсындырып, үз дөньясына алып кереп китте. Аның һәрбер шигырь юлы, йомшак, аһәңле, уңдырышлы туфракка төшеп шыта башлаган орлык шикелле, безнең күңелебездә җылы, матур хисләр уята бара иде.

Соңыннан, Туфан шигырьләрен кат-кат укыганнан соң, аның әсәрләрендә кайбер тиешенчә үк эшләнеп бетмәгән урыннар да, бик үк уңышлы яңгырамаган рифмалар да очратырга мөмкин иде. Әмма ул кичтә, Хәсән Туфан белән беренче мәртәбә танышу минутларында, безнең ул кимчелекләрне күрергә вакытыбыз булмады. Туфан поэзиясе безне, бары тик чын сәнгатькә генә хас булганча, тәмам үзенә буйсындырган иде. Безнең барыбызга да бер нәрсә — каршыбызда үзенең иҗаты белән татар поэзиясенең яңа һәм үзенчәлекле битен ачучы шагыйрь торганлыгы ачык иде.

Беренче хис — иң дөрес хис, диләр. Бу очракта ул, чыннан да, шулай булып чыкты. Һәм хәзер, ул кичтән соң инде сигез ел үткәннән соң, Хәсән Туфанның әле күптән түгел генә басылып чыккан сайланма әсәрләрен яңадан укыгач, шундый нәтиҗәгә киләсең: әйе, Туфан кызыклы, оригиналь һәм талантлы шагыйрь генә түгел. Ул, ихтимал, әсәрләрен хаклы рәвештә Тукай, Такташ, Җәлил кебек татар поэзиясе корифейлары иҗаты белән рәттән куярга мөмкин булган хәзерге шагыйрьләребезнең иң зурысыдыр.

* * *

Хәсән Туфанның татар поэзиясенә килеп керүе шактый үзенчәлекле була. Әдәбиятта беренче адымнарын ук Туфан тормышчан, реалистик рухтагы әсәрләр язучы шагыйрь буларак атлый. Ул егерменче еллардагы бик күп татар шагыйрьләре өчен характерлы булган абстракт символика, дини-мифик һәм шартлы-романтик образлар иҗат итү белән мавыгуны бөтенләй белмәде дияргә мөмкин. Туфан татар поэзиясенә һ. Такташның реалистик поэзиясе ирешкән зур уңышлар дулкыны белән килеп керде һәм татар поэзиясе үсешенең шушы югары ноктасыннан торып, аны алга, яңа иҗади уңышларга әйдәп китте.

Оялчан, яшь рабкор Хәсән Туфан 1924 елда «Кызыл Татарстан» газетасында шактый йомшак беренче шигырен бастыра. Шуннан соң нибары өч ел үткәч, ягъни 1927 елда Туфан инде танылган шагыйрь булып китә, күренекле тәнкыйтьче Галимҗан Нигъмәти аны татар совет әдәбияты күгендәге иң якты йолдызларның берсе дип атый.

1927 ел Туфан иҗатында үзенә аерым урын алып тора. Кечкенә күләмле шигырьләреннән тыш, шул бер ел эчендә генә дә ул «Урал эскизлары», «Ике чор арасында», «Башлана башлады», «Иске Рәсәй үлде», «Бибиевләр» кебек зур күләмле поэтик әсәрләрен иҗат итә. Ләкин авторның уңышын әсәрләр саны гына билгеләми. Туфан әсәрләре татар поэзиясенә бик тә кирәк булган эшчеләр темасын алып килделәр. Дөрес, Туфанга кадәр дә эшчеләр тормышы турында язучылар булды, ләкин аларда эшче образлары күбрәк абстракт, шартлы символлар сыйфатында гына сурәтләнә иде. Хәсән Туфан әсәрләрендә исә без катлаулы һәм тулы канлы эшче образларын очратабыз. Хәсән Туфанның 1927 елда иҗат ителгән әсәрләре аның үз иҗатында гына түгел, гомумән татар поэзиясендә матур һәм кабатланмас күренеш булып калды. Әгәр Хәсән Туфан ул әсәрләреннән соң бер генә юл шигырь язмаган булса да, аның исеме барыбер татар поэзиясе тарихына кереп калыр иде.

Туфанның әдәбиятка шушылай шаулап килеп керүенең сәбәбе нәрсәдә иде соң? Бу мәсьәләдә, барыннан да элек, Туфанның бик яшьләй хезмәт белән танышуы, шәхес буларак иртә формалашуы һәм, Урал революцион эшчеләре белән якыннан аралашу нәтиҗәсендә, тормышта үзенең урынын ачык билгеләве, дөньяга үзенчә карарга өйрәнүе хәлиткеч роль уйнады. Хәсән Туфан ярым крестьян, ярым эшче семьясында туа. Аның атасы, крестьян булудан тыш, мич чыгаручы, балта остасы, гомумән, ни тотса шуны эшли алырлык бер кеше була. Ә абыйлары, барысы да диярлек, читкә китеп, Урал заводларында эшлиләр.

Хәсән Туфан ундүрт яшеннән Уралда бакыр чыгара. Унбиш яшендә — шахтер; уналтыда — Лысьвен металлургия комбинатында токарь булып эшли. Ул Уралны аркылыга-буйга йөреп чыга һәм шул вакытта, Урал заводларының берсендә, 1917 елгы революцион вакыйгалар белән очраша.

Күрәсез, эшчеләр темасы Туфан өчен очраклы әйбер булмаган. Аның һәр нәрсәне бик тиз эләктерүчән яшь һәм саф күңеле завод тормышыннан алынган тәэсирләрне үзенә сеңдереп барган. Менә шуңа күрә дә, Хәсән аганың үзе әйтүенчә, аңа эшче образларын — Хабулларны, Минапларны һәм Бибиевләрне уйлап чыгаруның һич тә кирәге булмый. Ул геройларны тормышның үзеннән бөтен үзенчәлекләре, уңай һәм кире яклары, кабатланмас колоритлары белән бергә һәм хәтта еш кына фамилияләрен дә үзгәртмичә ала. Кыскасы, автор тормышта аларны ничек итеп күргән булса, шул килеш сурәтли.

Х. Туфанның укучыларны да, тәнкыйтьчеләрне дә үзенә бик тиз җәлеп иткән беренче зур поэтик әсәре «Урал эскизлары» булды. Шуннан соң ул бу әсәрендә эскизлар рәвешендә генә билгеләнгән темаларны да, образларны да тирәнәйтә һәм үстерә барды. Туфанның ул чордагы аеруча уңышлы эшләнгән әсәрләре итеп, һичшиксез, «Ике чор арасында», «Башлана башлады» поэмаларын һәм тематикасы белән дә, образлар структурасы белән дә аларга якын торган «Бибиевләр» поэмасын санарга кирәк. Сүз арасында шунысын да искәртеп үтик: автор үзе бу әсәрләрен поэма дип атамаган һәм, гомумән, аларның жанрын билгеләмәгән. Ихтимал, ул үзен тегеяки бу жанр кануннарына бәйләп куярга теләмәгәндер; әгәр алай итсәм, күңелемдә тулып ашкан уй-хисләрне сыйдырып бетерә алмам дип уйлагандыр. Һәм, чыннан да,

Х. Туфан әсәрләре формалары ягыннан бик үк гадәти түгел һәм алар классик мәгънәсендәге поэмага охшамаганнар да. Аларда, гадәттә, ачык беленеп торган сюжет та, традицион бәйләнеш, кульминация һәм чишелеш тә юк. Аның әсәрләре бары тик бер нәрсәгә — автор теләгенә — буйсынып, бер дә көчәнмичә, салмак кына җәеләүсә баралар һәм укучыны ихтыярсыз рәвештә үз артларыннан әйдәп китәләр. Ләкин, шулай булуга да карамастан, авторның бу әсәрләре тормыш күренешләрен иңләү ягыннан да, социаль тирәнлекләре, фикерләренең фәлсәфи мәгънәсе ягыннан да, композиция төзелеше һәм автор хисләренең киеренке бирелүе ягыннан да чын поэмалар, әлбәттә. Туфанның бу әсәрләрен язылырга тиешле булып та, язылмыйча калган монументаль полотна өчен эшләнгән эскизлар дип тә атап булыр иде. Чөнки аларның барысында да уртак образлар, гомуми мотивлар бар һәм алар хәтта мәгълүм дәрәҗәдә сюжетлары белән дә үзара бәйләнгәннәр. Аларда яшь Туфанның эпик язучы буларак үзенчәлеге бик ачык күренә. Әгәр лирик шагыйрь өчен иң мөһиме — үзенең дөньяга карашын, үз хисләрен һәм кичерешләрен сурәтләп бирү булса, эпик шагыйрь, психологик дөрес һәм кабатланмас итеп, кеше образларын тудыруны күздә тота. Туфан поэмалары татар поэзиясен нәкъ әнә шундый истә кала торган, колоритлы образларның бөтен бер галлереясы белән баеттылар да инде. Менә стихияле бунтарь һәм сукбай «суыгаяк Хабул». Аның яшәп килүче тәртипләргә каршы протесты вакыты белән бөтенләй йөгәнсез формаларга кереп китәргә мөмкин. Хабул образы авторның һәр өч поэмасында да бар һәм һәр поэмада ул укучылар алдында яңа, моңарчы билгеле булмаган яклары белән ачыла, характер буларак тулылана бара. Әйтик, «Башлана башлады» поэмасында без инде бөтенләй икенче характерлы Хабул белән очрашабыз. Патша төрмәләрендә утырып чыккан «ристан Хабул» инде күп нәрсәнең асылына төшенгән, күп кенә иллюзияләреннән ваз кичкән һәм аңлы рәвештә халыкны оештырырлык көрәшче булу дәрәҗәсенә күтәрелгән. Яки менә алаканат Минап —

Соңгы мужик тибы,
Соңгы мамонт кебек кызык ул.

Минап — әле фабрика казанында кайнарга өлгермәгән, кендеге белән вак миләкчә крестьян хуҗалыгына береккән кеше. «Бибиевләр» поэмасындагы «алаканатчарак» Гыймай да шул ук Минапның икенче бер төре булып тора. Аларның аермасы бары тик шунда гына: Минап хәйлә-алдауларны белми торган, башкалар авызыннан чыккан һәр сүзне дөрес дип кабул итүче самими бер кеше булса, Гыймай — хәйләкәр: я «ызгышу», яисә «майлау» белән төшемле эш эзли. Ул, Минап шикелле, авыр эштә, кызу цехларда түгел, бәлки «цех тышында, я күмердә, яисә утында» эшли. Ә аның абыйсы Чапый исә — «корычланган цехлардагы учак утында» кайный. Бу агайэнеләрнең характерларында гына түгел, аларның дөньяга, тормышка карашлары арасындагы аермалыкларны да Туфан гаҗәп оста итеп ачып бирә:

Бибиевләр,
Туган булсалар да,
Ятлар кебек гомер итәләр.
Ни турында гына гәп бармасын,
Сүзгә килә алар икәүләп.
... Гыймай абый яклый
Мал табуны,
Сатып алган җирдә
Баюны.
Чапый абый яклый
Бөтен җирне
Бушлай гына кулга алуны.

Мин Туфан иҗат иткән бу образларга алар татар поэзиясе тарихында үзләренә бөтенләй бер аерым урын алып торганлыктан болай җентекләп тукталдым. Әле хәзер дә, иҗат ителүләренә инде кырык елга якын вакыт үткән булуга карамастан, бу образлар тәссезләнмәгән. Х. Туфан поэмаларындагы ул образлар шул тикле җанлы, хәрәкәтчән, драматик киеренке һәм күз алдына скульптурадай килеп баса торган итеп

эшләнгәннәр ки, кирәк икән — тот та аның бу поэмалары буенча кинофильм төшер. Ләкин Туфанның ул еллардагы уңышы һәм шагыйрь буларак үзенчәлеге образ-характерларны скульптурадай төгәл эшләве белән генә чикләнми. Туфан әсәрләренең образлар тукымасы ук үзенчәлекле. Мисал өчен менә мондый поэтик образга игътибар итик:

Кичен
Кызыл чәчәк атты
Кабельләрдән
Аксыл бөреләр.

Бу образлар тулысынча ул чорда модада булган конструктивизм кануннары буенча эшләнгән. Анда бер әйбер бөтенләй башка характердагы икенче әйбер белән чагыштырыла, ягъни лампочкалар — бөре, ә электр яктысы — кызыл чәчәкләр итеп бирелә. Ләкин бу образ мәгънәне һич тә тоныкландырмый. Ә менә Туфан, сөйләмен ясалма рәвештә матурландыру артыннан куып, образ өстенә образ өя башлаган очракта эш шактый үзгәрә. Аның поэмаларын тикшергән-өйрәнгән кешеләр барысы да диярлек, шагыйрь теленең үзенчәлегенә мисал рәвешендә, «Урал эскизлары»ннан һаман бер өзекне китерәләр:

Кара сыер төсле кара төнне
Кемдер суйды:
Ялкынлы кан китте бугаздан...
Домналар ул,
Вулкан уянган күк,
Йолдызларга пожар сузалар.

Образның гайре табигый булуы, чыннан да, гаҗәпкә калдыра. Төн — кара сыер, домна мичендәге ялкын — сыер муеныннан ага башлаган кан, янәсе. Ләкин Туфанга эзлеклелек җитми. Без бер образны «йотып» җиткерергә дә өлгерә алмый калабыз, шундук икенчесе калкып чыга: домналар — уянган вулкан, ә аларның яктысы (димәк, өченче образ!) — йолдызларга сузылучы ялкын.

Соңыннан Х. Туфан үзе дә образларны болай тыгызлаудан ваз кичә һәм чагыштыруларны, метафораларны шактый экономияле куллана башлый.

Киң Уралның
Йөрәк моторына
Партиянең тогы тоташкан.

Яки:

Машиналар винты бушаса да,
Безнең уйлар винты бушамас, —

шикелле гадирәк итеп яза. Дөрес, монда да бер әйберне икенчесе белән чагыштыру бар, ләкин бу инде тышкы охшашлык буенча гына түгел, бәлки эчке, сәбәпле охшашлык буенча чагыштыру.

Һәм, ниһаять, яшь Туфан әсәрләрендәге образлар системасының тагын бер үзенчәлеген билгеләп үтәргә кирәк. Кагыйдә буларак, аның образлары һәрвакыт локаль эшләнгән, ягъни урынга, вакытка һәм герой психологиясенә бәйләнгән була. Мәсәлән, эскизларның бер җирендә Туфан болай дип яза:

Кичке кояш бүген
Көләч кызыл,
Төнге мартен төсле
Кызарган,
Карт торбалар
Топка каршындагы
Кочегар күк, кызынып торалар.

Беренче карашка, завод торбасын кочегар белән чагыштыру әллә ни уңышлы түгел шикелле. Ләкин һәрхәлдә бу образда эзлеклелек бар: кояш нурлары белән яктыртылган завод торбалары мич каршына җылынырга килгән кочегарлар кебек

тора. Ә эскизларның икенче бер урынында шул ук кояш бөтенләй башка ассоциация тудыра:

> Һәр таң саен
> Таудан кояш калка,
> Дарга чыккан канлы бунтарь күк...

Бу образ да көтелмәгәнчә, хәтта ятышсызрак булып күренергә мөмкин. Ләкин ул чик дәрәҗәдә локальләштереп бирелгән. Чөнки кояшны «һәр көн саен сызык санап, эх, ерак ла, ерак... чыгар көн» дип, төрмә рәшәткәләре арасыннан карап торучы бунтарь Хабул шулай күрә.

Локаль образ — шулай ук конструктивистлар уйлап тапкан лозунгларның берсе. Ләкин ул реалистик язу алымына һич тә каршы килми. Әйтик, Аксиньяны күмгәннән соң Григорий күргән кара кояш та шулай ук локаль образ, әмма тик шуның өчен генә без Шолоховны конструктивистлар исәбенә кертә алмыйбыз бит.

Х. Туфан поэмалары ирекле һәм иркен сулышлы булулары белән аерылып тора. Ул татар шигырен халыкның сөйләм теленә якынайту буенча Тукташ башлаган зур эшне дәвам итте. Аның без моңарчы сүз алып барган барлык әсәрләрендә дә нәкъ менә шул сөйләм интонациясе зур урын алып тора. Туфан үз стиленә халык сүзләрен, әйтемнәрен, мәкальләрен бик мул итеп сибеп, диалекталь сүзләр, вульгаризмнар катнаштырып язарга ярата. Аның поэмаларында ритм үзмаксат итеп алынмый, бәлки сыгылмалы, үзгәрүчән була һәм сүз кайсы персонаж авызыннан алып барылса, һәрвакыт үзенең мәгънәсе белән шул персонаж характерына туры килә торган интонациягә буйсындырып бирелә. Х. Туфан татар совет поэзиясенең рифмалар төрлелеген баетуга да зур өлеш кертә. Бик күп шагыйрьләр тарафыннан кулланылган, инде искергән, җанга тәэсир итми башлаган тартык яки сузык авазларның үзара тулысынча туры килүенә (әйтик, т а м ч ы с ы — к а м ч ы с ы) корылган рифмалардан баш тартып, Туфан татар фольклоры тәҗрибәсенә нигезләнгән (б ө р л е г ә н — б е р г е н ә м), эчке яңгырашка корылган рифма куллана. Дөрес, аның бу тәҗрибәсен һәр очракта уңышлы дип булмый. Аның әсәрләрендә көчәнебрәк ясалган, зәгыйфьрәк рифмаларны да очратып була. Мәсәлән, «Башлана башлады» әсәрендәге «б о р ы л д ы — у е б ы з», «я ш ә с е н — я ш ә р б е з», «җ ы е л ы ш — к ы с ы л д ы», «ө е б а р — и к е т а л» кебек рифмаларны һич тә авторның уңышы дип әйтәсе килми.

Х. Туфан алга таба бу мәсьәләгә игътибарын көчәйтә бара, әмма аның рифмага талымсызрак каравы соңгы елларда иҗат ителгән әсәрләрендә дә билгеле бер дәрәҗәдә саклана әле. «Бибиевләр» поэмасының, мәсәлән, беренче юлларында ук очрый торган «с е р д ә ш е м — к ө т ә б е з», «к и т е р ә — к и м е н д ә», «й ө р ә г е м — к и т к ә н с е ң» шикелле рифмалар әнә шул турыда сөйли. Шулай да, Туфан әсәрләрен укыганда рифмаларның ярлылыгы, төгәлсезлеге күзгә бәрелеп, тешкә тиеп тормый. Бу исә, шагыйрь интонациясенең көчле дулкыны, сүзләренең тирән мәгънәсе укучыны үзе артыннан ияртеп, аның бөтен игътибарын җәлеп итүдән килә. Югыйсә, әлеге кытыршы рифмалар әллә каян күренеп, сизелеп торырлар иде.

Хәсән Туфан иҗатының беренче чорына йомгак ясап, шуны әйтәсе килә: шагыйрьнең бу чорда иҗат ителгән әсәрләре саф эпик алым аша бирелгән ачык, үзенчәлекле характерларның җанлы итеп сурәтләнүе, стиленең киеренке образлылыгы, сөйләм интонациясе, хәрәкәтнең табигый һәм иркен үсеше белән характерлы.

* * *

1927 елгы күтәрелештән соң Туфанның иҗат активлыгы сизелерлек дәрәҗәдә сүлпәнәя башлый. Шагыйрь бөтен иҗат көчен поэмаларына сарыф итеп бетереп, яңа күтәрелешкә көч туплау өчен тукталып калгандай була. Аның әнә шул көч туплау чоры ун ел буена сузыла. Туфанның иҗади үсешен гел бер килеш, тигез генә үрләп барган итеп күз алдына китерүче кешеләргә, ихтимал, безнең бу фикеребез сәеррәк яңгырар. Чыннан да, Хәсән Туфанның тормыш тәҗрибәсе зур, иҗат материалы да йөзләрчә поэмага җитәрлек. Поэтик осталыгы да зур. Шулай булгач, нигә тукталып торырга иде аңа? Берсеннән-берсе әйбәтрәк шигырьләрне коясы да торасы иде шикелле. Башка профессия кешесе өчен ул, чыннан да, шулай булыр иде. Әмма язучылык

эшендә бу мәсьәлә шактый катлаулы тора. 30 елларда Туфан сәнгатьтә үз тавышын һәм үз юлын эзләү чорына аяк баса. Монда шунысы гаҗәбрәк: Туфан, тәнкыйтьчеләрнең бердәм фикере буенча, сәнгатьтә инде үз урынын тапканнан һәм аеруча әһәмиятле булган зур әсәрләрен язганнан соң, поэзиядә чын-чынлап үз тавышын эзләргә керешә.

Инде булган тормыш тәҗрибәсе белән генә канәгатьләнмичә, 1928 елда Туфан Кавказ һәм Урта Азия якларына сәяхәткә чыгып китә. Йомшак вагоннарда яки беренче классلы каюталарда үтми аның ул сәяхәте. Ул, Горький шикелле, кулына таяк тотып һәм аркасына биштәр асып, җәяүләп сәяхәт итә. Акчасы беткән очракларда төрле кара эшләрдә эшли: грузчик булудан, җир казудан да тартынып тормый. Эшләп бераз акча туплагач, тагын юлын дәвам итә. Туфанга поэмалар, романнар яки очерклар китабы язарлык зур нәтиҗәләр бирмәсә дә, бу сәяхәт шагыйрь өчен бөтенләй эзсез калмый. Туфанның утызынчы еллардагы иҗатында без акрынлап яңа сыйфат туплана баруын — шагыйрьнең чынбарлыкны лирик күзлектән карап сурәтли башлавын күрәбез.

Туфан иҗатында лирик алым аның 1927 елда языла башлаган һәм әлеге сәяхәтеннән соң тәмамланган «Бибиевләр» поэмасында ук үзен сиздерә башлаган иде. Шагыйрьнең баштагы чор иҗатына хас булган эпик хикәяләү алымы алга таба дулкынландыргыч лирик монолог белән алмашына барды. Туфан иҗатындагы бу яңа сыйфат аның 1933—34 елларда язылган «Ак каен», «Набат», «Канатлар» исемле шигырьләрендә аеруча тулы чагылды. Ул шигырьләрендә без бөтенләй яңа, бүгенге Туфанга, лирик Туфанга бик якын торган шагыйрьне күрәбез. Бу шагыйрьнең гади үсеше генә, «осталыгын арттыруы» гына түгел иде. Бу — Туфан иҗатының яңа сыйфатка: эпик хикәяләүдән, сөйләү интонациясеннән һәм иркен ритмнан нык оештырылган музыкаль фразага; кычкырып торган ачык буяулардан баш тартып бик төгәл һәм оста эшләнгән рәсемгә; төрле чагыштырулар белән артык тыгызланган, кирәгеннән тыш тәвәккәл язылган образлардан сурәтләү чараларын экономиялерәк куллана башлауга күчүе иде.

Әгәр Хәсән Туфанның халыкчанлыгы беренче поэмаларында «поэзиянең халык иҗаты белән бәйләнгән ягын алганда күбрәк мәкальләр, хикәяләр, әйтемнәр традициясен үстереп» килгән булса, соңыннан шагыйрь «халыкның лирик җыр традицияләренә күбрәк йөз бирә башлады» дип, Хатип Госман [1] бик тирән һәм дөрес фикер әйткән.

Бу, чыннан да, шулай. Мисал өчен «Ак каен» шигыренә мөрәҗәгать итик:

Яфраклары яшел ак каенга
Юл буеннан аклар килделәр,
Ак каенның ярлы авылдашын
Билбавына асып киттеләр.

Асучылар киткәч, сорый каен:
— Авырттымы муеның, Хәйбулла?
— Авыртуга түзәр идем, каен,
Тын алуы бигрәк авыр ла.

Монда барысы да: эчкерсез лиризм да, образ бирелеше дә, ак каенга һәм партизанга мөрәҗәгать итү дә, каенга бирелгән җавап та һәм формасы, һәм эчтәлеге белән халык җырына тартым. Хатип Госман бик дөрес әйтеп үткәнчә, бу хәл Туфанның «үз сурәтле фикерләвен халык күңеле белән якынрак, тирәнрәк бәйләргә теләвеннән килә. Классик поэзиянең дә хәзер ул шушы халыкчан ягына күбрәк тартыла, аның шушы сыйфатына күбрәк соклана» [2].

Ләкин шагыйрь әле һаман сәнгатьтә тулысынча үз йөзен һәм юлын табып җиткерә алмаган иде. «Ак каен» кебек коеп куйган шигырьләр белән беррәттән, Туфан ул чорда йомшак эшләнгән риторик шигырьләр дә күп кенә язды. Ялтыравыклы һәм көтелмәгән образлар ясауга караганда, гади итеп язарга өйрәнү шактый читен булды аңа.

[1] Хәсән Туфан. Сайланма әсәрләр. Казан, 1964 ел, 14 бит.

[2] Шунда ук.

Х. Туфанның утызынчы елларның икенче яртысында газета-журналларда басылган кайбер шигырьләрен укыйм да, татар поэзиясенә давыл кебек шаулап килеп кергән әлеге Хәсән Туфанмы икән бу, ялгыш басылган шигырьләр генә түгелме икән болар, дип аптырап куям. Күрәсең, Х. Туфан үзе дә аларны «ялгыш басылган» әсәрләр дип кенә исәпләгәндер — берсен дә үзенең соңгы җыентыгына кертмәгән. Ул чорда Туфан я юмористик шигырьләр, я балалар өчен әкиятләр язып карый, яисә яңадан эпик жанрдагы әсәрләр язуга әйләнеп кайтмакчы була. Кыскасы, утызынчы елларда Туфан аз язды, язган әсәрләре дә әйтерлек уңышлы булмады. Моның чыннан да шулай икәнлеген Х. Туфанның ун елга якын вакыт (1932—1940 еллар) арасында бер генә шигырь җыентыгы чыгармавыннан да күрергә мөмкин.

Әдәби, иҗади кыенлыклардан тыш, ул чорда тагын да зуррак, социаль мәгънәдәге кыенлыклар яшәвен дә истән чыгарырга ярамый. Утызынчы еллар, бигрәк тә аның икенче яртысы, шәхес культының үсә һәм социалистик җәмгыятебезгә бөтенләй чит булган формаларда чагыла барган чор иде. Ул чорда шагыйрьләрдән, күбрәк, дан җырлауны һәм ода язуны таләп итәләр. Туфан үзен, шулай кирәктер инде дип, ышандырмакчы, тормышта күргән нәрсәләре турында түгел, бәлки, чын күңеленнән, таләп ителгән нәрсәләр турында язмакчы була. Ләкин хис белән акыл арасында каршылык булганда, шагыйрь үз-үзен көчләп язарга мәҗбүр булганда, лирик поэзиянең хәле чиктән тыш авырая һәм ул үлүгә йөз тота. Утызынчы елларның икенче яртысында язылган Туфан шигырьләренең байтагы тәссез һәм хиссез булуы әнә шуннан да килә.

Ләкин Туфанның таланты югалып, адашып калмый. Мисал өчен аның үпкә һәм хәтер калу беләнрәк язылган «Сүзсез генә» исемле шигыренә күз салып үтик. Туфанны «дошман» ясап, 1937 елда Язучылар союзыннан чыгарганнан соң язылган ул:

Сугәргә мин тиеш идем шунда,
Намуслылар еларлык итеп,
Анамның гүр ташы астындагы
Сөякләре сыкрарлык итеп.
Мине сугәргә мин тиеш идем
Кемнәргәдер ошарлык итеп,
Анамның гүр ташы астындагы
Сөякләре сыкрарлык итеп...

Бу шигырь ул чакта, әлбәттә, басылып чыкмый һәм басылырга мөмкин дә түгел иде. Ул чактагы кешеләр күңелендә нинди уй-хисләр яшәвен аңларга ярдәм итә торган бу шигырьләрне Туфан үзе өчен язган.

Туфанның лирик осталыгы аның үз уйларын һәм хисләрен чагылдырган, күңеле кушкан нәрсәләр турында язган шигырьләрендә бик матур чагыла. Аның тормыштан бик яшьләй киткән якын дусты, зур шагыйрь Һади Такташка багышланган «Давыл», «Ул өйдә юк инде», «Бу ничек соң болай булды әле?» һәм утызынчы еллар ахырында, кырыгынчы еллар башында иҗат ителгән байтак әсәрләре («Очрашырбыз әле», «Кайлардан килә икән җил», «Соңгы очрашу») әнә шундыйлар. Туфанның бу шигырьләреннән шул нәрсә ачык күренә: 1937—39 елларда каушап-аптырабрак торганнан соң, шагыйрьнең таланты тагын ачылып, яңа көч белән үсеп китә. Ләкин 1940 елның көзендә Туфан бер гаепсезгә кулга алына һәм бу хәл аның бөтен тормыш һәм иҗат планнарын җимереп ташлый.

Берия төрмәләре һәм концлагерьлары турында байтак китаплар һәм истәлекләр язылды инде. Кайчан да булса төрмәләрдә һәм сөргеннәрдә Х. Туфан кичергән авырлыклар турында да язарлар әле. Бу елларда коточкыч авыр, иҗат итү турында уйларга да мөмкин булмаган (кулында бер кисәк кәгазь күрсәләр, хәзер карцерга ябалар) шартларда яшәвенә дә карамастан, Туфан язуын туктатмый. Киресенчә, нәкъ әнә шул читен чорда аның таланты моңарчы күрелмәгән дәрәҗәдә ачылып, көчәеп китә. Нәкъ әнә шул чорда Туфан иҗатының төп үзенчәлеген тәшкил иткән нәрсә — аның күңелгә тирән үтеп керә торган лирикасы үсеп китә. «Алга барышлый», «Иртәләр җитте исә», «Гөлләр инде яфрак ярадар», «Үзеңә булак итәсе иде», «Чачак сибелә җилдә», «Моабитны күрдем төшемдә» кебек формасы ягыннан гаҗәеп шома, тирән хиска ия булган шигырьләрен Туфан төрмәдә язган. Бу шигырьләрне хаклы рәвештә татар поэзиясенең энҗеләре дип атарга була. Мин ышанам: уннарча, йөз-

ләрчә елдан соң да бу кабатланмас шигырьләр, бу ялтырап торучы энҗеләр бәйләме һаман шушылай саф һәм кыйммәтле булып калыр; татар теле һәм татар халкы купме яшәсә — бу шигырьләр дә шулкадәр яшәр.

Хәсән Туфанның Язучылар союзында уздырылган бер җыелыштагы чыгышы хәтеремә сеңеп калган. Үзеннән алда сөйләгән бер иптәш иҗат эшен «газап»ка тиңләгәч, Туфан, аңа каршы килеп: «Мин беркайчан да иҗат минутларымдагы кебек тулы һәм зур бәхетле була алмыйм» — диде. Бу сүзләр безгә Туфан иҗаты көченең «серен» аңларга ачкыч бирә. Нахак-бәла аркасында якты дөньядан аерылган, төрмәнең калын стеналары эчендә үлем белән күзгә-күз очрашып яшәгән вакытларында да, күңеленә ятлап, Туфан шигырь язуын дәвам итә. Кем белә, иҗат шатлыгы белән рухланмаса, үзен шуның белән юатып яшәмәсә, ихтимал, Туфан үзенә кичерергә туры килгән коточкыч кыенлыкларны җиңеп чыга алмас та иде. Туфан ул шигырьләрен бастыру өчен язмый. Ул хәтта аларның кайчан да булса бер басылып чыгарына да ышанмый. Ул аларны язмый тора алмаганга, күңеле кушканга яза. Аның ул чордагы шигырьләрендә кимчелекләр, җитешсезлекләр бөтенләй юк диярлек. Алар гаҗәеп саф. Шуңа күрә дә ул шигырьләр иҗат ителгән вакытларында шагыйрьнең үзенә бәхет һәм яшәү көче биргән булсалар, бүген меңнәрчә укучыларның күңелләрен җылыталар.

Мондый кыен шартларда актив иҗат эшенә тотыну ансат кына булмый, билгеле. Башта Туфан күп яза алмый. Аның иҗаты бары тик 1947 елда гына чын-чынлап күтәрелеп, активлашып китә. Шул елны ул татар поэзиясенә җитди өлеш булып керерлек уннарча бик яхшы шигырь яза. Туфанның 1947 елгы иҗатын «уңышлылыгы» буенча, ихтимал, 1927 ел белән генә чагыштырырга буладыр. Аның бу чордагы иҗаты белән танышканнан соң бер нәрсә күзгә ташлана: Туфан төрмәдә дә марксизм-ленинизмга турылыклы Совет шагыйре булып калган. Шәхес культының гаделсезлеге һәм чамасыз рәхимсезлеге аны якты дөньядан калын таш стеналар белән аерып куйса да, Туфанның йөрәге һәм уйлары һәрвакыт халык белән бергә яшәгән. Халыктан, туган илдән аерылуны ул күз алдына да китерә алмаган.

Сездә идем, мәңге сездә калам,
Алгы сафлар, алгы мәйданнар:
Сездә генә бары җан азыгы,
Сездә генә бары илһамнар.
Бу яшәүнең тулы мәгънәсе бар
Сезнең сафта гына, туганнар! —

дип язды Туфан ул чорда, халыкка мөрәҗәгать итеп. Бу сүзләр — буш декларацияләр генә түгел. Үз бәхетсезлеге турында бик аз язды ул. Аның ул чор иҗатыннан нинди дер «төрмә лирикасын» эзләп маташу урынсыз булыр иде.

Туфанның бу елларда иҗат ителгән шигырьләренең бер зур циклы («Вәссәлам», «Гөлләр инде яфрак ярарлар», «Син дә көттеңме?», «Ни булды бүген сиңа?» һ. б.) Бөек Ватан сугышына багышланган. Сугыш турында язылган күп кенә яхшы шигырьләр бар безнең поэзиядә. Х. Туфан лирикасы алар арасында үзенә аерым урын алып тора. Ул сугыш вакыйгаларына карашын бары тик үзенә генә хас алымнар белән әйтеп бирә ала. Әйтик, аның «Кем тиде?» исемле шигырен укыганда әле хәзер дә тәннәр эсселе-суыклы булып китә һәм, фашистларның явызлыгына карата күңелдә туган ачудан, ирексез рәвештә йодрыклар кысылып куя.

Туфанның Җәлил һәм аның дусларының батырлыгына багышлап язылган шигырьләре дә байтак. Муса образы исә Туфанга аеруча якын һәм кадерле иде. Беренчедән, алар кайчандыр үзара дус булганнар; икенчедән, Туфан үзе дә, гаҗәеп кыен шартларда яшәгән кеше буларак, Җәлил кургән газапларны, башкаларга караганда ачыграк итеп күз алдына китерә ала. Туфанның Җәлил турындагы шигырьләрендә салкын риторика да, аның батырлыгына нинди дер кеше булдыра алмастай нәрсә итеп карау да сизелми. Мисал өчен Туфанның бу циклдан бер генә әсәрен — «Чәчәк сибелә җилдә» шигырен генә алыйк.

Кешене атарга алып баралар. Җәлилме әллә фашизм белән бәрелеш вакытында егылып калган меңнәрчә исемсез геройларның бүтән берсеме — анысы ул кадәр мөһим түгел. Мөһиме шул — Кешене үлемгә алып баралар. Кеше, кулларын артына куеп, эштән соң өенә кайтып килгәндәй, тыныч кына, ашыкмыйча гына атлый. Аны

атарга алып баралар! Ә шул күренешне тасвирлаучы Туфан шигырендә курку да, ыңгырашу да юк. Киресенчә, анда барысы да тыныч, мин әйтер идем, гадәттән тыш тыныч итеп бирелә:

Ике кулын артка куйган килеш
Үтеп бара алан утәли.
Сабыр гына искән урман җиле
Айлы юлга чәчәк сибәли.

Кешене атарга алып баралар, ә аның «иркәлисе килә юл буенда үскән баланны», һәм ул бу минутта үлем турында түгел, бәлки «җирнең киләчәге, сыйныфларсыз чоры хакында» уйлый. Туфан шигыренең мондый тонда баруы башта хәтта күңелдә ризасызлык кузгата. Шушындый коточкыч әйберләр турында ничек итеп тыныч кына язмак кирәк инде, дип уйлыйсың. Ләкин Туфан шигыре тыштан гына шулай тыныч, салмак күренә. Ә чынлыкта исә ул эчке бер киеренкелек белән сугарылган. Аның әлеге кешесе дөньяга куркынган күз белән түгел, саф, чиста күз белән карый, аек фикер йөртә. Ул дөньяның, табигатьнең бөтен матурлыгын күрә, шунлыктан аны үтерүчеләрнең кешелексезлеге тагын да ачыграк булып күз алдына килә. Шагыйрь Кешене дә табигатьнең аерылмас бер кисәге дип карый. Ә менә шунда, берьяктан, табигыйлек, кешелеклелек, тормышчанлык, икенче яктан, гайре табигыйлек, кешелексезлек, тормышны күрә алмаучанлык үзара бәрелешә. Бер кешенең тормышы никадәр кадерле, никадәр әһәмиятле булса да, Туфан бу шигырендә конкрет бер кеше тормышы турында гына сөйләми. Ул монда фәлсәфи гомумиләштерү югарылыгына күтәрелә, бу күренешкә, әйтерсең, киләчәк гасырлар күзлегеннән, югары гуманизм позициясеннән торып карый. Һәм менә шуңа күрә дә үзенең бөтен төзелеше белән реалистик булган әлеге шигырь әкият мотивы белән үрелеп китә:

Борылды да
 читкә китте пуля,
Читкә китте, протест биргән күк.

Ә шигырьнең ахыргы юллары җан ачысы белән алынган соңгы сулыш, реквиемның соңгы аккордлары кебек яңгырый:

...Үксеп искән җилдә чәчәк сибелә,
Чәчәк күмә
Яңа каберне...

Без әле шушы көнгә хәтле поэзия әсәрләрен тиешенчә бәяләргә өйрәнеп җитә алганыбыз юк, һәм әдәби әсәргә еш кына аның күләме буенча гына якын киләбез. Ә кайчакта бер кечкенә генә шигырь үзенең һәм фикер тирәнлеге, һәм художество әһәмияте, һәм укучыларның уй-хисләренә тәэсир итүе буенча кайбер калын роман, повесть яки пьесадан да әһәмиятлерәк булырга мөмкин бит!

Хәсән Туфанның бу чордагы шигырьләре Җәлилнең Моабит шигырьләре белән авазд аш. Җәлил үзенең шигырьләрен, Моабитның таш капчыгында ятуына да карамастан, чынбарлыкның караңгы якларына түгел, бәлки дошман коллыгыннан азат ителгән совет кешеләренең тыныч, бәхетле тормышларын сурәтләүгә багышлаган кебек, Туфан да хаклыкның тантана итәчәгенә ышанып, оптимистик рухлы күп кенә шигырьләр язды. Мәсәлән, аның «Җамали чамалый», «Гыйбрәт», «Туй «дога»лары», «Сез туган көн», «Ай чыга Арча кырыннан» кебек йомшак юмор һәм дөньяга якты караш белән өртелгән, ачык нур сибеп торучы шигырьләрен укыгач, аларның төрмәдә яткан кеше тарафыннан язылганлыгына ышану да кыен. Мондый шигырьләрне иҗат итү өчен Җәлил һәм аның дуслары кебек гаҗәеп зур тормыш көченә һәм батырлыкка ия булу кирәк, әлбәттә.

Билгеле, шәхес культы чорының гаделсезлекләре Туфан йөрәгендә дә эз калдырмыйча гына үтмәде. Моны шагыйрьнең шәхси трагедиясе дип кенә карап булмый, бу — илебезнең бик күп яхшы кешеләре, бөтен халык трагедиясе иде. Юк-юк дисәң дә, Туфан шигырьләрендә хәсрәт, сыкрау мотивлары («Овидий Назон», «Агыла да болыт агыла», «Тынма, давыл», «Сиңа») күренгәләп китқәләде. Һәм бу бер дә гаҗәп хәл түгел. Киресенчә, үзе яшәгән тирәлекнең шагыйрь иҗатында бер дә чагылыш

тапмавы сәер булыр иде. Ләкин шунысы әһәмиятле: Туфанның иң сыкраулы дигән шигырьләре дә укучыда пессимистик хис уятмый. Алай гына да түгел, алар кеше горурлыгына, кеше җанының бөеклегенә һәм хисләренең сафлыгына дан җырлыйлар. Кешегә дан җырлыйлар.

Ул чордагы Х. Туфан иҗатының асылын аңлау өчен, аның «Кайдадыр бер күргән идем» исемле озын шигыре (чынлыкта ул кечкенә лирик поэма) бик характерлы. Бу әсәрнең төбенә салынган фикерне кыскача болай дип билгеләп була: матурлык бөтен җирдә дә бар, тик аны күрә белергә генә кирәк.

Күрә генә бел син
Матурлыкны,
Ул һәр җирдә синең тирәдә.
Менә монда, койма өсләренә
Пулеметлар куйган җиргә дә,
Лагерь эчендәге баракка да,
Карцерга да, бикле өйгә дә
Кермимени? Керә! —
Кояш керә,
Урманнардан килгән җил керә,
Без таптаган сукмак читләренә
Яз килә дә чәчәк үстерә.
Һәр күңелдә азмы байлык ята,
Тик син аны күрә бел генә.

Х. Туфан беренче карашка бик гадәти һәм кызыксыз булып күренгән нәрсәләрдә матурлык күрә белә, шуңа күрә дә аның иң әрнүле шигырьләрендә дә тормышка ышану көче ярылып ята. Хәлсезләнгән, йончылган һәм йөрәге туган илгә кайту уе белән борчылып телгәләнгән вакытларында да:

Роман кебек күңелле син, юл!
Азмы синдә гомер уздырдым.
Ничә кием чабата синдә,
Ничә кием итек туздырдым! —
Роман кебек күңелле син юл! —

кебек күтәренке рухлы шигырьләр язды ул. Әлеге «Кайдадыр бер күргән идем» әсәрендә дә, үзен чолгап алган барак һәм киртәләрне сурәтләгәннән соң, Туфан:

Эх, бу дөнья, тере, җанлы дөнья
Сабантуй күк ямьле ләбаса! —
Табигатькә, аның кешеләренә
Карыйсың да күзләр камаша! —

дип дөньяның матурлыгына сокланa.

— Мин, — диде Хәсән Туфан Язучылар союзының бер утырышында, — бер нәрсәгә дә үкенмим, әгәр миңа яңадан бер тапкыр яшәргә тәкъдим итсәләр, мин үз тормышымны нәкъ шулай элеккечә үтәр идем.

Аның бу сүзләрендә үз-үзенә зур ышаныч, бернинди кимсетүләр дә, сынаулар да сындыра алмый торган горурлык яңгырый. Алда әйтеп кителгәнчә, ул чорда Х. Туфан поэзиясе моңарчы аның иҗатында күрелмәгән югарылыкка күтәрелде. Аның шигырьләре кеше хисен дөрес чагылдырулары, сафлыклары белән йөрәккә үтеп керә.

Әгәр иҗатының башлангыч чорында Туфан укучы күңелен, барыннан да бигрәк, сурәтләгән материалы, тере һәм үзенчәлекле образлары белән җәлеп иткән булса, соңыннан ул беренче планга н и ч е к язу һәм укучыда н и н д и хисләр кузгату бурычын куя. Күңелнең иң тирән җиренә барып җитә торган һәм тел белән аңлатып та булмый торган матур хисләр уята торган музыка әсәрләре шикелле үк, Х. Туфан шигырьләре дә сүзләрнең музыкасы, эмоциясе белән, акылдан бигрәк йөрәккә тәэсир итәләр.

Х. Туфан шигырьләренең болай уңышлы булуы — аның киеренке акыл һәм күңел хезмәте нәтиҗәсе. Туфан шигырьләрендәге искитәргеч көчле яңгырашлы саллылык аңа

ансат кына бирелмәгән, әлбәттә. Әйтик, менә аның интим, мәхәббәт лирикасы өлкәсендә татар поэзиясенең иң яхшы үрнәкләреннән берсе булган «Ромашкалар» исемле мәгълүм шигыре. Бу шигырьнең язылу тарихы турында автор үзе болай сөйли: сөргендә чакта Туфан озак еллар буена хат язышудан мәхрүм булып тора һәм өзелеп яраткан хатыны турында да, кызы турында да берни белмичә яши. Аның бердәнбер киңәшчеләре һәм юанычлары кыр ромашкалары була. Х. Туфан әнә шул ромашкаларның таҗ яфракларын санап, хатыны һәм кызы турында күрәзәлек итә. Һәм һәр ромашка, аны тынычландырырга теләгәндәй, «ярата», «хәтерли» дип әйтә. Ниһаять, аңа хатынының үлүе турында хәбәр килә. Менә шул чакта аның күңелендә йөрәк өзгеч юллар туа:

Юк, ромашка,
Минем йөрәкнең
Януларын баса алмыйсың.
Сөя әле, сагына һаман, дип,
Алдыйсың ич мине, алдыйсың!

Юк, ышанмыйм ромашкаларга
Алдаша ич алар, алдаша:
Аның кабере өстендә инде
Резедалар үсә ләбаса...

Һәм Х. Туфанның һәр шигыре диярлек күңелнең иң нечкә хисләре аша сугарылган тирән шәхси кичерешләр белән тәэмин ителгән. Аның шигырьләре йөрәк каны белән сугарылган.

Туфанның ул чорда иҗат ителгән күп әсәрләре формалары ягыннан да гаҗәеп шома эшләнгән. Ул татар поэзиясен яңа строфалар белән баетты. Туфан шигырьләренең строфикасы, кагыйдә буларак, биш юлдан торып, беренче һәм соңгы юл һәрвакыт кабатланып килә. Шулай итеп, строфаны урап ала торган алка барлыкка килә һәм әнә шул чара фикерне бер бөтен итеп туплап куя. Беренче строфада шигырьнең төп темасы, асылы әйтелә, ә калган строфаларда беренче строфаның бер юлы алына да, аңа яңа детальләр өстәлеп, үстерелә бара. «Гөлләр инде яфрак яралар» әсәре — Туфан шигырьләре строфикасының әлеге үзенчәлегенә бик ачык мисал. Мондый строфика шагыйрьдән бик зур осталык таләп итә. Беренчедән, шигырь үзенең күләме буенча катгый рәвештә чикләнгән: биш строфа, егерме биш юл — шуннан артык та, ким дә түгел. Менә шушы хәл шагыйрьгә артык җәелеп китәргә һич тә ирек бирми, аның кыска һәм шул ук вакытта тирән мәгънәле сүз белән эш итүен сорый. Шуның өстенә әлеге шул чикләнгән мәйданның да шактый өлешен кабатланган сүзләр алып тора. Шигырь барышында беренче строфаның һәр юлы өч, ә беренче юлы хәтта дүрт мәртәбә кабатлана. Шулай итеп, егерме биш юллык шигырьнең тугыз юлы кабатлануга китеп, бары тик уналты юлы гына «файдалы мәйдан»ны биләүгә китә!

Ләкин Туфан ул шигырьләрен шундый итеп эшли — андагы кабатлауларны бөтенләй сизмисең дә. Чөнки аның һәр кабатланган юлы яңача яңгырый, яңа мәгънә алып килә һәм укучы күңелендә яңа хис уята. Шулай итеп, фикернең спираль буенча үсеше барлыкка килә: шагыйрьнең уйлары әледән-әле элек башланган, ләкин инде югарырак стадиядәге моментына әйләнеп кайта.

* * *

Хәсән Туфанның 1953—1957 елларда язган әсәрләре аның үз иҗатында да һәм, гомумән, татар әдәбияты тарихында да үзенә бер аерым урын алып тора. Аның бу чордагы иҗаты — иҗади очышының югары ноктасы һәм, шуның белән бергә, хәзерге татар поэзиясе яулаган биеклекләрнең иң зурысы.

1953—57 еллар — илебез тарихында борылыш моменты булды. Тарихта шәхес культы дип исемләнгән, утыз елга якын сузылган эпоха тәмамланды. Ул эпохада илебез тормышында бик зур революцион үзгәрешләр ясалды, илебез моңарчы тарихта күрелмәгән дәрәҗәдә алга ыргылды, үсте, ныгыды. Ләкин шул ук эпохада, бигрәк тә утызынчы елларның икенче яртысында кеше ышанмаслык законсызлыклар, социа-

листик демократия нормаларын бозулар, Ленинның тарихта шәхес һәм халыкның роле турындагы васыятьләренә игътибар бирмәүләр дә бик күп булды.

Әгәр утызынчы елларда Туфан күңелендә Сталин шәхесенә карата нинди дер иллюзияләре булса да, төрмәдә һәм сөргендә яшәгән елларда аның ул иллюзияләре тәмам юкка чыкты. Ленинны күреп белгән һәм аның васыятьләрен хәтерләүче карт коммунистлар белән аралашу нәтиҗәсендә, Туфанның дөньяга карашы тагын да ныграк ачылып, яктырып китте. Менә шуңа күрә дә илебез тарихындагы әлеге борылыш башлануын Х. Туфан татар шагыйрьләренең барсыннан да алданрак сизеп алды һәм үзенең дәртле, ялкынлы шигырьләрендә бу турыда халыкка сөйләргә кереште. Аның ул вакытка караган шигырьләре, Туфан әсәрләренә хас булган лирик көчләрен һәм хис тирәнлекләрен саклаган хәлдә, яңа сыйфат белән дә баедылар. Аларда шагыйрьнең карашы үткенрәк, фикере тирәнрәк чагыла башлады. Туфан ул шигырьләрендә зур социаль мәсьәләләргә дә ешрак кагыла һәм җәмгыять алдында торган мөһим проблемаларны да тирәнрәк аңлап эш итә.

Менә аның «Ә Җир барыбер әйләнә» исемле шигыре:

Үтердең дә тынычландың бугай,
Яшереп «эзне»
Төрмәң төбенә?!
Бүрегең яна, бүрегең, инквизитор,
Нахак каннар яна бүрегеңдә!
О, күрделәр
Синең кем икәнне,
Изгәндә син кешене карцерда:
Егерменче гасыр формасына
Җайлаштырган маскаң астында
Инквизитор бабәкләре яна,
Җәзадан «тәм» тапкан бәбәкләр,
Канга катып беткән җиңнәреңнән
Нindидер «ямь» тапкан бәбәкләр.

Исеме әйтелмәсә дә, бу шигырьдән бернинди гаепләре булмаган меңнәрчә кешеләрнең каны кем аркасында коелган булуын аңлавы һич тә кыен түгел.

Әгәр Х. Туфанның егерменче еллардагы иҗаты сөйләм интонациясенә нигезләнгән эпик-хикәяләү үзенчәлеге белән, 1943—1953 еллардагы иҗаты лириклыгы һәм тирән эмоциональлеге белән характерлы булса, аның 1953—1957 еллардагы иҗатын тирән, дәртле фикер поэзиясе дип әйтергә мөмкин. Аның бу шигырьләрендә фикер һәм хис үзара берегеп, бер-берсен көчәйтеп килаләр.

Безнең гасыр кешеләре бик күп хәлләрне — революцияләрне дә, сугышларны да, гаделсез репрессияләрне һәм концлагерьларны да үз җилкәләрендә татыдылар. Ләкин фашистларның вәхшилекләре дә һәм бернинди культ та социализмның бөтен дөнья күләмендә үсеп баруын туктата алмады. Х. Туфанның «Сәлам сиңа, тормыш», «Россияннар», «Битараф ай», «Эстафета», «Барган саен еллар җылырак» һәм башка шигырьләре эпохабызның әнә шул әйдәп баручы тенденциясенә багышланган һәм югары гражданлык хисе белән сугарылган. Алар — Туфан иҗатындагы социаль лирика үрнәкләре.

Х. Туфан иҗатында, социаль анализның тирәнәя баруы белән берргәттән, чынбарлыкка фәлсәфи караш арта барды. Дөрес, иҗатының элеккерәк чорында да социаль проблемаларны читләтеп үтмәде һәм дөньяга фәлсәфи күзлектән карарга омтылыш ясады ул (мәсәлән, 1940 елда язылган «Очрашырбыз әле» шигыре шундый). Ләкин, фәлсәфи фикерле шагыйрь буларак, Туфан 1953 елдан соңгы чорда гына тулысынча формалашты. Бу хәл аның иҗатында яңа сыйфатлар тууга китерде.

«Сөйли торган материя» — Туфанның фәлсәфи лирикасына ачык мисал. Әсәрнең лирик герое олы юл буендагы миләүшә чәчәгенә мөрәҗәгать итә. Ят, чит кеше буларак түгел, бәлки үзенең туганы — материя буларак мөрәҗәгать итә ул аңа. Геройның фәлсәфи фикер йөртүе шигырьдә салкын һәм риторик рәвештә түгел, бәлки Туфанга хас булганча чын күңелдән, тәэсирле итеп бирелгән. Чөнки шигырь шагыйрь-

нең күптәнге һәм яраткан уе — җир йөзендәге бөтен нәрсәләр дә үзара якын туганнар дигән фикер белән сугарылган:

Мин — бу кырлар, сулар, җирләрдәге
Атомнарның иске туганы:
Материя мин, җаным,
Аның бары
Сөйли, җырлый, сагына торганы.

Фәлсәфи мотивлар шагыйрьнең саф «фәлсәфи» шигырьләрендә генә түгел, бәлки күп кенә интим әсәрләрендә дә («Кая шулай ашыгасың, йөрәк?», «Сүз кушасы килә талларга», «Һиндстан»ны эзлим» һ. б.) чагыла. Туфанның кеше һәм табигатьнең үзара аерылгысыз бердәмлеге турындагы фәлсәфи фикере аның «Төннәрдә дә уяу далада» исемле шигырендә бик ачык һәм образлы чагылыш тапкан. Автор бу әсәренең исеме астына «Эскизлар» дип куйган, һәм, чыннан да, эскизга хас булганча төрле характердагы өзекләрдән гыйбарәт ул.

Бу чорда Туфан иҗатының фольклор белән бәйләнеше тагын да ныгый төшә. Шагыйрь халыкның бетмәс-төкәнмәс иҗат чишмәсеннән иң яхшы нәрсәләрне ала да, аларны иҗади эшкәртеп, баетып һәм югарырак баскычка күтәреп, яңадан халыкның үзенә кайтара. Әйтик, менә халыкның традицион образыннан файдаланып язылган «Кырда ике ак канат ята» әсәре. Аккош — халык иҗатында турылык һәм сафлык символы буларак яшәп килә. Х. Туфан да аны шул мәгънәдә куллана. Ләкин ул бу образны үстереп, конкрет детальләр белән баетып җибәрә. Аның шигырендә без ике гади ак канатны гына түгел, бәлки ул канатларны сындырган ерткычны — «мыегындагы каннарны ялап» торучы төлкене дә күрәбез. Менә бу детальләр вакыйганы тагын да тулырак итеп күз алдына бастыралар. Ләкин автор моның белән генә чикләнеп калмый, образны зур социаль гомумиләштерү югарылыгына күтәрә, үстерә:

Освенцимда үтерелгән кыздан
Салдырылган ак күлмәк сыман
Җирдә ике ак канат ята...

Бу юлларны укыганнан соң безнең күз алдыбызга бер аккош образы гына түгел, бәлки һич гаепсезгә гомерләре киселгән меңнәрчә кешеләр килеп баса.

Хәсән Туфан татар шигыренә алмаз сафлыгы һәм үзенә генә хас яңгыраш кертте. Халык сөйләме байлыгына таянып, поэзия телен һәрьяктан матур булып ялтырап торырлык дәрәҗәгә җиткерде ул.

Туфанның бу чордагы шигырьләре тематика ягыннан да байый төште. Озак еллар буена туган халкыннан һәм әдәбиятыннан аерылып торган шагыйрь кайту белән кайнап торган тормыш эченә чумып китте. Үзе югында барлыкка килгән гигант үзгәрешләр («Еллар, ахыры, байтак үткәннәр»), илебездәге тормыш һәм яңа буын совет кешесенең рухи матурлыгы («Уралдан үтешли», «Монда да мин шундый», «Күбәләк»), халыкара хәлләр («Сугыш килә Мисыр өстенә») — барысы да аның иҗатында чагылыш тапты. Шагыйрь шулай ук үзен борчыган хәлләрне дә читләтеп үтмәде, аларга карата да үзенең фикерен кыю итеп («Кер чайкыйлар кызлар») әйтте.

Җыеп кына әйткәндә, Х. Туфанның 1953—1957 еллардагы поэзиясе аның иң зур җитди уңышы булды. Бу чорда ул бер генә йомшак, уңышсыз әсәр дә бастырмады. Аның бу чордагы һәр шигъри юлын, Шопен турындагы мәгълүм әйтемне әйләндереп, күктән төшкән энҗе дип атарга мөмкин.

Х. Туфан әле бүген дә поэзиябезне әйдәп баручылар сафында. Ул әле яшь, тәне һәм җаны белән яшь. Ул бөтен күңеле белән алга омтылып яши. Аның 1947 елда язган сүзләре бүгенге Туфанга аеруча килеп тора:

Үтик әйдә
Калган гомерне дә,
Үтик бары — алга барышлый,
Артта түгел, бушлай, бушка түгел,
Ә крепостьлар яулап алышлый
Һәм халыкка юллар салышлый.

Чын күңелдән киләчәктә дә шулай баруыңны телибез, шагыйрь!

*Ибраһим Нуруллин*

# ӘДИПНЕҢ ИКЕ ПЬЕСАСЫ

Шәхес культы елларында вульгар социологизм дип атала горган өрәк яңадан баш калкытты, күңелләргә шом салып, әдәбият белеменә дә зур гына зыян-зарар китерде. Бу өрәккә табынган әдәбиятчылар, тары бөртеге хакына энҗедән баш тарткан әтәч кебек, әдәбиятыбызның бик күп энҗеләрен читкә атып, дөресрәге, буржуазия малы дип игълан итеп, әдәбият тарихыбызны гаять ярлыландырдылар.

Вульгар социологизм «корбан»нарының иң күренеклесе Фатих Әмирхан булды. Аңа либераль буржуа язучысы дигән мөһер басылды. Иҗатына «анализ» әнә шул хөкемне һичнигә карамый раслауга гына кайтып калды.

Шөкер, ул заманнар инде узып китте. Галимнәр, аек күз белән карап, әдипнең иҗатына фәнни дөрес бәя бирергә омтыла башладылар, ярыйсы гына уңышларга да ирештеләр. Әмма бу әле эшнең башы гына. Зур әдип, публицист һәм драматург, ниһаять, татар әдәбияты тарихында үзенең лаеклы урынын алырга тиеш.

Бу мәкаләдә без Ф. Әмирханның драматургик эшчәнлегенә бер күз ташламакчы булабыз. Дөрес, аның беренче пьесасы «Яшьләр»не алай читкә типмәделәр. Ә инде «Тигезсезләр» пьесасы авторны буржуазия кулына бирүне аклау өчен иң зур дәлилләрнең берсе итеп китерелә иде.

1909 елда язылган «Яшьләр» пьесасында, сәхнә күзлегеннән караганда, җитди генә «гөнаһ» лар да күзгә ташлана. Вакыйга берлеге җитми, әллә ничә тема, катнашучылар күп, кайберләренең төп вакыйгага бәйләнеше бөтенләй юк, персонажлар гадәттән тыш озын сөйлиләр, драматургия күзлегеннән караганда артык булган бөтен бер пәрдә (2 нче пәрдә) бар.

Ләкин бу әле әсәрдә Ф. Әмирханның таланты чагылмый, анда әһәмиятле типлар, кызыклы характерлар юк, зур мәсьәләләр күтәрелми дигән сүз түгел. Олы фикерне дә, Әмирхан каләменә хас нечкәлекне дә, реализмның тантанасын да күрәбез без анда.

Ф. Әмирхан турында язган барлык әдәбиятчылар да дип әйтерлек «Яшьләр» пьесасында «аталар һәм балалар» проблемасы куелган диләр. И. С. Тургенев сүзләре биредә әсәрнең проблемасын билгеләр өчен уңайлы булганга гына кулланылмый, билгеле. «Яшьләр» пьесасы, һичшиксез, татар тормышына Тургенев романы яктылыгында карау нәтиҗәсендә туган. Пьесаның беренче күренешләрендә үк «Тургенев темасы»ның килеп кергәнлегенә игътибар итик. Хөсәен байның аттестатка әзерләнә торган улы Газиз рус әдәбияты буенча мондый сүзләрне кычкырып укый башлый: «Редко какому литературному произведению приходилось вызвать такую бурю, как это случилось с романом Тургенева «Отцы и дети». Шунысы характерлы, Газиз моны Хөсәен бай өендәге талаш-кычкырышларның асыл мәгънәсен сеңелесе Зәйнәпкә аңлатып биргәннән соң укый. «Бу кычкырышлар, бу тавышлар,— дигән иде ул,— безнең белән этиләр арасында түгел. Аңлыйсыңмы? Түгел. Бу тавышлар— иске тормыш белән яңа тормыш арасында».

«Аталар» һәм «балалар» тартыша. Иске белән яңа көрәшә.

Кемнәр соң алар иске тормышны яклаучы «аталар?» Бу лагерьга иң

элек Хөсәеннең кияве, печән базары сәүдәгәре Рәхимҗанны кертергә кирәк. Каенатасы сүзе белән әйткәндә, ул «ысулы кадим». Анынча, һәр «иске — изге». Надан, кире, бозык ул. Кыскасы, Рәхимҗан — типик «динмәгыйшәт айгыры». Икенчесе — Хөсәен. Аваз методы белән укытуны яклый ул, шәригать кысасы мөмкинлек биргән дәрәҗәдә яңалыкны кабул итәргә дә риза, уларын «адрес язарлык» һәм «газета укырлык» кына русча укытуга да каршы килмәгән. Икенче сүз белән әйткәндә, бусы инде — җәдитче татар купецы. Мәрьям һәм Фәхернисa, ирләренең койрыгы буларак, табигый, шушы лагерьга керәләр.

Пьесада тагын авторның үзе тарафыннан ук «милләтче» дип тәкъдим ителгән Зыя бар. Яше, өс-башы, сөйләшүе һәм аралашу даирәсе ягыннан ул «яшьләр» лагерена карый кебек. Әмма бу тышкы яктан гына шулай. Бер чагыштыру ясыйк.

«Р ә х и м җ а н. Әлегәчә, шул инде, кеше арасына керәсе килсә, Газизгә кибеттә дә күренгәләп, агайэне арасындарак йөрергә кирәк шул».

«З ы я. Көнен бер-ике мәртәбә кибетегезгә төшеп менсәгез, ара-тирә мәчеттә күренгәләсәгез, атагызның дус-ишләре белән катышкаласагыз, милли киемдә йөрсәгез — сезгә нинди зарар килер иде?» Күренә ки, журналист Зыя белән кадимче Рәхимҗан бер үк сүзне сөйлиләр, бер үк фикер әйтәләр.

Кечкенә, әмма характерлы бер деталь китерик. Фатыйма исемле бер студент кыз: «Ашагач, дога кылу фарызмы, түгелме?»— дигән сорау бирә. Динне яхшы белгән яшьләр дөресен әйтәләр: фарыз түгел. Шуннан кыз Зыяга мөрәҗәгать итә, тегесе болай ди: «Фарыз ук булмаса да, дога кылган яхшы». Менә бит нинди ул Зыя. Бөтен ус-теләге — бәхәстә урта юл эзләү, каршылыкларны килештерү. Моннан инде аның Газиз белән аның аталарын гына түгел, бәлки крестьян белән алпавытны, эшче белән капиталистны да килештерергә омтылганлыгын да аңларга мөмкин. Яшьләрдән кайберләре иске строй турында шактый ачы сүзләр әйткәч, Зыяның: «Бу сүзләрдән 1905 нче ел исе килә»,—дип ычкындыруы, билгеле, очраклы хәл түгел. Йосыфның моңа җавап итеп әйткән тапкыр сүзе Зыяга бик төгәл характеристика булып тора: «Кстати сказать, милләтче борынына бер дә килешми торган ис». Милләтче Зыя, димәк, «картлар» лагере вәкиле.

«Яшьләр» лагерена Газиз, аның энесе Йосыф, сеңелесе Зәйнәп, ишан атасыннан ваз кичкән Гали, радикал Әхмәт, учитель Зәкәрия, гимназистка Сара һәм башкаларны кертергә мөмкин. Татар тормышын асылыннан үзгәртү — менә аларның уртак теләге. Ләкин ничек, нинди юл белән? Бу сорауга биргән җаваплары исә бик чуар, бик төрле. Арада ике «программа» өстенлек итә. Беренчесен Гали әйтеп бирә: «...безнең бу көнге задачабыз (хәл итәргә тиеш нәрсә) — искене вату. Без бүген үк яңаны эшләп, татарның күз алдына китереп куя алмабыз... Без Рудиннар, Базаровлар була алсак, халыкка бертуктамый искене җимерү идея (фикере) сеңдерә сөйләсәк, киләчәктә чын эш эшләрлек кешеләр дә җитешерләр яки без үзебез үк күп тәҗрибәләр белән эшләрлек кешеләр булып чыгарбыз». Галинең һәм башка яшьләрнең рус разночинецларын, революцион-демократларын һәм народникларын күздә тотып сөйләгәннәрен дә искә алсак, югарыда китерелгән «программа»ны якынча революцион-демократик эчтәлекле мәгърифәтчелек дип бәяләп булыр иде.

Икенче «программа»ны «учительская школа тәмам итеп, аттестатка әзерләнүче» Әхмәт әйтеп бирә. Х. Ямашев, Г. Сәйфетдинов һәм Г. Коләхметовның да шул мәктәпне үткән кешеләр булганлыгын искә алсак, бу белешмәнең автор тарафыннан юкка гына китерелмәгәнлеген чамаларбыз. Өстәвенә, персонажлар Әхмәтне «социалист» дип атыйлар. Ләкин нинди социалист? Эсерлар да үзләрен шулай исемләгәннәр. Зыяның сүз арасында аны д е м о к р а т л а р вәкиле итеп каравыннан чыгып, без аны социал-демократлар юлын тотучы кеше итеп карый алабыз. Аның шул ук Зыяга җавап

рәвешендә әйткән «программасы» да моны раслый. «Юк, брат (берадәр) әгәр сез, татарны чынлап алга җибәрәсегез килсә, фәкыйрь халыкка: крестьян, рабочийга сознание (аң) кертергә тырышыгыз. Фәлән байның һиммәте, фәлән байгураның шәфкате дип кәгазь буяганчы, шул фәләннәрнең ничек итеп кеше эшләгәнне ашаганлыкларын, шулар эше аркасында баеганлыкларын языгыз».

Соң әсәрнең үзәк персонажлары Газиз белән Йосыф кайсы «программа»ны яклыйлар? Эш-хәрәкәтләре һәм уй-фикерләре аларны Галигә бәйләп куя. Тагын шунысы кызык: Газиз үзенең озын-озын монологлары белән Гали телгә алган Рудинны хәтерләтсә, кыска һәм үткен реплика, ирония һәм сарказмнары белән Йосыф нигилист Базаровны искә төшерә.

Революцион-демократик эчтәлекле мәгърифәтчелекне алга сөргән Ф. Әмирхан үзе якынча шулай ук Гали, Газиз һәм Йосыфлар карашын уртаклашкан.

Беренче карашка «нәрсә эшләргә?» дигән сорауга әсәр Гали «программа»сы яктылыгында, ягъни халык эченә кереп, бертуктаусыз аны агартырга, искене җимерү идеясен сөйләргә кирәк дип җавап бирә кебек. Ә чынлыкта исә, объектив рәвештә, пьесадан бу юлның көткән нәтиҗәне бирмәячәге аңлашыла. Халык соң интеллигенцияне үз арасына кертәме?— дигән сорауга Гали башта аның арасына көчләп керергә кирәк, дип җавап биргәч, учитель Зәкәрия үз башыннан кичкән хәлне сөйли. «Менә мин Казан губернасында ике ел учитель булып тордым. Әүвәлге елны балаларын укыттым, үзләре белән эшем булмады— ул елны ничего (зарарсыз). Ә икенче елны кичләрдә, карт мужикларны җыеп, газета укып сөйли башладым. Җыеннарына барып, белгәнемчә, файдалы совет (киңәш) лар бирә идем. Теләгәннәренә буш русча укыттым: нәрсә булды дип уйлыйсыз? Доңос ясап, урынымнан кудырттылар. Менә көчләп кереп хезмәт ит!»

Кала бер юл: Әхмәт «программа»сы. Әсәрдән чыга торган объектив нәтиҗәнең автор карашларынnан киңрәк һәм тирәнрәк булуы очрагына матур мисал бу. «Яшьләр» пьесасының чын мәгънәсендә реализм әсәре булганлыгын күрсәтә торган төп момент — нәкъ менә шушы.

Әгәр Ф. Әмирхан элеге «нәрсә эшләргә?» темасын гына алып, мәгърифәтне кайнар рәвештә яклый торган бер героен чынбарлыкның объектив законнары белән бәрелешкә кертсә, шуның рухи фаҗигагә юлыгуын күрсәткән булса, пьеса һәм идея-художество һәм драматургик яктан открывал булыр иде.

Әмма пьесада үзе бер әсәр сорый торган тагын бер зур тема — хатынкыз хокуксызлыгы темасы да яктыртыла. Ф. Әмирхан бу мәсьәләне дә чын-чыннан реалистик тирәнлек белән һәм оста художникларча хәл итә алган.

Менә Хөсәеннең олы кызы Фәхерниса, «ябык кына, зәһәр генә», килделе-киттеле бер хатын. Надан, вакчыл, гайбәтче, хорафатчыл. Кыскасы, Рәхимҗанга пар килгән, чиләгенә күрә капкачы. Тумыштан ук шундый булганмы ул? Яисә Хөсәен өеннән шул хәлендә чыгып киткәнме? Газиз болай ди: «Ун ел әүвәл ул үткен, булдыклы, нечкә күңелле, мәхәббәтле генә, зәңгәр күзле, тулы гына йөзле бер татар кызы иде. Сине, мине гакылдан шашып ярата иде». Соң нәрсә Фәхернисаны бу хәлгә китергән? Җавап эзләп ерак барасы юк, Газиз бик матур аңлатып бирә. Тирәлек, ди, иске татар тормышы, ди; «әүвәл холыксыз каенатa, каенана кул астында изелү; алардан котылгач, ике мәртәбә көндәш белән тору; ул да беткәч, атнасына икешәр мәртәбә ирен фәхешханәдән лаякыл исерек көенчә төяп кайтару».

Бу теманы тагын Зәйнәп образы тулыландыра. Фәхерниса хәленә төшмәсен өчен абыйлары аның күзен ачканнар: укытканнар, яңа фикерләр тукып торганнар, яңача яшәргә әзерләгәннәр. Инде аны атасы Габдрахман исемле егеткә кияүгә бирмәкче. Зәйнәп исә яңа идеяләр һәм абыйларының киңәше йогынтысында карышып маташа. Әмма элек-электән

килгән гореф-гадәтләр һәм ата-ана власте көчлерәк: Зәйнәп җиңеләчәк, аның киләчәге аянычлы булачак.

Пьеса, шулай итеп, Газизнең өйдән куып чыгарылуы һәм Зәйнәпнең, ата-ана кыставына каршы тора алмыйча, канаты салынып төшү белән тәмам була.

Әсәрдәге ике зур тема арасында бөтенләй бәйләнеш юк дисәк, хата булыр иде. Бәйләнеш, әлбәттә, бар. Зәйнәп вакыйгасы, мәсәлән, Газиз-Галиләр «программа»сының хатын-кызны азатлыкка чыгару мәсьәләсен хәл итүдә дә көчсез икәнлеген тагын бер кат раслый. Мәгърифәт ярдәмендә сеңелесен коллыктан азат итәргә хыялланган Газиз көчсезлеген үзе үк танырга мәҗбүр: «Әни ясаган тәэсирне җуярлык тәэсир ясый алмыйм. Өч елдан бирле үз фикеремә нәртеп китергәнем бер кызга, бүген — иң кирәкле дәкыйкадә [1] куәте калеп [2] бирә алмыйм».

Социаль һәм политик азатлык яулап алу өчен мәгърифәт коралы гына җитмәгән кебек, хатын-кызны коллыктан коткаруда да ул корал үзе генә көчсез. Пьеса безне әнә шундый нәтиҗәгә китерә. Бу исә дөрес нәтиҗә, реализм әсәреннән генә чыга алырлык нәтиҗә.

Ф. Әмирханның икенче пьесасы «Тигезсезләр» (1914) тоны, жанры һәм иҗат манерасы белән «Яшьләр»дән нык кына аерыла. Биредә инде ялангач публицистика юк. Карашлар, фикерләр көрәше дә анда төп нәрсә түгел. Автор безне «бусы яхшы, бусы начар» дип хөкем чыгармыйча, уңай сыйфатыннан тискәрегә, тискәресеннән уңайга акрынлап күчә торган, ягъни полутон белән язылган гадәти персонажлар белән таныштыра, аларның эчке дөньясына алып керә, шул кешеләрнең үзара мөнәсәбәтен лирик настроение белән сугара. Әсәрдә инде без тема күплегеннән туган таркаулык күрмибез. Ул бер бөтен, өсти дә, киметә дә алмыйсың. Кыскасы, сәхнә әсәре булу ягыннан «Тигезсезләр» «Яшьләр»гә караганда күп өстен.

Әнә шул пьеса (дөньяга килгән вакытыннан башлап соңгы елларга чаклы) бик күп әр-хур күрде. Революциягә кадәр әсәрне «ялтыравыклы ялган» дип атаган Ф. Сәйфи-Казанлы соңрак аны «...бөтенләе белән буржуа сыйныфын идеаллаштыру өчен язылган агитка» [3] дип бәяләде. «Тигезсезләр», — диде Г. Толымбай, — ...сәүдәгәрлекне һәм динне мактауга, эротикага өндәүгә корылган» [4]. «1914 нче елларны, — диләр соңгырак тикшеренүчеләр, — Ф. Әмирхан әнә шундый артта калуларга каршы көрәшүче «эшлекле» яңа тип байларны, сәүдәгәрләрне идеаллаштырып сурәтли башлый» [5]. Мисалга «Тигезсезләр» пьесасы китерелә.

Әдәбиятчыларның фикере бер эздән ага: Ф. Әмирхан татар либераль буржуазиясен и д е а л л а ш т ы р г а н.

Әсәрдә либераль буржуазия вәкилләре итеп санарлык өч персонаж бар: Сафи Насыйбуллин, аның улы Гомәр һәм атасыннан зур гына мирас алган Галиев. Акыллы һәм культурасы чамалы булган соңгысын хәзер үк читкә атыйк. Кала баштагы икесе.

Сафи Насыйбуллин, «искерәк модада европача киенә торган» купец, улын коммерческийда укыткан, бер кызы гимназия тәмамлап килә, икенчесе хосусый укытучыга йөри. Татар буржуазиясенең картрак буын вәкиле шундый икән, аңа каршы куелган яшь буын, атасын сәүдә эшендә иске ысул һәм гадәтләргә ябышып ятуда гаепләгән Гомәр нинди булырга тиеш?! Гомәр, һичшиксез, татар либераль буржуазиясенең иң алдынгы вәкиле, аның «каймагы». Әгәр бу тип идеаллаштырылган булса, ягъни автор иң якты шәхесләрдә генә табыла торган иң матур сыйфатларны, тагын да арттыра төшеп, Гомәргә туплаган булса, тәнкыйтьчеләргә кушылудан башка чара калмас иде.

Чынлыкта исә алай түгел. Бармы Гомәрдә көчле интеллект, киң ка-

[1] Д ә к ы й к а — минут.
[2] К у ә т е к а л е п — күңел куәте.

[3] Ике татар классигы турында. Казан, 52—53 битләр.
[4] «Совет әдәбияты» журналы, 1935, 4—5 сан.
[5] М. Х. Гайнуллин һәм Җ. Г. Вәзиева. Татар әдәбияты. XX йөз, II кисәк, Казан, 1954, 468 бит.

раш? Бармы политика, культура, әдәбият һәм сәнгать турында төпле фикер? Бит ул студентлар, гимназистлар, язучылар белән аралаша, аларның бәхәсләрен ишетә. Мондый вакытта һаман ул читтә, күләгәдә, тыңлаучы ролендә генә кала килә. Чөнки әйтер сүзе, уртаклашыр фикере юк.

Дөрес, бер урында аны да бәхәскә тарталар. Сүз сеңелесе Рөкыяның киләчәктә нинди юл сайларга тиешлеге турында бара. Кыз үзе художник булырга тели, Гомәр юристлыкка укырга димли. Фикерен ул менә ничек дәлилли: «...художество мәктәбеннән чыгып, бездә бер кисәк икмәк тә табар хәл юк. Әмма юрист һәрвакыт үз-үзен туендыра ала». «Корсак» фәлсәфәсе, мещанлыкның типик фикер йөртеше! Ни өчен соң Гомәр Рөкыяны нәкъ менә юрист ясамакчы, ник, мәсәлән, доктор түгел? Врач кеше дә үзенә икмәк таба ала ич. Юк, биредә Гомәр сеңелесенең киләчәген кайгыртудан бигрәк, үзен, үзенең коммерциясен кайгырта. Врач, врач инде, акчаңны түлисең дә дәваланасың. Ә инде үз кешесе, үз туган сеңелесе юрист булса, коммерсант өчен бөтенләй башка эш. Билгеле, Гомәр күңелендәгене язучы Сөләйман алдына бушатып сала алмый. Шулай да түбәндәге сүзләрне ычкындырып ташлый: «...яхшы юрист һәрбер эшнең б а ш ы н д а тора ала, теләсә нинди эштә ул файдалы (ассызык безнеке — И. Н.) була ала».

Гомәр идеаллаштырылган булса, ким дигәндә милләте турында чын күңелдән кайгыртыр, аны алга җибәрү, күтәрү өчен көчен дә, вакытын да, акчасын да кызганмас иде. Әмма пьеса дәвамында аңардан оптика магазинын юлга салу турындагы сүзләрдән башканы ишетмисең. Дөрес, ул магазинга өйрәнчек алганда «милләт интересын» күздә тота: татар малае булсын иде, ди. Юкса «кулларыннан һәрбер эш килерлек татар малайлары Печән базары тирәсендә он-тоз, читек-кәвеш әйләнәсендә, изелеп беткән сәүдәгәрләргә генә бәйләнеп яталар». Әмма шуңа ялгап, коммерсант кеше «...хәзергә әле эш белми торган кешегә жалованьены күп бирә алмыйм» дип кисәтеп куя, әлеккеге урында алган эш хакының яртысын гына бирергә вәгъдә итә.

Гомәр өчен милләт кайгысыннан кесә кайгысы өстенрәк торганлыгы Сөләйман сүзләреннән дә ачык күренә. Ул оптика магазинын юлга салу өчен Гомәрне мактагандай итә дә болай ди: «Ләкин әле Казаныгызның зыялыларыннан бераү яшь сәүдәгәрләрдән шактый зарланып утырды, һимматсезләр, сәүдәләренә бикләнәләр дә гомуми эшләрнең һәммәсеннән качалар, гомуми эшләргә беркадәр акча сарыф итәргә туры килә башласа, акчаларын бирәр тиенләп саныйлар, башка эшләрдә аталары гадәтләреннән читкә чыга алсалар да, бу тугрыларда аталары белән аермалары телләре белән киемнәрендә генә кала, ди...» Болай да үткер почмакларны шомартырга яраткан Сөләйман Гомәрдә кунак булып яткан вакытында хуҗага туры бәреп әйтә алмый, әлбәттә. Аның каравы уйлап-нитеп тормый торган Закир хакыйкатьне әйтеп бирә. Гомәргә төртеп күрсәтә дә ул кычкырып җибәрә: «Хак, хак, хак, Сөләйман әфәнде! Бу каһәр суккырлары һәммәсе шулай».

Ниһаять, менә ялган сөйли белми торган Рөкыяның абыйсы турындагы фикере: «И, таптыгыз да шәп кеше! Безнең абый андый мәҗлес өчен бер дә кул кеше түгел. Иң әүвәл, сәгать уникe тула башласа, аның күзләре йомыла башлый; икенче, андый нәрсәдән кызык та тапмый төсле ул, сәүдә дип җенләнгән бер кеше инде ул шунда...»

Кайда монда Гомәрне идеаллаштыру? Киресенчә, Ф. Әмирхан «маңгайга бәреп» әйтмичә генә аны тәнкыйть итә. Либераль буржуазиянең иң яхшы вәкиленә язучының мөнәсәбәте шундый икән, бу социаль катлауны идеаллаштыру турында сүз була аламы? Әлбәттә, юк.

«Тигезсезләр» пьесасы турындагы борынгы «әкият»не яклаучылар бәлки Рөкыя образын дәлил итеп китерерләр. Әнә бит, янәсе, Ф. Әмирхан бай кызын идеаллаштырган. Әйе, пьесадагы барлык персонажлар диярлек Рөкыяга гашыйк булган ке-

бек, драматург үзе дә аңа, һичшиксез, сокланган.

Ләкин биредә дә идеаллаштыру юк. Язучы аның кимчелекләрен дә яшерми. Бу кыз—иркә, иренчәклеге дә бар, кирәк икән, чытлыклана да белә, хорафаттан да азат түгел. Әнә шундый кимчелекләре булуга карамастан, язучы аның матурлыгына, яшьлек сафлыгына, дәртлелегенә, сәләтенә, беркатлылык белән кушылган аек акылына, романтик ашкынлыгына, туры сүзлелегенә, җыеп әйтсәк, тоташ көмештән коелгандай, бөтенлегенә (цельность) соклана.

Рөкыя тумыштан ук зирәк, хәрәкәтчән, сәләтле. Бала чагы һәм үсмер еллары «европача» яши торган купец семьясында үткән, гимназиядә яшәү идеалы турында бик күп кушпы фикерләрне күңеленә сеңдергән, рус әдәбиятыннан мәгънәви азык алган.

Культуралашкан семья һәм гимназия — менә ул яши торган дөнья. Моннан тыштагы дөнья аңарга әле ал да гөл булып күренә. Табигый, Рөкыя хәзергә саф, намуслы һәм бер бөтен булып кала килә. Ф. Әмирхан аны нәкъ шундый итеп күрсәткән икән, дөрес күрсәткән. Бу образ да «Тигезсезләр» пьесасында либераль буржуазия тормышының идеаллаштырылганлыгы турында сөйләми.

Кайбер тәнкыйтьчеләр Ф. Әмирханны темасы өчен дә гаепләделәр. Янәсе, кайда монда социаль тигезсезлек? Әсәр «...буржуа гаиләләренең үз эчендәге, көнкүреш-семья тормышында булган тигезсезлекләрдән, шуларны күрсәтүдән генә гыйбарәт»[1]. Алай карасаң, А. П. Чеховның «Тигезсезләр»не бик нык хәтерләтә торган «Акчарлак» пьесасын да юкка чыгарырга кирәк. Анда да — дворян һәм чиновниклар гаиләсендәге көнкүреш-семья тормышындагы тигезсезлек кенә күрсәтелгән. Треплев Нинаны сөя, Нина исә аңардан бизеп, Тригоринга гашыйк була. Аркадина Тригоринны ярата, бусы исә хыянәт итә. Медведенко Машаны сөя, Маша Треплев дип кибә һ. б.

Хикмәт сюжетның тышкы бәйләнешләрендә түгел, бәлки эчке мәгънәсендә.

Ф. Әмирхан пьесасында нинди тигезсезлек турында сүз бара соң? Иң әүвәл, Сафи байның ике кызы арасындагы тигезсезлек: табигать һәм җәмгыять Рөкыяга күбрәк нәрсә биргән, Сәлимәгә карата исә саранлык күрсәткән. Моннан инде икенчесе килеп чыга: Сәлимә Габдулла исемле студентны сөя, тегесе исә Рөкыяга гашыйк. Ниһаять, Сөләйман белән Рөкыя арасындагы тигезсезлек. Бер-берсен яраталар, ләкин араларында — яшь аермасы.

Күренә ки, «Тигезсезләр» пьесасында кеше бәхете, кеше язмышы мәсьәләсе куелган. Әгәр бу мәсьәлә мораль-психологик планда гына хәл ителгән булса да, әсәрне себереп түгәргә безнең хакыбыз юк. Кеше күңеле, кеше йөрәге һәм кеше җаны сәнгатьтә үзенең чагылышын табарга хаклы. Әмма пьесаны җентекләп тикшерсәк, мораль-психологик план артында, бик үк күзгә бәрелеп тормаса да, социаль планны да чамаларга мөмкин.

Әсәрдә сүз гомумән кеше бәхете турында түгел, бәлки буржуаз җәмгыять шартларындагы кеше бәхете турында бара.

Сәлимә, мәсәлән, ни өчен бәхетсез? Ул, унтугыз яшенә җитеп, гимназиянең дүртенче классына гына имтихан бирергә әзерләнеп йөри. Сәбәбен Гомәр әйтеп бирә: «Синең белән безнең заманнар бит башкарак иде». Гимназия тәмамларга хыялланган кызны икенче пәрдәдә инде без Гомәрнең магазинында кассир итеп күрәбез. Буржуаз практика эченә кереп киткән Сәлимә, табигый, элек тә бик ташып тормаган сөйкемлелегеннән мәхрүм калган. Габдулланың аны читкә тибәреп, яңа гына гимназия тәмамлаган Рөкыя артыннан йөри башлавы табигый.

Сәлимәгә бер юл кала: сөймәгән кешесенә — бай малае Гайсага кияүгә чыгу. Аның тормышының ничек булачагы Гөлчиһрә язмышыннан ачык күренә. Гөлчиһрә дә яратмаган кешесенә чыгарга мәҗбүр булган һәм хәзер, беренче мәхәббәтен сагынып, күңелсез көннәр кичерә.

Җилик Рөкыяга. Карап торышка,

[1] Татар әдәбияты, XX йөз, II кисәк, Казан, 1954, 468 бит.

ул бәхетле, киләчәге дә матур булыр төсле. Ләкин аның да матур хыял дөньясыннан реаль чынбарлыкка аяк атлыйсы бар әле. Хәзер үк инде ул чынбарлык белән конфликтка керә башлаган. Иң әүвәл Рөкыя үзенә тиң булырдай кеше, б е р б ө т е н кеше эзли, тик таба алмый. Бай кызы тәкәбберлеге түгел бу. Хикмәт аның вакка-төяккә бүленмәгән характер б ө т е н л е г е н д ә, табигать баласы булуында. Ә инде аңа таныш булган егетләр барысы да ничектер төссез-чырайсызлар, кечкенәләр, вак җанлылар. Ярты акыл Закир белән Галиевне әйтмибез дә инде, Габдулла да шундый. Абыйсы Гомәр дә шундый булгач, аның таныш егетләре һәм Сәлимәне алачак Гайса да аңардан ерак китмәгән булырга тиешләр.

Рөкыяның игътибарын җәлеп итә алырлык бердәнбер кеше — Сөләйман. Танылган язучы, чибәр, нәзакәтле, татлы телле. Ләкин бу мәхәббәт тә Рөкыяга бәхет китерәчәк түгел. Беренчедән, Рөкыя яшь ягыннан Сөләйманның кызы булырлык; икенчедән, бу язучы тышкы яктан ялтыраса да, ничектер сүнгән йөрәк ул. Кешене тыңлый белсә дә, акыллы киңәш бирә алса да, моны күңел кушуы белән эшләми. Яшь кызлар белән җиңелчә флирт, бай гаиләләрдә матур поза күрсәтеп йөрү, тормыштан туйган кеше кыяфәтенә кереп кыланчыклану — менә нәрсә белән ул үзенең эчке бушлыгын, идеалсызлыгын каплап килә. Сөләйманны Ф. Әмирханның идеаль образы итеп күрергә теләгән Ф. Сәйфи-Казанлы да хәтта, үз-үзенә каршы килеп, болай дигән иде: «...ләкин әсәр буенча Сөләйман урыны-урыны белән байлар табынына өйрәнгән, җәмәгать бәлешләрен ярата торган, буржуа тәрбиясе сәбәпле бозылган укымышлы кеше тибына охшый».

Рөкыя белән Сөләйман мөнәсәбәте вакытлы мавыгудан узмаячак. Үзенең яшен һәм, ихтимал, эчке бушлыгын күздә тотып, Сөләйман кызны беркадәр «суытырга» тырыша. «Син минем үзеңне сөйгәнемне белмә,—ди ул,—мин синең минем чал чәчләремне дә гафу итәргә әзер икәнеңне белмим. Шуларны белешкән минуттан безнең икебезгә дә җәһәннәм булыр. Мин сине, Рөкыя, шул минуттан чәчләренә чал кермәгән бөтен кешеләрдән көнләшә башлармын, мин сине газапларрмын, үзем синнән артык газапланырмын!»

Кыскасы, Рөкыяның чылтырап чыга торган саф көлүе, күбәләктәй очынып йөрүләре, дөньяга ачык, чиста күз белән каравы озакка түгел. Капиталистик чынбарлык аны да гарипләндереп ташлаячак. Әнә бит Гомәрнең вәгазьләре бушка китмәде: Сәлимә, гимназияне ташлап, сәүдә кешесенә әверелде, тиздән Гайсага кияүгә чыгачак. Рөкыя да, «аек карашлы» абыйсының киңәшен тотып, художественное училище турындагы фикереннән кайтыр, күп дигәндә юрист булыр. Апасы Сәлимә әйтмешли, «И, нишләп ялганлап торыйм соң», дип бер эшен оттырыр, икенчесен... Аннары хакыйкатьне тегеләйгә дә, болайга да боргалый башлар. Яисә инде, бу эштән бизеп, икенчегә ябышыр, аныннан да күңеле кайтыр. Калыр бер юл: кияүгә чыгу. Икенче бер «Гайса»га тап булыр да тук, ләкин кызыксыз яшәү белән яши башлар. Мондый тормыш белән килешергә теләмичә «бунт» күтәрсә, язмышы һәлакәт белән очланыр.

Буржуаз җәмгыятьтә матурның, сафның, бәхет идеалының язмышы әнә нинди. Сәлимә һәм Рөкыя образларында («Тигезсезләр» пьесасы башлыча шушы ике кыз турында) Ф. Әмирхан кешенең табигый омтылышлары, бәхет турындагы табигый хыяллары белән буржуаз чынбарлык арасындагы каршылыкны күрсәтеп бирде һәм объектив рәвештә капиталистик мөнәсәбәтләр хакимлек иткән җәмгыятьтә чын кешелек бәхетенә урын юк, дигән хакыйкатьне раслады. Әсәрнең пафосы һәм идея-художество көче әнә шунда.

Күренә ки, Фатих Әмирханның «Яшьләр»ендә генә түгел, бәлки «Тигезсезләр»ендә дә бернинди «бүкәй» юк икән. Сәнгатьчә оста эшләнеше өстенә, ул идея юнәлеше белән дә искермәгән булып, бүген дә тәрбияви әһәмияткә ия. Инде килеп, бу гүзәл пьеса сәхнәдән дә яңгыраса, нур өстенә нур булыр иде.

ӘДӘБИЯТ ТАРИХЫНА МАТЕРИАЛЛАР

# ЯҢА ЯРЛЫК

«Китапларның да язмышлары бар», ди бер борынгы мәкаль. Китапларның гына түгел, аерым кәгазьләрнең дә язмышлары була икән...

1912 елда тарих укытучысы Сәет Вахиди Мамадыш өязе татар авылларының берсендә ниндидер «хикмәтле», «изге» язу — бөти саклануы турында ишетә. Кызыксынучан укытучы, шактый тырышлыклардан соң, әлеге язуның эзенә төшә, хәтта ул «изге» язуны күреп уку бәхетенә дә ирешә. Баксаң, таушалып беткән бу кәгазь кисәге гадәти «шифалы» бөти генә түгел икән. 1523 елда Казан ханы Сәхип-Гәрәй тарафыннан бирелгән тарханлык язуы булып чыга ул. С. Вахиди ничек тә документны кулга төшерергә һәм дөньяга чыгарырга исәпли. Әмма хуҗалар «изге» кәгазьгә ябышып яталар. Тиздән Беренче бөтендөнья сугышы башлана, аннары Октябрь революциясе. Бары егерменче елларда гына С. Вахиди кыйммәтле документны яңадан кулга төшерә һәм 1925 елда аның фотокопиясен, рус һәм татар телләренә тәрҗемәсен матбугатка чыгара (Ярлык тексты икенче мәртәбә «Борынгы татар әдәбияты» китабында нәшер ителде). Әнә шулай итеп, Казан ханлыгы чорына караган бердәнбер татарча тарихи документ, 400 елдан соң гына, үзенең икенче, гыйльми тормышы белән яши башлый. Хәзер ул кәгазь фәндә «Сәхип-Гәрәй ханның тарханлык ярлыгы»[1] дигән исем белән билгеле.

Бу икенче, яңа ярлыкның табылуы да кызык кына. 1963 елда Казан дәүләт университеты аспиранты Р. Степанов Мәскәүгә, борынгы актлар саклана торган Үзәк архивка бара. Кандидатлык диссертациясе өчен материаллар эзләнеп утырганда, татарча язылган борынгы бер кәгазьгә күзе төшә моның. Нәрсә булыр бу? Кәгазьнең аскы кырында дүртпочмаклы борынгы печать тә бар. Тикшерә торгач, «Ибраима царя жалованная грамота» дигән сүзләр табыла. Ярлык! Тагын бер хан ярлыгы. Әйе, бу Олуг Мөхәммәтнең оныгы Ибраһим хан ярлыгы булып чыга. Ибраһим хан 1467—1479 елларда Казан тәхетендә утыра. Документ азагындагы тамга-печать тә аныкы.


Ярлык Мәскәү архивына[2] ничек эләккән соң? Әлеге архивтагы башка документларны да өйрәнгәннән соң, шул нәрсә ачыклана: 1685 елда Казан өязе Тыңламас авылының Котломөхәммәт Котлогошев дигән бер кешесе рус патшасы исеменә, үзенең тарханлык хокукын яңадан раслауны үтенеп, гариза яза. Аның бабалары «мөселман патшалары» заманында ук тархан булып торганнар икән (билгеле булганча, рус патшалары да, элекке татар тарханнарының экономик хокукларын танып, аларга кайбер җиңеллекләр тудыра торган булганнар). Котломөхәммәт Котлогошев, патша исе-

[1] Тарханлык дип милекле сыйныфлар, шул исәптән ханнар токымыннан чыккан кешеләргә билгеле бер хезмәтләре өчен бирелә торган экономик-юридик хокукны атаганнар; тарханлык хокукы бирелгән кешеләрдән налог, ясак-салым алмаганнар, кайбер очракларда хөкемгә дә тартмаганнар. Ярлык дип элекке ханнар тарафыннан төрле оешмаларга һәм кешеләргә бирелгән фәрман, әмер, боерыкка әйткәннәр.

[2] Борынгы актлар саклана торган Үзәк дәүләт архивы (ЦГАДА), 1173 фонд, 1 опись, саклану берәмлеге 196, 1 бит.

минә язган әлеге гаризасына кушымта итеп, борыннан калган тарханлык ярлыгының күчермәсен дә теркәгән. Ярлыкны рус теленә Артык Иманаев дигән кеше тәрҗемә итә («с сего списка... переводил Артык Иманаев»). Казан ханлыгы чорына караган сирәк ярлыкларның икенчесе биш гасырдан соң шулай дөньяга чыга.

Ярлык оригинал түгел, ә күчермә генә. Аның күчермә булуын түбәндәге дәлилләр белән исбатлый алабыз. Беренчедән, архив кишталәренә килеп кергәнче 200 елдан артыграк вакыт кулларда йөргән кәгазь болай чиста, бөтен саклана алмас иде. Икенчедән, язуның орфографиясендә «яңару» элементлары бар. Мәсәлән, XV гасырда «ч» авазы, гадәттә, бер нокталы гарәп «җиме» белән языла торган була, әлеге документта исә ул аваз соңрак, фарсылардан алынган өч нокталы «ч» хәрефе белән бирелгән. Өченчедән, һәм бу иң мөһиме, хан мөһерендә берничә ялгыш бар. Ә ханнарның үз билгеләрендә, бигрәк тә, «иман» сүзләрендә хата җибәрүләре ихтималдан ерак хәл. Дүртенчедән, ярлык хуҗасына бу кыйммәтле документның оригиналын ук гариза белән Мәскәүгә җибәрергә бернинди дә ихтыяҗ булмаган.



Ярлык 27,3×17 см. күләмле кәгазьгә кыеклап язылган. Барлыгы 12 юл. Теле — борынгы татар әдәби теле. Ярлык стиле һәм композицион төзелеше белән дә шул чордагы башка документларга якын тора, бигрәк тә, Сәхип-Гәрәй ярлыгы белән уртаклык зур. Ярлыкта кайбер стилистик кытыршылыклар, орфография хаталары очрый. Мәсәлән, мөһер тирәсендә ике мәртәбә кабатланган тәшәһһөдтә (иманда) бер урында «илаһ» урынына «иллаһ» язылган, ә азакта «аллаһ» сүзе бөтенләй төшеп калган: «лә илаһ илла-аллаһ, Мөхәммәт рәсүл-аллаһ; лә иллаһ (!) илла-аллаһ, Мөхәммәт рәсүл-[аллаһ]». Мөһернең уртасына шундый сүзләр язылган (төзәтеп укыйбыз): «Әс-солта[н], әл-әгъзам, гыйзз-[әддин]Ибраһим хан хәллад-аллаһу мөлкәһү вә әййаде солтан [әтәһү]» (Мәгънәсе — диннең күрке бөек солтан Ибраһим хан, алла аның дәүләтен мәңгелек, ә патшалыгын кодрәтле итсен).

## ЯРЛЫКНЫҢ ТРАНСКРИПЦИЯСЕ [1]

I Ибраһим ханымыз [2],

II суйургал сүзем. Ходай ризасы өчен, Мөхәммәт рәсүл-аллаһ шәфагате өчен бу үксез углул [3],

[1] Без тәкъдим иткән транскрипция, берничә билге җитмәү аркасында, фәнни-лингвистик төгәллеккә дәгъвә итә алмый.

[2] «Ханымыз» урынына «хан» гына булырга тиеш. Бу хата, күрәсең, XVII йөздә күчерүче тарафыннан җибәрелгәндер.

[3] Кулъязмада «углул» дип ялгыш язылган. Чынлыкта — угул.

III тол хатунны азат тархан булсын тидек. Бу азат йибәрелгән кем ирсәләрнең аты: башлыг

IV Гөл-Бостан-хатун, угылы Мөхәммәт-Газиз-хан, нәсәбе[1] шаһ, нәсәбе Җанәкә-солтан. Бу атлы кем ирсәләрне[2] азат,

V йибәрелде; тәкый Хуш-Килде атлыг чүрәсен бергә булсын тидек, вә тәкый Мөхәммәт-Гали Мөхәммәт-Газизнең

VI ийәсе суйургап биргән бу ике тамга урманын суйургап, ил агалары берлә ирәктә суйургадык.

VII Болардин билгесез кем-кем ирсә урманларына йөремәсенләр, иген-саба[3] сөрсә, хәзре-инар[4],

VIII алмасынлар; боларга көч берлә кунак кундырмасынлар, тархан, илче олаг-алмак[5] тотмасынлар;

IX кайу ма йандин көч тигермәсенләр тип, бу Хәйдәр-Гали-солтанның азат йибәргән Гөл-Бостан-

X -хатун, углы Мөхәммәт-Гали-Газиз-хан, нәсәбе шаһ, нәсәбе Җанәкә-солтан, тәкый Хуш-Килде атлы чүрәсе

XI бу кем ирсәлә[6] тота торган санлыг йарлыг бирелде. Тарих сигез йөздә, рамазан айының әүвәлендә бетелде.

XII Хаҗи Корбан-хафиз бетелде[7].

## ХӘЗЕРГЕ ТЕЛГӘ ТӘРҖЕМӘСЕ

«Ибраһим хан

Суюргал сүзем. Ходайның ризалыгы, алла илчесе Мөхәммәтнең шәфәгате (яклавы) өчен бу үксез угул (һәм) тол хатунны азат тархан булсын дидек. Бу азат җибәрелгән кешеләрнең исеме: Гөл-Бостан-хатун (һәм аның) улы шаһ нәселе, Җанәкә-солтан нәселе Мөхәммәт-Газиз-хан. Шундый исемле кешеләр азат ителде. Тагын (аларның) Хуш-Килде исемле хезмәтчесе дә бергә (азат) булсын дидек. Һәм тагын Мөхәммәт-Гали Мөхәммәт-Газизнең (элекке) хуҗасы бүләк итеп биргән бу ике тамга урманын ил агалары белән бергә ирәктә (кремльдә) (яңадан аларга) бүләк иттек. Болардан башка билгесез бернинди кеше (аларның) урманнарына йөрмәсеннәр; иген игеп, сабан сөрсә, хәзре-анбар алмасыннар; аларга көч белән кунак (фатирчы) төшермәсеннәр; тарханнар һәм илчеләр алардан олау һәм менү атлары алмасыннар; (шулай ук) теләсә кайсы яктан да җәбер итмәсеннәр дип, (элек) Хәйдәр-Гали-солтан тарафыннан азат ителгән Гөл-Бостан-хатунга, (аның) улы шаһ нәселе, Җанәкә-солтан нәселе Мөхәммәт-Гали Газиз-ханга, шулай ук Хуш-Килде исемле хезмәткәренә (алар) тота торган бу дәрәҗәле ярлык бирелде. (Һиҗри белән) тарих сигез йөздә рамазан аеның берендә язылды.

Хаҗи Корбан-хафиз язды».

* * *

Документның азагындагы дата, һиҗри белән 800 ел (милади исәбе буенча 1398 ел), Ибраһим хан хөкем сөргән чорга туры килми. Биредә ялгыш бармы, әллә ул дата ярлыкның элгәресен бирүче Хәйдәр-Гали-солтан дәверен күрсәтәме, хәзергә тәгаен әйтүе читен. Һәрхәлдә, документтан күренгәнчә, Гөл-Бостан-хатуннар гаиләсен тарханлык язуы белән беренче тапкыр Хәйдәр-Гали исемле солтан (патша) бүләкләгән. Димәк, Ибраһим хан гамәлдәге тарханлыкны икенче кат раслаучы гына булып чыга. Әмма

[1] «Нәсәб» сүзе өч урында дөрес язылса да, бер җирдә «нәсиб» дип, ялгыш бирелгән.

[2] Биредәге «не» кушымчасы артык булса кирәк.

[3] «Иген-сабан» булырга тиеш, «н» хәрефе төшеп калган.

[4] «Хәзре-инар» — хата; дөресе — «хәзре-анбар». Башка документлар буенча төзәтелде.

[5] Күчерүче, «элмәк» сүзенең мәгънәсен аңламыйча, «алмак» ка үзгәрткән; «алмак» булганда грамматик төзеклек югала. Башка ярлыкларда «олаг-элмәк» формасында кулланыла.

[6] Соңгы «р» хәрефе төшеп калган, «ирсәләр» дип укырга.

[7] Фигыль-хәбәр биредә актив формада, «бетеде» дип, бирелергә тиеш иде.

Хәйдәр-Гали-солтанның шәхесенә килгәндә, без бернәрсә дә кистереп әйтә алмыйбыз. Болгар патшалары, Казан ханнары арасында андый кеше х ә з е р г ә билгеле түгел. Дөресен әйткәндә, без Болгар патшаларының барсын да белмибез әле. Димәк, бу ярлык ярдәмендә Болгар чоры патшаларының берсенең исеме беленде һәм XIV гасыр Идел буеның политик тарихына беркадәр ачыклык кертелде дип исәпләргә мөмкин. Әлбәттә, бу мәсьәлә җентекләп тикшерүне сорый.

Борынгыдан сакланып калган ярлыклар шул чорда кулланылган әдәби тел нормаларын, бигрәк тә эш кәгазьләре телен һәм документлар стилен өйрәнергә материал бирә. Шуның өстенә, документтагы иҗтимагый-хуҗалык атамаларын тикшереп, без шул чорда гамәлдә булган социаль-политик мөнәсәбәтләрне беләбез. Мәсәлән, тарханлык ярлыкларында дәүләт учреждениеләре, чиновник-түрәләр исемлеге, салым-налог атамалары һәм башка күп төрле терминнар китерелә. Алар исә күп мәсьәләләрне ачыкларга ярдәм итәчәк. Бер генә мисалга тукталыйк. Сәхип-Гәрәй ярлыгында «суйургап» дигән бер сүз бар. Аны тикшереп, галимнәр Казан ханлыгында да «суйургал» дип аталган җир биләү системасы булуын ачыкладылар. Бу — фән өчен бик әһәмиятле яңалык иде. Чөнки, ярлык җентекләп тикшерелгәнгә хәтле, борынгы Урта Идел буенда нинди җир биләү системасы гамәлдә булуы турында тәгаен генә бернәрсә дә билгеле түгел иде. Ә феодализм дәверен өйрәнгәндә җир биләү мәсьәләсе төп проблемаларның берсеннән исәпләнеп, башка күп кенә сорауларны чишүдә ачкыч булып тора.

Ибраһим хан ярлыгында да тарихыбызны гыйльми дөрес өйрәнү өчен кирәкле, бик әһәмиятле фактлар бар. Аларның кайберләре Сәхип-Гәрәй ярлыгындагы мәгълүматларны куәтлиләр, икенчеләре исә безнең белемебезне тагын да тулыландыра төшәләр, ягъни яңалыклар бирәләр.

## КАЙБЕР АТАМАЛАРГА ҺӘМ АРХАИК СҮЗЛӘРГӘ АҢЛАТМА

С у й у р г а у сүзе бүләкләү, бүләк бирү, өлеш бирү, мәрхәмәт күрсәтү дигән мәгънәне аңлата. С у й у р г а л — бүләк, бүләк ителгән милек. Икенче төрле әйткәндә, с у й у р г а л — феодализм дәверендә милекле сыйныфлардан чыккан аерым кешеләргә хәрби хезмәттә булу һәм сугыш кампанияләренә актив катнашу шарты белән бирелә торган җир биләмәсе, утар. «Суйургал» алган алпавытлар шул утарны, андагы кешеләрне теләгәнчә изгәннәр, талаганнар. Сәхип-Гәрәй ярлыгында бу сүз бер генә мәртәбә һәм «суйургап» формасында кулланыла. Ибраһим хан ярлыгында исә «суйургал», «суйургап», «суйургадык» дигән формаларда да очрый.

У г у л сүзе элек «шаһзадә», «принц», «бәкзадә» дигән мәгънәләрдә, ягъни социаль атама буларак та кулланылган. «Угул» титулы, аерым очракларда, кешенең хан нәселеннән чыгуын белдергән. У г у л-у г л а н н ы ң «командующий», «гаскәр башы» дигән төшенчәләре дә бар.

Х а т у н «бикә», «ханым», «принцесса» мәгънәләрен белдереп, «затлы» гаиләдән чыккан хатын-кызларга карата кулланылган.

Ч у р ә гадәттә «кол» мәгънәсендә йөри. Әмма бу ярлыкта ул «хезмәткәр», «иректе ялчы», «хезмәтче» мәгънәсендә булса кирәк. Әгәр «кол» мәгънәсендә дип аңласак, алпавыт, тарханлык язуы алу белән, үзенең милке — колыннан мәхрүм калган булып чыга. Димәк, биредә бу сүз татар телендә моңарчы исәпкә алынмаган яңа эчтәлек белән китерелә.

А т, а т л ы, а т л ы г — исем, исемле,... дип аталган.

Т а м г а — моңарчы билге, галәмәт, пошлина, налог дигән мәгънәләре белән билгеле иде. Ә Ибраһим ярлыгында «ике тамга урман» дигән бөтенләй яңа контекстта китерелә. Димәк, ул пошлина алына торган объектның берәмлеген, күләмен белдерә торган, хәзергәчә билгесез төшенчәдә кулланылган. Киләчәктә бу җентекләп тикшерүне таләп итә.

И р ә к — хан яши торган крепость, ягъни «кремль»нең борынгы татарча исеме.

Х ә з р е-а н б а р. Бу атама бераз үзгәргән формада башка ярлыкларда да очрый. Ләкин бер тикшерүче дә аның дөрес мәгънәсен ачыклый алмаган. Безнең фикеребез-

чә, ул хосусый милектән алына торган процентны, ягъни пошлинаның бер төрен белдерә булса кирәк.

Олаг-элмәк — олау һәм менеш атлары. Элмәк — атланып йөрү өчен кирәкле мал.

Каюма йандин — кайсы яктан булса да, һәр яктан да.

Санлыг — дәрәҗәле, хөрмәтле.

Хафиз — укыган, белемле кеше. «Абзый» сүзе шул тамырдан.

* * *

Ибраһим хан ярлыгындагы яңалыклар болар белән генә чикләнми, әлбәттә. Ярлыкны чын-чынлап тикшерү, томанлы төшләрен ачыклау — киләчәктәге бурыч. Әмма, бернәрсә бәхәссез: яңа табылган бу документ филология һәм тарих фәннәре өчен кыйммәтле, әһәмиятле чыганак булачак.

М. ГОСМАНОВ,
Ш. МӨХӘММӘДЬЯРОВ,
Р. СТЕПАНОВ.

## *ТАТАРЛАР АРАСЫНДА РЕВОЛЮЦИОН ХӘРӘКӘТ КӨНДӘЛЕГЕННӘН*

*(1905—1912 еллар)*

**«Бу көннәрдә Казанда яшерен рәвештә басылган «Иттихад» (Берләшү) [1] исемле татарча бер газета заһир булды (күренде). Максады шәкертләрне берләштерүдер.»**

*«Йолдыз» газетасы, 1906 ел, ноябрь.*

**«Оренбургта социал-демократлар группасы новобранецлар (армиягә чакырылган яшь солдатлар) арасында русча һәм татарча прокламацияләр, үзләренең чыгарган китапларын таратмышлар.»**

*«Вакыт», 1906.*

**«Өфедә гает көнне иртә намаз вакытында мәчеттә татарча прокламацияләр табылмыш.»**

*«Вакыт», 1906.*

**«Казанда Крестовников заводында революционерларның боевая дружинасы кулга алынган һәм бер татарча типография табылган.»**

*«Вакыт», 1906.*

**«Бу көннәрдә Казанда Ягодный бистәсендә Мамадыш өязенең Риза Рахманов исемле кешенең фатирында бик күп татарча хәрефләр, өч данә хәреф кассасы, бер типография станогы, басарга әзерләнгән прокламацияләр һәм бик күп кәгазь табылмыш, фатир иясе кулга алынмыш.»**

*«Йолдыз», 1906, ноябрь.*

**«Оренбург. 27 январьда төнлә кораллы өч кеше «Дин вә мәгыйшәт» типографиясенә кереп, татарча һәм русча өч-дүрт пот хәреф алып чыкканнар. Һәм дә: «Без моны урламадык, бик кирәк булганга күрә алдык. Бәясен газета аркылы игълан итәрсез, түләрбез» дип хат язып, конверт эченә салып, өстәлгә куеп калдырганнар. Полиция боларны эзләсә дә хәзергә кадәр тотылган кеше юк.»**

*«Вакыт», 1907.*

**«Оренбург полициясе Казанга телеграмма биреп, Кәримов — Хөсәенов китап ширкәте типографиясендә басылган һәм Казанга җибәрелгән «Шәкертләр садасы» (тавышы) исемле китапны барып җиту белән тимер юлда ук конфискацияләргә куша.»**

*«Вакыт», 1907.*

---

[1] Җәя эчендәге аңлатмалар җыючыныкы.

«Урал» идарәсенең (татар социал-демократлар, большевиклар газетасы редакциясенең) «Эшчеләрнең котылуы аларның үзләренең эше булырга тиеш» исемендәге китапларының (редакциядә калган) 150 данәсе полиция тарафыннан конфисковать ителде. Бу газета идарәсенең бастырган биш китабыннан хәзергә кадәр дүртесе конфисковать ителде»[1].

*«Вакыт», 1907.*

«Өфе губернаторы кушуы белән Кәримовлар китап магазинында тентү булып, «Урал» газетасы чыгарган китапларның кибеттә булган барлык нөсхәләре конфискацияләнә һәм мондый китапларны сатканы өчен кибет хуҗасына 300 сум штраф салына.»

*«Вакыт», 1907.*

«Үткән ел августта Казанда яшерен типография белән тотылган Моратов судебный палата тарафыннан 6 айга крепостька хөкем ителгән.»

*«Вакыт», 1907.*

«Казанда «Шәрәфләр» типографиясендә басылган «Татар шәкертләре ни өчен ислах (реформа) сорый?» исемендәге китапның барлык тиражы полиция тарафыннан җыеп алынган. Китапның авторы Өфедәге Галия мәдрәсәсе шәкерте Галимҗан Ибраһимовдыр.»

*«Вакыт», 1908.*

«Казанның палата мәхкәмәсендә 1910 ел 18 февральдә сәяси эштә гаепләнгән Ибраһимов һәм Миңлеһади Вәлиуллин исемле егетләрнең эшләре каралып, мәхкәмә Ибраһимовны ике елга крепостька ябарга, Вәлиуллинны торыр өчен башка шәһәргә җибәрергә хөкем итте. Вактилә боларның фатирында тентү булып, гектограф (җилем басма), татарча шрифтлар һәм социал-демократлар тарафыннан татарча басылган прокламацияләр вә «Әлислах» темасына язылмыш тыелган язулар табылган».

*«Вакыт», 1910.*

«Үткән ел февральдә Өфедә жандарм һәм полиция түрәләре «Шәрык» типографиясе һәм «Кәримов — Хөсәенов ширкәте» китап кибетендә тентү ясап, кайбер китапларның тиражын тәмам җыеп алдылар. Мәсәлән, «Германиядә сайлау көне», «Халыкның мәгарифе», «Чын хөррият кайчан булачак», «Халык акчасы ни рәвештә җыела вә каю урыннарга тотыла» (дүртесе дә Г. Камал нәшрендә чыккан китаплар), «Яшь гомерем» (М. Гафури әсәре), «Тукаев шигырьләренең 4 нче кисәге» («Китмибез» исемле шигыре өчен), «Сәгыйть Рәмиев шигырьләре» һ. б.».

*«Йолдыз», 1912 ел.*

Җыйды — ***И. РӘМИ.***

---

[1] «Урал» чыгарган китаплардан калган дүртесе шушылар: «Гомуми сайлау хокукы», «Россия социал-демократларының партиясе авыл хуҗалыгы өчен нәрсә булдырырга тырыша», «Төрле милләтләрне җәберләү кемгә кирәк?», «Безнең якында булдырырга теләгән нәрсәләребез һәм төп максадыбыз».

# Китап күзәтү

## ЯШЬ УКУЧЫ ОБРАЗЫ

Бүгенге балалар әдәбиятында күп эшләүче, иң продуктив язучыларыбызның берсе Ләбибә Ихсанова дисәк, әллә ни арттыру булмас кебек. Балалар дөньясын, аларның уй-теләкләрен, характерларын һәм психологиясен белеп-өйрәнеп язылган әсәрләре белән Л. Ихсанова балалар әдәбиятын үстерүгә лаеклы өлеш кертә.

Әле 1963 елда гына Татарстан китап нәшрияты язучының «Космонавтлар урамы»[1] исемле хикәяләр китабын чыгарган иде. Бер елдан соң без Л. Ихсанованың «Тал бөгелә»[2] дигән яңа повесте белән таныштык. Ул бу китаплары белән әдәбиятка үзенчәлекле, яңа образлар алып килде, һәр ике җыентык авторның әдәби осталыгы үсә баруы, каләме тагын да чарлана төшүе турында сөйли. «Космонавтлар урамы» китабыннан «Марка», «Кызыл галстук», «Топ, топ...», «Магнитофон һәм ак халатлар», «Космонавтлар урамы» кебек хикәяләр аеруча матур тәэсир калдыралар. «Марка» исемле кыска гына хикәядә Л. Ихсанова шактый тулы эшләнгән ике образ, ике характер тудыра алган. Алар — Рөстәм һәм Илдар. Хикәя балаларны намуслы булырга, үз-үзеңә таләпчән карарга өйрәтә.

«Кызыл галстук» хикәясендә без борын өсләренә, маңгаена борчак-борчак тирләр чыккан кечкенә Шәүкәт белән танышабыз. Хикәяне укыгач, Шәүкәтнең сумкасын болгый-болгый, абына-сөртенә йөгерүе дә, күзләренең йолдыз кебек януы да — барысы да ачык булып күз алдына килә. Автор зур дәрт белән аның матур тормышы, балалык бәхете турында яза, бу бәхетнең зур корбаннар хисабына яулап алынган булуын сурәтләп, укучыны ерак үткән көннәргә алып китә.

«Космонавтлар урамы» җыентыктагы башка хикәяләрдән зуррак күләмле, образларның күбрәк булуы белән аерылып тора. Л. Ихсанова биредә юмористик характерлар тудыруга омтылыш ясый. Хикәянең теле гади, фикерләрне төгәл гәүдәләндерүче җиңелчә юмор белән өретелгән җөмләләр әсәрдәге геройларның характерына да бик тапкыр килеп тора. «Космонавтлар урамы»нда сүз бүгенге бала өчен иң типик хыялларның берсе — космонавт булу теләге турында бара. Камил белән Алик бик җиңел генә космонавт булырга хыялланалар. Ләкин көч куймыйча, тырышмыйча гына бу теләкне тормышка ашырып булмый икән шул. Язучының хикәядә үздырган төп идеясе әнә шундый.

Алик белән Камил, индивидуаль характер, әдәби образ буларак, бик матур, тормышчан чыкканнар. Бер үк уй-теләкләр белән янучы бу ике малайның һәрберсе үз характерына гына хас телдә сөйли, һәрберсенең үзенә генә хас холкы, гадәте бар. Космонавт булу дәрте белән күнегүләр ясап, караңгы бүлмәдә ялгыз утыручы Алик менә ничек хыяллана. «Космонавт киемеңне салып та өлгермисең, каршыңа йөгереп Камил килә. Светланалар, Фоатлар каршы ала. Аннары Мәскәүгә алып китәләр сине, Кремльгә алып керәләр. Ух, бер туйганчы Мәскәүне карап йөрисең инде шунда. Иң элек ул Ленин мавзолеена барыр иде... Аннары туйганчы мороженое ашар иде. Мәскәү мороженое тагын да тәмлерәк әле ул, тиз генә туеп та булмас...» (90 бит).

Камил образын исә язучы башка төрлерәк алымнар белән ача. Камил инде бөтенләй башка характердагы бала булып хәтердә кала. Камил төрле уеннар (авырлыкны югалту буенча күнегүләр ясау нияте бе-

[1] Л. Ихсанова. Космонавтлар урамы. Хикәяләр. Казан, 1963 ел.

[2] Л. Ихсанова. Тал бөгелә. Повесть. Татарстан китап нәшрияты, Казан, 1964 ел.

лән агач башына асылынып тирбәлү һ. б.) белән мавыга. Алик күбрәк хыялланырга яратучан бала булса, Камилдә уйлап табучанлык сәләте көчле.

Хикәядәге үзәк персонажларның өченчесе — Фоат, безнең уебызча, Камил белән Аликтан күп кайтышрак. Образга ышандыру, тормышчанлык көче җитми. Әсәргә ул авторның уңай идеалын гәүдәләндерүче әзер схема төсендәрәк килеп керә. Фоат артык туры сызык буенча ясалган. Автор бу үрнәк герое турында күбрәк үзе сөйли, ә менә аны, әсәрдәге вакыйгаларга катнаштырып, эше-хәрәкәтләре аша күрсәтүгә игътибар итмәгән.

Җыентыкта билгеле бер идеяне укучыга коры дидактик алымнар белән генә аңлаткан хикәяләр дә юк түгел. «Утрау малайлары», «Чемпион», «Ленин бабай дәфтәре», «Отряд байрагы» һ. б. шундыйлардан. Бу хикәяләрдә образлар индивидуальләштерелмәгән. Алар барысы да бер төслеләр. Таһир белән Заһирнең дә («Утрау малайлары») Малик белән Гөлсинәнең дә («Отряд байрагы») үзенә генә хас холкы, характеры, сөйләм алымнары күренми кала.

«Тал бөгелә» исемле яңа повестенда Л. Ихсанова язучылардан беркемнең дә моңарчы кулы тимәгән яңа өлкәне — интернат мәктәпләр тормышын тасвирлый. Бу яктан «Тал бөгелә» аерым игътибарга лаек. Л. Ихсанова, шәһәр балалары тормышын яктыртучы автор буларак, татар балалар язучылары арасында үзенә аерым урын тота. Юкса, безнең язучылар күбрәк авыл турында гына язарга яраталар. «Космонавтлар урамы», «Тал бөгелә» — татар балалар әдәбиятындагы шул бушлыкны тутыру ягыннан да гаять әһәмиятле китаплар.

Язучының «Тал бөгелә» повестенда да уңышлы эшләнгән әдәби образлар бар. Бу турыда сөйләгәндә, беренче чиратта, Фирдәвес образына тукталырга кирәк. Ул әсәргә оптимистик рух һәм җанлылык кертүче образларның берсе. Повестьта бу образга әллә ни киң урын бирелми. Шулай да Фирдәвес бик ягымлы, мөлаем, җанлы кеше булып хәтердә кала. Әсәрдә аның әти-әнисенә мәхәббәте, классташы Салихка булган дуслык хисләре матур сурәтләнә. Автор Салих һәм Фирдәвеснең үзара мөнәсәбәте аша татар балалар әдәбиятында аз яктыртылган бик кирәкле проблеманы — кыз һәм ир балалар арасындагы эчкерсез дуслык проблемасын күтәрә. Әсәрдә бу дуслыкны укучыны дулкынландырырлык дәрәҗәдә көчле итеп сурәтләнгән урыннар бар. Фирдәвеснең эчке дөньясы бүгенге тормышта булып торган конкрет вакыйгалар аша ачыла. Язучы Америка империалистларының яшь Кубаны блокадага алган көннәре турында сөйли. Бу җинаятькә совет кешеләренең гомуми нәфрәтен ышандырырлык тасвирлап, балада интернационализм хисләре тәрбияли.

Ләкин башка образларны эшләүдә автор мондый уңышка ирешә алмаган. Ни өчен? Чөнки Л. Ихсанова башка геройларның төп характер сыйфатларын үзе сөйләп бирә. Шуның нәтиҗәсендә характерның үсешен кызыксынып күзәтеп барып булмый. Укучы алдына әзер образ куела. Күп очракта мондый персонажлар автор фикерен үткәрү өчен кертелгән җансыз шәүлә генә булып калалар. Мисалга Рөстәм образын алыйк. Л. Ихсанова аның турында «хәйләкәр малай, мең төрле бәлаләрдән котылып чыга ала», ди. Персонажның тышкы портреты да, беренче карашка, автор биргән характеристикага бик тә туры килә кебек: «Аның бәләкәй яшел күзләре мәченеке төсле елтыр-елтыр итә». Рөстәмнең әсәрдәге эш-хәрәкәте моны раслыймы соң? Кызганычка каршы, юк шул. Рөстәм артык беркатлы, җебегән малай кебегрәк тәэсир калдыра.

«Тал бөгелә» повестенда геройларның эчке дөньясын сурәтләүгә зур урын бирелә. Образлар күбрәк эчке монологлар ярдәмендә ачыла. Ләкин «Космонавтлар урамы» хикәясе белән чагыштырганда, биредә алар кирәгеннән артык озын. Рөстәмнең, мәсәлән, бер очрактагы эчке монологына гына да китапта 3 бит ярым (16—19 битләр) урын бирелгән. Балалар өчен язылган әсәрләрдә монологларның болай сузылуы укучыны талчыктыра, сюжет агышын тоткарлый. Балалар гадәттә үткен фабулага, тиз алмашынучан вакыйгаларга корылган әсәрләрне яраталар. Повестьтагы Салих образын шулай ук тулыландырасы бар. Язучы аны классташы Фирдәвескә мөнәсәбәттә ачарга омтыла. Тик VIII класс укучысын повестьның буеннан-буена Фирдәвес турында гына уйларга мәҗбүр итү, геройның башка теләк һәм омтылышларын җитәрлек сурәтләмәү аркасында, бу образ шактый берьяклы ачылган. Л. Ихсанова бу ике образның характерындагы үзәк билгеләрне үткенләндереп бирми. Шуңа Рөстәм һәм Салихның үз-үзләрен тотышлары нинди дә булса уңай реакция тудырмый, укучы геройларны салкын кабул итә. Кыскасы, «Тал бөгелә» әсәрендәге геройларның күбе-

се үзләренә йөкләтелгән идеяне гәүдәләндереп җиткермиләр.

Без Л. Ихсанованың яңа повестеның әһәмиятен, бу әсәрнең әдәби һәм тәрбияви кыйммәтен кечерәйтергә һич тә теләмибез. Әмма шулай да, бер нәрсәне туры һәм ачык әйтергә кирәк: «Тал бөгелә» повесте образларының сәнгатьчә эшләнеше, сюжет төзелеше ягыннан «Космонавтлар урамы»ндагы уңай яктан искә алынган хикәяләрдән йомшаграк.

Ф. ИБРАҺИМОВА.

# ЙОЛДЫЗЛАР АСТЫНДА

Газиз Мөхәммәтшин китап сөючеләргә, күбрәк, кыска хикәяләр язучы буларак билгеле. «Йолдызлар астында»[1] исемле бу кечкенә җыентыкта да авторның үнечләп хикәясе урнаштырылган. Ул хикәяләрнең кайберләре белән без Газизнең элекке җыентыкларында ук очрашкан идек, икенчеләре исә яңалар, соңгы елларда иҗат ителгәннәр. Яңа җыентык Г. Мөхәммәтшинның хикәяләү стиле һәм почеркы ачыкланганнан-ачыклана баруы, әдәби осталыгы да үсә, камилләшә килүе турында сөйли.

Язучы без барыбыз да күреп-очратып йөргән, янәшәбездә генә яши-эшли торган гади кешеләрдән күңелдә калырлык, матур әдәби образлар тудыра, тормышта адым саен диярлек очрап торган гадәти вакыйгалардан эчке мәгънә таба, аларны сәнгать дәрәҗәсенә күтәрә белә. Гомуми интереслар белән янып яшәүче укытучы Сафихан абзый («Ялдан кайтканда»), үзенчәлекле характерлы, шул ук вакытта бик ягымлы Төер Гәрәй («Яз башы») һәм кешеләр язмышына аталарча кайгыртып карый белүче Мортаза карт («Балта остасы») кебек образлар шул турыда сөйли. Г. Мөхәммәтшин, күп төрле әдәби-сурәтләү алымнарыннан оста файдаланып, үзенчәлекле, оригиналь хикәяләр язган. «Балта остасы» исемле хикәядә, мәсәлән, төп образ үзе күренеп кенә кала. Аның кем, нинди кеше булуын без Мортаза карт сөйләве аша гына беләбез. Хикәядә, шул ук вакытта, төп образ белән беррәттән, әйбәт, мөлаем кеше буларак, Мортаза бабай үзе дә ачыла.

«Автобус кичегеп килә» исемле хикәя дә әйбәт тәэсир калдыра. Иртыш елгасындагы бер пристаньнан пассажирлар төяп, ерак Себернең Иманле районына автобус чаба. Автобуста — үзенә бер тормыш, төрле кешеләр, төрле характерлар... Татарстаннан килеп, Себер авылларына укытучы булып баручы Фәез, Ленинградтан килгән яшь врач кыз Нәсимә, атаклы аучы Янбай һ. б.

Шофер халкының, ни өчендер, болай да яманаты чыккан инде. Аларны аракы белән дус булуда гаеплиләр, шоферлар алдашырга, «сулга» эшләргә ярата дип тә өстиләр. Башта бу автобус шоферы турында да кайбер пассажирлар бик үк әйбәт фикердә булмыйлар. Болай уйларга сәбәпләре дә бар кебек. Әнә бит, тукталышка ул шактый кичегеп килгән, автобуста урын булмаса да, өстәмә кешеләр утырта. Юлның бик начар бер урынына җитеп, автобус канауга барып төртелгәч, пассажирлар арасыннан: «Әнә, ярты литрны сыптырган да, хәзер изрәп төшкән, рәхәтләнеп гырылдый, нахал!» дип, шоферны әрләргә тотынучылар да табыла. Ә чынлабрак карасаң, шофер бөтенләй гаепсез икән бит. Ул сугыш елларында Ленинградны саклауда катнашкан һәм шунда каты яраланган булган. Хәзер әнә шул яра кузгалган...

Рульгә Фәез утырырга мәҗбүр була. Авыруны якындагы больницага чак илтеп җиткерәләр. Килсәләр, анда хирург юк икән, операцияне Нәсимә ясый.

«Автобус кичегеп килә» дигән хикәядә әнә шундый көтелмәгән авыр шартларда үзара танышып, дуслашып киткән юлчыларның ышандырырлык образлары белән танышасың. Фәез белән Нәсимә һәм әсәрдә хәтта исеме дә әйтелмәгән шофер егет онытылмаслык булып истә калалар.

Г. Мөхәммәтшинның юмористик һәм сатирик хикәяләре дә байтак кына. Яңа җыентыкка бу төрдән «Шикаять», «Дару», «Яну», «Шаһгали нервысын саклый» кебек хикәяләре кертелгән. Язучы бу хикәяләрендә әйбәт кешеләребезнең кайбер сәер гадәтләреннән, үз-үзләрен тотышларыннан дусларча көлә, тормышыбызда очраштыргалый торган төрле эгоистларны, әрәм тамакларны, җинаятьчеләрне сатира уты астына ала.

[1] Газиз Мөхәммәтшин. Йолдызлар астында. Хикәяләр. Татарстан китап нәшрияты, 1964 ел.

Җыентыктагы хикәяләр, сәнгатьчә эшләнешләре, күтәргән мәсьәләләренең әһәмияте ягыннан булсын, барысы да бер үк дәрәҗәдә түгел, әлбәттә. Беренче карашка, «Күңелдәге таш» исемле хикәя үткен сюжетка корылган, анда оста каләм белән язылган һәм укучыга көчле тәэсир итәрлек аерым урыннар бар. Хикәядә вакыйгалар Себер авылларының берсендә бара. Ике дус егет — Таһир белән Фәрух — тайгага ауга китәләр. Ләкин тайга урманнарында күп куркынычлар күргән кыю аучылар бу юлы авыр хәлдә калалар... Котырган аю башта Фәрухка ташлана һәм аны җиргә бөтереп сала. Таһир тиз генә дустына ярдәмгә ашыга, әмма ярсыган ерткыч аннан җитезрәк булып чыга. «Таһирның берьяк яңагын утлы кисәү көйдереп алгандай булды. Күзләреннән яшен утыдай якты очкыннар көлтәсе атылып чыкты. Ике-өч адымдагы юан чыршы, меңнәрчә вак кисәкләргә чәрдәкләнеп, әкрен генә берьякка янтая башлады. Таһир соңгы минутта корыч пычагының аю корсагына салмак кына бата баруын һәм уң җилкәсенең, ничектер, сәер рәвештә чытырдап китүен генә сизеп калды. Ерткыч һәм кеше, канга буялып, кар өстенә икесе дә бергә аудылар...» (156 бит). Аннан соң — больница, лаклы ак түшәм...

Шушы урынга кадәр хикәя әйбәт бара, бирелеп укыла. Ахырга таба инде автор үз геройларын, аларның рухи хәлләрен, үзара мөнәсәбәтләрен ышандырырлык, дөрес итеп сурәтли алмаган. Таһир, айлар буе больницада ятып, ниһаять, сәламәтләнеп кайта. Ләкин авылдашлары аңардан йөз чөерә, аның белән сөйләшмиләр яки аңа йөрәк әрнеткеч авыр сүзләр әйтәләр, «куркак!» дип хурлыйлар. Ни өчен, диярсез. Үзенең иптәш егете Фәрух гайбәт тараткан, «аю миңа ябышкач, Таһир, ярдәмгә ташланасы урында, йөгереп кача башлады. Шунда аю мине җибәреп, үкерә-үкерә аның үзенә ыргылды. Мин килеп җитеп аюны чәнечмәсәм, бөтенләй беткән иде егет. Бәлагә тарган иптәшен, күрә торып ташлап качты», — дип сөйләгән! (158 бит). Кызганычка каршы, Таһир өстенә ташланган гайбәтне юкка чыгару өчен беркем берни эшләми диярлек. Таһир үзе эчтән яну белән генә чикләнеп кала. Хәтта үзен чыннан да гаепле саный (?), өзелеп сөйгән кызы Саниядән дә баш тарта, аңа «синең белән юлларыбыз аерыла, син хәзер теләсә нинди егетне сайларга хаклы» дип хатлар яза... Туган авылыннан китеп, зәңгәр атаудагы кеш фермасына эшкә керә.

Соңыннан автор барысын да аңлатып бирергә тырыша, әлбәттә. Санияне Фәрух та яратып йөргән һәм кызны, Таһирдан биздереп, үзенә карату өчен, ул иптәше өстенә шундый коточкыч яла яккан икән. Хикәя Таһир белән Саниянең үзара аңлашулары, яңадан кавышулары белән тәмамлана. Ләкин мондый ситуацияләргә укучыны ышандыруы кыен. Чөнки вакыйгалар тормышта булганча яки булуы мөмкин булганча түгел, ә авторга ничек кирәк, шулай үзгәртелгәннәр, ясалганнар.

«Хуҗалар» исемле хикәя, гомумән, ярыйсы гына язылган. Тормышның чын хуҗалары Эльфак кебек обывательләр түгел, ә бәлки, Әнисә белән Бәйрәм кебек, үз эшләренә намус белән караучы, җәмгыятебезнең алдынгы кешеләре, димәкче автор. Тик бу яхшы хикәянең күзгә ташланып торган бер кимчелеген әйтмичә үтеп булмый. Әнисә дә, Эльфак та, образ, характер буларак, асылда, диалогларда ачылалар. Укучы башта Әнисә белән хикәядәге «мин» (хикәя беренче заттан язылган) арасындагы җитди әңгәмәләр, төрле шаяртулар белән укмашып барган диалогларны бик табигый рәвештә, җиңел генә йотып бара. Ә менә Эльфак белән Әнисәнең ике биткә сузылган сөйләшү-аңлашуларына килгәндә исә моны әйтеп булмый. Эльфак үзенең мәхәббәтен белдерә, Әнисә аны кире кага. Монда бернинди уен-көлке, шаяру юк; һәр ике як бик җитди рәвештә үзләренең тормышка карашларын ачып салалар; ике төрле характер, ике төрле фәлсәфә, тормышка ике төрле караш чарпылыша. Һәм һәр икесе бик төпле итеп, бик шома әдәби тел белән, бик төгәл сүзләр, җөмләләр ярдәмендә тирән мәгънәле бәхәс алып баралар. Монысын инде персонажлар түгел, ә алар өчен автор үзе сөйли. Әйбәт хикәяне нәкъ менә шушы урыннар бозып тора. Әнисә белән Эльфакның үзара мөнәсәбәтләрен, дөньяга карашларын, характерларын автор арттырмыйча, реаль булган бүтәнчәрәк алымнар белән дә ача алыр иде бит. Моңа аның сәләте дә, осталыгы да җитәрлек иң.

Ә гомумән, кыска хикәяләр кебек авыр жанрда эшләп, соңгы елларда күзгә күренеп үсеп баручы, күп яза торган яшь автор Г. Мөхәммәтшин иптәшнең иҗатын төрле яклап тикшерү өчен материал җитәрлек. Бу күзәтү исә — аның шушы соңгы бер җыентыгы турында кайбер фикерләр белән уртаклашу гына.

Газиз ИДЕЛЛЕ.

# Әдәбият һәм сәнгать яңалыклары

## ТАТАРСТАН ЯЗУЧЫЛАР СОЮЗЫ ИДАРӘСЕНДӘ

Татарстан Язучылар союзы идарәсенең 16 июньдә уздырылган киңәйтелгән утырышында «Казан утлары» журналының быелгы 1—5 саннары тикшерелде. Утырышны, журнал редакциясенең эше турында кыскача кереш сүз белән, Язучылар союзы идарәсенең җаваплы секретаре *Зәки Нури* ачты. Журналның быел чыккан 5 саны, ул саннардагы материаллар буенча фикер алышуда унбишләп кеше катнашты. Фикер алышуда катнашучылар журналда басылган материалларның сыйфаты яхшыра баруын, редакциянең киң катлау укучылар массасы һәм авторлар белән элемтәсе киңәя, ныгый төшүен билгеләп үттеләр, редакция эшендәге аерым кимчелекләрне тәнкыйть иттеләр, журналның сыйфатын тагын да яхшырту, аның эшен җанландыру буенча күп кенә файдалы киңәшләр, тәкъдимнәр әйттеләр.

Журналның җаваплы секретаре *Әхсән Баянов*, редакция коллективының узган айларда ничек эшләве, 1965 елны нинди байлык белән каршылавы турында сөйләгәннән соң, язучыларны журналның алдагы айларга эш планы белән таныштырды:

— Алдагы саннарда журналыбызда нинди яңа әсәрләр басылачак соң? 5 саннан Шәйхи Маннурның «Муса» исемле яңа романы басыла башлаган иде. Зур күләмле бу роман 1965 елда басылып бетәр, дип уйлыйбыз. Моннан башка, редакция папкасында Нәби Дәүлинең «Җимерелгән бастион» һәм Гариф Гобәйнең «Чын вә ялган яки корьән серләре» исемле повестьлары, Ф. Хөсни, И. Нуруллин, Г. Мөхәммәтшин, М. Шәрифуллиннарның яңа хикәяләре бар. Шушы көннәрдә журналга Мәхмүт Хәсәнов «Юллар, юллар» исемле яңа романын китерде. Редакция язучыларыбызның иҗат планнары, нинди яңа әсәрләр язулары белән дә кызыксынып тора. «Казан утлары»на А. Расих интеллигенция тормышыннан алып язылган яңа романын, И. Гази «Онытылмас еллар»ның эпилогын, Г. Бәширов, Н. Фәттах, Г. Минскийлар яңа повестьларын китерергә вәгъдә бирделәр.

Поэзия әсәрләренә дә күп урын биреләчәк. Без инде берничә мәртәбә яшь авторларның яңа шигырьләрен туплап бирдек. Бу эшне киләчәктә дә дәвам итәргә уйлыйбыз. Алдагы саннарда Ә. Давыдов, Ш. Галиев, Г. Афзал, Г. Латыйп, З. Мансур һәм башка шагыйрьләрнең лирик шигырьләрен бирәчәкбез. Х. Туфан, Ә. Давыдов, М. Садри, З. Нури, И. Юзиев, Р. Әхмәтҗановлар яңа поэмаларын төгәлләп киләләр.

«Казан утлары»ның һәр санында очерклар, юл язмалары, публицистик мәкаләләр басылып килә. Бүгенге көннең әһәмиятле проблемаларына багышланган әдәби очеркларга киләчәктә дә киң мәйдан биреләчәк. Очеркларның тематикасын төрләләндерү, аларның географикасын киңәйтү өчен дә тырышабыз. Алдагы саннарда Г. Галиев, Р. Мостафин, Ә. Маликов, С. Шакир, М. Хәмитов, Г. Ахунов, М. Юныс һәм башка иптәшләрнең яңа очерклары чыгачак.

Тәнкыйть-библиография бүлеге дә эшен җанландыра төшәргә тиеш. 1964 елдан без күренекле язучыларыбызның иҗат портретларын бирә башлаган идек. Бу эш быел да дәвам итә. 7 санда Р. Сверигинның Фатих Хөсни иҗатына багышланган хезмәте басылды. Бу санда Р. Мостафинның Х. Туфан турындагы мәкаләсе басыла. Алдагы саннарда Г. Афзал, Р. Төхфәтуллин һәм башка язучыларыбызның иҗат портретларын бирергә уйлыйбыз.

Бөек Октябрьның 50 еллыгы һәм Татарстан АССР төзелүгә 50 ел якынлашу уңае белән, әдәбиятыбыз һәм культурабыз үсешен яктырткан актуаль мәкаләләр, фәнни хезмәтләр дә журнал битләрендә зур урын алачак. Журналыбызның һәр санында даими рәвештә рецензияләр биреп барырга тырышачакбыз. Быел укучылар Р. Мостафин, Г. Иделле, Р. Башкуров, Р. Шириязданов, Ф. Хәмидуллин һәм башка иптәшләрнең рецензияләре белән танышачаклар. Журналда шулай ук әдәбият тарихына караган материаллар, истәлекләр, китап укучыларның яңа басылган әсәрләргә карата фикерләре чыгып барачак. Артистлар, композиторлар, сәнгатебезнең башка өлкәләрендә эшләүче күренекле кешеләр турында мәкаләләр, очерклар бирү планлаштырыла.

Филология фәннәре докторы, профессор *Хатип Госман* журналның быелгы саннарында чыккан истәлекләр турында сөйләде:

— Истәлекләргә киң урын бирү — әйбәт күренеш. Шәхес культы заманнарында язучыга, аның шәхесенә игътибар кимегән иде. Язучыны шәхес буларак өйрәнү әдәбият фәне өчен дә, укучылар өчен дә бик кирәк. «Казан утлары» журналында урнаштырылган истәлекләрдән мин С. Әдһәмованың Ш. Бабич турындагы язмаларын аеруча яратып укыдым. Әдәбиятны әйбәт белүче һәм аңлаучы иптәш тарафыннан язылганга булса кирәк, бу истәлек шагыйрьнең иҗатын аңлау өчен дә күп әйбер бирә. М. Бәдәйлинең Ш. Бабич турындагы истәлеге дә

нигездә яхшы. С. Шакирның Хәйретдин Мөҗәй турындагы истәлеге документларга бай, дәлилле булуы белән аерылып тора. Әмма әдәби һәм фәнни кыйммәте зур булган бу истәлек-очерк таркаурак язылган. Аңа стиль берлеге, композиция бөтенлеге җитеп бетми. Журналда басылган кайбер истәлекләрнең теле бик үк әйбәт түгел. Киләчәктә редакция эшчеләре бу мәсьәләгә дә җитди игътибар бирергә тиешләр.

— Мин, Хатип Госман сүзен дәвам итеп, театр сәнгатенә караган мәкаләләргә, артистлар турындагы истәлекләргә тукталмакчы булам,— диде филология фәннәре кандидаты *Баян Гыйзәт*. —Театр сәнгате турында мәкаләләр, аерым спектакльләргә карата рецензияләр чыккалап торса да, журнал редакциясе бу өлкәдә җитәрлек активлык күрсәтми әле. Андый материалларның «Казан утлары»нда күбрәк урын алуларын теләр идем.

Әдәбият галиме һәм тәнкыйтьче *Хәсән Хәйри* очеркларга һәм публицистик мәкаләләргә анализ ясады:

— Быел басылганнардан М. Хәмитовның «Биш ел үткәч» очеркын иң уңышлысы дияр идем. Күп яктан отышлы әсәр бу. Ул тормышчан фактларга, әдәби детальләргә бай. Автор тормышны өйрәнеп, белеп язган. Хөснимәрдәновның «Якташларым» исемле очеркы да миңа ошады. Р. Ишморатованың «Авылда бер көн»е җиңел кулдан, уйланмыйчарак язылган. Аны, бәлки, «Җидеелләлык сәхифәләре» дигән рубрикада бирергә кирәк тә булмагандыр. Н. Мостафинның «Солдат язмышы» әйбәт укыла, мавыктыргыч язылган. Очеркның теле дә әйбәт, композициясе дә төзек. Очерклар турында сүзне төгәлләр алдыннан бер искәрмә ясыйсы килә. Әле һаман да безнең очеркларның тематика ягы таррак. Безнең очеркистлар гел колхоз тормышы, председатель һәм бригадир турында гына язарга яраталар. Очеркларның тематикасын бик нык киңәйтү белән бергә, безгә зуррак мәсьәләләргә багышланган, проблематик очерклар булдыру турында да уйларга вакыт.

— Н. Мостафинның «Солдат язмышы»н мин дә яратып укыдым,— диде *Газиз Иделле*. —Татар халкының Тукаев кебек курку белмәс уллары әле байтактыр. Аларны эзләргә, табарга кирәк һәм ул кешеләр турында язарга кирәк. Х. Хәйри фикеренә мин дә кушылам. Әйе, М. Хәмитов әйбәт очерк язган. Әмма М. Хәмитов кебек тәҗрибәле очеркисттан безнең тагын да яхшырак әсәрләр көтәргә хакыбыз бар. М. Юныс безнең әдәбиятка үзенчәлекле яңа темалар, моңарчы без аз белгән яки бөтенләй диярлек белмәгән тормыш материалы алып килде. Аның очерклары, беренче чиратта, әнә шул яклары белән игътибарны җәлеп итә.

*Афзал Шамов*, күбрәк, редакция эшендәге кимчелекләр, җитешсезлекләр турында сөйләде:

— Киләсе ел зур әдәби даталар — Г. Тукай, Ф. Әмирхан, М. Җәлил елы. Бу даталарны тиешле югарылыкта билгеләп үтү өчен журнал бүгеннән, җиң сызганып, эшкә алынырга тиеш.

Монда җаваплы секретарь читтә яшәүче авторлар белән редакциянең элемтәсе әйбәт диде. Миңа килгән кайбер хатлар ул элемтәнең бик үк әйбәт булмавы турында сөйлиләр. К. Гыйрфановның С. Рәмиев турындагы истәлекләре редакция папкасында озак вакытлар ятканнан соң гына дөнья күргән. Анда да күп кыскартулар белән басылган. Һәм мондый фактлар бер генә түгел. Киләчәктә мондый әйберләрне булдырмаска кирәк.

А. Шамов чыгышыннан соң, *Гомәр Бәшировның* идарә утырышына язган хаты укылды. Ул хатта редакция эшендәге аерым кимчелекләр тәнкыйтьләнә, редакция сотрудникларының хезмәт шартларын яхшыртырга кирәк, дип әйтелә.

— Озак еллар буе редколлегия члены булып эшләгәнгә күрә,—диде *Ибраһим Гази*,— мин редакциядәге хәлне шактый яхшы беләм. Монда, артык кызып китеп, А. Шамов редакция эшчеләренә күп гаеп ташлады, кайбер кимчелекләрне арттырып, күпертеп күрсәтте. Ул, мәсәлән, К. Гыйрфановның истәлекләрен артык озак яткырдылар, бик нык кыскартып чыгарганнар, диде. Ул материалны кыскартып, редакция бик дөрес эшләде. Чөнки тулы килеш ул әйбер басарлык хәлдә түгел иде. Авторлардан килгән әйберләрне редакция шул көенчә түгел, ә төзәтеп, эшкәртеп чыгарырга тиеш.

*Мәҗит Рафиков* А. Гыйләҗев, И. Нуруллин, С. Сабиров һәм Р. Фәизов хикәяләрен уңай яктан бәяләде. С. Хәкимнең «Үрләр аша» поэмасы, Ә. Давыдов, З. Нури, Ә. Ерикәй, Ш. Галиев, Ә. Баянов шигырьләре турында сөйләде.

*Атилла Расих* та чыгышын хикәяләр турында сөйләүдән башлады:

— Безнең прозада хикәя жанры активлашып килә. Бүгенге хикәяләребез сыйфатлары, сәнгатьчә эшләнешләре ягыннан да югары торалар. И. Газиның «Гаепсез гаепле»ләр», И. Нуруллинның Тукай турындагы хикәяләре әйбәт тәэсир калдырды. М. Рафиков М. Маликованың «Юлдашлар» исемле хикәясе йомшак, эшләнмәгән, диде. Мин бу фикер белән килешмәс идем. С. Сабиров безнең әдәбиятка үз темасы белән килгән, үзенчәлекле автор. Ләкин соңгы елларда ул активлыгын шактый киметте. Н. Дәүлидән мин күбрәк көткән идем. Аның «Өч кирпеч» хикәясендә көлүнең максаты әллә ни зур түгел. А. Гыйләҗевнең «Үги ана яфраклары» хикәясенә аерым тукталырга кирәк дип саныйм. Бу хикәядә автор «Өч аршын җир» повестендагы көчле якларын тагын да үстергән, көчәйтеп җибәргән. А. Гыйләҗев кешеләр язмышы турында яза, җылы итеп, аларны яратып яза.

— Кайбер вакытларда журнал битләрендә очракны тәрҗемәләргә дә урын бирелә,— диде *Ә. Давыдов*. — Кемне кайчан тәрҗемә итү турында журнал төпле бер фикергә килергә тиеш.

*Галимҗан Латыйп* Ә. Давыдов фикерләре белән килешмәгәнлеген әйтте. *Нурихан Фәттах* журнал эшенә, җәмәгатьчелек тәртибендә, тәҗрибәле язучыларны тартырга кирәк, алар редакция эшчеләренә ярдәм итсеннәр иде, дигән теләк белдерде.

Шул ук утырышта гражданнар сугышында һәлак булган батырлар истәлегенә Казан шәһәрендә салыначак монументны төзүдә

язучыларның катнашуы турында да сүз булды. Утырыш, бер тавыштан, монумент төзүдә ярдәм итәргә, дигән карар кабул итте.

## ӘГЕРҖЕДӘ ӘДӘБИЯТ АТНАЛЫГЫ

Май ахырларында язучыларның Г. Әпсәләмов, Х. Туфан, Л. Ихсанова, Ш. Галиев, И. Юзиев, Ә. Баянов, Ә. Маликов, С. Шакир һәм Ш. Бикчуриннар составындагы зур бер группасы Әгерже районында булып кайтты. Монда, Татарстанның иң ерак районнарының берсендә, 19 майдан 25 майга кадәр татар әдәбияты атналыгы уздырылды. Әгерже районы кешеләре язучыларны бик җылы каршылады, аларга тирән ихтирам, зур хөрмәт күрсәтте. Атналык чын мәгънәсендә әдәбият, сәнгать бәйрәменә әйләнде. Атналык көннәрендә язучылар китапханәләрдә, мәктәпләрдә, Культура йортларында, колхоз клубларында һәм кыр станнарында чыгышлар ясадылар, мәктәп балалары, эшчеләр, колхозчылар һәм район интеллигенциясе вәкилләре белән очраштылар. Бу көннәрдә татар язучыларының яңа әсәрләре буенча фикер алышулар, укучылар конференцияләре үткәрелде.

19 майда район Культура йортында атналыкны ачу тантанасы булды. Кичәне КПСС-ның Әгерже райкомының икенче секретаре иптәш Г. Габдуллин ачып җибәрде. Татарстан Язучылар союзы идарәсенең председатель урынбасары Г. Әпсәләмов Әгерже хезмәт ияләренә Татарстан язучыларының кайнар сәламен тапшырды, бүгенге әдәбиятыбызның үсеше турында сөйләде. Х. Туфан, Л. Ихсанова, Ш. Галиев, Ә. Баянов, С. Шакир яңа әсәрләрен укыдылар.

Икенче көнне язучылар ике мәртәбә (көндезге һәм кичке сменаларда) Әгерже татар урта мәктәбе һәм 74 рус урта мәктәбе укучыларында кунакта булдылар. Кичен район китапханәсендә Г. Әпсәләмов, Х. Туфан әсәрләре буенча укучылар конференциясе уздырылды.

21 май көнне язучылар, ике төркемгә бүленеп, авылларга чыгып киттеләр. Г. Әпсәләмов, Ш. Галиев, Ә. Баянов, С. Шакирлар (ахырдан бу төркемгә Ш. Бикчурин белән И. Юзиев та килеп кушылды) составындагы беренче группа, районның Иж-Буби, Биектау, Кадрәле, Кодаш, Тирсә авылларында булып, мәктәп укучылары, игенчеләр, терлекчеләр, механизаторлар белән очраштылар. Икенче төркем Көчек, Кырынды, Барҗы авылларында шундый ук очрашулар үткәреп кайтты.

Тантананы ябу кичәсе 25 майда Ленин исемендәге клубта үткәрелде. КПССның Әгерже райкомы секретарьлары язучыларга район хезмәт ияләре исеменнән зур рәхмәт әйттеләр. Атналык уздыруда катнашкан барлык язучыларга район партия комитетының һәм район башкарма комитетының Мактау грамоталары тапшырылды.

## НУР БАЯННЫҢ ТУУЫНА 60 ЕЛ

Май аенда республикабыз җәмәгатьчелеге күренекле шагыйрь Нур Баянның тууына 60 ел тулуны киң күләмдә билгеләп үтте. Газета-журналларда татар совет поэзиясен үстерүгә күп көч куйган патриот шагыйрьнең тормыш юлы һәм иҗаты турында мәкаләләр, замандашларының истәлекләре басылды. Татарстан радиосы шагыйрь иҗатына багышланган тапшырулар оештырды.

31 майда язучыларның Габдулла Тукай исемендәге клубында Нур Баянны искә алу кичәсе уздырылды. Кичәне, Нур Баян иҗатының әһәмияте, татар совет әдәбиятындагы урыны турында кереш сүз белән, Габдрахман Әпсәләмов ачты. Шагыйрьнең тормышы һәм иҗат мирасы турында доклад белән Хәсән Хәйри чыкты. Г. Кашшаф, А. Гумеров, шагыйрьнең улы Р. Баянов, Минзәлә педагогия училищесының әдәбият укытучысы В. Һадиев Нур Баян турында истәлекләр сөйләделәр. Соңыннан шагыйрьнең якташлары — Минзәлә педагогия училищесы студентлары, шәһәребез артистлары һәм композиторлары көче белән концерт бирелде. Концертта Нур Баян шигырьләре, аның сүзләренә язылган җырлар, татар халык көйләре башкарылды.

## Ш. МӨХӘММӘДОВНЫҢ ТУУЫНА 100 ЕЛ

20 майда СССР Фәннәр академиясенең Казан тел, әдәбият һәм тарих институты, Татарстан Язучылар союзы белән берлектә, күренекле татар язучысы Шакир Мөхәммәдовның тууына 100 ел тулуга багышланган гыйльми совет утырышы уздырды. Утырышта язучының тормыш һәм иҗаты турындагы докладны филология фәннәре докторы, профессор М. Гайнулин ясады. З. Максутова, С. Ногманов, Б. Урманчы һ. б. язучы Ш. Мөхәммәдов турындагы истәлекләре белән уртаклаштылар.

## ГЕРОЙ ШАГЫЙРЬГӘ ҺӘЙКӘЛ

Тагын берәр елдан шәһәребезнең Беренче Май мәйданында Советлар Союзы Герое, Ленин премиясе лауреаты Муса Җәлилгә һәйкәл ачылачак. Мәрмәр постаменттагы 6 метрлы бронза сыннан гыйбарәт булган бу мәһабәт монументның авторлары — СССР Сәнгать академиясенең член-корреспонденты, РСФСРның атказанган художнигы, дәүләт премиясе лауреаты скульптор В. Е. Цигаль һәм архитектор Л. Г. Голубовский. Һәйкәл сөекле шагыйребезнең якты истәлегенә лаеклы бүләк булачак.

## ГАДЕЛ КУТУЙ МУЗЕЕ

29 майда Казан шәһәренең 130 мәктәп укучылары, тантаналы шартларда, күренекле татар совет язучысы Гадел Кутуйның музей-бүлмәсен ачтылар. Музей ачу тантанасына композитор Җәүдәт Фәйзи, СССР Фәннәр академиясе Казан тел, әдәбият һәм тарих институтының гыйльми сотрудникы З. Усманова һәм язучының улы Рөстәм Кутуй да килгән иде. Музей-бүлмәдә Гадел Кутуйның тормышы һәм иҗатына бәйләнешле күп кенә кызыклы материаллар җыйналган. Киләчәктә укучылар музейны тагын да баетырга, тулыландырырга уйлыйлар.

## ИҖАТ СЕКЦИЯЛӘРЕНДӘ

Татарстан Язучылар союзы каршындагы шагыйрьләр секциясенең 2 июньдә булып үткән утырышында Касыйм Фәсәховның «Дивана» исемле поэмасы укып тикшерелде. Авторның бу яңа поэмасы буенча фикер алышуларда 8 кеше катнашты. З. Нури, Н. Арсланов, Г. Афзал, Ә. Давыдов, И. Юзиев, Ш. Галиев, Ә. Баянов, А. Сәләхетдиновлар поэманың кирәкле, кызыклы темага язылуын билгеләп үттеләр. Шуның белән бергә, поэма әле эшләнеп бетмәгән, шактый таркау, диделәр. Авторга әсәрен эшләп бетерү юллары күрсәтелде, әйбәт тәкъдимнәр әйтелде.

* * *

Шул ук көнне драматурглар секциясенең дә чираттагы утырышы уздырылды. Утырышның көн тәртибендә ике мәсьәлә иде: 1) Туфан Миннуллинның иҗат отчеты; 2) Октябрьның 50 еллыгына әзерлек.

Яшь драматург Т. Миннуллин нинди әсәрләр өстендә эшләвен әйтте, киләчәккә иҗат планнары турында сөйләде. Ахырдан авторның «Очканда, кагынганда» исемле пьесасы укып тикшерелде. Туфан Миннуллин иҗаты, аерым алганда әлеге пьесасы буенча, Р. Ишморат, А. Гыйләҗев, Ә. Бикчәнтәева, Х. Гарданов һәм башкалар чыгыш ясады.

Икенче көн тәртибе буенча филология фәннәре кандидаты Бәян Гыйззәт чыкты. Бөек Октябрьның 50 еллыгын каршылау уңае белән, татар совет драматургиясенең иң яхшы үрнәкләрен яңадан матбугатка чыгарырга кирәк, диде докладчы.

* * *

14 июньдә проза секциясендә М. Маликованың «Кыр ягы» исемле яңа хикәясе тикшерелде. Утырышта хикәя жанры, аның үзенчәлекләре турында җитди һәм файдалы сөйләшү булды. Чыгыш ясаган иптәшләрдән А. Расих, А. Гыйләҗев, Х. Сарьян яшь авторга үзенең хикәяләрен тагын да яхшырту буенча киңәшләр бирделәр.

## ӘДӘБИ КИЧӘЛӘР, ОЧРАШУЛАР, КОНФЕРЕНЦИЯЛӘР

13 майда Бондюгтагы икенче урта мәктәптә Ә. Касыймовның «Гомер ике килми» романы буенча укучылар конференциясе булып үтте. Әсәр турында фикер алышуларда 11 кеше катнашты. Романның авторы Ә. Касыймов китап укучыларның күпләгән сорауларына җаваплар бирде, әсәрнең язылу тарихын сөйләде. Аннан бер генә көн алда, 12 май көнне, Ә. Касыймов Алабуга китап кибетендә әдәбият сөючеләр белән очрашкан иде.

* * *

Шәһәрнең Идел буе районы Культура сараенда эшче яшьләрнең язучылар белән очрашу кичәсе булды. Анда татар язучыларыннан Нәби Дәүли, Әнвәр Давыдов, Зәйни Шәһиморатов үзләренең әсәрләрен укыдылар. Соңыннан үзешчән артистлар көче белән концерт бирелде.

* * *

15 майда Мәскәү шәһәренең Тарихи китапханәсе залында Ә. Еникинең «Рәшә», А. Гыйләҗевнең «Өч аршын җир» повестьлары буенча укучылар конференциясе булып узды. Конференциягә татар язучыларыннан А. Расих, Г. Ахунов һәм Башкортстаннан В. Исхаков та катнашты.

* * *

22 майда Ленинград шәһәренең татар яшьләре А. Расихны, Г. Ахуновны һәм башкорт язучылары М. Галине һәм В. Исхаковны үзләренә кунакка чакырдылар. Очрашу бик күңелле узды. Язучылар бүгенге Татарстан, аның әдәбияты һәм сәнгате турында сөйләделәр, Ленинград яшьләрен яңа чыккан әсәрләр белән таныштырдылар. Ленинградлылар исә язучылар хөрмәтенә үзешчәннәр көче белән зур концерт куйдылар.

* * *

26 майда Ленинград шәһәренең Салтыков-Щедрин исемендәге китапханәсендә төрле милләт язучылары белән очрашу кичәсе булды. Бу кичәгә татар язучыларыннан Г. Ахунов катнашты.

* * *

27 майда Ә. Еники, Н. Дәүли, Ә. Давыдов, Н. Арсланов, Ж. Тәрҗеманов, Г. Бакиров, Г. Латыйп, Ә. Бикчәнтәева, Ш. Галиев һәм башка язучылар «Яшь ленинчы» газетасында кунакта булдылар. Анда бүгенге балалар әдәбияты алдында торган җитди проблемалар тикшерелде, балалар әдәбиятын үстерүдә һәм пропагандалауда балалар газетасының роле һәм бурычлары турында сүз барды.

* * *

Июнь башларында пионерларның республика слетына килгән яшь хәбәрчеләр «Яшь ленинчы» газетасы редакциясендә журналистлар, язучылар белән очраштылар. Зәки Нури яшь хәбәрчеләрне балалар өчен чыккан яңа китаплар белән таныштырды. Нәби Дәүли, Ләбибә Ихсанова, Әминә Бикчәнтәева, Шәүкәт Галиев, Галимҗан Латыйп һ. б. яңа әсәрләрен укыдылар.

* * *

9 июньдә, Казанда М. Әуэзов исемендәге Казакъ дәүләт академия театры гастрольләре тәмамлану алдыннан, Бөтенроссия театр җәмгыятенең Татарстан бүлегендә казакъ артистлары белән очрашу уздырылды. Кунакларыбызның спектакльләре турында фикер алышуларда артистлар, театр белгечләре, язучылар катнашты. СССРның халык артисты Ш. Айманов, театр белгечләре Б. Гыйззәт, Р. Усманова, И. Иляловаларның чыгышлары аеруча кызыклы, файдалы һәм эчтәлекле булды.

* * *

Язучы Рафаэль Төхфәтуллин Баулы районы Акбуа нефтьчеләре поселыгының китап кибетендә әдәбият сөючеләр белән очрашты. Соңыннан автографлар белән китап сату оештырылды. Шул ук көнне кич Рафаэль Төхфәтуллин Акбуадагы 1 номерлы татар урта мәктәбе укучылары алдында чыгыш ясады. «Алтын канатлы кош» дигән яңа хикәясен укыды.

7 июньдә Рафаэль Төхфәтуллин Минзәлә шәһәренең Үзәк китапханәсендә шәһәр интеллигенциясе белән очрашты. Татар әдәбиятының торышы турында сорауларга җавап бирде.

## Алдагы саннарда:

Ш. Маннур. **Муса.** Роман. Дәвамы.

Ян Райнис шигырьләре.

Ш. Галиев, Ә. Давыдов, З. Мансур шигырьләре.

С. Әдһәмова. **Галимҗан абый һәм аның белән узган көннәр турында.** Истәлек.

Р. Мостафин. **Җирдә эзең калсын.** Публицистик мәкалә.

Х. Хәйри. **Бүгенге романнарыбызның жанр үзенчәлекләре.** Әдәби тәнкыйть.

Н. Юзиев. **Сүз чыгар шагыйрьләрдән хикмәт белән.** Әдәби тәнкыйть.

Әдәбият тарихына материаллар.

Яңа басылып чыккан китапларга рецензияләр.

●

Җаваплы редактор **Рафаэль Мостафин.**

Редколлегия: **Хәй Вахит, Ибраһим Гази, Әмирхан Еники, Гази Кашшаф, Шәйхи Маннур, Габдрахман Минский, Сибгат Хәким, Нил Юзиев.**

Наборга бирелде 10/VI-1965 ел. Басарга кул куелды 26/VII-1965 ел. ПФ 08136. Кәгазь форматы 70×108[1]/[16]. Учетн.-изд. табак 12,2. Басма табак 10(14). Заказ Л-818. Тираж 20 500 экз. Бәясе 40 тиен.


ТАССР Министрлар Советы каршындагы Матбугат идарәсенең Камил Якуб исеме ндәге матбугат комбинатында басылды. Казан. Бауман урамы, 19. 1965 ел.

# САЛАВАТ КҮПЕРЕ

Ф. ӘХМӘТОВ музыкасы

Н. ЮЗИЕВ сүзләре





Бәясе 40 тиен
Цена 40 коп.

Индекс
73367

*Ежемесячный литературно-художественный и общественно-политический журнал*

**КАЗАН УТЛАРЫ**

*(Огни Казани)*

ОРГАН СОЮЗА ПИСАТЕЛЕЙ ТАТАРИИ